# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Луиза ЯНСУАР. Яратуның чәрдәкләре оча җилгә... *Шигырьләр.* ........ 3

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Без андый малай түгел. *Повесть.* ........ 8

Ренат ХАРИС. Тагы бер союзник. *Поэма.* ........ 54

Нәзифә КӘРИМОВА. Озын-озак язмышлар. *Повесть-истәлек.* ........ 59

Алисә ЗАРИПОВА. Кышкы салкыннарны яз назына төреп... *Шигырьләр.* ........ 112

Зиннур ХӨСНИЯР. Әллүки. *Роман.* ........ 116

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Бүләккә – эти. *Хикәя.* ........ 149

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Нурлан КАЛЫБЕКОВ. Тирмәмнең эче балкый... *Шигырьләр.* ........ 159

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Хатларда да безнең язмыш (*Равил ФӘЙЗУЛЛИН архивыннан).* ........ 162

ӘБУГАЛИСИНА МӘГАРӘСЕ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Мәгърифәтченең көнкүреш шартлары турында замандашлары. ...170

Фотоархив: *Нәкый Исәнбәтнең тууына – 125 ел.*
*Сәхифәне Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА әзерләде.* ........ 177

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Руфия МӨХЕТДИНОВА. Тормышның матурлыгыннан көч алам! ........ 179

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Беренче гармунчы. *(Фәйзулла Туишевның тууына – 140 ел).* ........ 181

Варисларга васыять. *(Нәкый Исәнбәтнең тууына – 125 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ........ 182

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ........ 183

*2023 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге.* ........ 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 12 (1226) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасарлары:* **Вакыйф Нуриев, Вахит Имамов.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер).
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.11.2024, график буенча 29.11.2024, басылып чыгу вакыты 05.12.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2842. Тираж 4525.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2024 ел



Луиза
Янсуар

# ЯРАТУНЫҢ ЧӘРДӘКЛӘРЕ ОЧА ҖИЛГӘ...

## Кайнозой

*Это раннее утро в Позднем меловом периоде.*
Лин Хеджинян

*В конце Мелового периода произошло самое известное и крупное массовое вымирание многих групп и растений. Вымерли голосемянные растения, водные рептилии, птерозавры, все динозавры, исчезли аммониты, многие брахиоподы, практически все белемниты. Причины меловой катастрофы до конца не известны.*
Интернеттан

**1**

Мин таңнарда сулышыңны тыңлап ятам.
Мин таңнарда сулышыңны ятам тыңлап.
Без белмибез бу эраның кайчан, ничек
Төгәллисен үз тарихын. Калыйм сулап.

Һәм исемдә калдырыйм һәр җыерчыкны,
Һәрбер җөйне, һәрбер эзне тәнеңдәге.
Күзләреңнән укып алган җөмләләрне.
Иренеңнән үбеп алган хәрефләрне.

Бу эрада – гасыр саен – бар да яңа.
Бу эрада – гасыр саен – иске бар да.
Кулларында кешеләрнең әле мылтык.
Кулларында кешеләрнең әле балта.

Алар кыра, кабиләләп һәм ырулап,
Шундый ук кан акканнарны йөрәгеннән.
Ә аннары, төрбәләргә урнаштырып,
Җан сорыйлар мәетләрнең өрәгеннән.

Луиза ЯНСУАР (1981) – *шагыйрә; Россия-Италиянең Халыкара «Белла» һәм республиканың М.Җәлил исемендәге, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләре лауреаты. «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

**2**

Мин таңнарда сулышыңны ятам тыңлап.
Мин таңнарда сулышыңны тыңлап ятам.
Күктән коя самолётлар үлем уты:
Йә бер яктан. Йә бер яктан. Йә бер яктан.

Сулар яна. Урманнар һәм юллар яна.
Һәм тереләй кешеләрме яна?! Белмим...
Мөнбәрләрдән сүзләр ява: «Алар – безне...»,
«Без – аларны...», «Тыныч булсын өчен илем...»

Карап тора мәгърур таулар тәрәзәдән.
Күл өстеннән күтәрелә сөттәй томан.
(Бозлар киткән. Һәм түшәлгән хәтфә үлән).
Догаларда – зар, инәлү: «Кичер, Ходам...»

Мин чәчләреӊ сыйпыйм синеӊ, керфекләреӊ.
Нинди матур – Син дә! Мин дә!! Ил дә!!! Җир дә!!!!
Бу – Кайнозой. Өченче чор. Антропоген.
Яратуның чәрдәкләре оча җилгә.

## Адонис белән биш сөйләшү[1]

*(Дубай көндәлегеннән)*

**Беренче сөйләшү**

*Дорога и дом любят меня...*
*Что будет делать любовь,*
*Когда я умру?*
Адонис

Бу мәхәббәт йөри безнеӊ аша:
Карамыйча чикләр, читлекләргә.
Җанны таптап узган итекләргә.
Йөзен каплап тузган битлекләргә.

Бу мәхәббәт елый безнеӊ аша:
Аналарның күз яшьләре булып.
Башакларга кояш нуры тулып.
Учларымнан диңгез комын юып.

Бу мәхәббәт көлә безнеӊ аша:
Аңарга без – нарасыйлар һаман.
Куркуыбыз чаба, шашып, алдан.
Һәм кычкыра: «Бу!» – дип...
«Бу, – дип, – яман!..»

Авызлары тулы күпме ялган.
Кемдер шуа әнә ап-ак кардан.
Кемдер шуа әнә ап-ак кардан.
Һәм җан бирә җиңеләеп аннан.

Мин беркайчан инде белә алмам:
Иркәләде микән аны кояш
Ул теләгән кадәр... Үпте микән?
Учларымнан ага ап-ак комнар...

Җилферди ак җилдә ап-ак җилкән.
Кендегемнән, тибеп һәм сулкылдап,
Хәтерләтә үзен иске ярам.
Һәм төшләргә кереп саташтыра
Онытылган күптән... Нәсел тамгам.

**Икенче сөйләшү**

*Вы варите меня в котелке ваших молитв, вы меня разбавляете солдатской похлёбкой, добавляете перец тирана, и разбиваете меня, как царский шатёр, воздвигая мой череп как флаг.*
Адонис

Табаннарым иркәләнә тоеп
Ап-ак комын. Назлы ак дулкынын.

Әйтерсеӊ мин – сөеклесе аның.
Әйтерсеӊ мин кылмаганмын золым.

[1] Адонис – безнеӊ заманның иң танылган гарәп телле шагыйрьләреннән берсе, чыгышы белән сирияле, гомеренеӊ күпчелек өлешен Ливанда һәм Франциядә уздыра.

Әйтерсең мин салмаганмын яра.
Якмаганмын учак ап-ак карда.
Берни дә юк сыман – кага ярга.
Берни дә юк сыман – кага ярга.

«Кичер, – ди ул, – кичер кешеләрне:
Көчлеләрне кичер, көчсезләрне.
Үчлеләрне кичер, үчсезләрне.
Юньлеләрне кичер, юньсезләрне.

Һәм үзеңне кичер – иң азактан.
Котылырга – тома бу газаптан...»

**Өченче сөйләшү**

*Я выясняю тон нашего века и его надлом – век крошится песком, слипается цинком; век туч, прозванных ордами, и пластинок, прозванных мозгами. Век покорности и иллюзий, век кукол и пугал, век ненасытного мига, век бездонного упадка. Мои жилы не срослись с этим веком: я рассеян, и ничто не соберёт меня.*

Адонис

Мин шулкадәр ардым нәфрәтләрдән.
Мин шулкадәр ардым ләгънәтләрдән.
Мин шулкадәр ардым гадәтләрдән.
Мин шулкадәр ардым хәсрәтләрдән.

Һәм сүзләргә дыңгычланып тулган
Чүбектән мин туйдым – шулкадәрле.
Айбалтадай айкала да тора
Өстебездә һаман кем каһәре?

Мин шулкадәр көтәм җирдә сүзнең
Кичерүен хаталарын... Безнең.
«Кичер, – дисең, –
башта кичер үзең...»
Комнар буйлап кызыл кәлтә уза...
Һәм калдырмый эзен.

**Дүртенче сөйләшү**

*Я переживаю тайну на груди восходящего солнца. Я укрываюсь детством ночи, пока моя голова лежит на коленях утра. Я ухожу, сочиняя книги исхода, и встретить меня невозможно. Ведь я – паломник, одолевший эпоху.*

Адонис

Ул сүзләрнең төсен белә, тәмен,
Ул сүзләрнең белә авырлыгын.
Ул аларны яра, тегә, тезә –
Һәм калдыра бары калырлыгын.

Ярарлыгын – илгә, көнгә, җиргә.
Калганнарын төреп йөрәгенә
Кире сала.
Үзе белән ала.
Ә сүзләрсез дөнья бөлә генә.

Алып китсә ул сүзләрне шагыйрь
Үзе белән, башка мәгънә тапмый –
Бүләк итәр өчен Ватанына...
Комнар буйлап...
Карлар буйлап атлый...

Һәм кыйтгалар буйлап...
Каклый аны
Челләсе дә, җилләр, яңгырлары...

«Шунда күрдек...» –
дип сөйлиләр аны.
«Шунда күрдек...» –
дип сөйлиләр аны.

Тик сөйлиләр бары күргәннәрен
Чәчләре ак комдай уңган картны.

Пышылдыйлар:
«Ул бөтенләй шашты...»
Пышылдыйлар:
«Эзләгәнен тапты...»

Беркем белми ни тапканын аның.
Беркем белми –
Нәрсә югалтканын.
Ул, төннәрен күз яшенә манып,
Тамагыннан берни үтмәгәндә,
Йота шигырь итеп
Үз Ватанын.

**Бишенче сөйләшү**

*Возьми его, это мой сон,*
*сшей его и надень как рубаху.*
Адонис

Мин ак чүлдә җилфердимен тып-тын.
Җилләр уйный, уйный, иркәләнеп,
Кочып минем кояш каклаган бу
Боп-борынгы арык җилкәләрем.

Һәм юлчылар уза минем аша –
Юлын калдырганнар...
Адашканнар –
«Учларымда тотам бар дөньяны,
Без – Аллалар!» – диеп саташканнар.

Мин аларга бернәрсә дә әйтмим.
Мин сүзләрдән тектем ак күлмәгем,
Һәм җирләдем җирнең бер юләрен –
Ап-ак җилгә...
Булсын дип бүләгем.

Мин гүләгән шәһәрләрне тыңлыйм.
Мин дөрләгән шәһәрләрне тыңлыйм.
Кәлтәләрнең кыштырдавын комда.
«Туктагыз!» – дип күтәрелгән кулын –
Кешеләрнең.
Кулын, күтәрелгән:
«Үч алыгыз!» – диеп. «Җәзалагыз!»
Бу кадәрле гарипләрне, белмим,
Ничә гасыр тагын дәваларсыз?

Мин ак чүлдә җилфердимен тып-тын.
Мин башын да беләм. Ахырын да –
Вәхшилекнең. Һәм яшәвен аннан
Сиздермичә нәсел тамырында.

Кешелекнең. Комнар ага, ага...
Һәм авыша дөнья төнгә таба.
Комнар буйлап кызыл кәлтә уза –
Сиздерми дә... Һәм кайдадыр тама
Кып-кызыл кан... Җып-җылы кан...
Карга.

***

Шундый тын. Шундый тын Җиһанда.
Тавышлар еракта. Кар ишә.
Пышылдый сулышың җилкәмә:
«Бу Кыш та безгә бик килешә...»

Күзгеләр елмая, хәтердә
Уятып үткәннең аһәңен.
(Бизмәнгә салып кем үлчәгән
Наз тулы йөрәген адәмнең?!)

Шундый тын. Шундый тын Җиһанда.
Булмаган гүя бер өермә.
Пышылдыйм учыңа исемең.
...Һәм кайта ярату – өенә.

## Мин анда чәчәкләр үстерәм

Икебез өчен дә бер үк Күк.
Мин анда чәчәкләр үстерәм.
Һәм көләм синең һәр сүзеңнән.
Һәм йөрим болытлар өстеннән.

Икебез өчен дә бер үк Җир.
Ул Җирдә юк алыш, юк сагыш.
Юк чикләр. Юк читләр. Юк бикләр.
Бомбалар. Атом-төш нурланыш.

Икебез өчен дә бер үк Җан.
Тора ул мең төсле төсмердән.
(Һәм безне беркем дә сөрмәгән!)
Мин анда чәчәкләр үстерәм.

## Нинди!

Дөресме син, дөнья, ялганмы?
Беркайчан ышана алмадым!
Яңгырлар көйдерде... Дөрләтеп,
Сулышка капланды карларың...

Күзләрем камаша ямеңнән,
Гамеңнән – мизгеллек, гомерлек...
«Миннән соң ни калыр?!» –
Көч, бәлки,
Бу сәер дәгъвадан көләрлек.

Сөярлек – көтмичә берни дә...
Һәм мәгънә тапмыйча... үләрлек.
«Онытма!» – дияргә ымсынам...
Һәм аңлыйм:
Бу нинди юләрлек!

## Намус

Намус бер генә сатыла.
Ә аннары инде
Ул атала башка төрле:
Белми – сине, мине.

Ә аннары аңа ярый
Тегеләй дә болай:
Менә монсы – ару гына.
Монсы – бигрәк кулай.

Ә аннары күзгеләрдә
Тора гел елмаеп –
Әллә үзе... Әллә йөзе... –
Булмый никтер танып.

Кул бирә ул кулны бирмәс
Адәмнәргә, әнә.
Мәҗлесләрдә тост күтәрә:
«Бу, – дип, – шундый хәйлә...»

Шелтә белән күзен кыса:
«Син, – дип, – бигрәк төксе...»
...Тамагымнан әнкәемнең
Никтер күкрәк сөте

Күтәрелә шул мизгелдә...
Ярсый далам җиле...
Намус бер генә сатыла.
Ә аннары инде...

Белми: Кемгә. Кемне.

## Литургия

*Тебе в спину – крест.*
*А за мной – образа.*
*Д.А.*

*У тебя внутри соловьи поют.*
*Н.И.*

Йөрәгемдә йөрәге бар.
Тибешендә назын тоям.
Ә урманнар өскә ава...
(Нинди матур Синең Дөньяң!)

Сөйләшәбез сүзсез генә.
Ул ишетә. Мин елмаям.

Шәмнәр яна – эргәсендә.
(Нинди гадел Синең Дөньяң!)

Йөрәгеңдә йөрәге бар.
Пышылдавын тоеп... Уян.
Ә урманнар өскә ава...
(Нинди сабыр Синең Дөньяң!)

...Кыш җырлаган былбылыңны
Саклый алсам иде... Ходам!

## И!..

Мин бүген кошларын тыңладым
Җиһанның
Беренче ишеткән шикелле... И юләр!
Җим сиптем.
Һәм үптем туфракны – өч аршин...
Син анда юклыкны белсәм дә
Төп-төгәл.

Зәп-зәңгәр Күк барын абайлап,
Елмайдым.
(«Син еллар буена кая соң югалдың?!»)
Һәм искә төшердем күкрәгең сөтенме?
Күкрәгем сөтенме?
...Оялдым!

Җилләрнең җитенен
Тарадым уч белән.
Сыйпадым каеннар ярасын.
Пышылдап:
«Терелеп торды бит...
Ул безне...
Инде бар хәтәрдән аясын!!!

Һәм тамчы каргышы ятмасын.
Беркемнең.
Беркемгә. Беркайчан. Беркайда».
Ирендә – күшеккән туфрагы ачысы.
Илемнең.
Әле Ил бугай ла...



Айгөл
Әхмәтгалиева

# БЕЗ АНДЫЙ МАЛАЙ ТҮГЕЛ*

ПОВЕСТЬ

**Без балыкка җыенабыз яки Сәрия апа безне базга сала...**

Биш минутка иртәрәк ычкынсак, хәзер яр буенда рәхәтләнеп утырасы идек. Юк, Саматка майонез чиләге ярамады: зуррагын алыйк, зуррагын алыйк, моңа балык сыямыни, имеш. Нокса суыннан акула каптырырга җыена диярсең.

– Көтеп тор, бакчадан зәңгәр чиләкне чәпим дә чыгам, – дип, кармагын миңа тоттырды да кире кереп киткән булды.

– Абы-ы-ый! Мин дә, мин дә! – Шулчак аларның ишегалдында тычкан чинаган кебек нәзек тавыш ишетелде.

Гел булды бу. Әнисе Әминәне дә тагып җибәрә хәзер... Аның аягы белән барып җиткәндә, барып җиткәч, ашыйсым килә дип шыңшый башлаганда, кайтыгыз дип, телефон шалтыраячак. Сәрия апа әйткән сәгатьтә кайтмый кара! Минем әнине усал дигән була Самат, аныкы – ... ярар, әйтмим инде. Минем әни усал түгел, ул бары тик истер... эстер... эти әйтә, эстеричка, ди, вәт.

– Киттек! – Кармакның берсен зур чиләкне башына кигән Саматка суздым.

– Киткән, ди. Әминәне көтәсе. – Самат чиләкне йөзенә үк төшерде, яз көне циркта күргән артистка охшап калды. Кыланып, чиләкне барабан каккандай бәргәләп тә алды. Беләм инде, кәефе төшкәнен сиздерәсе килми.

Көтәбез инде, кая барасың. Беренче тапкыр түгел лә... Ничаклы көтәсе икәнен дә чамалыйбыз.

Бүген Әминәне ияртми генә, Самат белән икебез көн буе су буенда балык тотып ятарбыз дигән идек. Ике көннән җәй бетә, рәхәтләнеп ял итеп каласы килгән иде. Аннан башлана-а-а... Мәктәп, өй эшләре... Әле

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан 2023 елда уздырылган татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Повесть» (үсмерләр әдәбияты) номинациясендә беренче урынны алган әсәр.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА (1973) *– язучы; М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

барып керүгә «мин җәйне ничек үткәрдем» дип инша яздыртырлар. Ник кәгазьгә язарга кушалардыр, һич аңламыйм. Менә сөйләргә кушсалар, эһ димичә ярып салыр идем. Шәп җәй булды. Үзебезне гел тәртипле тоттык, андый-мондый кырын эшләр эшләмәдек – без андый малай түгел. Малай дип... Бездән тотам калмый ияреп йөргән Әминә ул исемлеккә кермәсә дә, кайбер малайларны бер якка бәреп ега, чын мәгәр.

Казан читендәге бу бистәгә алар былтыр җәй көне күченде, күрше урамдагы ике катлы, балконы урман ягына караган коңгырт түбәле өйдә яшиләр. Ә безнең өй яңа салына торган күпердән ерак түгел, урамның бу очындарак. Капкадан чыгуга – каршыда урман, бераз атласаң, аста Нокса елгасы. Елга дип, суы тезгә дә җитми үзенең. Шулай да рәхәт анда, кармак салып утырасың, вак-вак балыклар да эләккәли.

Без дә башта шәһәр үзәгендәге ун катлы йортта өч бүлмәле фатирда яши идек. Бервакыт әтинең сабыры сынды:

– Җитте, эштән кайткан саен машина куярга урын табалмый әйләнеп, күпме йөрергә була? Үз җирең, үз йортың белән яшәүгә җитәме соң?! – дип кабатлап кына калмыйча, өй салу турында ныклап хыяллана башлады.

– Нәрсә сөйлисең, Назиф? Аңа күпме акча кирәк! Самат мәктәпкә ничек барыр? Җирне кем карый? Мин бу тырнакларым белән чүп утап, түтәл карап ятарга җыенмыйм! – Әнинең төрле төскә буялган озын тырнаклары иң шәп дәлил булса да, әтинең бер ягы бар – башына уй кердеме, эшләми калмый.

Ике ел эчендә без кайнап торган шәһәр уртасыннан авыл кебек тыныч кына утырган бистәгә үз йортыбызга күчендек. Кызык инде: Ноксаның бер ягында биек-биек йортлары, тукталышлары, мәктәпләре, кибетләре белән шәһәр гөж килә, ә икенче ягында, басма аша чыгуга, рәхәт тынлыкта кешеләрнең үз йортлары тезелеп киткән.

Самат белән ничек танышканны сөйлимме? Ул пәйда булганчы, безнең урамда яшьтәшем юк иде, олырак малайлар белән әллә ни борчак пешереп булмый – аларның үз серләре, татарча да сөйләшмиләр. Мәктәпкә дә берүзем йөрим. Үзем дип, машинада әти илтеп куя, әни алып кайта. «Менә юлны төзеп бетерсәләр, турыдан гына йөрешле булыр иде», – дип, төзелеш тәмамланганны көтәләр. Былтыр май аенда, укуның соңгы көнендә чын-чынлап үзем генә кайттым, әнинең эштән китәргә, мине кайтарырга мөмкинлеге булмады. Аның телефон аша өзми-куймый кабатлаган инструкциясе мондыйрак иде:

1. Автобус тукталышына барганда, юлны зебра аша гына чыгасы. Анда да як-якка бик игътибар белән карарга!

2. 68 нче номерлы автобуска утырып, өске урамда Мәчет тукталышында төшәргә.

3. Төшкәндә әйбәтләп тикшер: рюкзак үзеңдәме, телефоның төшеп калмаганмы?

4. Юлны зебра аша гына чыгасы. Анда да як-якка бик игътибар белән карарга!

5. Өйгә тиклем җәяү байтак атлыйсы, шикле кешеләр очрый күрмәсен!

6. Бәйсез этләр күп йөри, кулыңа берүк берәр таяк тот!

7. Урау булса да, таш салган урамнан кайт, алайса, кроссовканың карар җире калмас!

8. Өйгә керүгә «кайтып җиттем» дип шунда ук шалтырат!

Боларны сүзен-сүзгә ятлап бетерсәм дә, ярар дисәм дә, үземчә генә эшләргә булдым. Төзелеп яткан юл аша урман янына, аннан басма аша гына җиппәрсәм, ике атлап бер сикерүдә капка төбендә булам ла! Нәрсә дип автобус көтеп тинтерәп басып торыйм! Рюкзак буш диярлек – дәреслекләрне тапшырып бетердек, анда алмаш аяк киеменнән башка берни юк.

Бу яктан әтигә охшаган мин: нәрсә уйладым – шуны эшләдем. Мәктәп капкасыннан чыккач, әз генә чигәне кашып тордым да юлны тагын да кыскартырга мөмкин икәнен аңлап алдым. Сукмак эзләп тормыйча, таудан выжлап төшсәң, әнә, урман кул сузымында гына. Әллә уку беткәнгә, баш нык шәп эшли башлады түгелме – рюкзакны астыңа саласың да, әйдә, әллүр! Кыш көне генә чана шуарга димәгән!

Тузганак чәчәге белән чуарланган тау итәгенә тырышып-тырмашып төшеп җиткәндә, минем күңел мәтәлчек ата иде: җәйге каникулда көн саен килергә кирәк монда. Чалбардан бүселеп чыккан ак күлмәк итәгенең сарыга буялганын күргәч кенә эч пошып куйды куюын. Тапны бетерергә теләп, ышкып-ышкып карасам да, нишләптер бетү түгел, киресенчә, тагын да ныграк таралды ул. Ярар, әни күргәнче үзем ялт кына юып алырмын. Ел буе чыдаган рюкзакның бер як каешы өстән өзелгән булып чыкты. Шулай инде, моңарчы чана булып хезмәт иткәне юк иде бит аның.

Кайда ком, кайда вак таш өемнәре тезелеп киткән юлдан атлаганда, аклы-каралы кроссовка кирпеч төсенә керде. Анысы да баш бәласе түгел: эченә су кертмичә генә елга читеннән йөреп аласың да барысы да чики-пуки...

Әллә нинди тәмле үлән, яфрак, чәчәк исләре килеп торган урман сукмагыннан атлаганда, борыныма шашлык исе килеп бәрелде. Аны ашказаным да тойды бугай, авыр сулап, эндәшеп алды. Уң якта, кечкенә генә алан уртасында ак майкалы бер ир-ат шашлык пешереп маташа иде. Урманда учак ягарга ярамый дип, олылар атлаган саен әйтеп тора, үзләре, әнә... Һич аңламассың бу зурларны. Әйткәнне тыңламыйлар дип, безне орышкан булалар тагын... Үлән өстендәге җәймәгә аякларын җәеп утырган, кыска сарафанлы, зәңгәр чәчле апа телефонына күз текәгән. Шәрә тәненә подгузник кына кигертеп куйган бәләкәй балалары җәймә тирәли йөгермәкче була, ике-өч адым атлый да егыла, атлый да егыла. Кызык инде. Артын мәзәк итеп туңкайтып торган чагында үлән өзеп кабарга да өлгерде ул. Телефонына карап утырган җиреннән әнисе ничек күреп алгандыр – ялт кына үрелеп, бәбәйнең авызыннан үләнне алып ташлады.

– Ах ты, козявка, ах ты, поросёнок, – дия-дия, артын да чәбәкләгән булды. Юк, ачуланып түгел, үзе дә көлә иде.

Миңа әтинең дә, әнинең дә «поросёнок» дигәне юк. Әти кайчак «Булат Назифович» дип җиппәрә, әни кайчак «сандугачым» ди. Чәчем саргылт, күзем зәңгәр, бит очымда бераз сипкел булганга шулай ди микән... Алай диюен әти ошатмый: «Кыз баламыни ул сиңа», – ди. Миңа ни... талашып кына китмәсеннәр. Алайса, шундый бер бәләкәй генә сүздән башлыйлар да тиз генә туктый алмый тинтериләр...

Менә инде, мин дә Самат белән танышуыбыз турында әйтергә теләгән җирдән әллә кайларга кереп киттем.

Кыскасы шул. Басма буена килеп җиткәч, аяк киемен чистартыйм дип, ярдан төшеп, елга читенә басуым булды, аяк йөзеннән ләмгә баттым да

куйдым. Шуны күрергә теләгәндәй, әллә каян гына нәзек гөрләвек тә йөгереп килде, кроссовканың эченә су тулды.

– Хи-хи-хи! Дурак!

Башымны күтәреп карасам, басманың бер башында, кулына уенчык автомат тотып, сары шортиклы бер малай басып тора. Минем яшьләрдә булыр. Кызыл футболкасына Бэтмен рәсеме төшерелгән. Аягында кызыллы-яшелле кроссовка. Светофор!

– Сам такой! – дидем мин, явызланып, аның сүзенә җенем чыгып.

– Я не дурак, не лезу в воду!

– А ты... а ты... Светофор! Ха-ха-ха! Стопудово, носки зелёные!

Әллә үзенең нинди оекбаш кигәнен белми инде – малай тиз генә иелеп аягына карады.

– Нет у меня носков! – Мактангандай, борынын тартып куйган була әле җитмәсә.

Ничек тә сынатасым килми иде, беткән баш беткән дип, чалбар балагын өскәрәк җыердым да суга атладым. Кроссовка инде күрәсен күрде, әни барыбер сыртны каезлап алачак. Кара абзаңны дигәндәй, төймә борынга мыскыллы гына караш ташладым. Су хәтәр салкын булса да, аякны рәхәт кытыклап, әкрен генә ага. Җиңне сызганып, төптә яткан вак ташларга үрелдем. Сизеп торам, теге малайның да күзе кызыга, минем кебек су ерып йөрисе килә. Сер бирергә генә исәбе юк, борынын чөеп, автоматын күккә төбәп, сакчы шикелле басып торган була. Кыланчык!

Тик түзмәде, басмадан чыкты да аяк киемен өстә үк салып калдыргач, миннән өч-дүрт адым читкә, су эченә кереп басты. Күз кырые белән генә әледән-әле карап ала: чалбар балагы, кәчтүм җиңе юешләнгән, рюкзагының өзек каешы суда чайкалган кешене күргәне юк диярсең.

– Чё уставился? – Төшеп калганнардан түгел мин, кулымдагы вак ташларны аның алдына ыргыттым. Ташлар «булты-ыйх» итеп чумган мәлдә малай түшендәге Бэтменга кадәр су чәчрәргә өлгерде.

– Говорю же, дурак! – Малайның минем кәчтүм төймәсе шикелле түп-түгәрәк, кап-кара күзләре нишләптер ачулы тоелмады. Тагын «дурак» диюенә бу юлы нишләптер минем дә ачу килмәде.

Икәүләп елга төбеннән төрле төстәге вак ташларны җыеп, аннан читтәге ләмгә тезеп мәтәшкәндә, исемен дә белдем: Самат икән. Аннан икәүләп озак кына бака кабырчыгы да эзләп йөрдек, тапмадык кына. Тагын уйнаган булыр идек – аңа әнисе шалтыратты. Самат «алллё» дип кенә әйтергә җитеште, телефонның теге ягындагы тавыш бөтен урманны яңгыратты. Әле генә бер-берсен уздырып, әллә ничекләр итеп сайраган кошлар шунда ук дәррәү каядыр качышып беттеләр, Нокса суы да ике як ярыннан җыерылыбрак, тагын да тыныбрак ага башлады. Басманың бераз бөкре култыксалары күзгә күренеп турайды. Усак яфраклары, әмер булгандай, лепердәүдән шып туктады. Наратларның бөдрә башлары кайсы якка чайкалган булса, шул якка янтаеп катып калды. Урман, сулыш алырга куркып, тораташка әйләнде.

– Самат! Кая китеп югалдың? Мин сиңа озак йөрмә дип әйтмәдемме? Ят җирдә шикле кешеләр килеп чыкса? Хуҗасыз этләр ташланса?.. (Бөтен әниләр дә бер үк сүзне ятлаган икән). Са-са-са... ла-ла-ла... ба-ба-ба...

– Ән-ни! Без монда уйныйбыз! Короче... короче... Булат белән уйныйбыз. Аhа... аhа... аhа...

Телефонын сүндергәч, Самат сузып кына:

– Мне домой пора, – дип куйды, соры төскә кергән шортигына карап, авыр сулап.

– Син татармыни? – дидем мин, әнисе белән татарча сөйләшкәнен ишеткәч, шаккатып.

– Ну да! – диде Самат, инде аяк киемен кия-кия. – Әни кайтырга куша.

Әни дигәннән... Кайтып җиттем дип әнигә шалтыратырга тиешлегем кылт итеп искә төште. Өйгә ерак калмаса да, «кайтып җитәм» дип шалтыратырга була бит – шуны уйлап, рюкзактан телефонны эзләргә тотындым. Ә-ә, мин бит аны мәктәптән чыккач, чалбарның арт кесәсенә салган идем, шунда булырга тиеш. Тиеш иде дә – тик телефон анда да табылмады. Тәк. Телефон югалту чалбар балагын пычрату гына түгел, җәзасы саллырак. Икене югалттым инде, тәҗрибәм бар. Алары төймәле иде, ә монысын әти Яңа елда гына алды, сенсорлы. Кыш бабай алып килгән дигән булды – әйтерсең мин инде кемгә нинди бүләкне кем алганын белерлек яшьтә түгел... Минем борын салына башлады. Самат алдында елап торып булмый бит, ике кулны чалбар кесәсенә тыгып, яр буен да, суга төшмәде микән дип, елга төбен дә барлап чыктым. Самат хәтта өр-яңа автоматын да җәлләмәде: аның көпшәсе белән ләмне актарып карады.

– Вот дурак!

– Әйтмә әле шулай дип!

– Сиңа әйтмим мин! Үземә!

– Үзеңә дә әйтмә. Ямьсез сүз.

– Яра-ар. – Самат кулына телефонын алды. – Номерыңны әйт, шалтыратасы гына бит. Айн маминт табабыз.

Башлы малай икән үзе. Кыска итеп алдырылган кара чәчле башы тикмәгә генә йомры түгелдер. Минем номерны җыйгач, колак торгызып күпме генә тыңласак та, телефонның... көенә аваз салганы ишетелмәде.

– Да ты шевели мозгами. Мужыт мәктәптә калгандыр? – Самат, биленә таянып, аякларын ике якка аерып, шәһәр ягына карап торды. Аның буе минекеннән бераз кечкенәрәк, гәүдәсе дә, башы да йомры. Минем нечкә, озын аякларым янында Саматныкы әкәмәт юан булып күренә икән. Менә ул детектив шикелле сораулар яудыра башлады: – Мужыт син мороженое алырга туктагансыңдыр? Селфи ясарга? Тик-токка берәр нәрсә төшермәдеңме?

– Юк инде. Таудан шуып кына төштем дә туп-туры әнә шул сукмактан кайттым. – Мин яшен тизлегендә хәтеремнән үзем үткән юлны барлап чыктым. Мөгаен, рюкзакка утырып шуганда, чалбар кесәсеннән төшеп калган. Тизрәк кире барырга да эзләргә кирәк, алайса, әни үтерәчәк!

– Киттек! – Самат та миңа иярде.

– Сиңа бит әниең өйгә кайтырга кушты. – Самат белән күңеллерәк булса да, мин аңа да энисеннән эләккәнне теләми идем.

– Ә без спортсменнар шикелле йөгереп кенә барабыз да йөгереп кенә кайтабыз.

Шәп малайга охшап тора бу Самат!

Икәү урман сукмагыннан мыш-мыш килеп йөгергәндә, аңа аланда

шашлык ашап утырган апа-белән абыйны күрсәтеп, бәбәйләренең ничек итеп үлән капканын тасвирларга өлгердем. «Козявка»лары йоклый иде булса кирәк, бер кулына шашлык таягы тоткан апа икенче кулындагы журналны җилпәзә итеп селки-селки, җәймәдә яткан бәбәй өстеннән бөҗәк куа иде.

Төзелеп ятучы юлны аркылы чыгып, тау янына барып җиткәндә, минем юеш кроссовка да, Саматның кызыллы-яшелле кроссовкасы да балчыкка буялып, кирпеч төсенә керде.

– Моннан! Менә моннан шудым! Әнә теге кадый торган үлән яныннан! – Инде телефонымны тапкан кешедәй, шатланып кычкыра-кычкыра, тауга үрмәләргә иде исәп.

– Хәзер шалтыратам. Тавышын ишетербез... Аа! – Саматның уң як кашына олы гына бер бөҗәк кунуга, уч төбе белән шунда шапылдатты. – Вәт дур... Зараза! Тешләп тә алды. Хә...

Шортик кесәсенә кулын тыккан җирдән сүзе бүленүгә аның артын да бөҗәк тешләде дип уйлаган идем. Алай булып чыкмады. Ике кесәсен дә кат-кат карады, хәтта кулындагы автоматының тәтесенә дә күз ташлады.

– Телефон! Төшеп калга-а-ан...

Алдан сөйләшеп куйганда да болай ук була алмас иде. Күрәсең, без спортчылардан да катырак йөгергәнбез дә шунда төшкән инде ул. Нишләргә? Без тауда минекен эзләгән арада Саматныкын берәрсе табып, алып китсә?

– Әни үтерә. Ике телефон югалттым инде! – Самат шулай дигәч, чын мужикларча, аңа уң кулымны суздым. Ул, берни аңламый, күзләрен челт-мелт китереп, миңа карады.

– Бир бишне! Мин дә шулай. Монысын тапмасак, өч була! Курыкма, әниләр алар шулай дигән генә булалар, үтермиләр.

– Беләм дә... әйдә, җәлт кенә эзлик инде.

Бәхеткә, телефонны уйлаганнан да тизрәк таптык. Менеп барганда, кечкенә куак булып утырган чәнечкеле үлән янына җитүгә, кара тышлы телефонымны күреп тә алдым, «Тапты-ы-ымм!» – дип кычкырып та җибәрдем. Әни 17 тапкыр шалтыраткан! Сыйныф җитәкчесе Марьваси-ловна – 5 тапкыр! Мәрьям Василовна инде ул, алай тутырып әйтеп торган юк, шулай кыскартып кына җиффәрәбез.

Әти 3 тапкыр гына җыйган. Иң беренче эш итеп әтигә шалтыратмакчы идем дә, зарядкасы бөтенләй бетеп, телефон күз алдында сүнде дә куйды.

Хәзер Саматныкын да тапсак...

– Спортсменнар шикелле йөгереп кенә кайтабыз да... – Самат бу юлы шәрә балтырына кунган кигәвенгә селтәнде. – Нигә гел мине тешли соң болар? – дип зарлангандай итте.

Яңа дустыма бер-бер яхшылык эшлисем килә иде. Әнә бит, минем аркада күпме кыенлык күрергә җитеште! Өсте-башы пычранып бетте, телефоны югалды. Җитмәсә, усал бөҗәкләр дә аңа гына һөҗүм итә. Миндә мәктәп костюмы булгач, якын килергә куркалар бугай. Уйлап-уйлап тордым да, рюкзакны салып, аңа тоттырдым.

– Мә, «чана» белән төш. Сиңа жалко түгел!

– Ә син?

– Мин бая шудым. Шәп!

– Дав-вай! – Самат, күзләрен очкынландырып, рюкзак өстенә җайлап утырды да, карлы таудан шугандай выжлап ук шумаса да, бер кулы белән автоматын тотып, икенчесе белән этенә-этенә, аска юл тотты. Мин, телефонны учыма кысып, бу юлы кырый-кырый гына басып, ипләп кенә төшәсе иттем.

Рюкзакның икенче каешы да өзелеп чыгуны исәпләмәгәндә, урман ягына без югалтуларсыз чыктык. Каеш нәрсә инде ул, барыбер мәктәпкә барасы юк. Иртәгәдән – каникул.

Ә бүген... бүген Саматның телефонын табарга кирәк.

Килгән сукмактан йөгереп кайтып булмый иде – әкрен генә, уңга да, сулга да яхшылап карый-карый, күзләр талганчы күпме генә эзләнсәк тә, телефон табылмады. Бая гына аланда утырган гаилә дә, җир упкандай, юкка чыккан.

Бүгенге көн безнең икебезгә дә давыл вәгъдә итә иде. Шуны аңлап, башны муен тирәсенә җыя төшеп, аптыраган кыяфәттә атлый бирдек.

– Син кайда торасың? – Монысы сүз юктан сүз булсын өчен соравым иде.

– Әкият урамында. Ә син?

– Безнеке Кабушкин.

– Әәә... – Самат артык сүз дәшмәде. Борчылганын аңлыйм да, булышып булмый шул.

– Кайчан күчтегез?

– Өченчекөн.

– Ә-ә-ә... – Бу юлы минем сүз бетте.

Сөмсеребез коелган хәлдә басма аша чыгуга, Саматның кисәк кенә адымнары саташа башлады. Каршыбызга, җил-җил атлап, ике якка каеннар тезелгән тар гына сукмакны тутырып, кара бөдрә чәчле курчак кебек кызчыкны күтәргән бер апа килә иде. Атлавына, өстендәге соры спорт костюмына караганда, нәкъ спортчы инде! Тик бераз... бераз тазарак кына.

– Абы-ы-ы-ый! – Бөдрә чәч, авызын җәеп, бер кулы белән әнисенең башына чәбәкәй итә-итә, үлә-бетә сөенеп елмая иде.

– Ах сезне! – Апаның адымнары тагын да шәбәйде, хәтта минем колак яфрагын аның кайнар сулышы пешергәндәй булды. «Саматның әнисе!» Әллә миндә күрәзәчелек сәләте ачыла инде – каяндыр шушы уй китереп бәрде.

– Әни, мин... без... – Самат, яшь кычытканнан да курыкмыйча, сукмакның читенәрәк шуышты да уенчыгын аркасына яшереп, миңа борылды. – Бу – Булат. Алар Кабушкин урамында тора.

– Шулаймыни-и-и? Кабушкиннар, бабушкиннар... Ни майтарып йөрисез сез, ә? Мин сиңа әйтмәдемме әллә кая китеп югалма дип, ә? – Апа, кызчыкны җилтерәтеп җиргә бастырды да, башта Саматны, аннан мине юла урынына бөтереп карады. Аннан, юан ботларына чаба-чаба, ах-вах килергә тотынды. – Күрегез боларны, күрегез! Эт талаган кыяфәткә кергән икесе дә! Телефон югалтырлык итеп кайда чабышасыз?

Сукмак буйлап килгән ике егет, ападан читкәрәк чыгуын үтенеп тормадылар, бәласеннән башаяк диделәрме, үзләре тайпылып, урап үтүне хәерлерәк күрделәр.

Мин түгел, Саматның әнисе күрәзәче, ахры. Әле кайтып та җитмәдек, телефон югалтканны каян белеп алган ул – монысы табышмак иде. Күрәзәче

булса, югалган әйбернең кайда икәнен дә белә дигән сүз бит. Саматны бәхет басты, алайса.

Кызчык, абыйсыныкы шикелле зур кара күзләрен түгәрәкләндереп, миңа карап тора иде.

– Чин кем? – диде ул, әнисенең чалбарына тотынып.

– Булат дидем бит. – Самат канәгатьсез генә шулай дип мыгырдады, беләм, аның да, минем шикелле, бу хурлыклы тирәдән тизрәк ычкынасы килә – чөнки алда да, артта да кешеләр атлаганы күренде. Тик әнисе икебезне ике җилкәдән шундый итеп тоткан – без күлмәк якасы капкадагы кадакка эләккән шикелле чак эленеп торабыз.

Сеңлесен җавап канәгатьләндермәде. Ул миңа шулай ук текәлеп:

– Чин кем? – дип кабатлады.

– Булат, – дидем мин, кырку гына итеп. Бәйләнчек черки шикелле күзгә керердәй булып карап торган кызга, авызымны кыйшайтып, тел күрсәттем.

Чәрелдек тавыш урманны яңгыратты:

– Әнни-и-и-и, ул миңа тер күрсәтә!

– Хәзер күрсәтәм мин аларның үзләренә, икесенә дә! Марш өйгә! – Апаның кулыннан ычкынуга, бөтен көчкә элдертергә иде исәп, тик ул җитезрәк булып чыкты, җибәргән уңайга кабат эләктереп тә алды. – Кая чапмакчы?

– Өйгә кайтырга куштыгыз бит. – Үрнәк укучы шикелле, авыздан тулы җөмлә яңгырады.

– Әниең өйдәме?

– Эштә.

– Менә кайтсын гына, сөйләшәм әле мин аның белән! Сәрия апаңның кем икәнен белмидер әле! – Апа кызчыкны баягыча кулына күтәрде, Саматның яшелле-кызыллы төскә кергән шортигын күреп, артына берне чәпәде дә, безгә үз артыннан атларга әмер бирде. – Ничәнче телефон монысы, әйт әле?

– Өченче. – Саматның борын тартканы бик кызганыч ишетелде.

Кызчык, әнисенең кыска сары чәчле башына тагын чәбәк-чәбәк килә-килә:

– Терефонны тапты-ык, терефонны тапты-ык, – дип чәрелдәде.

Баядан бирле сорарга курыккан Самат, түзмәде, әкрен тавыш белән:

– Әни, ә син каян... – дип әйтеп бетерә алмады, әнисе, үз кесәсеннән аның телефонын тартып чыгарды да, борылып, безнең борын төбендә селкеде.

– Ярый, шалтыратканмын, урманда берәүләр ишетеп, шулар табып бирде. Авызыңны ерма! Әлгә әле сиңа моның өчен! Сазда аунагандай пычранып беткәнең өчен дә... Ике ишәй... Монысын күр, ә. Мәктәп киемен ни кыяфәткә керткән!

– Уку бетте лә. – Миңа да мескен генә борын тартып торудан башка чара калмады.

Янәшәдән барган Самат миңа каш астыннан гына күз салды, аның кызганыч йөзен күргәч, куркуга төштем. Әнисеннән эләгер микән? Ә бит барысы да минем аркада... Апаның гәүдәсе үзе генә дә куркытырлык шул! Минем әти дә аның янында «Ока» машинасы кебек кенә күренер. Дөресрәге, «Джип» янында «Ока» кебек. Ә менә аяклары мәзәк икән. Тезгә кадәр әйбәт кенә төшкәннәр дә, тезгә җиткәч, икесе ике яккарак киткән кебек. Шуны күреп, минем көләсе килә башлады. Көләргә ярамаганын аңлыйм. Әнисе

ишетсә... Тик авызны җыеп булмый, ерыла да китә, ерыла да китә. Миңа карагач, Саматның да йөзенә елмаю кунды. Без, сүзсез генә бер-беребез белән шулай көлешеп атлаганда, теге кычыткан чыпчыгы эшне харап итте:

– Ән-н-ни, арар көреп барарар! – дип сөрән салды ул. Бәләкәй балалар «р»ны әйтә алмый дигән булалар, бу кыз бөтен «л» авазын да «р» дип әйтә.

– Хәзер еларлар!

Сәрия апаның бик тыныч итеп шулай диюе авызны тиз җыйдыртты. Минем баш кай якка таба эшләргә белми интекте. Ничек дөрес булыр? Хәзер рюкзакны кочаклап, агачлар арасыннан бөтен көчкә үзебезнең өйгә элдерсәм, Сәрия апа куып та маташмас бәлки. Мин нигә кирәк аңа, минем үз әнием бар... Алай итсәм, сатлыкҗаннарча Саматны ташлап качкан кебек килеп чыга... Алай да, тегеләй дә уйлап маташкач, ни күрсәк тә, бергә күрербез дигән фикергә килеп, атлавымны дәвам иттем.

Саматларның өе безнең күрше урамда булып чыкты. Зур, кызыл кирпечтән, ике катлы. Балконнары да бар, урман ягына карап тора. Капка төбендә матур булып тәбәнәк сирень куаклары чәчәк аткан. Коймалары да кирпечтән, капкада звоноклары да бар.

Сәрия апа капканы ачты да, безне җилтерәтеп, ишегалдына үткәрде. Кызчыкны өй ишеге янындагы тәбәнәк эскәмиягә утыртып куйды, икебезне дә, баягыча җилкәдән тотып, өй артындагы сарайга таба алып китте.

– Әни-и-и! – Самат, кәҗә шикелле аякларын җиргә терәп, киреләнергә маташты. Мин, үзебезне ни көткәнен белмәгәч, мышык-мышык борын тартуымны гына белдем.

– Еларсыз дидем бит! – Ул арада әнисе кеше ышанмас тизлек белән сарай ишеген ачты, аннан ялт кына идәндәге зур капкачны күтәрде. – Базга салам икегезне дә! Әниләрне тыңлый торган малайлар булып чыкканчы шунда караңгыда утырырсыз! Тычканнар белән серләшеп!

– Ән-н-ни! – Еламсыраргa миңа да чират җитте. Әни монда булмаса да, мине ишетмәсә дә, авыздан шул сүз чыгып йөгерде. Мизгел эчендә әллә ниләр уйларга өлгердем: эх, мәктәптән әни әйткәнчә автобус белән генә кайткан булсам... Инде өйдә, кичтән пешерелгән беленнәрне микроволновкада җылытып, куертылган сөткә мана-мана, корсагымны пух итеп утырасы кеше идем бит... Алай итсәм, Самат белән танышмаган булыр идем инде...

– Ә безнең песи бар! – дидем мин, котылу чарасы тапкандай куанып. Әйтерсең моңарчы гомерендә дә тычкан күрмәгән Сэм, мине эзләп монда килә дә, базга төшеп, андагы тычканнарны тотып бетерә һәм безне әсирлектән коткара.

– Күп телләшеп торсаң, песиеңне дә үзебезнең тычканнарга азык итеп бирермен. Йә, кайсыгызны беренче төшерим?

Ыффф... Ыффф... Ыффф... Бу без шулай Самат белән чиратлашып борын тартабыз.

Сәрия апа, җәза тәмен озаккарак сузарга теләп, әле баз авызына үрелеп карады, әле безне җилтерәткәләп алды. Бераздан, сүз куешкандай, елый да башладык. Монда, агайне, алдыңда караңгы баз авызы ыржаеп торганда, малай кеше булсак та, холык күрсәтү мөмкинлеге юк шул... Ул арада теге бөдрә башның тавышы сарай тирәсен генә түгел, бөтен урамны яңгыратты:

– Әни-и-и, абыйны базга сармааа! Базга сармааа! – Үзен бәйләп шунда

ыргытырга җыеналармыни, үкерепме-үкерә. Бәләкәй генә, бая чәрелдек кенә күренгән кызчыкның кай җиреннән чыгадыр ул тиклем тавыш.

– Салам! Үзен генә түгел! Дустын да! Бергә күңеллерәк булыр!

– Буратны базга салма! Буратны базга салма!

– Күп чәрелдәсәң, сине дә төшерермен!

Шулай дигәч, инде тавыш тынарга тиеш иде. Тынды да. Тик озакка түгел. Кызчык, баягыдан да катырак итеп:

– Ән-ни! Минем пес итәсе килә-ә-ә! Минем нык пес итәсе килә-ә-ә! – дип кычкырырга тотынды.

Сәрия апа чарасыз иде. Безне ычкындырып, баз капкачын шапылдатып япты. Җиңел сулап куярга өлгермәдек, өстерәп дигәндәй алып чыкты да өйләренә кушып салынган мунча ишеген ачып:

– Кеше кыяфәтенә кереп юыныгыз, хәзер кием бирермен. Табышкансыз икән. Ишәй белән кушай, – дия-дия, безне мунчага кертеп җибәрде.

Икебез дә чиста футболка-чалбар киеп, кеше кыяфәтенә кереп юынып чыккач, аннан Сәрия апа безне яшел суганлы һәм йомыркалы пирожки белән чәй эчерткәч кенә, мин үзебезнең өйне искә төшердем. Бетте баш. Мин бит әллә кайчан әнигә «кайтып җиттем» дип шалтыратырга тиеш идем...

Өйдә ни көткәнен сөйләп тормыйм. Юк, юк, сорамагыз да, сөйләмим. Капка төбендә полиция машинасы торганны да, әнинең елый-елый косметикасы юылып беткән күзләре нинди сәер төскә керүе турында да, безнең өйдә Марьвасиловнаның аптыраган кыяфәттә әрле-бирле йөренүен дә – берсен дә сөйләмим. Бәлки берәр вакыт, көем килсә, сөйләрмен. Ә хәзер, юк, бер сүз дә әйтмим. Мин бит сезгә Самат белән ничек танышуыбызны гына сөйлим дидем. Вәт.

## Без нигә балык тотмадык яки Әминәне ни өчен шөпшә тешләде

Бик ялынып сорасагыз, теге атнада өчәүләп балыкка төшкәнне сөйли тора алам. Шул инде, анда да Әминәне тагып җибәрде Сәрия апа. Ул көнне дә капка төбендә шушылай көтеп тинтерәдек. Ярты көн үткәндер, күренделәр. Черки таламасын дип, кызыйга озын җиңле кофта, чалбар кигерткән. Тышта кояш кыздыра! Муеныннан урап бәйләгән яулык өстеннән бейсболка да чәпегән.

– Шулай озак, – дип мыгырданды Самат, канәгатьсезлеген яшермичә.

– Өйрәнә торыгыз. Мужик бит сез. Өйләнгәч, хатыннарыгызны әле болай гына көтеп тинтерәрбез дисезме... – Сәрия апага Әминәнең яулыгы ошап бетмәдеме – сүтеп кире бәйләргә кереште.

Мин үзалдыма маңгаемны җыерып куйдым. Димәк, бөтен ир-егетләргә дә бер үк язмыш язылган. Өйдә өчәүләп берәр кая барырга җыенсак, бездә дә шул ук хәл: әнинең киенгәнен, бизәнгәнен көтәбез, көтәбез... «Булды» дигәч, әти белән сөенә-сөенә машинага чыгып утырабыз, әни туфлиен киеп, ишек биклим дип кала. Без тагын көтәбез, көтәбез, көтәбез... «О, ярты ел да үтмәде!» – дип, мәҗбүри елмаеп каршы ала аны әти, әле генә кырык сүзгә җитеп зарланганын, еларга җитешеп, рульгә суккалаганын онытып. «Кире кердем. Үтүк калмаганмы, газ сүнгәнме – тикшереп чыктым. Тиз генә күлмәгемне дә алыштырдым – тегесе килешеп бетми.

Кигәндә, причёскамны боздым...» Әнинең исе дә китми, әти дә авызына су каба. Әнинең җилкәсенә таралган кара бөдрә чәчләренә, кошларның канат очыдай читкә каерылып торган матур кашларына, тез өстен каплар-капламас торган зәңгәр күлмәгенә, бая гына кигән ак алка урынына хәзер зәңгәр ташын җемелдәтеп ялтыраган көмеш алкасына бер карап куя да машинаны кабыза.

– Миңа да калмак киләк! Мин дә балык тотам! – Моңа тиклем бөтен «л» урынына «р» дип әйткән Әминә, логопедка йөри башлаганнан бирле, «р» урынына кайчак «л» куеп сөйләшә иде. Безнең колак күнеккән, ничек сөйләшсә дә, аңлыйбыз. Мәгәр аның кебек үзсүзле, тискәре бала дөньясында юктыр! Ул, әнисенең яулык бәйләткәненә сабыр гына риза булып торды да, безгә карап, кармак таптыра башлады.

– Иртәгә әтиең сиңа да алып кайтыр, – диде Сәрия апа, бейсболканы Әминәнең күзенә үк төшереп. Тегесе ә дигәнче аны өскә күтәрде.

– Миңа бүген килә-ә-әк! Би-и-ил! Да-ай! – Әминә ялт кына абыйсы кулындагы кармакка үрелде.

– Биргән ди! Сындырасың хәзер! – Самат читкә тайпылды.

– Мә, минем кармакны тот. Авыр ул, күтәреп барасым килми, – дидем мин, бу тискәре кызның киресен эшләвенә өмет итеп. Шулай булды да. Башы эшли тагын үзенең, карап-карап торды да:

– Син күтәлеп бал, балыкны мин тотам, – диде, нәкъ әнисе шикелле, әмер биргән рәвешле итеп.

Сәрия апа безгә кояш рәсеме төшерелгән чүпрәк сумка – шопер сузды, борынга сгущёнкалы, яңа пешкән круассан исе килеп бәрелде.

– Ишетсен колагыгыз: Әминәдән күз аласы булмагыз! Башыгыз белән җавап бирәсез! Корт чакмасын... егыла күрмәсен... бата күрмәсен...

Мәзәк бу Сәрия апа: анда безнең тезне дә күмәрлек түгел, батам дисәң дә, батып булмаганны белеп тора юкса...

Әти әйтмешли, ярты ел да үтмәде, безнең әзерлек тәмамланып, каеннар арасындагы сукмактан Нокса буена юл тоттык. Кара майка, кара шортик, кара чәпелдек кигән Самат алдан атлый, беләгендә – зәңгәр чиләк, бер кулында – өр-яңа кармак. Уртада – вак-вак адымнарына карасаң, йөгергәндәй тоелган Әминә теркелди: кайчагында сыңар аягында сикергәләп алырга да җитешә. Мин аның тән сакчысы шикелле артыннан барам: уң кулымда кармак белән майонез чиләге, сулында – тәмлүшкәле пакет. Аннан килгән тәмле ис, балык тоту теләген куып, борынны кытыклый. Усал булса да, болай әйбәт кеше ул Сәрия апа. Аның эшкә барасы юк, сату өчен өйдә генә төрле тәмле әйберләр пешерә. Тортлар, гөбәдияләр, чизкейклар, круассаннар – ни генә юк. Бөтенесе дә телне йотарлык була! «Пешергәндә шуларны кабып карый-карый юанаеп бетәм», – дип зарлана үзе. Аның холкына нәзек, юка гәүдә бөтенләй килешмәс тә иде, андыйдан кем өркесен... Ә Сәрия ападан хәтта безнең урамдагы хуҗасыз Рекс та шүрли. Үткән-сүткән бөтен кешегә хәлсез итеп булса да өреп маташа, Сәрия апаны күрсә, койрыгын бот арасына кыстырып, юлның икенче ягына чыгып сыза.

– Сок хочу! – Әминә, мине абындыра язып, кырт туктады да кулымдагы сумкага ябышты. Унысы ун төсле фломастерга буяган тырнаклары мәченекеннән ким түгел, ахры; ялт кына эләктереп тә алды. – Сок бил!

– Юк! Барып җиткәч эчәрсең! – диде Самат, артына борылмый гына.

Әйтерсең сеңлесе аннан рөхсәт сорап эндәшә... Әйләнеп караса, ул инде Әминәнең кечкенә каптагы алма согын трубочка белән ачарга маташканын күрер иде. Кызчык кәгазь капны бармаклары белән ныграк кыстымы, үтә күренмәле таякчыкны нәни түгәрәккә төртүгә, күзенә алма согы чәчрәде. Мин инде аны урман яңгыратып елый башлар дип көткән идем, керфеген челт-мелт китереп кенә алды да «өфөөлттт» дигән аваз чыгарып, әллә ни арада сокны эчеп тә бетерде. Биш-алты адым да атламады:

– Абый! Мин пештем! – дип, өстендәге кофтаны салдыруны таләп итә башлады ул.

– Пешсәң, хә аюга тотып бирәбез, ашар, – дигән булды Самат, бу юлы да борылмый гына. Компьютердан «Маша и медведь» мультигын карап, ятлап бетергән Әминәне аю белән куркытып буламы инде, йә?

– Әйдә, сал, сал, син дә черки симертерсең, – дидем мин, үземнең беләккә кунган черкине аңа таба куып.

Кызый юри ике күзен борын тирәсенә бер ноктага җыеп, кылыйландырып, миңа ямьсез итеп карады. Үзенчә үртәве, беләм. Бала-чага бит, нишләтәсең... Шулай да ал кофтасының ычкындыра башлаган сәдәфләрен кире төймәләп куйды.

Басмадан әллә ни ерак түгел карт өянке бар – Самат аны Казан белән бер яшьтә ди, каян беләдер. Менә шул. Казан белән бер яшьтәге өянке астында безнең үз урыныбыз бар. Кармакларны салып куярга бик җайлы анда: калкавычлы башын суга ыргытасың, ә сабын яр читендәге икегә аерылып торган төп уртасына кыстырасың да балык чиерткәнен көтеп утырасың. Ул көнне без анда барып җитә алмадык. Чөнки Әминә «Әйт әле, күбәрәк, сөйләшик бергәләп» дип җырлаган мәлдә, аның иренен шөпшә тешләде һәм тирә-якны күкрәткән тавыш астында безгә яшен тизлеге белән кире кайтырга туры килде.

## Чапаев абый яки Әминә чүмеч белән чебен үтерә

Самат белән безне минем әни агылый белән тагылый ди. Сәрия апа ишәй белән кушай ди. Җәйнең бөтен көне күбрәк урманда яки Саматларның ишегалдында үтә. Иртән әти белән әни, эшкә киткәндә, мине уятып, бүген ниләр эшләргә тиешлегемне башта алмаш-тилмәш әйтеп чыгалар. Йокы аралаш ишеткәннәр, уянгач, ком тузаны шикелле тузгып тараласын бик әйбәт белгәнгә, ватсапка да язып салалар. Югыйсә башта ук шулай гына итәсе бит инде, тәмле йокыны бүлеп уятасы да түгел. Юк шул, әбизәтелне минем «ярар... ярар... ярар...» дигәнне үз колаклары белән ишетү кирәк.

– Сэмның суы бетмәсен, тамагы кибәр. Көн кызу. Хәтергә ал. Тартмасын чистартырга онытма.

Монысы – әти. Өскә карап торган коңгырт чәчен бармаклары белән генә тарый-тарый, миңа песи турында искә төшерә.

– Ярар, әти.

Сэм – үз йортыбызга күчү белән нәни йомгак килеш кенә алган песиебез. Хәзер үсте, тазарды инде, йоннары күпереп тора. Аның шаянлыгын белсәгез! Икенче катка менә торган баскыч буенда качышлы уйнарга ярата. Берәрсенең менеп баруын күрсә, җәлт кенә шунда ташлана да ал тәпие белән җилкәгә суга: тукта, ашыкма, бераз уйнап алыйк диюе. Андый чакта

әти баскыч астына кача да башын күтәрми генә кулын сузып, бармакларын биетә. Сэм рәхәтләнә инде шаярып: әтинең кулына ташлана, тешләгәндәй дә кылана, тәпие белән дә суккалап-суккалап ала. Боксёр диярсең!

– Тору белән койма буендагы чәчәкләргә су сибәргә онытма.

Монысы – әни. Бер дә тырнакларым ямьсезләнә дип тормый, ишегалдын, капка төбен тутырып, чәчәкләр утырта ул. Яз башыннан чиратлашып балкырга тотыналар: башта кызыл, сары, ак лалә чәчәкләре елмая, алар коелып беткәндә, нәни-нәни ромашкалар күзен ача, лилияләр ап-ак чәчәк ата, аннан дәлияләр, кашкарыйлар сары, кызыл, шәмәхә чәчәккә күмелә. Мин исемнәрен белмәгән әллә нинди гөлләр койма буйлап кояшка таба үрмәли. «Алары суны аеруча ярата – ди әни, – шуңа иртән дә, кичен дә күп итеп коендырырга кирәк», – ди. Бу эш – минем өстә. Минем дип, йокыдан торуыма Самат килеп җитә, аннан икәүләп гөлләр дә, үзебез дә лычма булганчы су сибеп мәшәләнәбез.

– Ярар, әни. – Керфекләрне һаман аска тарткан йокы аралаш мин әнинең иелеп чәчемне сыйпаганын, маңгаемнан үбеп алганын тоям.

– Суыткычта бәрәңге белән кәтлит бар, җылытып аша.

– Ярар.

– Урамга чыксаң, ачкычны төшереп калдыра күрмә.

– Ярар.

– Телефоныңның тавышын аерма!

– Ярар.

– Сәрия апаңнарда пыр тузмагыз, Илшат абыең да кайткан, колагын тондырмагыз.

– Ярар.

– Аңа үзем әйтермен. Кич безгә килерләр, шашлык кыздырырбыз, самавыр кайнатырбыз.

– Ур-ра! – Бу сүздән йокы әллә кая китеп кача. Йә безнең, йә Саматларның ишегалдында бергәләп кич утырулар еш эләкми, чөнки Илшат абый өйдә тормый ул, «КАМАЗ»ында ерак юлларга йөри. Ул кайткан көннәрдә барыбызга да бәйрәм: кич бөтен урамга гармун тавышы яңгырый, шашлык исе тарала, самавыр торбасыннан бөтерелә-бөтерелә төтен күтәрелә. Ул да, минем әти дә бик матур җырлыйлар, икәүләп татарча сузып җибәрәләр: «Җидегән чишмәләрдә җиде улак, җиде ула-а-а-ак, челтер-челтер ага көмеш су-у-у-у...» – Андый чакта черкиләр дә очудан туктый, җил дә тынып, тыңлап тора, хәтта болытлар да бер урында катып калган шикелле тоела. Кайчак Илшат абый, бармакларын гармун төймәсе буйлап йөгертә дә минем әнигә ымлап: «Әйдә, Гөлназны җырлатыйк әле», – дип, берәр кызу көй уйнарга тотына. Шул мәлдә – әтинең туп-туры сызылып торган кашлары үзенең «Мазда» автомобилендәге билгегә әверелә, «Ииии-ххх, Илшат, шундый матур утыра идек бит», – дип аһылдап куя. Әни ялт итеп аның кабыргасына төртә. Ә Сәрия апа җырла дигәнне көтеп тормый, җырлыйсы килгән мәлдә, ире нинди көй уйнауга карамастан, «Ай былбылым, вай былбылым» дип башлап җибәрә. Илшат абыйга, елмаюын күрсәтмәс өчен башын читкә борып, шул көйгә күчүдән башка чара калмый. Әти исә, көлеп җибәрмәс өчен кисәк кенә каты-каты итеп ютәлләргә тотына. Әни, үзе дә сизмәстән, шашлык янында туралмыйча калган суганны алып кимерә башлый.

Димәк, бездә шундый рәхәт кич утыру булачак!

Булырга тиеш иде. Ләкин...

Сөйләсәм, сез безнең хакта «болар бигрәк тәртипсез балалар икән», дип уйларсыз инде... Сөйләмәсәм, ни өчен ул көнне кич утыра алмавыбызның серен белми калачаксыз. Һем... Ярар, ул хәтле ялынгач, иркенләп сөйлим инде.

Әти белән әнине мин бу юлы караваттан гына кул изәп түгел, капка төбеннән үк озатып калдым. Көн тизрәк үтсен дә тизрәк кич җитсен! Ак футболкасын зәңгәр джинсы чалбар өстеннән чыгарып салган, аягына минеке кебек чәптерки генә элгән әти капканы ачып башта әнине уздырды, борылып, миңа баш бармагын күрсәтте. Алар икесе дә төз буйлы. Әни биек үкчәле туфли кисә, әтидән бераз озынрак та күренә әле. Шуңа да концертка, спектакльгә бергә барганда, әни тигез табанлысын кия. Ә эшкә, үз машинасында йөргәндә, аягында без шикелле үкчәле туфли. Әти аның белән ничек итеп газга, тормозга басып булганына шакката. Әни алай диюенә зәп-зәңгәр күзләрен балкытып елмая гына. Кап-кара чәч бөдрәләрен иңбашында тирбәтә-тирбәтә, безгә кул изи дә үзенең шоколад төсендәге «Фольксваген»ына кереп утыра. Аптырарсың инде: минем әнинең үз чәче – сары төстә һәм туп-туры. Ул аны хәзер гел кара төскә буяп йөри, кайчак зур-зур бөдрәләр дә ясый. Югыйсә без аны ничек тә яратабыз: әни бит ул! Ә Саматның әнисе, киресенчә, караңгы төстәге чәчен гел сары буяуга буйый, һәм тумыштан бөдрә булуын ошатмыйча, чәчтарашханәгә барып, турайтып кайта. Нигә алай эшләгәнен бервакыт үзеннән сораган идек, Сәрия апа авыз ачканчы, Илшат абый кул селтәде:

– Мужиклар, сез лутчы хатын-кыз эшенә кысылмагыз. Алар бөтенесе дә без ир-атларның кәкре кабыргасыннан ясалган, аларны мәңге турайта торган түгел, – диде ул, безнең берни аңламаганны күрсә дә, төшендереп тормыйча.

Без Самат белән интернеттан башта кабырганың нәрсә икәнен, кайда икәнен эзләп таптык, аннан үзебезнең кабыргаларны бармак белән каезлый-каезлый авырттырып бетердек. Ләкин ул кабыргадан ничек хатын-кыз ясалырга мөмкин икәненә тәки төшенә алмадык.

Бүген көн бөтенләй акрын уза иде. Әле кич җиткәнче! Күзең күгәрер! Самат белән башта бездә Сэмны уйнаттык, тәлинкәсенә күп итеп китекат куйдык, кибекмәсен дип, ташып чыкканчы су да салдык. Аннан Сәрия апа шалтыратты:

– Малайлар, ашавыгызны онытып уйнап ятмагыз, марш өйгә кайтыгыз! Пылау әллә кайчан сеште! – диде ул, телефоннан шалт кына әмер биреп. Ул минем үз өемдә икәнемне әллә оныта инде – гел шулай «өйгә кайтыгыз» ди. Әни аңа: «Гел синдә ятып ялкытып бетерәләрдер, бездә, шар суксалар да, беркем юк, уйнасыннар иркенләп. Суыткыч тулы ризык – җылытып кына ашый алалар», – дип әйткәләп караган иде. Җиңәрсең Сәрия апаны: «Күз алдымда булсалар, минем дә җаным тыныч, синеке дә. Аерым казан асмыйм, ризык бөтенебезгә җитә. Күп сөйләшмә!» – дип, авызын гына каплый әнинең.

– Пылауны әкре-е-ен генә, ашы-ы-ыкмый гына ашыйбыз, яме? – диде Самат, капканы бикләп, аларга барырга дип урамга чыккач.

– Аһа... Нигә? – дидем мин, аңлап бетермичә.

– Алай кич тизрәк җитә.

Нәрсәдер дөрес булмаса йә аңламый торсаң, Самат хәзер бер дә элеккечә «дурак» дими, ул сүзнең ямьсез икәнен үзе дә аңлады.

Безнең урам – бистәдә иң матуры! Өйләр бер якка кына тезелгән, каршыда – урманның сакчылары шикелле, шундый төз, матур ак каеннар тезелеп киткән. Бераз баргач – бик матур балалар мәйданчыгы. Кайчан карама, атынгычта, турникта, карусельда ыбыр-чыбыр мәш килә. Бүген ни өчендер анда бала-чага юк, безнең күрше Клавдия Ивановна белән аның ире Василий Иванович кына атынгыч тирәли йөренәләр иде.

– Здрасьте, Василий Иваныч! Здрасьте, Тётклава!

Самат һәм мин икәүләп хор белән кеше төсле итеп исәнләштек. Әмма яннарына ук килмәдек. Чөнки авыз пешкән бар – бер үк тырмага әллә ничә кабат басарга башка тай типмәгән! Хикмәт шунда: әти Василий Иванович белән танышкач, өйдә аның турында сүз чыкса, «Чапаев, Чапаев абыегыз» дип кенә телгә ала иде. Безгә ни, безне мәктәптә дә, өйдә дә зурлар белән хөрмәтләп, әйбәтләп исәнләшергә, ярдәм кирәк чакта булышырга өйрәтәләр. Бервакыт урамда каршыбызга шактый авыр әйбер күтәреп кайтып килгән Василий Ивановичны күргәч, кычкырып исәнләштек тә кулындагы сумкасына барып ябыштык:

– Здрасьте, дядя Чапаев! Давайте, мы вам поможем!

– Так, ребятки... Постойте. Я сам... Я сам...

Безнең үз киребез кире иде. Бөкрәя төшеп атлаган Василий Иванович күзебезгә бетәшкән бер карт булып күренгәдер, аңа ярдәм итәсе килү теләге бик көчле, сумкасын күтәрешеп, өенә илтү иде исәбебез. Ләкин Самат белән икебез ике почмагыннан тарткалаган мәлдә чүпрәк сумканың бавы өзелеп тә китте, ул ташлы юлга килеп төшкән уңайга чырт иткән тавыш та ишетелде.

– Ну щас я вам покажу... будете расплачиваться и за Чапаева, и за пиво...

Аның тавышындагы ноталардан без эшнең шактый хөрти икәнен сиздек. Ул арада тирә-якка әчкелтем сыра исе таралды, сумка төбеннән ерганак булып саргылт сыекча агып чыкты. Безгә: «мы просто... просто... хотели помочь», – дип, борын астыннан мыгырдана-мыгырдана, табан ялтыратырга гына калды.

Бу хәлдән соң Чапаев, әй, Василий Ивановичтан минем әти белән әнигә дә эләккән булса кирәк, чөнки кичен әтидән миңа эләкте...

Шуннан бирле без Василий Иванович белән дә, аның хатыны белән дә гаять итагатьле итеп исәнләшәбез, алар да безгә елмаеп кына җавап кайтара.

– А что вы тут делаете? Играете? – Самат түзмәде, телне кычыттырган сорауны бирергә ашыкты.

– Да вот, мужа выгуливаю, – дип елмайды Клавдия Ивановна, ирен култыклап ипләп кенә атлаган җиреннән.

– Как собаку что ли?

Бетте, күк күкрәве мөмкин хәзер... Ләкин, бәхеткә, Василий Иванович та сүрән генә итеп елмаеп куйды.

– Ему же второй раз инсульт был, прогулки нужны. Свежий воздух... – Хатыны, безгә олыларча җитди итеп аңлатып, ире ягына кайгыртучан караш ташлады.

– Да, верно... Вот, ребятки, смолоду надо о здоровье думать. Играйте,

бегайте, занимайтесь спортом – это, оказывается, не простые слова... – Василий Ивановичның бер як бите читкә тартылып, авыз кырыен да тартып торган шикелле иде.

Без янә хор белән:

– До свиданья, Василий Иваныч! До свиданья, Тётклава! – дип әдәпле генә саубуллашып, алар яныннан китеп бардык. Елмайсалар да, аларның күзләре елый шикелле тоелды.

Без кайтып кергәндә, Илшат абый ишегалдында, тәрәз буендагы челтәрле эскәмиядә тәмәке көйрәтеп утыра иде. Диңгезчеләрнеке шикелле буй-буй сызыклы тельняшкасының җиңнәрен сызганып куйган, терсәге белән тезенә таянган да уйга баткан. Безне күргәч, тәмәкесен тиз генә сүндереп, яшергән булды. Әйтәм бит, кызык ул зурлар: үзләре безгә «ярамый, ярамый» диләр, үзләре шуны ук эшлиләр. Безнең сыйныфтагы Эдикның электрон тәмәке тартканын кайтып әйткәч, ничек шаккаттылар: бу яшьтә! Үпкәсен агулап! Әти-әнисе нәрсә карый?... Киттеләр инде, киттеләр... Үзләре үрнәк күрсәтәләр, үзләре орышалар – һич аңлый торган түгел.

– Сез, шельмалар, тәмәкегә якын киләсе булмагыз, яме? Алайса, менә минем кебек шәрә баш калырсыз, – диде Илшат абый, баш түбәсенең уртасында ялтырап торган пеләшен сыйпап, безнең уйны укыгандай.

– Ә синең чәчең кая китте, Илшат абый? – Мине ул сорау әллә кайчаннан кызыксындыра иде, сорарга гына кыймый идем, менә хәзер җай чыкты.

– Һи, ул җүләр чәчләр минем акыллы башны ташлап киткән булдылар, кайда адашып йөриләрдер, кем белсен, – диде ул, туры җаваптан качып.

– Әти, бүген Булатларга барабызмы? – диде Самат, күзен әтисенең пеләшеннән алмый гына.

– Шуннан кайтып киләсез түгелме?

– Ә без кич шашлык пешерәбез! – Әйтерсең Илшат абыйның гомердә дә шашлык ашаганы юк – минем тавышым шундый кызыктыргыч чыкты.

– Шашлык – менә анысы әйбәт... Кичкә ерак әле, барыгыз, бар, пылау суктыра торыгыз.

Өй эченә, пылау исен күмеп, гадәттәгечә тәмле камыр исе таралган иде. Сәрия апа заказга пешергән гөбәдияләрен кечкенә табаларга тезеп куйган, чөеп бәйләгән яулыгының бер койрыгы әтәчнеке шикелле дерек-дерек мәзәк итеп селкенеп тора. Әминәгә дә бәләкәй генә куна тактасы белән кашык хәтле генә уклау тоттырган: анысы да, кыланчык, башына кызыл яулык, биленә кызыл алъяпкыч бәйләгән. Нәни бармаклары белән пәрәмәчкә охшаган нәрсәдер ясап маташа. Кулы килешеп тора үзенең!

Безне күргәч, онга буялган борын очын беләге белән сөртеп алды да:

– А я пиложки лепила! Сама! – дип мактанырга ашыкты.

Сәрия апаның йомры таза бите кызарып чыккан, маңгаенда бөрчек-бөрчек тир бөртекләре.

– Телеңне кая куйдың? Татарча сөйлә!.. Икенче катка менми торыгыз, бөтен тәрәзәләрне ачтым, җилләсен. Кулыгызны юыгыз, ашарга утырыгыз. – Аның һәр җөмләсе командирның солдатларга эндәшкәне кебек ишетелә: шалт та шолт, ялт та йолт. Менә ул таза беләкләре белән җәлт-җәлт селтәнеп, кызыл матур тәлинкәләргә безгә күп итеп пылау салды, тәлинкәләрне кухня уртасындагы түгәрәк өстәлгә тезде. Аскы каттагы бу бүлмәләре гел

кызылдан гына тора аларның: шкафлары да кызыллы-каралы, суыткычлары да, зу-у-ур тәрәзәнең бер як читеннән идәнгә тиклем тиеп торган ак пәрдәләренә дә кызыл розалар төшкән. Хәтта тәлинкә-чынаяклары да кызыл төстә. Ак эскәтер өстендә ут шикелле янып утыралар.

Бая гына пылауны әкрен генә ашыйбыз дип сүз куешканны онытып, ә дигәнче тәлинкәнең төбен ялтыратканбыз. Аннан Илшат абый ерактан алып кайткан тел йотмалы карбызны суктырдык. Вак гөбәдияләр белән чәй эчеп, урыннан кузгалганда, мин дә, Самат та көчкә селкенә идек. Урындыкка басып кулын юып маташкан Әминә, безнең аю шикелле алпан-тилпән килгәнне күреп, чеңләп көлеп җибәрде. Самат аңа йодрык күрсәтте.

– Кашык-тәлинкәләрне чәй содасы белән юып, чүпрәккә генә тезегез. Өстәлне сөртегез. Үз артыгыздан чиста итеп калдырырга өйрәнегез, ике кулыгыз бар. – Сәрия апа болай дип, без өстәл яныннан кузгалган саен кабатлый. Ияләштек инде, мин хәтта өйдә дә өстәлне үзем җыештырам, әни бик сөенә шуңа. Дөрес, еш кына ул мин юган чынаякларны соңыннан үзе чәй содасы белән юып тезә. Болай эшләргә Сәрия апа өйрәтте: «Теләсә ниткән химия белән юып, ашказанын да, кулны да бетерер хәл юк, чәй содасы йә гәрчич порошогы менә дигән чистарта», – ди ул. Ә менә минем өстәл җыештырганны күрсә, әти әнигә каш җыерып карый. «Малайларны менә шулай хатынша итеп үстерәсез дә, аннан чын ирләр калмады дип, зар елыйсыз», – дип ачулана. Әни аңа җавап итеп: «Әнигә булышканнан гына хатыншага әйләнми ул! Кыз балам юк, барысына берүзем ничек өлгерим?» – ди. «Кыз алып кайтыйк», – ди әти. Сөенә-сөенә, аңа мин кушылам: «Әни, Саматның сеңлесе бар, миңа да кирәк! Исемен Әминә дип кушарбыз! Давай, апкайт!» Сүз шул таба борылгач, әни мин юган чәшкеләрне алып, үзе кабат юарга тотына...

Самат кашык-тәлинкәләрне юып, мин өстәлне сөрткән арада Әминә каршыма килеп басты да, билендәге кызыл алъяпкычын салып, миңа сузды. Шул гына җитмәгән иде! Кызга гына әйләнәсе калган ди монда! Мин кирәкми дип кулын эткән саен киреләнеп, учыма сона. Түзмәдем, алъяпкычны алып бөтердем дә иелеп, тиз генә шкаф тартмасына салып куйдым.

– Булат әшәке-е-е! Булат плохой!

Ну бу Әминәне! Корт чаккандай чәрелдәп еламаса!.. Җитмәсә, елаган арада, күрә микән дигәндәй, кара күзләрен мизгелгә генә як-якка йөгертеп, әнисенә дә карап ала. Иркәнең иркәсе!

– Ал да бәйлә инде, Булат дим! Ул яратып кына, болай гына бәйләргә куша! Бәләкәй бит әле ул, тыңламый нишлисең...

Сәрия апаның шулай диюеннән бит очыма ут капты. Аһа менә, кызлардан яраттырып торам ди хәзер!

Кулына зур сөлге тотып, икенче каттан төшеп килгән Илшат абый ишетеп калган икән:

– Бәләкәй булгач, олыларны тыңларга өйрәнсен! Шулаймы, кызым? Абыйларың синнән олы, алар әйткәнне тыңла!

Әминә, болай да күперенке иренен турсайтып, әтисенә каш астыннан гына карап алды, шулай да елаудан кырт туктады, озын керфекләренең берсендә юеш тамчы эленеп калды.

– Самат, улым, өске каттагы тәрәзәләрне яп. Әминә егылып төшә

күрмәсен. Без мунча кереп чыгабыз. Әминәне елатмагыз, ишетсен колагыгыз! Уен белән мавыкканчы, татарчага өйрәтегез. Урамда кызлар белән комда уйнап утырса, марҗа кызына әйләнә дә куя...

– Яра-а-ар. – Самат кызганыч кына шулай дип сузды.

Сеңлең булу бер яктан рәхәт, икенче яктан, бер дә рәхәт түгел. «Син абыйсы» диләр дә бөтен җаваплылыкны өскә аударалар да куялар. Әнә, Самат Әминә аркасында ничек тинтери?! Ул баланы елатма, черкидән тешләттермә, туңдырма, татарча сөйләшергә өйрәт, санарга, хәреф танырга өйрәт, сәпиттә утыртып йөр... Имеш, син олырак. Имеш, син – абый кеше! Имеш, син – яклаучы, син – саклаучы... Имеш, син көчле! Салпы якка салам кыстыра белә инде олылар...

Сезгә генә әйтәм, зарлансам да, мин үземнең дә Әминә кебек сеңлем булуын бик теләр идем! Чын мәгәр! Өйрәтер идем әле, санарга да, укырга да... Сәпит артына да утыртып йөрер идем. Минем дә абый буласым килә! Юк бит. Әнидән сораган саен ул сораудан кача гына...

Илшат абый белән Сәрия апа мунчага кереп киттеләр, без, Әминәне татарчага өйрәтергә тиешлекне аңлап, баш ватып калдык. Бер дигән сөйләшә ул, тик, әнисе әйтмешли, башка балалар белән комлыкта йә урамда уйнап керсә, безнең белән дә русча гына такылдый башлый. Аңа ияреп, без дә русчага күчкәнне сизми дә калабыз. Аннан Сәрияападан барыбызга да эләгә: уклау тота-тота катыланып беткән бармагы белән маңгайга шундый оста итеп чиртә! Күздән яшь атылып чыгардай була кайчак!..

– Нәрсәле уйныйбыз? – Самат, Әминәгә кырын-кырын гына карап, зал ягындагы диван астыннан конструктор тартып чыгарды. Без нәрсә дә булса төзи башласак, Әминә аны шунда ук җимерергә тотына – бу юлы да ул кош шикелле очып, яныбызга килеп басты. Абыйсына, авыр сулап, уенчыкны диван астына кире тыгып куюдан башка чара калмады.

– Давайте, поиглаем в пливедение! – Кызый, кулларын чәбәкли-чәбәкли, сыңар аягында сикерергә тотынды.

– Татарча әйт, приведение ничек була?

– Не зна-а-а-ю-ю-ю...

Әминә генә түгел, без үзебез дә белми идек. Тиз генә телефоннан гуглить иттек: өрәк дигән сүз икән.

– Өрәк! Өләк! Поиглаем в пливедение! – Әминәнең шатлыгы эченә сыймый, тагын да катырак сикерә башлады.

Самат тиз генә икенче каттан үзенә дә, миңа да караваттан җәймәләре алып төште, без аларны башка ябындык та, Әминәне куркытырга теләп, төрле куркыныч авазлар чыгарып, баскычтан бер менеп, бер төшеп йөгерергә тотындык. Куркытырсың! Безнең хәрәкәтләрдән эче катып, шырык-шырык көлеп утыра. Самат, җәймәне эләктергән ике кулын канат кебек җәеп, баскыч култыксасына ук менеп басты.

– Амина, а ты знаешь, я ведь однажды умер! – диде ул артистларча серле, калын тавыш белән, һәм күзен йомып, авызын «ооо» дип әйткәндәй очлыландырып, култыкса өстендә катып калды.

Әминә бермәлгә көлүдән туктап, аңа бик аптыраган төстә карап торды.

– Как? Как? Вот же ты! Живой же! – Кызчыкның йөзе җитдиләнгәннән-җитдиләнде.

– Я сначала умер, а потом воскрес! – Самат, урамдагы һәйкәл шикелле,

бер кулын алга сузып, әз генә талпынып алды да кинәт култыксадан очып та төште.

– Вот сейчас точно умеррр! – Әминә, шатлыгыннан кул чаба-чаба, «р» авазын үз урынына куеп, аның янына йөгерде. Мин дә, башымнан бөркәнгән алсу җәймәне идәнгә ташлап, Самат янына чүгәләдем.

– Авырттымы? – дидем мин, аның елардай булып тез башын уганын күреп.

– Аһа. Әй, хәзер бетә ул... – Самат иренен тешләде, үзенә үрелгән Әминәне кулы белән этеп җибәрде. – Кит әле...

– Ә мин сине әнигә әйтәм! Ул мине елатмаска кушты! – Кызыйның күзеннән очкыннар чәчрәде. Елый башласа, Сәрия апа хәзер мунчадан атылып чыгачак. Кухня ягына чыга торган ишекләре дә бар, ялт пәйда булачак...

Самат, үз хәлен онытып, аксаклый-аксаклый торып басты, җәймәсен өскә томырды.

– Пить хочу! – Әминәнең еларга итеп челт-мелт килгән күзләре миңа укталды.

– Татарча әйт! – Тел күрсәтергә җыенган җиремнән вакытында кире уйлап өлгердем. Безнең вазифа искә төште.

– Су бир! Су кирәк! – Кызыйның күзләре инде бу минутта шукланып елтырый иде. Кай арада әллә ничә төрлегә әйләнә белә ул?..

Без өчәүләп кухняга кердек. Мин кечкенә чынаякка краннан су агызып, Әминәгә суздым, әмма Әминәгә бу чынаяк ошамады, ул абыйсыннан башкасын таптыра башлады. Самат аптырап тормады, стенага беркетелгән торбага эленгән аш чүмеченә су агызып, аңа бирде. Күрәсең, бик кызык тоелды – Әминә үзалдына елмая-елмая суны эчеп бетерде дә чүмечне кулыннан ычкындырмый гына зал ягыннан урап килде. Без өстәлдәге вак гөбәдияләргә, суыткычтагы лимонадка һөҗүм ясаган арада, выжылдап йөргән бер чебенне күреп, аны куаларга тотынды. Менә әлеге чебен суыткыч янында, идәндә торган өч литрлы банканың капкачына килеп кунды. Ул да булмады, Әминә аш чүмече белән чебенгә китереп тондырды. Тик уңышсыз селтәнгәндер – чебен, бәхетле выжылдап, зал ягына очып китте. Без дә, духовка тоткасына эленгән сөлгеләрне эләктереп, аның артыннан йөгердек. Чебенне кем беренче үтерә – җиңүче шул булырга тиеш иде. Чебен безнең арттан, без чебен артыннан йөгереп йөргән мәлдә кухняга кергәч, мин, бозга баскандай, линолеумда таеп та киттем, артыма килеп тә утырдым. Идәнгә, күрәсең, лимонад түгелгән иде – шоп-шома булып калган. Миннән күреп, кызык итеп, Самат хәтта сыңар аягында шуып та карады, йөзенә бәхетле елмаю таралды. Әминә дә, чүмечен өстәлгә ташлап, безгә кушылды. Артымның авыртуы турында да, юешләнгән шортик турында да уйлап торырлык түгел идем, бу мизгелдән мәхрүм калырга теләмичә, ашыга-кабалана торып бастым. Без суыткыч буеннан тәрәзә янына, тәрәзәдән суыткычка тиклем беребезне икенчебез уздыра-уздыра шуып уйнаган арада идән тәмам шугалакка әйләнде. Аяк табаннарыбыз бөтенләй майлап куйгандай булды. Анысы да бәла түгел: тиз генә йөгереп залга чыгабыз да идәндәге күперенке келәмдә табаннарны корытып, янә кухняга чабабыз: идән кипкәнче уйнап өлгерәсебез килә. Тәмам кызып килгәндә, мунчадан кухняга чыга торган ишек киерелеп ачылды, анда өстенә кыска

гына халат элгән Сәрия апа күренде. Аның күз төбенә, маңгаена зәңгәр балчык сыланган да кызык булып катып калган, ирен өстендә вак-вак юеш тамчылар күренә. Ул, башта борын канатларын селкетеп, нидер иснәнде:

– Майны түкмәгәнсездер бит? – Күзе ялт кына идәндәге өч литрлы банкага төште, ул урынында иде. Без, аркабызга уклау белән сылагандай, өчебез берьюлы шым булдык. Берәм-берәм ялт кына зал ягына чыгып, күзеннән югалдык. – Самат, улым, көзге астыннан яңа лампочка алып бир әле, ут сүнде мунчада, – дип кычкырды ул безнең арттан. – Нәрсә эшләдегез сез монда, ә? – Шулай диюгә нидер чылтырап идәнгә төште, шул мизгелдә Сәрия апа аһылдап кычкырып та җибәрде. Самат белән мин, котыбыз очып, кухня ягына сикердек, Әминә ни өчендер тиз генә баскыч астына кереп посты. Ишек буеннан үрелеп карасак... Сәрия апа суыткыч буенда басып тора, уң як кулының беләзегенә капкачы да ачылмаган килеш пыяла банканың өске өлеше килеп кадалган, беләзегеннән кан сиптерә.

– Илша-а-ат! Илша-а-ат! – дип кычкырды Сәрия апа, мунча ягына карап, коточкыч тавыш белән. Без тын алырга да, селкенергә дә куркып басып торабыз. Менә ишектә зур балакларына күбәләк рәсеме төшкән трусик кигән Илшат абый күренде, ул да Сәрия апага карап, тынсыз калды. Тагын бер-ике секундтан ул аңын җуеп егылыр кыяфәттә иде.

– Илша-а-ат! «Скорый» чакыр! – Сәрия апаның тавышы аны бик тиз аңга китерде.

– Нишләдең? Нәрсә бу? – Илшат абый аның кулындагы пыяла банкага үрелде.

– Ала күрмә! Аннан канны бөтенләй туктатып булмас! Шалтырат дим «Скорый»га!

– Хәзер... хәзер... телефон... Корт чаккыры... кая соң... Нәрсә дим?

– Киселгән диген. Кан туктамый диген... – Беләген бармагы белән кысып тоткан Сәрия апаның төс-кыяфәтенә карап еларлык та, көләрлек тә иде. Тик көлеп кара! – Әйтәм аны мунчада ук борыныма көнбагыш мае исе килгән кебек иде... Банкасы үзе ватылмаган кебек күренде. Күтәреп караган идем – яртысы идәнгә тәгәрәде, өсте, әнә авырлыгы белән кулыма килде дә кадалды!

Безне ай күрде, кояш алды – яшен тизлеге белән Әминә янына, баскыч астына кереп чумдык. Олыларда безнең кайгы юк – «Ашыгыч ярдәм» килгәнне көтәләр. Илшат абыйның мыш-мыш килгәне ишетелә – идәндәге сыек майны сөртеп изалана булса кирәк. Үзе нидер мыгырдана. Түзәсеңме, дип, әледән-әле Сәрия апага эндәшеп ала.

Ярый әле, «Ашыгыч ярдәм» озак көттермәде. Илшат абый капка төбенә чыгып каршы алды. Кара күзлекле, кулына кечкенә чемодан тоткан ак халатлы олы гына яшьтәге абый белән яшь кенә бер апа, туфли өстеннән бахилла кигән килеш Сәрия апа янына кухняга үттеләр. Нишләткәннәрен карыйсыбыз бик килсә дә, баскыч астыннан борынны чыгарырга куркабыз, тын калып, аларның сөйләшкәненә колак салып торабыз.

– Хы-ы-ым... Ничек болай эшли алдыгыз, ә? – Врач абый бу трюкка үзе дә аптыраган, ахры. Мөгаен, Сәрия апа янында баш чайкап басып торадыр.

Сәрия апаның кыска гына итеп хәлне төшендерергә маташканы ишетелә. Тик банканың ни сәбәпле чатнаган булуын гына аңлата алмады. Хәер, ничек аңлатсын, Әминәнең аш чүмече белән чебен үтерергә маташканын күрмәде бит ул.

– Ханым, сез ниме... спиртлы эчемлекләр белән мавыгырга яратасызмы әллә?

Берничә секундлык тынлык. Илшат абыйның «кх» итеп куйганы ишетелә.

– Каян чыгып? Ниткән эчемлек? – Кулын бәйлиләр микән – Сәрия апа ы-ы-ыһ... дип ыңгырашып ала.

– Гафу итегез, тик йөзегезгә караганда...

Без Сәрия апаның зәңгәр балчык сыланган күз төбен, маңгаен, тир бәреп торган ирен өстен күз алдына китерәбез дә үзебез дә сизмәстән әкрен генә хихылдап куябыз.

Янә берничә секундка сузылган тынлык.

– Мунчада идем дип торам бит. Монысы маска. Монда бал сылаган идем.

– Аааа... мунчада бал тотасыз, димәк... – Бигрәк кызык булып чыкты бу врач абый. Нигәдер сөйләндерә дә сөйләндерә Сәрия апаны. Әллә ниткән сораулар белән тинтерәтә... – Ачы балдыр әле...

– Ачы түгел! Балны тоз белән бутыйм да биткә сылыйм.

– Малайлар майны түккән, димәк... Була, була, балачакта алардан әллә ниләр көтәргә була. Шуңа да балачак инде ул! – Врачның күңелле тавыш белән шулай диюеннән без, ниһаять, җиңел сулап куябыз.

– Менә, әлегә булды. Әйдәгез, больницада тегәрләр. Үзегез белән медицина полисын алырга онытмагыз. Сез озата барасыздыр бит? – Врачның Илшат абыйга әйтүе булгандыр, Илшат абый сүзсез генә баш каккандыр – җавап яңгырамады.

– Озак торырбыз микән? – Сәрия апаның тавышы борчулы. – Теге хәсрәтләр (ягъни без) үзләре генә кала бит... Илшат, Назифка шалтырат, эштән кайтса, балаларны үзләренә алып китсен. Безнең кайчан кайтасын кем белә...

Нишләптер безне орышу турында бөтенләй онытты ул, шулай да чыгып барышлый, баскыч астына күз ташлап:

– Ишетсен колагыгыз, Әминәне күздән ычкындырасы булмагыз! – дип кисәтеп узарга онытмады.

Өч литрлы банка һәм көнбагыш мае аркасында без ул кичне шашлык та ашый алмадык, кичке болытлар, җилбер җилләр, сайрар кошлар да әти белән Илшат абыйның «Җидегән чишмәләрдә-ә».... дип җыр сузуын ишетүдән мәхрүм калды. Сәрия апа, соңыннан күпме генә баш ватмасын, банканың ватылу серен тәки белә алмады, чөнки без үзебезне партизаннарча тоттык: Әминәне сатмадык.

Үзебез манма су булып, иртәгәсен көн буе келәм юганда, Әминә, тирәбездә тулганып, «Майны кем түкте?» дип, бездән допрос алып изалады изалавын.

## Әнинең исеме «матурым» яки Әти ничек итеп тычкан тота

Әти белән әни эшкә бармаган көн – минем өчен бәйрәм. Алайса, алар иртән чыгып китәләр, кич арып-талып кайтып керәләр, бер-беребез белән юньләп күрешмибез дә. Көнем гел Саматларда үтә. Тикмәгә генә Сәрия апа, мине эләктереп дуылдатып сөйгән чагында: «Безнең өченче сөягебез бит син, әйме», – димидер, аның кочагыннан ничек ычкынырга белми

тартылганымнан кычкырып көлә-көлә. Ярар, үзләре гаепле. Юкса, мин дә, Самат та башка малайлар шикелле җәйге лагерьга барырга теләгән идек. Әти дә риза иде. Сәрия апа бит... «Әнә урман, әнә су – лагереңны бер якка бәреп ега! Мин көн буе өйдә. Йөрсеннәр шунда күз алдында. Әминәне дә җәйгә бакчага илтмим, абыйлары белән уйнасын рәхәтләнеп», – диде дә мине дә үзләренә «уллыкка» алды да куйды.

Әтинең кайда эшләгәнен әйттемме әле сезгә?.. Юктыр. Чөнки кайда икәнен үзем дә белмим. Бөтенләй үк белмим түгел инде, ул эшләгән оешма өйләргә су кертү белән шөгыльләнә. Ничек гади генә аңлатыйм икән? Әти сөйләвенчә, коелар казыйлар, торба сузалар, шул торбадан суны кешеләрнең өйләренә, мунчаларына тоташтыралар. Аның эш урынында бер дә булганым юк, офислары Казан үзәгендәге биек бер йортның беренче катында урнашканын гына беләм. Әти әйтә, җәй көне урак өсте безнең, тын алырга да вакыт юк, ди. Берәр атнага ял алып булса, Төркиядән булса да урап кайтыр идек, ди. Тугызынчы яшем китте инде, әле минем Төркияне бер дә күргәнем юк! Саматныкы да. Ә менә Илшат абыйның анда булганы бар! Сөйлә әле дип тинтерәтсәк тә, елмая да бер үк сүзне генә кабатлый: «Анда диңгез, анда су күп!» – ди. Хи, су монда да бар инде ул, Ноксага төшәсең дә яланаяк рәхәтләнеп аркылы-торкылы йөрисең...

Әнинең Гөлназ исемле икәнен әйткәнмендер. Ул педи... педи... Юк, балалар врачы түгел... Ничек соң әле... Педикул... Юк, юк... Педикюрист! Әти шулай ди инде, әни генә ошатмый алай диюен. Кызларның, апаларның битләрен, керфекләрен, кул-аяк тырнакларын матурлый торган үзәктә эшли минем әни. Врач шикелле, ак халат, маска киеп! Үзе дә шундый матур ул, гел карап кына торасы килә. Шуңа да әти аңа гел «матурым» дип дәшә, бәләкәй чакта мин әнинең исеме шулай дип уйлый идем.

Шимбә, якшәмбе көннәрендә алар икесе дә ял итәләр, мине бәхет баса! Өчебез бергә булганда, шундый рәхәт! Сәрия апа нинди генә тәмле әйберләр белән сыйламасын, әни пешергән кузгалаклы йә гөмбәле ашка, макаронга йә казылык турап кыздырган йомырка тәбәсенә, әни ясап биргән үләнле чәйгә берни дә җитми! Ул өйдә булган көнне кояш безнең тәрәзәләрдән бөтен бүлмәләргә кереп тула. Ял көннәрендә хәтта Сэм да елмаеп кына йөргән шикелле. Әти әйтә, песиләр елмая да, көлә дә белми ди, белмәс! Сэмның күперенке мыекларына, өскәрәк кайтарылып торган авыз читләренә, шаян кысылган күзләренә чыккан елмаюны ничек күрмәскә була? Ул гөлләргә су сибеп йөргән әнинең аякларына сырпаланып китә, аннан диван аркасына сикереп менә дә телефонын карап утырган әтинең җилкәсенә тәпиләрен куя.

Бу ялда әти ишегалдына атынгыч ясап куярга булды. Тип-тигез итеп кыркылган яшел газон өстендә чәчәк түтәлләреннән башка кыска буйлы ике алмагач кына үсә, шулар арасында селкенеп утырырсыз дип, урынын да билгеләп куйды. Мин дә аның янында тирәләп йөрим: җирдә яткан төрле зурлыктагы тимер торбаларны тоткалап карыйм, әти миңа сварка аппаратының нигә кирәклеге турында сөйли.

Бакча ягына караган тәрәзә ике якка ачылган иде, чебен кермәсен өчен куелган тимер челтәр аша әнинең еламсыраулы тавышы ишетелде:

– Нази-и-и-и-иф!

– Әү, матурым? – Әти, эшен калдырып, тәрәзә буенарак килде.

– Залда тычкан йөри! Кер тизрәк!

– Песи бар бит, тотсын!

– Ке-е-ер, мин куркам! – Әнинең ис... истерикасы башланырга итә иде.

Әти, башын чайкап, кулындагы такта кисәген терраса идәненә куйды да өйгә юнәлде, мин дә, аның мускуллары кабарып торган беләкләренә эчемнән генә соклана-соклана (минем әти нинди көчле!), артыннан атладым.

– Әллә миңгерәүләнгән иде ул – алпан-тилпән йөри, менә моннан, плинтус буеннан кереп китте! – Әнинең сулышы ешайган, маңгае тирләп чыккан, бармаклары сизелер-сизелмәс дерелди.

Әти диван астына иелде, мин песине эзләп чаптым.

– Сэм! Сэм!

Безнең песинең әле бер тапкыр да тычкан тотканы, гомумән, тычкан күргәне юк. Вәт бүген мастер-класс күрсәтсен әле!

Сэм икенче кат идәнендә койрыгын җәеп, ялкау гына йокымсырап ята иде, аны кочаклап, ук шикелле, беренче катка томырылдым.

Анда... идән уртасында кечкенә туп шикелле йоп-йомры тычкан йөри, диван өстенә менеп баскан әнинең күзләре атылып чыгардай булып ачылган, йөзе агарган әти, үз гомерендә беренче тапкыр күргәндәй, идәнгә карап каткан.

– Сэм, давай! Безгә дошман кергән! – Эх, бу хәлне Самат күрми кала инде – шуңа эчем поша иде. Видеога да төшереп җитешеп булмас микән? Песине тычкан өстенә диярлек ыргыттым – ничек каптырганын күрәсем килә иде. Тик песи, утка пешкәндәй чиный-чиный, тычканга түгел, башта диван өстенә, аннан баскычка сикерде. Аның тизлеге белән чагыштырсаң, космоска очып китүче ракета ташбака булып тоелырга мөмкин.

Ул арада тычкан, бу хәлгә исе киткәндәй, юнәлешен үзгәртеп, баскычка таба борылды. Песи, аңын җуйгандай, башта күзләрен йомды, аннан баягыдан да яманрак тизлек белән әллә туп-туры икенче катка ук сикерде инде – секундның кайсыдыр өлешендә бөтенләй күздән югалды. Мин аны эзләп урап төшкәндә, әти дошманны почмакта торган тузан суырткычның таягы белән уңышлы рәвештә юк иткән иде. Их, барысы да шундый коточкыч тиз булды – бер мизгелне дә телефонга төшерергә өлгермәдем.

Әнине тынычландыру тычканны юк итүгә караганда авыррак булып чыкты. Башта ул аякларын идәнгә куярга куркып, диваннан төшмичә утырды.

– Мин куркам! Мин җирәнәм! Мин куркам! – Кара, кайчагында Әминәдән дә уздыра икән минем әни, югыйсә зур бит инде ул. Бәләкәй генә тычканнан ничек куркырга була?

– Өй ишеген ачык калдырып йөрисез дә керә инде ул тычкан, керми нишләсен... – Әти үз батырлыгыннан үзе айнып бетә алмый бугай, нервыланган шикелле.

– Песи булган өйгә тычкан керәмени, кеше көлкесе... – Әнинең тавышы һаман калтырый.

– Шәһәр песиләре үзләре тычканнан курка, күреп торасың... Дүрт стена арасында, дөнья күрми яшәсәң шул инде ул. Бакчага да чыкканы юк бит аның.

– Чыксын, тәпиләрен үзең юып кертәсеңме соң?

– Тәпиен юмасак, идәнне юарбыз.

О-о-ох, башлана... Уч төбе кадәр генә тычкан шундый зу-у-у-ур

сөйләшүгә сәбәпче булсын, имеш. Ул сөйләшү ничек дәвам итәр иде, тик шул минутта капкада домофонга бастылар һәм әти белән әни, авызга су капкандай, кисәк шып булдылар.

– Тиллу-у-у! Тиллу-у-у! Тилу-у-у-у-у-у-у-у-у-у!

– Ур-ра! – Бездә әле видеодомофон булмаса да, урамда Самат басып торганына шигем юк. – Самат килде!

– Агылый белән тагылый... – Әнинең тавышы йомшарды, үзе көлемсерәп куйды, тик идәнгә күз төшерүгә, аякларын тагын да җыебрак диван аркасына елышты.

Мин Саматны каршы алырга чыгып киткәндә, әтинең мәче башлы йөнтәс башмакларны әнигә сузып:

– Мә, матурым, боларны кисәң, бер тычкан да якын килми сиңа, – дип көлгәнен ишетеп калдым.

## Мин кунакка җыенам яки Киткәнче үк өйне сагынам

Без кунакка җыендык. Саматның дәү әтисе белән дәү әнисе Болгар дигән шәһәрдә яши икән. Вәт. Илшат абыйның ялы булгач, атна уртасында шунда кайтырга булганнар.

– Бу ишәй белән кушайны ничек аерасың, – диде Сәрия апа, мине дә үзләре белән ияртергә булып.

Тиз генә план да төзеп куйды: минем әти белән әни дә атна азагында Болгарга барырга, анда кунак булырга, экскурсиядә йөрергә, Идел буенда балык тотарга, көймәдә йөрергә тиеш булды.

– Кит инде, шушыңа тиклем Болгарны бер барып күргәнегез булмасын инде, – дип, аһ-ух килде Сәрия апа, әти белән әнигә уйлап торыр өчен вакыт калдырмыйча. – Чит илгә чыгып чабарга әзерләр, борын төбендәге Болгарга аяк басканнары юк! Андагы тарих соң... Ярар, йөз ишеткәнче бер күрүең хәерле. Киләсез булгач, киләсез!

Ярты елга кунакка китүеммени: кич әни зур кара рюкзакка миңа бер кочак кием тутырды.

– Кинәт салкынайтса, җылы кофтаңны салдым. Яңгыр яуса, алмашка кара кроссовкаңны куям. Футболкаң ярты көнгә дә чыдамый, алыштырып тор... Әллә үзебез белән генә барысыңмы? Кешегә мәшәкать ясап... Ярар, җыенгач, барырсың инде... Әдәпле тот үзеңне. Өйдә чабышып уйнамагыз. Иделдә су Нокса ише түгел, якын килә күрмә... Назиф, әллә ялларда үзебез белән генә барыр микән соң?.. Ярар инде... Тегендә-монда менеп, кулаягыңны сындыра күрмә... Күршедә умарта бар диде Сәрия апаң, корт чага күрмәсен... Калынрак курткаңны да салыйм микән әллә...

Әни әллә миңа әйтә, әллә үз-үзе белән сөйләшә – аңламассың, җавап та көтеп тормый – үзе сөйли, үзе төрә-төрә киемнәрне тутыра. Әти, телефонында кешеләрнең сторисларын карап, ял итеп, диванда яткан җиреннән, башын калкытып-калкытып куя.

– Матурым, кышкы пәлтәсен салырга онытма, яме, – диде ул, бик тә җитди итеп.

– Көлеп ят менә. Ул бүген утыз градус. Хәзер җәйне белеп буламыни – боз да китереп явар, пәлтә дә кирәк булмас димә.

– Улым, армиягә киткәндә, пажалый, әниеңне дә ияртеп барырга туры

килер болай булса... – Әти миңа ни өчендер шелтәлерәк караган шикелле. – Егет бит син, нәрсә кирәк – шуны эләктер дә әллүр кунакка.

– Әнине тыңламаска өйрәтеп ятасыңмы олы башың белән? – Әнинең тавышы башка ноталарга күчә барганы сизелә.

– Тыңламасын димим. Үз башы белән дә уйларга өйрәнсен! Гел әни әзерләгәнне көтеп, әзергә бәзер яши алмас.

– Син гел шулай, киресен әйтмәсәң... – Әни шкафтан алган җылы куртканы кире тыкты, ишегеи шапылдатып япты.

Бәхеткә, аның беренче катта калган телефоны шалтырады да куерырга иткән болытларны шунда ук таратты да куйды. Әти яткан урыныннан торды да, без озын тәнәфестә кыңгырау шалтырауга ашханәгә ничек йөгерсәк, шундый тизлек белән баскычтан аска томырылды:

– Хәзер, матурым, үзем алып менәм, – дигәне инде зал ягыннан ишетелде.

Җәлке, Илшат абый безне, мин күзаллаганча, «КАМАЗ»ында түгел, күп гомерен гаражда үткәргән ак «Рено»сында алып бара булып чыкты. Багажникта, ул әйтмешли, энә төртерлек урын да юк иде: минем зур дигән рюкзак андагы төенчекләр, карбызлар, кавыннар, чиләкләр, самокатлар арасында бәләкәй генә булды да куйды.

Сәрия апа һәр әйберне тотып-барлап, кат-кат тикшереп чыкты.

– Бер капчыкта киптерелгән ипиләр булырга тиеш, салынганмы?

– Самат, калдыр дим бу самокатны, анда иске вилсәпитләр җитәрлек.

– Әминә, кул-аяксыз бу курчакларны нигә дип тутырдың, балакаем?

– Илшат, буш күкәй савытларын тәки алмагансың...

– Булат, синекендә ватыла торган нәрсәләр юкмы?

– «Пятёрочка»га туктап, берәр капчык күмер аласы булыр, сыяр микән...

Юеш салфетка белән руль, бардачок тирәләрен сөртеп маташкан Илшат абый нәкъ минем әти шикелле уфылдап:

– Әйе, Болгарда кибет тә, күмер дә беткән, – дип, авыз эченнән бик әкрен генә мыгырданды.

Әллә каян ишетеп тора Сәрия апа, ярты гәүдәсе белән багажник эченә кереп киткән җиреннән:

– Ярар, алайса, шунда туктарбыз, – дип, тиз генә аның белән ризалашты.

– Сәрия, минем кармакларны тыктыңмы? – Илшат абый, бу юлы кычкырып, шулай дип сорады, тик Сәрия апа аны ишетмәде. – Сиңа әйтәм, кармаклар бармы?

– И-и, анда кармакка урын калмады бит... – Сәрия апа, таза гәүдәсенең бил булырга тиешле урынына ике кулын куеп, Х хәрефенә охшаган аякларын биетеп, аптыраган төстә багажникка карап торды.

– Калмас менә... Дүрт кармакны да өскә генә куй, сынарлык булмасын! – Кара, Илшат абый усал да була белә икән, кычкырмаса да, тавышы белән дә ялт тыңлатырлык. Алар Сәрия апа белән нык охшаган: икесе дә зур гәүдәле, тазалар. Илшат абыйның футболка астыннан, карбыз тыгып куйгандай, корсагы да бүлтәеп тора. «Анысы минем авторитет аның», – ди Илшат абый, безгә күз кысып.

Ниһаять, урнаштырасы әйберләрне җыеп бетерделәр. Без өчәүләп арткы утыргычка кереп чумдык. Уртага, кечкенә кәнәфигә, каеш белән каптырып, Әминәне утырттылар. Башындагы киң кырлы ак эшләпәсе аңа җайлы итеп терәлеп утырырга комачаулый иде, тик әнисе күпме

генә әйтмәсен, тәки салырга ашыкмады кызый. Башын каз шикелле алгарак сузып, эшләпә астыннан әле миңа, әле Саматка карап ала-ала, кукраеп утыруын белде. Илшат абый, машинаны кабызгач, артка борылып:

– Ну, малайлар, кузгалдыкмы? – дип гадәтенчә күз кысты.

– Хе. Мин малай түгел! – диде Әминә, этисенә, шуны да белмисеңмени дигән шикелле, күзләрен зур ачып, шаккатып төбәлеп.

– Кит аннан!.. Кузгалдык, алайса, кызлар! – Монысын янындагы Сәрия апага карап әйтте Илшат абый.

Бистәнең һәр урамы безгә хәерле юл теләп озатып калды. Әти белән әни иртәдән эштә иде, алар ике көннән соң безнең янга кунакка кайтырга тиешлеген белсәм дә, бу минутта кисәк кенә ямансу булып китте. Шар шикелле ак башлы чәчәкләргә күмелгән капка төбеннән, үзебезнең өй яныннан узып барганда, инде хәзер үк эти-әниемне, Сэмны сагынырга өлгерүемне аңлап, эчемнән әллә нәрсә сызылып үтте. Чөнки мин аларны бик ярата идем.

## Казакъстан шәһәр түгел яки Тун кигән кыз карга аулый

Казанны чыкканчы без өчебез дә бер сүз дә сөйләшмичә, тәрәзәдән генә карап бардык. Мондый тынлык Сәрия апага да, Илшат абыйга да бик сәер тоела иде, ахры, тоталар да артка әйләнеп карыйлар, тоталар да карыйлар. Ә без, Самат сул якка, мин уң якка күз текәп, кырыйдан йөгереп үткән биек йортларны, тукталышта басып торган кешеләрне, берсен-берсе уза-уза чабышкан машиналарны күзләп, авызга су кабып кына барабыз. Әминә кузгалып киткәннән бирле әле эшләпәсен, әле аякларындагы кызыл сандалиен рәтләү белән мәшгуль. Шунысы кызык: хәтта ул да дәшми! Ак носкилы аякларына сулын уңга, уңын сулга кигән сандалиларын сала да, инде дөресләдем дип уйлап, янә шул рәвешле киеп куя. Карап-карап тора да тагын сала. Аркылы куелган каеш аңа ныграк иелергә комачаулый, шуңа ул аякларын күтәреп, үзенә якын ук китерә. Нәни бармаклары белән бик тырышып, сандали бавын бер ычкындыра, бер эләктерә.

Юлның бу тирәсе миңа да таныш. Чөнки без Уфага кайтканда, менә шушы автосалон, аннан мәчет, аннан зур кибет яныннан үтәбез. Уфада минем дәү эти белән дәү әни яши. Без анда елга биш-алты тапкыр кайтабыздыр. Үзләре Казанга елга бер-ике килә. «Пенсиягә чыккач, гел сездә генә ятарбыз әле менә. Эштән китеп булмый бит», – диләр. Видео аша сөйләшеп торгач, күрешкән шикелле буладыр инде. Әни белән дәү әни быр-быр-быр сөйләшкәндә, мин кул болгыйм, дәү этигә сәлам дип дәшеп узам – шуның белән шул.

– Булат, кара! – Самат миңа юлның икенче ягында тезелеп торган экскаваторларны күрсәтә икән. Берсенең чүмече һавада асылынып калган, шунда каска кигән абый басып тора.

– Ул нәрсә?

Әминәнең дә теле ачылды.

– Экс-ка-ва-тор, – диде Самат, инде хәзер ком тавы өстендә бөтерелгән тракторга төбәлеп.

– Иска... ик! – фатр – ик!... – Әминәнең үзендә аның кайгысы юк, аны очкылык тота иде.

– Тәк, егетләр, сез ничәнче класска күчтегез әле? – Кызык бу Илшат абый, гел шулай дип сорый, бер дә хәтерендә тотмый.

– Икегә! – дидек без Самат белән икәүләп.

Илшат абыйның көзге аша артка күз ташлаганы күренде.

– Сезнең кебек чакта мин бөтен шәһәр исемен белә идем!

– Бөтенесен, бөтенесенме, әти? Бөтен дөньядагынымы? – Саматның тавышындагы горурлыкны ишетсәгез!

– Бөтенесен дип... нууу... пачти. – Илшат абый, каршыга килгән машиналарның фара яктыртканын күргәч, аларга кул күтәреп рәхмәт әйтеп узды. – Каешларыгыз эләккәнме? ГАИ тора диләр монда... Эләксә шул. Примергә, мин сезгә бер шәһәр исемен әйтәм, шуның соңгы хәрефенә башланган икенче шәһәрне кайсыгыз тизрәк әйтә, ә? Киттекме? Казан!

– Нижнекамск! – Уфага кайтканда, әти бу шәһәрнең төтенен гел телгә ала.

– Маладис, Булат! Йә, Самат улым, синең чират. К хәрефенә?

– Казан...

– Гел Казан булмас инде.

– Киев!

– Кабул иттек. Булат, йә?

– Владивосток!

– Тагын к... Катеринбург!

– Анысы Екатеринбург.

– Казакъстан!

– Нуу, анысы шәһәр түгел, ил... Ярар, икенче имтиханга сез картаны шәпләп өйрәнегез, җәме. Хәзер лутчы, даваегыз, агач исемнәрен. Башлыйм. Каен!

– Нарат.

– Тал.

– Липа.

– Липа татарча түгел бит, юкә була ул.

– Лиана.

Без тәмам кыза-кыза кычкырып кабатлаганны күзен ялт та йолт әле миңа, әле Саматка күчереп күзәткән Әминә дә кысылырга ашыкты:

– Лиана агач түгел, ул минем подружка! – диде, протест белдереп.

– Агач ул, маймыллар сикереп йөри торган. – Саматның үз туксаны туксан.

– Алмагач! – дидем мин бәйгене сүрелдерергә теләмичә.

– Ча... ча...

– Чаган! – диде Сәрия апа. Аннан н хәрефенә башлаган бүтән агач тапмыйча, уенны туктатырга туры килде.

Бераздан без бик озын күренгән күпер буена килеп җиттек. Илшат абыйга укытучы буласы калган: ул гел сорау бирергә ярата. Безнең җавапны да көтми үзе, белмәгәнне аркасы белән дә тоядыр, шунда ук үзе сөйләп тә ташлый.

Әллә кая кадәр җәелгән, көзге кебек ялтырап яткан зуур елгага ымлап:

– Булатның безнең Чулманны күргәне булмагандыр әле, шулаймы? –

диде ул, миңа күзгедән карап. – Татарстанда әллә ничаклы матур җирләр бар, чит илләрең бер якта торсын. Киләсе җәйдә барыгызны төяп, бер күрсәтеп кайтырмын әле. Ятмагыз монда кайда яшәгәнегезне дә белмичә, – диде ул, бу юлы Сәрия апага борылып.

Ләкин Сәрия апа аны ишетмәде, ул «э-э-эфф-фе-е-е», дигән авазлар чыгарып, йокымсырап киткән иде. Әминә дә, эшләпәсе белән йөзен каплап, башын бер якка авыштырып, мес-мес килеп йоклый иде.

Самат белән без исә, Илшат абый сөйләгәннәрне маҗаралы әкият тыңлагандай, авыз ачып тыңлауны белдек.

– Теге якка карагыз әле... – Илшат абый бармагы белән уң якта җәйрәп яткан болын-тугайларга күрсәтте. – Менә анда җәйләрен көтү-көтү атлар йөргән, көтүчеләр бояр кебек: һәрберсенең аягында чигүле читекләр, мин сиңа әйтим, өсләрендә кайры туннар, башларында кеш бүрекләр, маллай...

– Әти-и-и, җәй көне салкын булганмыни, нигә бүрек кигәннәр? – Самат гел шулай акыллы сорау уйлап таба ул, әйтәм бит, нык башлы!

– Юк, бүрекне примергә генә әйтәм. Анысын кыш көне кигәннәр. Болгар бабайларыбыз бик бай яшәгән димәкче булам мин сезгә. Монда бит су юлы буйлап әллә кайсы илләрдән сәүдәгәрләр килгән: Болгардан балык, кеш тиреләре, бал алып киткәннәр.

– Ник, үзләрендә балык юк микәнни? – Ышанып бетмичә, мин дә кысылам. Безнең бәләкәй генә Ноксада да балык булганны, чит илдә нишләп булмасын...

– Болгар балыгы тәмлерәк булгандыр инде... – Илшат абый, алда кыштыр-кыштыр гына барган кызыл машинаны узган мәлендә сүзен өзеп торды, тәрәзәсеннән күз салып: – Хатын-кыздыр дип уйлаган идем аны... – дип мыгырданып куйды. – Ул Болгарның кызларын сөйләдемме әле? – Чибәр икән үзләре, чәчләрен ике якка шәпләп үреп куйганнар. Бәләкәйдән үк ут булып үскәннәр: егетләр кебек ат өстендә чапканнар, уктан атканнар, бер төзәүдә кошның күзенә генә тигерә торган булганнар. Менә моннан атып җибәрсә, безнең капка башына кунган карганы эх тә итми бәреп төшергәндер, маллай.

Байтак еракта калган Казанны, шундагы санап бетергесез йортлар арасыннан Илшат абыйларның капка башын сайлап менеп кунаклаган карганы, шул каргага таба очкан укның бер-ике сәгать буе сызгыра-сызгыра барганын ничек кенә күз алдына китерергә маташсам да, барып чыкмады: хәтта уемда адашып беттем.

– Әти-и, син каян шулай күп беләсең ул? – Самат инде, ник алай дип сорыйдыр. Хәзер әтисе: «Китап укырга кирәк, бөтен нәрсәне белерсез», – дип, шап итеп пичәт сугып куячак.

– Китап укырга кирәк, сез дә белерсез. – Әйттем бит. Үзе кайчан укыйдыр – дальнебойщик руль артында китап тотып йөрми бит инде югыйсә.

Илшат абый безгә шулай дип вәгазь укый башлаганда, минем баш мие, компьютер кебек, «перезагрузка»га китәргә маташа иде, керфекләрне кисәк йокы басты. Күземне йомганда төш күрергә дә өлгердем: өстенә җылы тун, аягына матур читек кигән озын толымлы нindидер кыз, бер кулына ук, икенчесенә аш чүмече тотып, әллә чебен, әллә карга ауларга җыена иде...

## Без акча эшлибез яки Ут белән уйныйбыз

Саматларның дәү әнисе белән дәү әтисе дә шулкадәр матур урында яши икән. Аларның да йорт каршында – урман. Андагы агачлар безнең Нокса буендагыдан күбрәк тә, биегрәк тә. Капка төбенә тау итеп ком китереп бушатканнар, вәт безгә юл төзеп уйнарга шәп бу!

– Булат, Булат кайткан! Кая, тот әле җегетләр кулын! – дип исәнләште минем белән Саматның бабасы. Машинадан төшкәнче, ят кешеләр булгач, оялып торган идем, күзләре көләч елмайган күксел чәчле бабай шулай дип кулымны кысkач, оялу качты.

– Исәнмесез, Фәрит абый! – дип олыларча исәнләшем мин дә, һаман кысып, селкеп торган каты учтан кулымны ычкындырырга теләп. Илшат абый аңа бая «бабай» дип эндәшкәч, мин дә Фәрит бабай дияргә уйлаган идем дә, бер дә карт күренмәгәч, абый диясе иттем. Чапаев абый белән булган сабактан соң олы кешеләргә эндәшкәндә уйлабрак дәшәргә кирәклеген аңлаган кеше бит, ни дисәң дә...

Башына кып-кызыл яулык бәйләгән Нәсимә апа сәлам биреп тормады, Самат белән икебезне бергә кочаклап, шап-шоп итеп аркабыздан гына сөйде. «Менә, ичмаса, эшче куллар кайтты миңа, эшче куллар кайтты», – дип кетер-кетер көлде үзе.

Юл буе йоклап кайткан Әминә капка төбенә килеп туктаганда гына уянган иде, кәефе качкан, ярты битенә шуып төшкән эшләпәсе астыннан турсайган иреннәре күренә. Сәрия апа аны көйләп маташмады, җил-җил атлап, машинадагы әйберләрне бушатырга да тотынды. Кызый бер сүз дәшми генә дәү әнисенең итәгенә башын төртте дә тик басып торуын белде.

– Минем кызымны нинди үгез сөзгән дә нинди чебен тешләгән? Их, мин аны... – дия-дия, Нәсимә апа аның эшләпәсен тагын да аскарак тартып куйды. – Җәтрәк өйгә керегез, мантый гына пешергән идем, әйдәгез, әйдә, суынганчы ашарга кирәк. Дәү әтиегез олы карбыз алган сезгә дип, аның тәмлелеген күрсәгез... чак телемне йотмадым, – дип, безне өйгә әйдәкләде. Ул үзе дә шундый тәмле итеп, кетер-кетер итеп, көйләп сөйләшә икән. Кызык, Сәрия апа ул яктан бер дә әнисенә охшамаган.

«Мантый гына пешердем» дигән иде Нәсимә апа, өстәлдәге тәмлүшкәләрне күрсәгез! Токмачлы шулпа, авыл катыгы, авыл эремчеге, итле бөккән, бәрәңге шәңгәсе, гөбәдия, төрле салатлар, мин исемен белмәгән әллә ниләр, әллә ниләр... Карбызга чират җиткәндә, бер кешенең дә авыз ачарлык хәле калмаган иде. Шулкадәр сыйлады Нәсимә апа, шулкадәр сыйлады, Илшат абый аны: «Әби, син минем Сәриядән дә остарак пешерәсең!» – дип мактаган саен, тәлинкәләргә төрле пирог кисәкләрен өсти генә торды.

Мин сезгә ул көнне кичкә кадәр шул өстәл тирәсендә булашып, әйләнептулганып йөргәнне, урманга кереп, Сәрия апага чәч юар өчен кычыткан җыйганны, ком тавының уртасыннан тоннель ясап уйнаганыбызны, шуннан шуышып йөри тогач, колак тишекләренә кадәр ком тулып, мунчада көчкә юынып чыкканны сөйләп тормыйм, нәрсәсе бар инде.

Ә менә икенче көнне җиң сызганып эшкә чыкканны сөйли алам. Анысы болай булды.

– Бәрәңгене корт басты, агулап та карадык, бетә торган жук булмады,

кияү, – дип зарланды Фәрит абый, умартачыларныкы кебек эшләпәсен җилпәзә урынына йөзе алдында селки-селки.

– Һе... – Илшат абый чигәсен кашып алды. Без баскыч буйлап лапас түбәсенә үрмәләп маташа идек, кулын каш өстенә куеп, безгә дәште. – Малайлар, төшегез әле монда... Акча эшлисегез киләме?

Шәп булыр иде ул! Үз акчаңа туңдырма йә чипсы алып ашауга җитәме соң?!

– Алайса, шул. Менә сезгә боевое задание. Икегезгә ике банка тотасыз. Менә бу паласатый жукларны күрәсезме? Аларны берәмләп банкага җыя барасыз. Һәр пленный өчен лично үзем бер сум түлим. Алдашасы түгел: абизательны һәр кортны берәмләп саныйм! Җыйганда ук санап җыегыз, үзегезгә җайлырак булыр... Без кар базын рәтләп алабыз, эш беткәч, Иделгә балык тотарга аппарам үзегезне!

– Өй базына да тотынган идем әле. Кирпеч җитеп бетми, алып кайтасы бар. – Фәрит абый сүз уңаеннан үзенекен кыстырды.

Безнең шөгыль башта бик җайлы тоелган иде. Фәрит абый биргән перчаткаларын киеп алдык та Самат белән бәрәңге арасына кереп киттек. Перчатка белән булса да, бер дә тотасы килеп тормый икән ул кортларны! Чиркандыра! Шулай да һәр корт өчен бер сум түлибез дип торганда, шабашкадан баш тартасы да килми...

– Бррр! Әйдә, лутчы яфрагы белән генә өзәбез дә салабыз! – Самат шулай дигәч, миңа ни – мин кунак. Бер рәттән ул, икенчесеннән мин, күренгән һәр кортны яфрагы белән бергә банкага тутыра барабыз, әле бит буталмыйча санарга да кирәк. Икебез дә кычкырып саный башлаган идек тә, бик тиз җеп очын югалттык.

– 15!

– 17!

– 18 дигән идең бит, ничек унбиш булсын...

– Әй, бутадың...

– Мине дә...

Сөйләшми генә, эчтән генә санарга булдык. Җаен да таптык: ун корт салган саен, рәтнең бер кырыена мин, икенче кырыена Самат яфраклар өзеп куярга булдык. Ун яфрак булса – димәк, йөз корт җыйганбыз! Йөз сум! Вафли тышлысын алсаң, өч туңдырма җитә! Бәләкәй каптагы чипсы алсаң, бишне алырга була!

Кояш болыт артына качып, инде бу кортлардан тәмам гарык булып, яфрактагы кызыл бөҗәкләр күзгә җиләк булып күренә башлаганда, Самат ягында – 31, минекендә 33 яфрак җыелган иде. Сөйләштек-киңәштек тә, икебезнеке дә тигез булсын дип, аның банкасына тагын егерме корт җыеп салдык. Күңелләр күтәрелеп китте: бер көндә өч йөз утыз сум акча эшләп ташла әле син! Иртәгә бакчаның икенче ягын да шулай җиң сызганып чистартып чыксак, 660 сум дигән сүз! Әле кесәгә кермәгән шулкадәр акчаны нәрсәләргә тотарга дип баш ватып, аңа ниләр тиясен исәпләп азапланганда, эшләрен төгәлләп, Фәрит абый белән Илшат абый да безнең янга кереп җитте.

– Кая, карыйк әле, ниләр майтардыгыз икән? У-у-у, монда, кортны гына түгел, бәрәңге сабагын да бетергәнсез түгелме? – Ялангач тәненә кызыл балчык сыланган Илшат абый пыяла банкага шыплап тулган яфракларны күреп, күзен маңгаена менгерде.

– Ярар, кияү, калганы да бик җитәр, аптырама. Син главное җегетләргә зарплата түләргә онытма. – Маладис Фәрит абый, иң кирәклесен искә төшерергә онытмады. Ике кулы белән биленә таянып, бик озаклап бакчага, аннан күк йөзенә карап торды. – Җилләп килергә җыена әле бу...

– Дәү әти, теге ягын иртәгә җыябыз, яме! – диде Самат, аннан банкасын әтисенең кулына сонды. – Әти, сана – 330 корт!

– Да ну!

– Ну да! Булатныкы да – 330!

– Кая, китерегез әле... – Илшат абый ике банканы да үз янына куеп, җиргә иелде, үзе дә әле иелеп, әле як-яклап кортларны санагандай итте. – Арттырасыз бит, 329 гына.

– Юк! Кат-кат санап бардык! 330! – Саматның да, минем дә хаксызлыкка күз йомар хәлебез юк иде.

– 329!

– 330!

– Ә-ә, әнә теге яфрак астындагысын күрми торам. 330! – Ниһаять, Илшат абый бирелде, булдыргансыз дип, безнең кулларны кысты: – Бухгалтер өйдә, зарплатаны түләсен, шеф кушты диярсез, яме.

– Әти, иртәгә йокыдан торгач ук чыгабыз, күбрәк җыярбыз, яме!

Без капкадан чыгып, «бухгалтер» Сәрия апа янына юл тотканда, бакчада калган Фәрит абыйның әкрен генә:

– Кияү, малайларны иртәгә бакчага кертмә инде, бөтен бәрәңгене яфраксыз, безне бәрәңгесез калдыралар бит, – дип пышылдаганын ишетеп алдык. Жәлке, 660 сум эшлибез дип торганда...

Ярар, кулга кергән хезмәт хакы да аз түгел иде. Казанда булсак, без әллә кайчан өске урамдагы «Пятёрочка»га барып, аны ялт кына туздырып кайткан булыр идек тә...

– Монда да кибет бар, сәпит белән мамин барып кайтабыз!

Урман ягыннан сызгырган тавыш белән җил чыкты. Карап торсаң, кызык: биек агачларның иң очында гына калган яшел ботаклары әле бер якка, әле икенче якка селкенә. Каен агачлары да вальс әйләнергә җыенгандай күренә. Кайда гына булса да, урман, су, болытлар, кояш һәрчак матур икән. Хәер, кояш бая без корт җыйганда югалды, күк йөзендә юрганга охшаган күгелҗем болытлар гына йөзеп йөри.

Без Самат белән икәү комлык янына чүгәләп, акчаны кайда, ничек туздыру мәсьәләсен хәл иткәндә, моңарчы өйдә булып күзгә-башка чалынмаган Әминә ике якка киерелеп ачылган тәрәзәдән ярты гәүдәсен асылындырды:

– Мин дә барам!!! – диде ул, каршы килмәслек тавыш белән, авызын очлайтып. Без ни дә булса әйткәнче, акробат шикелле, алгы бакчага әйләнеп тә төште. Хәзер чырыйлап еларга тотыныр дип көткән мәлебездә, тәбәнәк капканы ачып, бер аягына аксаклый-аксаклый, безнең янга чыгып та җитте.

– Кая барасыз? Мин дә барам! – Үзе бер кулы белән тез капкачын тоткан, курчакныкы шикелле кабарып торган ак итәге пычранган. Бөдрә чәчен әллә үзе, әллә әнисе, бик тырышып, кадаклаган шикелле, баш түбәсенә җыеп куйган.

Сәрия апа белән Нәсимә апа иртәдән бирле кыяр тозлыйлар, Әминә алар янында кызык тапмый, күрәсең. Мин аны үзебез белән иярергә каршы түгел идем. Самат кына чыраен сытты:

– Без сәпит белән барабыз, барабыз да тиз генә кайтабыз!

– Мин дә сәпит белән барам!

Әминәнең өч тәгәрмәчле сәпит белән безнең арттан теркелдәвен күзаллау куркынычрак иде. Үзенчә бик тиз барырга тырышса да, ташбакадан әллә ни артык җире юк шул.

Без аңа кибеттән берәр тәмле әйбер алырга вәгъдә биреп, күпме генә үгетләп карасак та, теләгеннән кире кайтырга исәбе күренмәде Әминәнең. Самат хәтта аңа үзенең телефонын биреп торырга да риза иде, «Маша и медведь» мультигын карап утырырсың дип тә юмалады – юк булгач юк. Без кызып-кызып бәхәсләшкән мәлдә ачык тәрәзәдә Нәсимә апаның кетер тавышы ишетелде. Аннан ике бит алмасы алсуланган йөзе дә күренде:

– Кайда йөрисез дип котым очты. Даваегыз, бакчада юныгыз да өйгә керегез. Гарасат килә, зилзилә килә анда, урамда утырмагыз. Хәзер килеп тә җитәр, бәреп тә китәр, Алла сакласын...

Ул шалтыр-шолтыр китереп тәрәзәне япты. Ишегалдында Сәрия апаның:

– Малайлар, кайда сез, марш өйгә! – дип, кыска гына әмер биргәне ишетелде.

Миңа монда бик ошый иде: әллә кайчаннан кунакка кайтып йөргәндәй хис итәм үземне. Беркем дә аһ-ваһ килеп, кыланып, янымда тирәләп тә йөрми, Самат һәм Әминә белән бердәй кабул итәләр, рәхәт.

Халык тыз-быз килгән арада барыбер ялт кына кибеткә барып кайтырга булдык. Гарасат, зилзилә ни ул – яңа кунакларммы, ир белән хатынмы – безгә барыбер иде. Бәреп китәрдәй булгач, бик үк юньле кешеләр булмавы да бар, нәрсә дип аларны көтеп утырыйк... Лутчы Әминәне көтә-көтә баруыбыз...

Капка төбендә чирәмдә яткан сәпитләргә атлангач, безнең кәрван кибеткә юл тотты. Алдан, кибетнең кайда икәнен белгән кеше буларак, Самат җилдерә, уртада – бая гына түбәсенә җыелган чәче кай арададыр тузгып таралган Әминә бар көченә педаль әйләндерә, аның тән сакчысы шикелле, азактан мин барам. Башта урман буен, аннан бер-берсенә тоташкан гаражлар тирәсеннән үттек. Сәпитләрдән төшеп, юлны аркылы чыктык. Янә кузгалып киткәндә, буявы кыршылып беткән яшькелт сәпитнең тәгәрмәч чылбыры, нәрсәдер эләктереме, чыжлаган тавыш чыгарырга тотынды. Бераздан аңа, кайтаваз шикелле, кайдадыр якында гына, күк күкрәгән тавыш кушыла башлады. Күк йөзе кинәт караңгыланып китте. Берән-сәрән яңгыр да тама башлады. Самат тизлеген арттырса да, Әминә шушыннан да ары теркелди алмый иде – хәйран гына калышты. Абыйсына, туктап, көтеп торудан башка чара калмады:

– Ну вот! Әйттек бит иярмә дип!

– Мин арыды-ы-ым... – Әминә төймәдәй күзләре белән абыйсына да, миңа да шулай итеп мөлдерәп карады – аны ачуланып та булмый иде.

– Әнә, теге кызыл түбәле өй артында «Пятёрочка», яп-якын. Мин кышкы каникулда андагы бөтен морожныйны ашап бетердем!

Кайчак шулай арттырырга ярата инде Самат. Туңдырма мәсьәләсендә шыттырса да, якын дип арттырмаган булып чыкты.

Тырыша торгач, кибет буена тәки килеп җиттек. Сәпитләрне ишек төбенә яткырып, кибет ишегеннән керүебез булды, кинәт дөбер-шатыр килеп, кайдадыр нидер ишелде, җимерелде, чытырдады, коеп яңгыр яварга

тотынды. Урамдагы кешеләр, сумкалары белән башларын каплап, берәм-берәм кибет эченә йөгереп керделәр.

Тәрәзәдән караганда, урамда шундый куркыныч тоелды: дөнья караңгыланган, әкәмәт көчле җил чыккан, һавада кәгазьләр, полиэтилен пакетлар, тагын әллә ниләр очып йөри, юлның икенче ягындагы агачлар җиргә тиярдәй булып сыгылып тирбәләләр. Вакыт-вакыт тагын да куркыныч булып китә: башта чытырдап яшен яшьни, күп тә үтми, өстән әллә нәрсәләр тәгәрәп төшкәндәй, күк күкри.

Сөйләшмәсәк тә, өчебездә дә бертөсле уй булгандыр: без хәзер ничек кайтырбыз?.. Самат кесәсендәге кәгазь акчаларны чыгарып, кимемәгәнме дигәндәй, тагын бер кат санап карады. Әминә, тавышын югалткандай, сүзсез генә аның футболка итәгенә ябышып торды. Олыларда безнең кайгы юк иде: кемдер лычма булып, сыену эзләп кибеткә керә, кемдер, алган әйберсен кочаклап, ишек төбенә барып баса да урамга карап тора. Өченчеләре һич исләре китмәгән төстә рәт араларында әйбер караштырып йөри.

Яңгыр туктаганын көткән арада Самат белән мин өчәр туңдырма, икешәр кап чипсы ашарга өлгердек. Әминә шоколадлы туңдырма сайлаган иде, яртысына җиткәндә почмагы кителеп, җебеп, ак футболкасына, ак итәгенә тап-тап коңгырт тамчылар чәчрәде. Җебегән дә инде бу кызлар, кем инде туңдырманы шулай тел очы белән генә, ялап-ялап кына ашасын? Хәзер эреп төшә лә ул. Ялт-йолт – каптың да йоттың, шулай интегеп торырга...

Чипсы ашаганнан соң су эчәсе килә башлады. Без, инде ничәнче тапкырдыр, эчкә кереп киттек, кесәдә әле бераз акча калуы күңелне кымтырыклап тора иде. Нәрсә алырга белмичә байтак сайланып торгач, өчебезгә өч төрле сок алырга һәм бүлешеп эчәргә дип хәл иттек.

Кесәдә, ниһаять, җил уйнап, безнең акча тәмам беткәндә, урамда давыл да беткән, яңгыр да туктаган иде. Әмма, кич булмаса да, урамда караңгы иде. Тирә-якта сынып төшкән агач ботаклары, картон кисәкләре аунап ята, асфальтта чокыр-чокыр сулар җыелып тора. Аһа, сәпит белән чажлап, чәчрәтеп үтәргә шәп булган!

– А-а-а, юешләнгән! – Әминә сәпитенең утыргычын учы белән сөртеп карады да шыңшып куйды. – Мин анда утырмыйм!

– Кибә бит ул, менә кара! – Башта кулым белән, аннан футболка итәген әйләндереп утыргычны сөртсәм дә, кызый киреләнүен белде.

– Утырмагач, бар, җәяүләп кайта тор! Без Булат белән тагын бер җиргә барабыз! – Әһә, Самат та хәйлә капчыгын селкергә өйрәнеп бетте!

– Мин дә барам! – Әминә, итәгендәге тапны кулы белән ышкып, тагын да ныграк таратты да сәпитенә менеп утырды.

– Мин сезгә шундый җир күрсәтәм! – Әллә Саматның экскурсия ясап, миңа Болгарны күрсәтә торасы килә инде? Чөнки тыюлыкка, музейга без минем әтиләр кайткач, зурлап, барыбыз бергә барырга булдык.

Шәһәр дип аталса да, Болгар бер дә Казанга да, Уфага да охшамаган. Монда биек-биек йортлар да, трамвай да, троллейбус та күренми.

Безнең сәпитчеләр кәрваны мондый тизлек белән юеш асфальттан әллә ни ерак китә алмады алуын. Бер урамга борылгач, Самат кулы белән каядыр ымлады:

– О, карагыз!

– Ә ул нәрсә?

Сизеп торам, ул безне һәйкәл күрсәтәм дип алып килмәде, юлыбызда очрагач кына тукталасы итте.

Һәйкәл янында, җирдә, соры матур таш өстендә, йолдыз эчендә ут яна иде. Мондыйны телевизордан күргәнем бар: мәңгелек ут, бер дә сүнми, диләр. Чындыр: шушындый яңгырда да сүнмәгән бит!

– Ух ты! – Әллә Самат үзе дә беренче тапкыр күрә инде, җиргә ыргыткан сәпитенә чак абынмыйча, ут янына чүгәләде. – Монда кыш көне ут янмый иде.

– Абый, ә ул чын утмы? – Әминәнең дә күзләре елтырый.

– Чын инде, яна бит. Эх, безгә чипсы түгел, сосиска аласы калган, пешергән булыр идек...

Шулхәтле туңдырма суктырганнан соң да ничек ашау турында уйлыйсы килә бу Саматның...

Ут шундый матур иде. Йолдыз эченнән ялкынланып-ялкынланып килеп чыга.

– Ә телевизорда мондый ут янында мылтыклы сакчылар тора иде! – дидем мин, беркем юклыкка бераз аптырап.

– Яңгыр яуган да кайтып киткәннәр. – Белдекле төстә шулай диде дә Самат җирдән чыбык-чабык җыеп килде. – Эх, сосиска алган булса-а-ак...

Бу чыбыкларга ут элдерергә теләп, күпме генә тырышсак та, барып чыкмады: юеш булгач, алар без теләгәнчә бенгаль утлары кебек балкып янарга уйламадылар да.

– Абы-ы-ый, минем кайтасы килә! – Әминәнең сабыр савыты тулды, ут белән уйнау аңа артык ошамады.

Без Самат белән, монда иртәгә полный әзерлек белән килергә сүз куешып, кайту ягына борылдык. Кайткан шәйгә Әминәнең тизлеге әкренәйгәннән-әкренәйде, аяклары арыдымы, бермәлне ул педальне әйләндерүдән бөтенләй туктады.

– Без сине бүтән беркая ияртмибез!

– Сытык пәрәмәч булдың инде!

– Әйттекме барма дип?

– Абы-ы-ый, ул ватылды-ы!

Карасак, өч тәгәрмәчле сәпитнең бер педале төшеп калган, кызый ничек кенә тырышмасын, лыч су булган башмагы белән аны әйләндерә алмый иде.

Артка борылып, төшеп калган педальне эзләргә җай булмады – кайдадырерактарак баягыча яшен уты ялтырады. Эре-эре тамчылар белән яңгыр коярга тотынды. Үч иткәндәй, бу юлы инде кибеткә кереп ышыклана торган да түгел – ул артта калды, без юлны чыгып, гаражлар ягына җитеп килә идек. Андый чакта баш тиз эшли үзе: Самат бер кулы белән Әминәне җитәкләп, икенчесе белән сәпитен өстерәп чабарга тотынды, мин дә, бер кул белән үземнең сәпитне, икенчесе белән Әминәнекен эләктереп, алар артыннан йөгердем. Яңгыр шулкадәр котырып ява: чиләкләп-чиләкләп кемдер су коя диярсең. Киң ябалдашлы агач астына кереп посканда, безнең футболкалар сыгып алмалыга әверелгән иде. Шулчак Әминә кычкырып-кычкырып еларга тотынды:

– Минем ашыйсым килә! Минем пес итәсем килә! Мин курка-а-ам! Әнни-и-и!

Башка чакта сеңлесен битәрләргә генә торган Самат бу юлы ачуланмады, аны кочаклап алды:

– Ник куркасың, без бар бит! Яңгыр сиңа тими лә, – дип, аны юатырга тотынды.

– Абый, яшен кайчан бетә? – Әминә чытырдатып күзен йомган икән.

– Вәт куркак! Бетте бит инде ул. – Минем шулай диюем булды, каршыда ут сызыгы киселеп үтте, дөбердәп күк күкрәде. Без өчебез дә бер-беребезгә елыштык. Алда куркыныч торганда, шулай бербөтен булу көч бирә икән – курку хисе кими төште, Әминә үзенең кечкенә учы белән минем кулны кысканда, үземне бөтенләй чын егет итеп тойдым хәтта. Их, минем дә сеңлем булса... Мин һәрчак аның яклаучысы булыр идем. Курыкма дип көч биреп торыр идем. Саклаучы булыр идем...

Шулчак хыялларымнан бүлендем: югара барган яңгыр пәрдәсе аша безнең каршыда гына ак машина күренде. Самат, әллә каян танып:

– О! Әти! – дип агач астыннан йөгереп чыкты, кулларын болгый-болгый, сикерергә тотынды.

Чынлап та, рульдә әтисе иде. Янында Сәрия апа да утырган икән, Илшат абый безне берәм-берәм эләктереп кабинага сонгач кына, Самат белән икебезнең маңгайга Сәрия апаның юан бармагы эләккәч кенә күрдек аны...

– Кеше куркытып, кая югалдыгыз сез, җен балалары?

– Кибеткә бардык. Ыффф.

– Ул телефоныгызны ник үзегез белән алып йөрмисез, ә?

– Төшеп калыр дип курыктык. Ыффф.

– Мин сезгә өйгә керегез димәдемме?

– Дидең. Ыффф.

– Дәү әниегез зилзилә килә, өйдә утырыгыз димәдеме?

– Диде. Ыффф.

Самат белән чиратлашып борын тартабыз. Маңгайга чирткән урын күзне дә кычыттыра.

– Әни, ә ул килдеме? – Самат барыбер батыр йөрәкле инде.

– Кем?

– Кем инде... Зилзилә апа...

– Нинди апа? – Сәрия апа безгә таба борыла. Багажникка безнең сәпитләрне томырып бетергән Илшат абый да машинага утыра, кузгалып китәбез..

– Шул инде. Дәү әни әйткән. Тагын кем абый... Гар... гар...

– Гарасат, – дим мин, искә төшерүемә шатланып.

– Ах сезне, татар балалары! – Сәрия апа көләргә дә, еларга да белми иде бугай, аһылдады, уфылдады. – Соң, давыл «ураган» дигән сүз бит ул, ишеткәнегез юкмыни?

– Бар. Бая дәү әни әйтте. Без аны кешеләр дип уйладык.

– Менә әйтәм бит мин сезгә китап укыгыз дип. Сезнең ул телефоныгыз җүнсезлеккә генә өйрәтә, башсыз гына калдыра. – Илшат абый юеш башын сыйпап, артка борылып, безгә карады, аннан әнисенең алдына сыенып шым гына утырган Әминәгә күз ташлады: – Минем бәләкәй кызымны яңгыр куркытканмы әллә? – диде.

Әминә ялт кына тураеп утырды:

– Мин гел дә курыкмадым! Абый да әйтте, Булат та әйтте, без барында курыкма, әйттеләр. И мин курыкмадым!

– Менә маладис абыйлары! Чын җегетләр шулай була ул, кызлар янында сер биреп тормый! – Илшат абый көзгедән безгә күз кысты. Аның шулай диюен ишеткәч, маңгайдагы бармак эзе дә онытылды.

Соңыннан мыш-мыш килеп багажник юганны, сәпитләрне чистартканны, Нәсимә апаның ике сүзнең берендә: «И балалар, йөрәккәемне табан астына төшердегез бит» – дип кабатлап, безнең тирәли йөргәнен сөйләп торсам, сезгә кызык булмас. Нәрсә инде... Давыл башлангач, ишегалдын, урман буйларын тирәләп, безне эзләгәннәр. Миңа да, Саматка да шалтыратсалар да, безнең телефоннар компьютер өстәлендә җырлап яткан. Машинага утырып, бөтен шәһәр эчен айкап чыкканнар. Ну таптылар бит менә, ерак китмәгән идек лә без... Шунысы кызганыч: һава торышы болай ямьсезләнгәч, Иделгә балык тотарга гына төшеп булмады.

## Ишек белән очып була яки Без урламый гына кирпеч алып кайтабыз

Икенче көн матур башланды. Иртән үк без йоклаган бүлмәгә елмаеп кояш карады. Ачык тәрәзәдән тәмле алма исе кереп тулды. Ишек астыннан, борыннан кытыклап, коймак исе ургылды. Тормас җиреңнән сикереп торырсың. Бүген минем әти белән әни дә кунакка кайтырга тиеш! Кичә, йокларга ятканда, мин әтинең сөтле чәй төсендәге пижамасын, әнинең мәче башлы башмакларын күз алдына китереп, аларны сагынырга өлгерүемне аңладым. Әз генә вакыт үткән югыйсә, ә минем бик тә аларны күрәсем, борынымны терәп, кочакларына сыенасым килә. Югыйсә кунакта бик-бик рәхәт! Шунысы кызык: монда беркем дә тик тормый, гел нәрсә дә булса эшләп йөри икән. Фәрит абый белән Илшат абый өйгә ашарга гына керәләр. Нәсимә апа: «Кияү бар чагында моны төзәтеп куегыз, тегесен менгерегез, монысын төшерегез» – дип, аларга һаман эш табып тора. Сәрия апа яшелчә тозлый, варенье ясый, ашарга пешерә, палас юа – ул да бөтерелеп кенә тора. «Әни янына сыйланырга гына кайтмыйлар инде», – дип көлә үзе. Нәсимә апа мунча яга, ит турый, күршеләренә кереп чыга – аның утырып торганы бөтенләй күренми. Без дә уйнап кына йөрмибез: корт чүпләргә бүтән чыгармасалар да, Самат белән помидор сабакларын бәйләдек, мичкәләргә су агыздык, ярылган утынны матур итеп өеп куйдык. Монда телефон тотып утырасы килми: урамда да бик рәхәт. Әминәгә тиклем, аякларына чалыштырып кигән сандалиларын салып тормый гына өйдән урап чыга да, кечкенә чиләккә су салып, баскычны юып алган була.

Гел эшләп кенә торалар икән дип уйлый күрмәгез тагын! Урманга кереп, качышлы уйныйбыз; ком тавында без ясаган машина юлларын, күперләрне күрсәгез! Тагын бер яңа уен таптык: бакча янындагы лапас түбәсендә үзебезгә штаб ясадык. Бик биек түгел ул, Әминә дә баскычтан үзе менеп төшә. Без уенчык автоматларны шунда яшердек, пластик шешәләрдән бинокль ясадык. Әминә өйдән чынаяк, тәлинкәләр, киптерелгән кырлыган яфраклары алып чыкты. «Иван чәй» диде аны Нәсимә апа, алар гел шуны чәй итеп кайнатып эчә икән. Әминә дә, чынаякка яфрак, су салып куя да, без түбәдә шуыша-шуыша разведкадан кайтканда, кояшта җылынып, чәй әзер дә була.

Лапасның зәңгәргә буялган ишеге гел ачык тора, эчтә берни дә юк. Нәсимә апаның тавыклары җәй көне бакча артында, челтәр белән әйләндереп алынган утарда яши икән.

Олылар күрмәгәндә, без бу ишеккә эчке яктан асылынып, чиратлашып, рәхәтләнеп атынабыз. Без дигәч тә, алай да Әминәнең буе җитми анда, җитсә, гел шунда җилфердәп торыр иде. Ул безгә кызыгып карап кына тора.

Саматның чиратында беребез дә көтмәгән хәл булды.

– Әминә, кара, син болай итә алмыйсың! – Самат, маймыл шикелле аяклары белән үрмәли-үрмәли, ишек буйлап менде, аны кырт селкетеп, атынырга тотынды. Мин аның ишек белән бергә ничек итеп һавага очканын, аннан җиргә төшеп утыруын күрми-аңышмый да калдым. Керфек йомып ачкан арада ишек җирдә ята, Самат, тәхеттәге падишаһ шикелле, ишекнең нәкъ уртасында утыра иде.

– Вот это ттрю-ю-ю-ю-юк! – диде Әминә, әллә куркудан, әллә абыйсына соклanудан кисәк кенә русчалап.

Самат үзе, тиз генә ушына килә алмыйча, шул халәтендә утыра бирде. Өйдән чыгып килгән Илшат абый безгә карады да ни сәбәпледер ялт кына кире борылып кереп китте, аннан тагын пәйда булды.

– Аяклы казалар!.. Мин сезне теплица буендагы ишекне сөйрәп килгәнсез дип торам тагын...

Ишек өчен маңгайга эләгә алмый калды, чөнки Илшат абый ишекне торгызып, урынына куярга маташканда, без өчәүләп урманга чыгып сыздык. Саматның терсәге матур гына булып сыдырылуны күрмәмешкә салышсак, ишек маҗарасы шуның белән тәмамланып та өлгерде.

Урманда кулга тәпәчләр тотып, разбойниклар булып чабышып уйнаганда, Әминәнең бармагына шырпы кадалды. Аңа дөнья яңгыратып чырылдарга шул җитә калды. Әллә кайчагында бик оста итеп хәйләли инде ул: авыртмаса да, шулай шәрран яра, аның янында булашуыбызны шундый бер кинәнү белән карап тора. Үз тирәсендә бөтерелеп йөрүебез бик ошый, ахрысы.

– Ал! – Сәрия апаның копиясе бу Әминә, юешләнергә өлгергән керфекләрен челт-мелт китереп, бармагын минем күз төбенә үк күтәреп, әмер бирүен ишетсәгез. Булат та дими, абый да дими. «Ал», имеш... Урта бармагында үзе дә рәхәтләнеп тартып чыгара алырдай шырпы кисәген ә дигәнче юк иттем, кызыйның шунда ук авызы ерылды.

Тәпәчләрне ташлап, урманнан чыктык – яңа шөгыль кирәк иде. Уң як урамда кемдер нидер төзергә җыена, ахрысы: бер-берсе өстенә өелгән цемент капчыклары, такталар, күзне кызыктырырдай аксыл-сары ком тавы, матур итеп тезелгән көрән кирпечләрне күргәч, безнең аяклар шул тарафка атлады.

Ял көне булгангамы, эшләүче кеше заты күренмәде. Ком тирәли башта разведчиклар шикелле әкрен генә урап чыктык. Учка алып, агызып карадык: шундый коры, Сәрия апаның иләгеннән он сибелгән шикелле генә түгелә.

– Әйдә, окоп ясыйбыз! – Самат шулай диюгә, бая ишеккә үрмәләгән җитезлек белән икебез дә ком тавына ташландык. Әминә бер читтә калшаеп утырган, чит-читләре сытылган, төсе җуелган зур чиләкне өстерәп килде: башка уенчык булмагач, шунда йә чәй кайнатырга, йә аш пешерергә җыенуыдыр.

Без тау түбәсен ике кул белән көри-көри шактый зур окоп казып мәш килгәннән соң, бая гына бик матур булып утырган тау күзгә күренеп ямен җуйды: җәлпәкләнеп, шәлперәеп калды. Аны ничектер күркәмрәк кыяфәткә китерәсе иде бит...

Минем күзем капчыклар артында торган мичкәгә төште, тиз генә йөгереп карап та килдем. Мичкәнен яртысында су бар, шәп! Суны безнең окопка ташысак, менә дигән кое булачак!

– Әминә, чиләкне бир, кое ясыйбыз.

– Бирмим, анда пылау пешә.

– Ооо, пешкән инде. Давай, ашыйбыз да аннан су ташыйбыз.

– Кашык юк. – Әминә иренен кыегайтып уйга калды.

– Бар! Менә! – Мин җирдән яфрак өзеп алдым – Нәсимә апа кичә генә бакчада бака яфрагы дип күрсәтте, гел кашыкка охшаган.

– Һе. – Кызый чиләктәге ком, вак таш, яшел үлән, тагын әллә нәрсәләр тутырылган «пылау»га карады. Безнең кашык белән шуа торган түгел шул.

Саматның башы җитте:

– Пылауны кул белән ашыйлар. Менә, кара! – Пылауны учы белән чумырып алды да, ашаган кыяфәт ясап, сеңлесенең кәефен күтәргәннән соң, чиләкне бушатмакчы булды.

– Булат ашамады-ы-ы!

Уф, бу кызларның көен көйләгәнче, эти әйтмешли, чыннан да, чәч агара икән... Ничек кирәк алай Әминә әзерләгән пылаудан авыз итеп, аны юмалап, комны бушатып, мичкәгә барыйк дисәк, чиләкнең төбе ярык икәнне абайладык. Безнең план өзелде.

– Дәү әнинең чиләген алып киләбез! – Саматның ике күзе юеш карлыган шикелле ялтырады.

– Мужыт үзебезнең комлыкта кое ясарбыз? – Минем телдән шул сүз тәгәрәде. Анда су да, чиләк тә бар, ни дип кабат монда килеп йөрергә...

Шулай хәл иттек тә. Нәүмизләнеп калган окопка, боегып янтайган иске чиләккә «пока» дип кайтып китәргә булдык.

Шулчак Самат:

– Дәү эти кичә кирпеч кирәк диде, баз ясарга. Әнә кирпеч! – диде, бармагы белән тип-тигез тезелгән кирпечләргә күрсәтеп.

– А-а-а. Аны машина белән генә апкайтып була!

– Әтинең машинасы бар бит. Пока апкайта торыйк. – Самат кире борылды, эшлекле кыяфәттә ике кулын биленә куеп, өем тирәли урап чыкты. Зәңгәр шакмаклы шортигы кендегеннән аска шуып төшкән дә мәзәк булып түгәрәк корсагы тырпаеп тора. Иртән кигәндә ак булган футболкасы, комда ауный торгач, минеке кебек үк исеме билгесез бер төскә кергән.

Без башта икешәр кирпеч күтәреп кайтмачы идек, ләкин Әминә: «Мин дә апкайтам!» – дип өзми-куймый тинтерәтергә тотынды.

– Авыр ул, күтәрә алмыйсың! – Самат та, мин дә үгетләргә маташтык үзен.

– Күтәрәм! Бир!

Кире кызның кулына берне тоттырдык та, үзебез дә берешәр кирпеч кенә алырга булдык. Чөнки бераз баргач, кызыйның барыбер: «Мин арыдым!» – дип чәрелдисен, аның кирпечен үзебезгә алырга кирәк булачагын чамаладык.

Ни гаҗәп, кирпечне күкрәгенә кысып, мыш-мыш килеп атласа да, маңгаена бөрчек тир бәреп чыгып, әледән-әле борынын тартып барса да, кызый зарланырга ашыкмады. Шулай да ул миңа нишләптер кызганыч тоелды. Булышасым килеп:

– Әминә, давай, мин күтәреп барам, – дип ярдәм кулы сузарга булдым.

– Юк, үзем! – Вәт тискәре бу!

– Әзрәк күтәрәм дә аннан сиңа бирермен.

– Юк, үзем!

Шулай диде дә аһылдап кычкырып та җибәрде. Безнең өчлекнең һәрчак алдында барган Самат, борылып, сеңлесенә карады.

– Как всегда инде!

Кирпеч, Әминәнең кулыннан тәгәрәп, аның аягына килеп төшкән икән. Кызчык, сул аягының бармакларына күрсәтеп, «ы-ы-ы-ы-ы» дип ыңгырашырга тотынды.

– Абы-ы-ый! Авырта-а-а!

– Елама! Әйттек бит сиңа күтәрмә дип.

– Авырта-а-а-а! – Кызчыкның күзләреннән яшь тамчылары бәреп чыкты.

– Басып кара. Атлый аласыңмы? – Саматка доктор булу килешер иде. Ике куллап корсагына терәп барган кирпечне җиргә ыргытты да, иелеп, сеңлесенең бармакларын бик иплəп кенә тотып карады ул.

– Юу-у-у-ук!

– Менә болай итеп барып кара. – Самат сул аягын җирдән сөйрәп, уңына янтаеп, әкрен генә йөреп күрсәтте.

– Авырта-а-а!

Бераз башны эшләткәннән соң, Әминәне күтәреп кайтудан гайре юл юк икәнен аңладык. Аны җиргә утырттык та, сукмактан тайпылып, урман читеннән берәр такта кисәге эзләргә тотындык. Такта булмаса да, юан гына агач ботагы тапкач, сөенечебез эчкә сыймады. Әминәне шунда утыртып, агачны икебез ике яктан тотып кайтырга булдык. Өйгә кайтып җитәлмәгән кирпечләрне сукмак читенә куеп, кире килеп аласы иттек. Ләкин Әминә барында барысы да без теләгәнчә генә буламы соң инде?! Кызый аягына төшкән кирпечне һич кенә дә калдырып китәргә теләмәде, апкайтам дип кочаклап торуын белде. Саматның: «Йә сине калдырабыз, йә кирпечне», – дип ультиматум куюына да һич исе китмәде аның:

– Булат мине дә, кирпечне дә күтәрсен! – дип, сөзеп кенә миңа карап куйды.

Нишлисең... Самат белән икебезне муеннардан кочкан Әминәне таякка утыртып, култык астына кирпечне кыстырып, капка төбенә кайтып җиткәндә, Самат та, мин дә шыбыр суга баткан идек.

Шунысына гына аптырадык, Әминәне әкрен генә җиргә бастыруга, ул:

– Әни, дәү әни, кара, минем аяк авырта, мине күтәреп апкайттылар! – дип сөрән сала-сала, чатыр чабып йөгерә-йөгерә өйгә кереп китте.

– Ну бу Әминә! – Самат аның артыннан йодрык күрсәтергә генә өлгерде.

## Каникулда китап укыйбыз яки Безне видеокамерадан күрәләр

Кирпеч вакыйгасы алай гына үтеп китмәде... Майкасын салып, теплица тирәли нидер эшләп йөргән Илшат абый янына сөенечле хәбәр җиткерергә

кергән идек югыйсә. Бирегә кайтып җитү бәхетенә ирешкән бердәнбер кирпечне күрсәтә-күрсәтә, теге урамда кирпечнең «муре» икәнен бер-беребезне бүлә-бүлә сөйләгәндә, Илшат абыйның йөзе сүрәнләнде.

– Тәк... Өч кирпеч алып кайтмакчы идегез, шулаймы?

– Әйе, сөйләдек бит инде, әти.

Саматның ирене турсайды. Бер сөйләгәнне кат-кат сорый Илшат абый, юкса, ишетеп тора.

– Хуҗасы юк дисез инде.

– Беркем дә юк анда, әти.

– Беркем булмаса... Кеше әйберен алу нәрсә дип атала? Йә, йә... Ник тындыгыз? – Илшат абый күзләрен кысып, гел безнең укытучы Марьвасиловна шикелле, тишәрдәй булып карады.

– Ы-ы-ы.. ну-у-у... – Безнең тел бәйләнде.

– Йә, әйтегез, сез бит башлы малайлар.

– Без бит... өчне генә... – Тагын шыбыр тиргә бата башладык.

– Мин сездән ничәне алдыгыз дип сорамыйм. Кеше әйберен! Рөхсәтсез алу! Нәрсә дип атала дим?

– Это... Это... урлау.

– Димәк, сез караклар булып чыгасыз? – Эх, бу Илшат абый. Әллә кая китереп терәде.

– Юу-у-у-ук... – Самат та, мин дә пошамангa төштек.

– Ничек юк булсын? Сез хуҗасы юк дип, аннан кирпечләрне урлап кайткансыз. Хәзер менә артыгыздан полиция килсә, ни диярсез? Без урламадык, сорамыйча гына алдык диярсезме? Шул урлау булып чыга бит барыбер... Эх сезне... Хәзер, иң башта, алып кайткан кирпечегезне дә, юлда калганнарын да аккурат кына урынына илтеп куясыз. Аннан кайту белән китап шкафыннан Тукайның «Су анасы» әкиятен табып, монда алып чыгасыз, минем янда икегез дә икешәр тапкыр кычкырып укыйсыз! Шылдымы?

– Шылды... – Җәйге каникулда бер дә китап укып утырасы килми иде дә, тик мондый гына җәзага ничек тә түзәргә туры килер. Чыннан да, полиция килеп җитсә...

Кирпечләрне, Саматның әтисе әйткәнчә, аккурат кына урынына илтеп куеп, өйдән матур рәсемле китапны тотып чыкканда, бездә бераз өмет уты бар иде: Илшат абыйның мәрхәмәте килер дә, безгә ике түгел, бер генә тапкыр укырга рөхсәт итәр дип уйлаган идек. Ләкин үз сүзеннән сантиметр да чигенмәде: башта Самат, аннан мин чиратлашып укый торгач, Су анасының алтын тарагын урлап качкан малай турындагы әкиятне дүрт тапкыр тыңлаганыбызны аңладык. Әкиятнең азагын, «Мин дә шуннан андый эшкә кыймый башладым, «Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым» дигән куплетын Илшат абый хәтта җыр итеп җырларга да мәҗбүр итте. Югыйсә хуҗасы юк дип, кеше әйберсенә беркайчан да тияргә ярамаганын болай да аңлаган идек...

Тик... полиция барыбер килде. Без хәтта ачык тәрәзәдән чыгып качарга да өлгермәдек.

Пилмән, тәмле кыстыбый белән сыйланып, аннан бер табак сливаны бөкләп куйганнан соң, караватка авып, Самат белән телефонда уйнап ята идек. Шуның белән мавыкканга инде, капка төбенә машина килеп

туктаганын да күрми калганбыз. Күргән булсак... әнә, бакча ягында да тәрәзә киерелеп ачык тора – тот та сыз шуннан...

– Малайлар! Чыгыгыз әле монда! – Сәрия апаның тавышы безне зал ягына торгызып чыгарса... Ишек төбендә полиция киемендәге бер апа, бер абый басып тора. Алар артында Саматның дәү этисе, дәү әнисе, Илшат абый. Әминә генә күренми.

Бетте баш! Мине төрмәгә алып китсәләр, эти белән әнине күрми калам икән! Алар бит бүген кайтып җитәргә тиешләр. Кайтырлар да, «Булат кайда?» – дип сорарлар. «Аны полиция төрмәгә алып китте», – дияр Нәсимә апа. Әни кычкырып елый башлар, эти кашын җыерып, өстәлгә бармаклары белән тукылдап алыр... Шуларны күзаллап, үземне дә, эти белән әнине дә кызганудан чүттән генә күзгә яшь тулмады. Бигрәк инде, бер кирпеч өчен... Без бит урлыйбыз дип түгел...

– Менә шушылар инде безнең малайлар... – Сәрия апа «безнең» дигәч, эчкә аз гына җылы кереп китте. Мужыт полиция кешеләре үзләре Сәрия ападан куркып, чыгып таярлар әле. Безнең Казанда, әйткәнем бар бит, урамдагы усал Рекс та курка аннан...

– Шулар шул... – Яшь кенә апа, безгә текәлеп карый-карый, зал уртасындагы зур өстәл янына кереп утырды. – Йә, утырыгыз әле сез дә.

Чәй эчәргә җыенгандай, бер якка шушы «кунаклар» утырды, икенче якка Самат белән без чүмәштек. Шулчак, кухнядан кулына карбыз кисәге тотып, Әминә дә килеп чыкты. Карап-карап торды да, карбызлы кулы белән минем футболка җиңенә тотына-тотына, янәшәдәге урындыкка менеп утырды.

Опека органыннан дип, исемнәрен әйтеп таныштырсалар да, ишетсәм дә, мин аларны ишетү белән онытып та җибәрдем. Чөнки уем, һаман эти белән әни кайтканда, үземнең аларны күрә алмаячагым турында гына иде.

– Бик күңелсез хәл, бик күңелсез... Балаларга мәңгелек ут турында мәктәптә дә сөйләп торалар юкса, кай җирләре белән тыңлыйлардыр...

Бер дә кирпеч исе килми әле монда... Безнең колак шомрайды.

Сүзләреннән аңлашылды: баксаң, болар безне кирпеч урлаганга түгел, кичә мәңгелек ут янында чыбык белән уйнаганга эзләп килгәннәр икән!

– Видеокамерада бу балалар ап-ачык күренә, кемгә кунакка кайтканнарын ачыклау кыен булмады...

Без дәшми генә әлегә башны иеп утырабыз, Сәрия апа, безнең янга басып, ипле тавыш белән генә тегеләрне җөпләп-җөпләп тора.

– Йә, малайлар, сез анда нәрсә эшләргә җыенган идегез соң? – Яшь апа алай бик үк усал итеп тә сорамый.

– Чыбык... яна микән... дип карамакчы идек.

– Уйнамакчы идек.

– Сосиска пешермәкче идек, ә безнең сосиска булмады. Вәт! – Әминә чатнатып шулай дигәч, яшь апа башын тотты.

– Ужас!

– Юк инде, малайлар утның чынмы-юкмы икәнен генә тикшермәкче булганнардыр... – Әлегәчә сүзгә кушылмаган абый шулай дигәч, Сәрия апа да: «Шулай, шулай, шулай, шулай», – дип кабатлады.

Безнең исем-фамилияләрне, кайда, кайсы мәктәптә укуыбызны сорашып, бик озаклап безгә дә, олыларга да патр... патриотик тәрбия сәгате үткәргәннән соң гына чыгып китте алар.

Безнең кай җиребезгә нәрсә эләккәнен аңлагансыздыр. Бер генә тапкыр да түгел...

– Нүжәли мәңгелек утның нәрсә икәне турында бер дә сөйләгәннәре юк? – дип, Фәрит абый кайта-кайта сорады. – Вәт замана! Алайса, сез безнең батырлар турында да, кешеләр тынычлыкта яшәсен дип, сугышта үлеп калганнар турында да берни белмисез дигән сүз бит. Үзегез ил сакчылары буласы егетләр!

– Менә, бабай, сиңа эш: оныкларга сөйлә тарих турында. Телефонда утырып, надан кала бит алар болай барса... Безнең дә гомер әллә ничек үтә, балаларның акылы турында уйларга да вакыт тапмыйча... – Илшат абый, башына каты уй төшкән кешедәй, бу юлы бик җитди иде.

## Әти белән әни кайта яки Тавыклар исереп йокыга тала

Бераздан ишегалды гөр килә иде. Минем әти белән әнине дә монда туганнары шикелле кочаклап каршы алдылар.

– Булат безнең малайга әйләнде, шулай булгач, сез дә туган инде, туган, – дип кетер-кетер килде Нәсимә апа, әнине аркасыннан сөеп.

– Тот әле, Назиф энекәш, егетләр кулын, – дип, әтинең кулын озаклап селкеп торды Фәрит абый.

Әти минем колакны угалап күрешкән булды, әни, озак кына җибәрми торып, кочагына сыендырды. Бигрәк инде, әллә-ә-ә-ә кайчаннан күрешмәгән кешеләр шикелле... ну миңа бик рәхәт иде, чын!

Тагын да рәхәте – читлегенә утыртып, Сэмны да алып кайтканнар!

– Чит кешеләргә калдырып булмый, чыгып югалса дип куркам, – дип акланырга маташкан иде әни, Нәсимә апа кул гына селтәде.

– Күңелең киң булса, бөтен нәрсә сыя, бер аптырама, – диде ул. – Читлектә тотма, йөрсен рәхәтләнеп. Песидән ни зыян...

Сезгә сер итеп кенә әйтәм: зыянны күрсәтте инде Сэм күрсәтүен. Зал ягындагы тәрәзә төбенә менеп алоэ гөлен бәреп төшерде. Шкаф түбәсенә сикереп, вай-файны өзеп төште. Фәрит абыйның иске күлмәге тирәсендә иснәнеп йөргәч, шул тирәне юешләп куйды. Раковина янындагы стаканны идәнгә төшереп ватты... Калганнарын әйтеп тормыйм... Олыларның бертуктамый гөр-гөр килеп сөйләшүләре, табын янында озаклап утырулары да сезгә кызык булмас.

Болгар тыюлыгына барырга, аннан Идел буена төшеп, көймәдә йөрергә, шашлык пешерергә дигән пунктлардан торган күңелле кич көтелә иде – барыбыз да шуңа әзерләнеп йөрибез. Безгә мунчада юынып чыгарга, чиста киемнәрне кияргә дигән әмер бирелде. Аһа, чиста кием кигәч, комлыкта аунамаска, лапас түбәсенә менмәскә дигән сүз бит ул. Ә безнең вакыт бар әле, кызлар шикелле, тәти киенеп, кулны тезгә куеп, капка төбендә утыра алмыйбыз ла без!

Бакчада зу-ур тәгәрмәч эчендә яшелчәләргә сибәргә дигән су җылынып тора – башта шунда чыбык йөздереп ярыштык. Бер төрле уен тиз ялкыта бит ул, тагын нишләргә дип торганда, теплица янындагы чиләккә күз төште. Нәсимә апа анда әллә катык, әллә эремчек салып куйган – әчкелтем исе борынны кытыклый.

– Әйдә, тавыкларны ашатабыз!

– Әйдә!

Бакча артындагы тавыкларга Нәсимә апаның беркөн ашарга салганын карап торган идек: шундый кызык ул тавыклар, кыт-кыт дип җимгә ташланалар, үзенең авызында бар килеш, башкасы авызындагысына үреләләр. Ул арада үзенеке җиргә төшә, анысын икенче тавык эләктереп китә. Күзәтеп торсаң, бер тамаша!

Чиләкне икебез бергә тотып, тавыклар янына чыгып киттек. Алар, безне күрүгә, өскә ташланырдай булып чабып килеп тә җиттеләр. Колаклары төшкән иске кәстрүлгә, тагаракка чиләкне чак бушатырга өлгердек. Тавыклар яу шикелле шунда өерелделәр. Бер кабалар да, башкалар күрмәсен дигәндәй, шунда ук читкә торып чабалар. Тагын кәстрүл янына йөгереп киләләр. Кызыл кикрикле, чуар койрыклы әтәч кенә, аларга үз телендә нидер сөйләп, акыл өйрәтергә маташа бугай да, аны ишетүче-тыңлаучы гына юк. Ахыр чиктә әтәч моны үзе дә аңлады, ахры, «кыки, кыки» дия-дия, үзе дә башы белән тагаракка чумды.

Буш чиләкне бакчага, урынына чыгарып куйдык та, яңа кызык эзләп, урамга таба юнәлдек. Тик безне тәрәзә аша Сәрия апаның тавышы куып тотты:

– Юынмадыгызмыни һаман? Марш мунчага!

Без бит тыңлаучан балалар: борылдык та, чиста киемнәрне тотып, юынырга кереп киттек.

Мунчадан чыксак, хикмәт: Нәсимә апа да, Сәрия апа да, култык астына тавык кыстырып, тыз-быз чабышалар – бакча артыннан лапас тирәсенә ташыйлар үзләрен. Тавыклар, үлгән кебек, башларын салындырганнар, тавыш-тыннары юк.

Монда кием пычрату турында уйлап торырга җай юк иде, нәрсә булганын беләсе килеп, без бая гына җырлый-җырлый тамак туйдырып калган тавыклар янына торып чаптык.

Минем әти белән әни дә шунда читтә шаккатып басып торалар, майкасын алдын артка кигән Илшат абый тавыклар тагарагы тирәсендә кайнаша. Ә тавыклар... тавыклар аклы-кызыллы юрган булып, бөтенесе хәрәкәтсез сузылып ятканнар. Бары әтәч кенә, койрыгын әле дерт-дерт селкетеп, әле тамагы тыгылган кешедәй хәлсез гырылдап, сәер итеп бертуктаусыз йөренә. Аның күзе сукырайган бугай, әле бер җиргә килеп бәрелә, әле икенче җиргә.

– Әллә келәткә төлке кереп буганмы үзләрен? – Минем әнинең зәңгәр күзләре шаккатудан зу-ур итеп ачылган.

– Гөлназ, матурым, келәт түгел, утар бу, түбәсе юк, күрәсең бит. – Әти аның биленнән тоткан килеш, әкрен генә колагына шулай диде.

– Сиңа көләргә булсын... – Әни әтигә бераз үпкәле карап куйды.

Ул арада Нәсимә апага ияреп, Фәрит абый да килеп җитте, тавыкларны иелеп-иелеп, тоткалап карады. Иелеп, хәтта тагарактагы без бая китереп салган суны да иснәде әле ул.

– Әбисе! Нәрсә ашаттың тавыкларга?

– Нәрсә, нәрсә... Нәрсә булсын... Көндәгечә, бодай сиптем дә төйгән бәрәңге ашадылар. Хараплар булганнар, әй, суеп та житешмәдек... – Нәсимә апа аһ та ух килә, Фәрит абыйның гына йөзе тыныч күренә. Менә алар Илшат абый белән бер-берсенә карашып алдылар, Илшат абый да иелеп тагаракны иснәде. Нидер уйлап, күзе белән безне эзләп тапты.

– Ташбашлар! Килегез әле! Монда кердегезме бүген?

– Кердек.

– Сезнең эш түгелме?

– Без... ни... ашаттык кына...

– Тәк. Ни салдыгыз монда?

– Чиләктәге катыклы суны. Теплица яныннан.

– Ай Аллам! Памидурларга сибә торган суымнымы? Тавыкларгамы? – Нәсимә апа, бот чабып, тагын аһ-ваһ килүен дәвам итте. – Сабагы нык булсын, памидурлары каралмасын дип, чүпрәсен, катыгын, ачыган сөтен кушып сибә идем...

– Карале, Сәрия, помидорга шулай чүпрә суы сибәләрмени? – Минем әни тавыклар турында онытып, Сәрия ападан помидор турында сорашырга тотынды.

– Булган икән, алайса, хәлләр. – Фәрит абый үз тирәсендә бәрелеп-сугылып йөргән әтәчнең койрыгын эләктереп: – Син маладис, аякта калгансың, үзебезнең брат! – дип, аны мактап алды. – Әбисе, лапаска ташыган тавыкларыңны кире китереп куй, айныгач йөгереп йөрерләр.

– Бу агылый белән тагылый монда кайтып та тынгы бирми икән, – дип, гаепле йөз белән елмайды әни, Нәсимә апага карап. Шул арада миңа каш астыннан гына шелтәле карап куйды.

– Алар ни, явызлык белән түгел бит. Бала-чага барысын каян белеп бетерсен...

## Без шәһри Болгар белән танышабыз яки Фәрит абыйны очкылык тота

Тавык вакыйгасы җил-давылсыз үтте. Әкәмәт тәмле бәлеш белән сыйланганнан соң, без машиналарга утырып, Болгар тыюлыгына экскурсиягә киттек.

Самат белән Әминә монда беренче тапкыр гына түгел бит, алар минем шикелле авыз ачып йөрми. Ә мин шакаттым! Әллә-ә-ә кайчаннан сакланган мавзолейларны, Илшат абый «карандаш» дип күрсәткән биек манараны, музей эчендәге әйберләрне күргәч, иягем бөтенләй муенга төшеп китмәде микән әле.

– Менә безнең элекке бабайлар балыкны шундый кармак белән тоткан. – Илшат абый безгә, пыяла астындагы кармакларны, кызларның иске алкаларын, борынгы бабайларның сугыш коралларын күрсәтә-күрсәтә, әллә нинди маҗаралы хикәятләр сөйләде. Аны мин генә түгел, минем әти белән әни дә авыз ачып тыңлады. Шундый кызык кеше икән бу Илшат абый, шундый күп нәрсәләр белә! Китапны күп укыдым дип чын әйтә инде, алайса. Мин әле аны юрамалый гына, шыттырып кына әйтәдер дип уйлый идем...

Бик озак йөрдек без тыюлыкта. Сакланып калган хәрабәләрнең ташларын тотып карый-карый, кайчандыр, бик күп еллар элек, шушында яшәгән кешеләрне күз алдына китерә-китерә. Ул кешеләр – безнең ерак бабайларыбыз диде Илшат абый. Шушында яшәгәннәр, икмәк үстергәннәр, болын тутырып ат, сарык, сыер көтүләре көткәннәр... Ул чакта ук әллә ниләр уйлап чыгара белгәннәр: шәһәр мунчасына җылы су да, салкын су

да торбалардан килгән, торбалардан чыгып киткән. Шулай дигәч, минем әтинең күзе янарга тотынды, монысы аның өлкәсе бит:

– Шул гасырда ук шундый системаны көйләгәннәрме? Шә-ә-әп! Уйлап чыгара белгәннәр!

– Әйтәм бит, Болгар ханлыгының даны әллә кайларга киткән дим!

– Әти, ә аларда сотовыйлар булганмы?

– Интернет?

Болары безне кызыксындыра. Илшат абый безнең борын очына имән бармагы белән басып ала:

– Юк. Алар китап укыганнар! Шуңа бөтен нәрсәне белгәннәр! Интернет кирәк тә булмаган!

Әминәне җитәкләгән Сәрия апа белән минем әни фотога төшеп мәш киләләр. Таш өстенә дә менеп басалар, кулларын күтәреп тә кыланалар. Үзләре дә бәләкәй бала кебек инде, безне әйткән булалар...

Вәт шәп көн булды бу! Борынгы бабайларыбыз, тарих турында күпме әйбер белдек! Үз күзең белән күргәч, гел галәмәт икән ул, менә монда эчтә әллә нәрсә кымыр-кымыр килә. Музей эчендә без әле зу-ур Коръән китабын да күрдек, анысы турында Илшат абый түгел, экскурсовод апа сөйләде. Болгар шәһәренә ерактан илчеләр килүе хакында да, аннан соң Болгар ханының ислам дине кабул итүе турында да шул апа әйтте. Аннан озак кына Ак мәчет янында йөрдек, шундый матур, әкият илендә кебек! Тирә-ягы чәчәккә күмелгән, уртада кечкенә күл кебек сулык та бар.

Бермәлне колакны иркәләп, моңлы тавыш ишетелә башлады. Азан тавышы, анысын беләм. Казанда күрше урамнан өскә күтәрелсәң, анда җыйнак кына мәчет бар. Тик безнең анда бер дә кергән юк әле. Ә менә азан тавышын гел ишетәбез.

– Бигрәк моңлы әйтә.

– Әйе, тәннәрне чемердәтә.

Безнең әниләр ни өчендер шыпырт кына сөйләшәләр. Әтиләр дә, Фәрит абый да, манара ягыннан килгән тавышны башларын аз гына иеп, тын гына калып тыңлап торалар. Алар сөйләшмәгәч, без дә шаулашырга базмадык: Әминә эшләпәсен ике кулы белән тотып, азан тынганчы күзен манара өстеннән алмады. Мин мәчеткә берән-сәрән кереп барган түбәтәйле абыйларга, яулыклы апаларга карап тордым. Самат кроссовка очы белән аяк астындагы вак ташны тәгәрәтеп изаланды.

Идел буена төшеп көймәдә йөзгәнне, учак ягып бергәләп шашлык ашаганны сөйләп вакытыгызны алмыйм. Шашлыкның тәмле икәнен болай да беләсез, ашаганыгыз бардыр. Бик рәхәт булды. Илшат абый гармун уйнаганда, әти белән матур итеп: «Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, йөзек салды-ы-ым» дип җырладылар. Сәрия апа «Ай былбылым, вай былбылым» дип сузып җибәргәндә, аңа нәкъ шундый ук тавыш белән Нәсимә апа кушылганда, Фәрит абыйны очкылык тота башлады.

Аннары минем әти белән Илшат абый:

> – Без андый малай түгел,
> Без мондый малай түгел.
> Кая барсак та ярыйбыз –
> Күгәргән калай түгел,

– дип такмакладылар.

– Сезнең, ташбашлар, «Әлдермештән Әлмәндәр»не дә караганыгыз юк бит әле.

Илшат абый гармунын тезеннән төшерде дә Самат белән мине җилкәбездән кочты, үзе нигәдер безгә түгел, әтигә эндәште:


– Назиф дус, малайларның телен саклыйсы иде бит, ә. Татар икәннәрен онытмасыннар иде. Менә мин гел юлда, әллә кай чит җирләргә йөрим, үзебезнең татарны очратсаң, йөрәккә май инде, маллай! Рәхәтләнеп үзебезчә, авыз тутырып сөйләшеп җибәрәсең... Кайсыберсе, татар булса да, бер авыз сүз белми, тора инде утын пүләне кебек... Йөрәк әрни андыйларны күреп. Безнең малайларга аңлатасы иде менә шуны...

Сәрия апа аякларын чирәмгә сузып утырган, Әминә аның тезенә башын салып йоклап киткән. Аягын чалыштыргач, ялгыш кигән сандалилары дөрес булып күренә. Сәрия апа аның чәч бөдрәсен бармагына урап, уйнап утыра, үзе: «Иии, йомшаккаем, бәбкәччәем», – дип пышылдый. Минем әни Сәрия апаның иңсәсенә башын куйган да, сәер бер елмаю белән Әминәнең кабартма кебек күперенке кул аркасына карап тора. «Мин дә шундый бер кыз алып кайтыйм микән әллә?» дип уйламый микән? Вәт шәп булыр иде!

Караңгы төшеп, сәйраннан кайтып килгәндә, машинада йоклап китүемне сизми дә калдым. Шундый серле төш күрдем: төшемдә бер кеше дә юк иде. Әле генә без йөргән сукмаклардан, үләннәрнең башын сыйпый-сыйпый, җил йөгерә. Үзе йөгерә, үзе кош, курай, чалгы, тагын әллә нәрсәләр тавышы чыгарып, туган җир, туган тел турында җыр җырлый. Мин ул җырның сүзләрен дә ишетәм, көен дә бик тиз отып алам, кушылып җырларга телим – тик шул арада кисәк кенә ят тавышлар килеп кушыла да әле генә отканымны шул арада онытырга да өлгерәм. Җил үпкәләгән шикелле тына төшә. Ул да булмый, аның көчсезләнгән җырына каяндыр якыннан гына Илшат абый, аннан минем әти, әни, Саматның әнисе, дәү әтисе, дәү әнисе тавышы кушыла, баягы сүзләр дә, җырның көе дә колагыма янә килеп сарыла. Мин, шул авазның татлы тәмен, җанымны иркәләгән аһәңен, назын җуярга теләмичә, иреннәремне тибрәтеп, кабатларга тотынам...

***

Мин бу көйне онытмадым. Казанга кайткач та гел колагымда кайтаваз кебек чыңлап йөрде ул. Менә ике көннән мәктәпкә баргач, җәйне ничек үткәрү турында инша язарга кушсалар, язып мәшәкатьләнгәнче, җырлап кына күрсәтер идем. Яки авыз тутырып сөйләп кенә чыгар идем. Менә, Әминәне көтеп торган арада сезгә кыска гына итеп сөйләдем бит әле. Туярга да җитешмәгәнсездер. Туйдырсам, әллә кайчан бүлдерәгән булыр идегез. Вәт. Ә хәзер Нокса буена, балык тотарга киттек. Вакытны бушка уздырырга без андый малай түгел лә...



Ренат
Харис

# ТАГЫ БЕР СОЮЗНИК

ПОЭМА

*«ПОЗИС» заводы коллективына багышлана*

*У России есть только два союзника – её армия и флот.*
Император Александр III

***

Замана герое эзлим...
Кабат үзгәрде Заман –
күп һөнәрләр дөнья куйды,
фәһемебез дә яңа...
Аллаһ биргән акыл җитми,
ясалма акыл кирәк –
бәлки үлемсезлек серен
ача алырбыз тизрәк...
Пушкиннар һәм Лермонтовлар
заманы күптән узды...
Нидер тагы Җир шарының
төп законнарын бозды.
Онегиннар, Печориннар...
дуэль барьерларында
атышып әверелгәннәр
заман геройларына...
Ата-аналарын саткан
Павлик Морозовлар да,
ил-халыкка үрнәк булып,
эленеп торды диварда...
Бүген заман кансызланды,
үзгәрделәр дуэльләр –
баллистик ракета тотып
барьерга басты илләр...

---

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты; җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Кем соң Замана герое?..
Геройсыз мөмкин түгел –
бишьеллыклар заманында
тәрбияләнгән күңел
эзләнә – охшыйсы килә,
үрнәк, гыйбрәт аласы –
шулар яшәргә өйрәтә
Җирдә адәм баласын.

Кем бүген безнең герой? Кем
чорының хасиятен
туплаган һәм җаныбызны
ияртергә ниятли?

Казан аша Кытайгача
тиз юл салу эшендә
бардыр, күптер безгә үрнәк,
маяк булыр кешеләр.
Нефтьчеләр, төзүчеләр
арасында да күптер.
Ә галимнәрнең акылы
нинди зур, ничек үткер!
Ә балалар безнең нинди?!
Шаккаткыч ич балалар –
хәтта академиклар да
шаклар катып калалар...

Бәлки, һәммәбез геройдыр?!
Җитте! Эзләмим – баста! –
дигән идем, колагымда
рифма туды: Дон-бас-ста...

Рәхмәт, рифма! Мин бит сиңа
тылсымлы көч дип карыйм –
син – автомат патронында
корыдан-коры дары;
синең көч белән пуля-сүз
тизрәк оча ясканып –
кемнедер үлемнән йола,
кемнеңдер ала җанын...

Әйе, әйе, Донбасстадыр!
Юл тотыйм шунда төбәп,
бүген шул иң кешелекле
хисләр тупланган төбәк;
бүген шунда догаларның
көче сыналган урын –
бүген шунда Ватан өчен
хәлиткеч көрәш кыры...
Шунда тартыла күңелем,
шунда ашкына уем...
Бүген шунда – Донбасстадыр –
заманабыз герое...

Военкорр итеп алмаслар –
яшем бит артык олы...
Тәвәккәлләп карыйм мәллә –
барыйм әдипкорр булып!

Чынлап белешеп карадым...
Күндерделәр бармаска...
Гуманитар ярдәм белән
барып кына Донбасска,
янәсе, теләгәнеңне
күреп кайта алмассың,
«бомба төшеп ватып куйса
күзлегең пыяласын»,
анда безнең Буа түгел,
анда, янәсе, хәтәр –
йә өеңә китертерсең
күз яше тулы хәбәр;
янәсе, сиксәнне уздың,
туксаныңны да тутыр –
автомат итеп каләм тот,
өеңдә язып утыр...

«Җиңүне әзерләүчеләр
арасында юкмыни
геройлар?» дигән гади уй
айнытты шундук мине...

Әйе, мин гусар түгелмен –
чәчемдә инде кырау....
Ниятләр киң, ә вакыт тар –
шул йөрәкне яндыра...
Мин Үлемнән курыкмыймын...
Куркам мәшәкатьләүдән –
авыр бит, «икейөзенче
йөк» булып кайтса гәүдәң...
Фатих Кәрим, әнә, ауган
дәһшәтле атакада
каләмнән һәм автоматтан
фашистка ата-ата...
Андый бәхет миңа тимәс...
Беркемгә дә тимәсен –
Җирдә беркем беркемгә дә
«Иртә китте!» димәсен...

Шундый уйлар айкаганда
йөрәгемне, башымны,
котмәгәндә очраттым мин
бик таныш якташымны...

Очрашу сирәк, чөнки ул
Яшел Үзәндә яши...
«Китә казлар»ны[1] укыган...

[1] Р.Харисның МХО уңаеннан язылган поэмасы

Мине кунакка дәште:
– Донбасс якларына бездән
ата казлар китә, – ди, –
ВСУ «леопард»ларын
ватык чүлмәк итә, – ди...
Курск Дугасында алар,
чыгып Т-34тән,
Гудериан танкларын
металл ватыгы иткән...
«Алёша» дигән танктан
шул «ата казлар» чыгып,
дошман бронеколоннасын
тар-мар иттеләр чукып...

«Позис»ны мин суыткычлар
чыгара диеп беләм...
Якташым кызыксындырды
«ата казлар»ы белән...
Чирек гасырдан артык ул –
заводның директоры...
Аны сөйрәп үтә алган
хәтәр корткычлык чорын
Мәскәүдән килгән министр,
теге – сәрхуш – елларны
япмакчы була заводны,
каплап сулыш юлларын,
«Нам пустячки не нужны...» – ди,
гильзага чиртә-чиртә,
мыскыллы елмаю белән
бөтен заводны үртәп...

«Сезгә кирәкмәсә, безгә –
илгә кирәк булачак!» –
диеп, япь-яшь гендиректор
тын алырга юл ача:
тончыга язган цехларның
бугаз төбеннән тишеп,
миенә кислород бирә...
Ул менә шундый кеше!
Бүген дә аның заводы,
ил мәнфәгатен үтәп,
яу кырларында яуланган
җиңүне тәэмин итә...

***

Һәм мин әнә шул заводта...
Тикшерделәр... Керттеләр...
Генеральный директорга
тиз генә белгерттеләр...

Каршылады, смартфонын
колактан ала-ала...
(Нишлисең, хәрби директор
һәрвакыт постта кала)...

«У России союзники –
её Армия и Флот...
плюс ПОЗИС!» дигән шигарьне
укыдым, күңел тулып.
«...ПОЗИС!» дигән өстәмәле
лозунг завод диварын
плакат иткән, иң заманча
мәгънә белән сугарып...
– Патронсыз һәм снарядсыз
армия – исәп кенә,
пушка, танк – металл өеме,
автомат – күсәк кенә,
ә кораблар һәм катерлар
балык тотарга кала, –
диде директор, кулына
снаряд ала-ала, –
император Александр
Өченченең фикерен
без, завод белән җыелып,
ноктасына җиткердек.

***

Өстәмә авторы белән
цехлар буйлап йөрибез:
беребез – хәрби командир,
әдәбикорр – беребез...

Үтергеч корал цехында,
конвейер тасмасында
үрә баскан снарядлар
көяз солдатлар сыман.
– Менә безнең «ата казлар»,
шушындый озын сафта
тәүлек буе бертуктаусыз
агылалар Донбасска...
томшыклары шундый каты –
тишә хәтта корычны.
Безнең һәрбер җиңүле көн
шул «казларга» бурычлы...

Конвейерның як-ягында,
ала алмый күзләрен,
ядрәләрне сыйпап назлый
цехның хатын-кызлары!
Берничә көннән яугирләр,
шиксез, шәһит китәчәк
бандера өерләренең
тетмәләрен тетәчәк...
Конвейердагы ханымнан
мин шаяртып сорадым:
– Артык иркәләмисезме
шушы үлем коралын –
кемнедер үтерәчәк ул,

баласын ятим итеп?..
– Кемнедер түгел, дошманны,
котырган фашист этен, –
диде ханым, кулындагы
«солдатны» сөртә-сөртә, –
дөмексен ул СССРны
оныткан хайван, мөртәт...

Гендиректор да ишетте
ул ханымның сүзләрен.
Аны иңеннән сыйпады...
Юеш иде күзләре…
– Мин дә мәңгелек түгел бит,
эшемнән китәчәкмен,
киткәндә шушы хатыннар
кулларын үбәчәкмен,
күрегезче бармакларын,
тотыгызчы учларын –
скрипачларда да юктыр
мондый бармак очлары,
булса рәссам Бенуада
булыр мондый да күзләр –
аларга күренә хәтта
микрон тирәнлек эз дә! –
диде генераль директор
һәм конвейер кырында
сәнгатьче кебек сөйләде
Бенуалар турында.
Рәссамның улы Николай
Альбертович Бенуа
бу заводны Советларга
бүләк иткән зат булган...

Шартлау тавышы аша да
пушканы бик ерактан
билгели торган җиһазны
Бенуа уйлап тапкан...

Үзем тыңлыйм... Күз алдыма
шагыйрь Дәрдемәнд басты:
ул Советларга тапшырган
иллеләп алтын базын,
гәзит-журналлары белән
типографиясен дә...
Ике мирас та хезмәттә
илнең бүгенгесендә...

***

Һай!.. Бар иде заманалар...
Хәтта уйлау да – язык:
дәүләт серен ятка ачып,
аңны аракыга манчып,
хәрби заводларны ябып,
«челночниклар»га юл сабып,
сөт көтүен суеп иткә,
галимнәрне куып читкә,
үзебезне салып таптап,
чит илнекен генә мактап,
артка чигенеп һәр эштә,
ташламас диеп фәрештә,
дәүләтсез кала яздык!..

Ә директор ышанмаган
бернинди фәрештәгә,
өстән янап торсалар да,
үзенекен эшләгән,
башының, йөрәгенең дә
җиңен иплә сызганып...
Аның хәтере төбендә
яра йөргән сызланып –
Воронежда фашистларга
каршы торган чагында
әтисенең бер аягын
ярчык өзгән чалгыдай...
Фашизмга мәңгелек үч
тотып яши бүген дә...
Үче аның һәр снаряд
гильзасының төбендә...
Капсюль булып береккән ул,
көтә корыч бәргечен –
Исән – Ватан сугышында
корбан булганнар үче!
Бу хис биредә дә яши –
кыздырып тора эчтән,
бөтен заводка, әлбәттә,
гендиректордан күчкән...

***

Тагын бер цехка үттек без...
Ветеран цех... Шаулырак...
«Пустячоклар» чыгарып, ул,
дөбердәп эшләп тора.
Цехка ветераннар кайткан,
ташлап сад-бакчаларын.
Берсе әйтте: – Разве безгә
өйдә ятарга ярый –
заводыбызга һәм илгә
безнең куллар кирәктә?!
Директорыбыз сызгыргач,
килдек ихлас йөрәктән...
«Яратып эшлә эшеңне,
эшләгәнеңне ярат!» –
Бездән калган бу өндәмә
бүген дә тора ярап...
Станок мине ярата,

мин станокны аңлыйм...
Миңа тиздән җитмеш тула.
яратып эшлим, армыйм...

Һәм алар кочаклаштылар
ирләрчә – җыйнак кына...
Гендиректор горур иде –
елмайды тыйнак кына...

– Безнең «казлардан» коткармый
корыч түш, бетон түбә.
Снарядка, боёк булып,
эткәй аягы тибәр, –
өзелгәне, Воронежда
яу кырында калганы,
үлмәс полкның мәңге исән
нәфрәтенә ялганып!.. –
диде директор, орынып
снаряд капсюлына...

Россиянең союзнигы
иде аның кулында. –

«Позис»ка «Алёша» дигән
танкның каһарманы
махсус килгән, рәхмәт әйткән,
олылап завод данын.
Снарядларның берсен үпкән
чыгарып конвейердан,
баласын кочаклагандай
аны кочаклап торган...
– Болар булмаса, – дигән ул, –
пушка кулсыз җиң генә,
снарядлар танкларны
алып бара җиңүгә!..

***

Гендиректорның кулында
җитәкчелек коралы.
Биш минуттан биш минутка
гел чылтырап тора ул.
Казаннан да, Мәскәүдән дә –
төрле-төрле шәһәрдән
йә заводка нидер кирәк,
йә үзләренә ярдәм,
кемне йөри-йөри тыңлый,
ә кайсын – басып үрә –
Верховныйга генералдай:
«Понял! Есть!» – дип бетерә...
Һәм кемгәдер кичекмәстән
тын гына боерык бирә,
күз карашын әллә кая,
ерак-еракка терәп...

Без суыткыч цехларына
кермәдек... Ул болай да
һәр өйдә диярлек, безгә
китереп тора файда.

***

Якташымның чакыруы
максатыма мач килде,
ялкаулана язган күңел
дәртле хискә ач иде –
барып кайттым кунакка мин!
Һәм бик дөрес иткәнмен –
...Плюс «Позис»та аныкланды
эзләгәнем, көткәнем...

Император Александр
Өченченең сүзләре
бүген дә мөһим, бүген дә
мәгънәләрен үзгәртми.

Бу сүзләргә һәр ватандаш,
һәр завод, кертеп өлеш,
«...һәм плюс» дип, үз исемен
өстәп эшләргә тиеш.

Замана герое дигәч...
Заман дулап үзгәрә...
Үзгәреш болгавырында
җиңел герой эзләүләр,
табулары, ләкин кыен,
авыр үрнәк аласы...
Уяу булырга өйрәтә
герой адәм баласын!
Иле белән бер адымлы,
халкы белән бер уйлы
гендиректор плюс «ПОЗИС» –
бүген күңел героем!

Ләкин бер үкенеч калды –
башыма да килмәде –
бер снарядка булса да
теләк яза белмәдем!
Язар идем дога итеп,
үбеп корыч корпусын:
«Җилфердәсен безнең байрак,
дошманныкы хур булсын!»

*19-30 сентябрь, 2024.*
*Казан.*

Нәзифә
Кәримова

# ОЗЫН-ОЗАК ЯЗМЫШЛАР

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

### Инәй янына – Салаватка!

Бервакытны әткәй нәнәй янына Салаватка баруын искә алып сөйләгән иде. Ул елны нәнәйгә 99 тулырга тиеш, һәм ул кызы Салисә белән кияве Батыр абыйларда яши иде. Әткәй болай дип сөйләде: «Инәй бераз сырхаулап тора, күзләре авыртканга башы да сызлый. Мине күргәч, бөтенләй үзгәреп, канатланып китте. Башта, әлбәттә, елап алды. Аның хакында күп еллар элек «Кайгысын да, шатлыгын да яшькә чылата» дип язган идем бер шигыремдә. Тиз тынычланды. Җанланып, шаян сүзләр дә сөйләп алды. Инәй әйтә:

– Ходайга шөкер, әле дә балаларым бар. Сез булмасагыз, мин нәрсә эшләр идем! – Шуннан дәвам итә: – Мине беренче иремә чыкканчы да, Борискин авылыннан тол калып кайткач та, соратучылар байтак булды. Шуларның берсе дә гомерле дә, юньле дә булмады, хәтта балаларыннан да рәт чыкмады».

Әткәй нәнәй турында күп кенә кызыклы нәрсәләр сөйләгән иде: «Инәй әле Борискин авылына Әмин исемле кешегә (Салих абыемның атасы) чыкканчы ук, минем булачак әтиемнең энесе Хафиз аңар яучы җибәргән. Кире какканнар. Инәйнең олыатасы Хафиз (аның да исеме Хафиз булган): «Бирмим, каты кешеләр», – дигән. Бирмәгән. Хафиз үзе инәйгә ошаган югыйсә.

Кыз чакта инәемне Фаттах Шәйхетдиненә сораталар (Сәйфи Кудашның этисе). Ләкин олыатай каршы килә: «Тәнәкәбезне бирмибез. Затлары карак», – ди. Горур карт була ул. Үзләре фәкыйрь, гаиләләре ишле, шулай да күңелләре тартмаган кешегә кызын бирмәгән.

Ире Әмин үлеп, инәй Келәшкә кайткач, аны тагы бер егет сораттыра. Башта килешәләр. Йола буенча егет ягыннан түшәк-ястык китерәләр. (Имеш, кияү белән кәләш башта шушы ястык-түшәктә ятарга тиеш). Инәемнең иң өлкән абыйсы Гали каршы төшә: «Алар әдәпсез нәсел, аракы эчәләр, тәмәке тарталар. Каладан башлары кайтмый», – ди. Бу кешегә дә бирмиләр. Түшәк-ястыкны Миңзифа исемле олы апасы теге адәмнәрнең ихатасына илтеп ташлый. Теге егет бүтән кызга өйләнә, бераздан хатынын ташлап, читкә чыгып китә, әйләнеп кайтмый. Бәрсуәнбаш авылыннан бер ир яучы җибәрә. Исеме Сәрвәй була. Аның хатыны үлгән, балалары булмаган. Ул ике яшьлек Салих агаемны улы итәргә ниятли. Бәлки ул яхшы кеше дә

*Ахыры. Башы 10, 11нче саннарда.*

булгандыр. Олыатаем тагы бирми. «Үз баласы булмаган кеше чит баланы яхшы күрмәс. Кызымны да, оныгымны да бирмим!» – дигән. «Менә шулай итеп, мин ничә язмыштан узып киттем, – диде инәй. – Олыатаең мине синең әниең булыр өчен саклаган икән, улым!»

Энесе яучы җибәрткәннән соң тугыз ел узгач (1915 елда), атаем минем булачак инәемне икенче хатынлыкка сората. Бу олыинәемнең ризалыгы белән эшләнә. Инәемнең әтисе – олыатаем да, аның уллары Гали белән Фатих та каршы килмиләр. «Сафаның байбичәсе фатиха биргәч, күнәмен, Сафа үзе дә күңел ятарлык кеше. Эшлекле. Яманаты чыкмаган», – ди олыатаем.

«Олыатаең ярлы булса да, акыллы иде, фәкыйрь булса да, хөр яшәде», – ди инәем. Инәй кабатлый: «Атаеңа тикле берәүнең хәләл хатыны булдым, биш-алты яучыны кире кактылар, мин атаеңа язган булганмындыр, күрәсең, бүтән язмышларны узып... Әгәр алай булмаса, бу дөньяга шундый улым да килмәгән булыр иде», – дип, мине аркамнан кагып, сөеп ала.

Белеп калыгыз, инәй сөйләгәннәрне сезгә дә җиткерәм дип, әткәй әнисе турында мин белмәгән, ишетмәгән күп нәрсәләрне сөйләде. Инәй сөйләде дип, әткәй дәвам итте: «Атаең белән аның беренче хатыны – олыинәеңнең кече кызы Саимә үпкә чиреннән үлде. Ул тере вакытта ук Саимәнең ире Сәмигулла икенче хатын алды. Бер көнне ул Саимәне безгә китереп ташлаган. Шундый изге күңелле олыинәең әрнүенә, хурлануына чыдамый, авыру кызын яшь кәләшле кияү йортына кире илтеп куя. Ул көнне атаең калада иде. Мин шомырт җыярга киткән идем».

Шомырттан кайткач, инәй чирле Саимә янына бара. Тегесе рәхмәтләрен белдереп, кашмавындагы берәр сумлык ике көмеш тәңкәне үги анасына кисеп бирә. Саимә әйтә: «Син өйдә булсаң, мине монда китермәсләр иде, син җибәрмәс идең», – ди. (Саимә апаның ике кызы була. Берсе Разия исемле, икенчесе – Рәшидә. Анысы бәләкәй чагында ук үлә. Разия апаны мин дә хәтерлим әле. Ул Уфада яшәде, әткәйләргә килеп йөри иде. – *Н.К.*)

Кече инәем елый-елый кайта да көндәшенең аягына егыла. «Рөхсәт ит миңа Саимәне алып кайтырга», – ди. Олыинәем, кече инәйне кочаклап, елый-елый әйтә: «Бар! Рәхмәт сиңа! Бар!» – ди.

18 көннән Саимә вафат була.

Инәем болай диде: «Сәмигулла хәләл көн итмәде, харам көн итте. Үз хатынының әҗәлен 18 көн дә көтмәде ул. Шуңа күрә Тәңре каһәрләде аны. Кешенең әҗәле Ходай кулында, әҗәл көткән кешенең гомере кеше кулында. Чирле кешене рәнҗетү – зур гөнаһ ул».

Мин килгәч, инәй матур күлмәген, үзем чит илдән алып кайтып бүләк иткән матур кофтасын киеп алды. Ашап-эчкәч, күчтәнәчләрне – чәй, лимон, конфет, алмалардан өлеш чыгарып, аларын да өчкә бүлеп төрде дә дус карчыкларына тапшырырга китте. Нинди әйбәт йола! Күчтәнәч бүлешү – шатлык бүлешү, яхшы хәбәр бүлешү ул! Хәбәр шул: улы килгән!

Йөзне узып киткән инәемә
Беркөн шулай мыжып зарланам:
– Көяр кайгым, әйтер казам юк,
Ә шулай да, инәй, мазам юк.

Гамьнән бушап булмый. Ник алай?
Дошман талый, дуслар тарткалай,
Берәү яла яга сүз белән,
Берәү яра сала күз белән.

Минә шулай, инәй, мазам юк –
Хәер, атап әйтер казам юк.
– Зарың шулмы, – ди ул, – исәрем?
Минем бүтәнчәрәк исәбем:
Селкетмиләр бахыр алмагачны
Алмалары бүтән калмагачтын...
1989 ел.

## Тимербулатка әткәй нәсыйхәте

«Сиңа юл биргән кешегә рәхмәт әйт. Югыйсә сине йә тәкәббер, йә ахмак дип уйлаулары мөмкин.

Биргәндә ике куллап бир, алганда берсе дә җитәр. Дөньяң һәрвакыт тулы һәм түгәрәк булыр, күңелең бәйрәм итәр.

Әйтәләр бит: «Мәскәү күз яшьләренә ышанмый!» – диләр. Ә син, дустым минем, кешеләрнең күз яшьләренә ышан, чөнки син Мәскәү түгел.

Сине онытмасыннар дисәң, үзең дә аларны онытма, Әгәр дә сине оныталар икән, аларга үпкәләмә – алар сине холыклары начар, йә булмаса хәтерләре кыска булган өчен онытмаган, димәк, син яхшы эшләрең, тәртибең, сүзләрең белән үзең турында хәтерләтергә оныткансың.

Минем теләгем – Тимербулат кош тотучы булып түгел, җырчы кош булып үссен иде. Җырчы кошларга авыррак булса да».

## Мөфтидә кунакта

Бервакыт әткәй Тимербулат белән икесенең мөфти Тәлгать Таҗетдин белән очрашуы турында сөйләгән иде. Алар сәгатьтән артык сөйләшеп утырганнар. Тимербулат бу әңгәмәне видеога да төшергән. «Сүз асылда ике халык – татар белән башкорт арасындагы мөнәсәбәтләр турында булды, – диде әткәй. – Бу җәһәттән мөфти дә борчыла икән. Бигрәк тә татарларның кыланмышларын гаепли. Башкортлар да алардан ким түгел».

«Мөфти акыллы кеше булып күренә, 44 яшьтә, дүрт баласы бар икән. Бер нәрсә сәеррәк тоелды миңа, – диде әткәй. – Ул безгә бер чынаяк чәй дә тәкъдим итмәде. Мин бит аның кунагы. Яшькә ул минем улымнан да кечерәк. Күрәсең, бу мохиттә кунакка ризык тәкъдим итү йоласы юктыр».

**Мостай әйткән:** «Язучы йөрәгенең кыюсызлыгы – аның талантына хыянәт итүче».

«Әлбәттә, шагыйрьне вакыт тудыра, ләкин ул аны шагыйрьдән тудыра, башка бер нәрсәдән ясамый».

«Мәхәббәт чәчеп, сагыш урдым».

## Кайсын Кулиев

Әткәй Мәскәүдә хастаханәдә ята. Июнь ае булса да, нигәдер көннәр суык, шыксыз тора иде. Шулай бер көнне төштән соң әнкәй, әткәйгә шалтыратып, Кайсын Кулиевның үлеме турында хәбәр иткән. «Трубканы

алгач та, күңел нидер сизенде, үлем хәбәре килә дип уйлап куйдым, – диде әткәй. – Кайсын турында ул хәбәрне көткән идем инде... Акрынлап кына кайгы баса килә, баса килә... Аны җирләргә бара алмыйм инде. Врач та ул сүзләрне ишетүгә кырт кисте.

Ярослов Смеляков үзенең бер шигырендә безне – дүрт шагыйрьне – Кайсын, Рәсүл, Давыт һәм мине – бер арбаның дүрт тәгәрмәче, бер юрганың дүрт дагасы дип язган иде. Бер көпчәк сынды, бер тәгәрмәч читкә тәгәрәде, бер дага очып китте. Без өчәү генә торып калдык.

Җеназасына бара алмадым инде, бәлки азактан үкенергә дә туры килер. Врач та катгый булды, – дип кабатлады әткәй. – Кайсынга исән чагында бик игътибарлы булдым, бу яктан үкенечем юк кебек», – дип, әткәй үзен-үзе тынычландырды шикелле. Ләкин: «Тышта җил, болыт. Эчтә – кайгы-хәсрәт», – дип тә өстәде.

### Тынычланамы соң?!

Кайсын Кулиев Мәскәү хастаханәсендә ятканда, мин дә шалтыратып, хәлен белгәләдем. (Без таныш идек, улы институтка кергән выкытта Илгиз фатирында торган иде. Очрашуларда да күрешергә туры килгәләде.) Бик авыру, көч-хәл белән сөйләшкән Кайсын абый берсендә: «Кымыз эчсәм, хәлем әйбәтләнәчәк дип әйтәләр, Мостай кымыз табып җибәрә алмасмы?» – диде. Әткәйгә ул сүзләрне җиткердем. Әткәй әллә кайсы районнарны айкап, шифаханәләрдән белешеп, көч-хәлгә Шафран районыннан табып, кымыз җибәрде. Кымыз вакыты түгел, февраль ае иде, атлар савылмый дигәннәр. Әткәй кымызны самолёт белән җибәргән, аны Кулиевның улы Эльдар каршы алган. Азмы-күпме булса да, Мәскәүгә килеп җитте, тапшырылды ул кымыз Кайсын абыйга. Шул вакыттан соң әткәй үзе дә Мәскәүгә килде, үзе белән дә кымыз алып килде. «Кайсын бик сөенде!» – дигән иде шул чакта әткәй. Кымызга гына түгел, күрешүләренә сөенгәндер дип уйлыйм. Тик, ни аяныч, әҗәл чире тисә, кымыз гына алып кала алмый икән шул.

Кулиевның хәле бик авырайгач, исән калуына өмет өзелгәчтер инде, аны Мәскәүдән туган ягына – Нальчикка алып китteләр. Кайсын Кулиевны каршыларга бөтен шәһәр, барлык халык урамга чыккан диделәр. Шул вакыт: «Мин үземне соңгы юлга озатуларын, җеназамны үз күзләрем белән күрдем», – дип әйткән ди Кайсын Кулиев.

### Көндәлекләрдән

25.10.91. «РСФСР язучылары ике Союзга бүленде. Һәр артель үз басуын сукалап, үзенекен чәчеп, үз уңышын үзе җыймакчы. Болар барысы да – тилелек, акылсызлык, аңсызлык. Әдәбиятның гомум кыры бар – яхшылык, мәңгелек орлыкларын шунда утыртырга кирәк. Болар – әйтергә кирәк, ике артель генә түгел, усал этләр сагы астында явыз, хакимлеккә сарылучы көтүчеләр иярткән ике сарык көтүе. Тора-бара алар бер-берсе белән үлгәнче сугышырга әзер торган киек җанварларга әвереләчәк. Миңа Мәскәүдән шалтыратып, әле бер, әле икенче көтүгә керергә үгетлиләр. Нишләргә соң миңа, мин бит көтү хайваны да, көтү җанвары да түгел. Үзләре шәхеснең азатлыгы, төркемнәрдән, партия диктатыннан ирекле булу хакында лаф ора, ә үзләре күп төрле группировкаларның берсенә мине дә төртеп кертмәкчеләр. Әгәр бармыйсың икән, син – дошман! Әгәр дә син митингка

барып, анда акырмагансың икән, димәк, син халык мәнфәгатьләрен якламыйсың. Уфадагы «коллегаларым» мондый таләпләрне бер генә тапкыр куймадылар миңа. Кайвакытта күзгә карап: «Халкың өчен син нәрсә эшләдең соң?» – дип тә сорадылар».

23.11.91. «Миңа бик авыр. Чыдый алмаслык. Мин үземнең иҗтимагый, әхлакый идеалларымның хәрабәләре астында калдым. Чыга алырмынмы? Кичә сугыш герое, шагыйрә Юлия Друнинаның үз-үзенә кул салып вафат булуын хәбәр иттеләр. Күрәсең, ул да шул ук хәрабәләр астында калып тапталгандыр».

2.02.92. «Ватаныбыз авырый дип, озак сөйләнделәр. Ә менә бер көнне, декабрь аенда, Белоруссиянең караңгы урманында өч славян юлбасары бер төн эчендә безнең авыру Ватаныбызны буып үтерде.

Замананың хаксыз язасына
Әллә күнде җаным, әллә сүнде.
Утларына төшеп янар идем,
Мин янарлык утлар юк та инде».

02.02.92. Әткәй икенче ай инде Переделкинода. Һәрвакыттагыча Муса Гали белән килгәннәр иде. Яңа башлаган «Кичке табын» дигән әсәре авыррак язылса да, әткәй яхшы гына алдырткан. «Әкренләп языла», – диде. Алар янына Рәсүл Гамзатов та килгән. Бер ай чамасы булам дип әйтте, ди.

«Хәзер инде Рәсүл югарыдагылар гына дәвалана торган җирләргә йөрүдән мәхрүм калган, үзгәргән, – дип сөйләде әткәй. – Күп еллар иҗат йортларына йөргәне юк иде. Азатлыкны тоюдан аның җаны куанганын аңладым. Ул монда үзе. Гади бер шагыйрь – Рәсүл Гамзатов. Безне – минем белән Мусаны күргәч шатланды. Без дә нииндидер яңарып киткән Рәсүл белән күрештек. Төрле дәрәҗәдәге хөкүмәт даирәсендәге хокукларын югалтуы белән ул иреклерәк, югарырак булып тоелды миңа.

Рәсүл белән бергә йөрергә чыгабыз, бильярд уйныйбыз. Шулар гына. Ә ул безгә минем килүне билгелик әле, ди. Элеккечә утыруларны искә төшереп, ым кага. Мусада бер шешә бар-барын, без ул хакта дәшмибез әле. Шулай да кичке аш алдыннан чакырдык Рәсүлне. Ә инде кичке аштан соң ул безне буфетка алып китте, анда бик кыйммәтле (300 сум) француз коньягы саталар икән. Бик кыйммәтле эчемлекләрдән мин рәхәтлек тапмыйм. Андыйлар минем өчен түгел. Рәсүл кыстады, эчерде безгә. Әйтәм бит, бер ләззәтен тапмадым. Шуның өстенә чын коньяк түгел, ясалма булып чыкты, ахры».

Шул көннәрдә шигырь туган:

«Илнең коты киткән бу көннәрдә
Сыгылып төшкән чакта ир бәндәләр,
Харап булмам әле, харап булмам,
Рәсүл белән Муса эргәмдәләр.
Мин инанам, дөньялыкта алар
Чын дуслыкның татып белә татын.
Юкка гына икесе дә алар
Йөретмиләр пәйгамбәрләр атын –
Рәсүл, Муса».

– Бу шигырь кебек нәрсә Рәсүлгә ошап җитмәде, – диде әткәй. Дан иркәләгән Рәсүлебез әллә ике исемне янәшә куйганны килештермәде инде?

Ләкин бер-ике көннән Рәсүл Гамзатов Муса Галигә багышлап үзе дә шигырь язган. Алар өчәүләп ул шигырьне русчага юлга-юл тәрҗемә ясаганнар. Аннан соң Рәсүл Гамзатов әткәйнең «Кысыр уйлар» шигырен авар теленә тәрҗемә иткән. Тәрҗемәне янә русчага күчереп, сүзмә-сүз сөйләп биргән. Муса Галигә багышланган шигырьне дә өчәүләшеп һәр сүзен тикшереп чыкканнар. «Кызыклы лаборатория килеп чыкты. Рәсүл аварчасында кайбер урыннарын үзгәртергә булды», – дип сөйләде каенатай.

## Переделкинода

5.02.92. «Время» программасын карадык, күңелгә ятышлы хәбәрләр юк. Шул ук вакытта Казан кайный. Татарстан халкының тамагына үтәрлек берәр ризык пешерә алырлармы, әллә күбек кенә булып калырмы? Күбек тамак туйдырмый. Бүген Уфадан Марат Шәрипов шалтыратты. Миңа төрки халыклар оешмасының шәрәфле Президенты урынын тәкъдим итте. Ул турыдан- туры: «Безгә байрак кирәк!» – диде. Мин дә турыдан-туры әйттем: «Мин теләсә нинди байрак тегә торган, теләсә нинди төскә буйый торган чүпрәк түгел. Мин беләм, башта гомум төрки булачак, аннан соң инде руска каршы барачак, – дидем. – Минем дә, минем халкымның да руска каршы байрак күтәрерлек сәбәпләре юк», – дидем. Әгәр дә мин шундый хәрәкәтнең президенты булсам, теләсә нинди әтрәк-әләм, котырынган чүп-чар минем артымда, минем исемнән теләсә нинди тузга язмаган нәрсәләр сөйләячәк. Илгиз белән бу хакта телефоннан сөйләшкәндә әйткән идем, ул миңа: «Юкка ризалашмагансың», – диде. Ул бик акыллы булса да, һаман да җәмгыятьнең сөремле иллюзияләре тәэсирендә.

Инде икенче тапкыр сөйләшкәндә, Илгиз минем белән ризалашып: «Әткәй, мин сине аңладым», – диде. (Кызганыч, консерватив әткәйләрне бик соңлап аңлыйлар шул).

Әле генә ишеттем, Воровский урамында (Мәскәүдә), язучы Юрий Бондарев җитәкчелегендә бер төркем рус язучылары Евгений Евтушенконың карачкысын яндырганнар. Гаҗәеп батырлык! Демократлар Россияне яндыра, рус язучылары карачкылар яндыра. Кем нәрсә булдыра, шуны эшли.

...«Кечке табын» әсәре бик авыр бара. Язганым йөрәктән чыкмый, баштан чыга. Рәсүл дә атна буена бары бер шигырь язды. Ул да эш бармый дип зарлана».

## Экстрасенс (көндәлекләрдән)

«...Шушы көннәрдә Переделкинога Рәсүлне карарга дип экстрасенс, ырымчы килгән иде. Рәсүлдән соң миңа керде. Мөлаем гына яшь хатын. Безнең Әминә Аралбаевага (багучы) шул тиклем охшаган! Суйган да каплаган инде! Яше дә шул чама. Сәгать ярым сеанс үткәрде. Кулы башыма тигәч, күңелемә тынычлык кайткандай булды. Көнкүреш ыгы-зыгылары читкә китте. Ырымчы шәмнәр яндырып, ярты сәгать буена миннән зәхмәтләрне куды. Ул миңа кагылса, шәм чытырдый башлый. Кагылмаса, туры итеп, сузылып, тыныч кына яна. Шәмнәрне сүндергәч, куллары белән тагы бик озак эшләде. Азактан балавыз эретеп, кофе калдыгы белән күрәзәлек иткән шикелле мине нык рәнҗетеп, зәхмәт кагылдырган кешенең

кыяфәтен сүрәтләп бирде. Бик таныш кешене күз алдына бастырды. «Күп ирләрнең, бик күп ирләрнең рухына кара сөрем яккан зат – хатын-кыз булып чыга. Ә сезне нык дошман күреп, җаныгызны әрнеткән кеше – ир затыннан», – диде. Янә ул минем башымны тирәләй чолгап алган сфераның (ауранын) төсле сурәтен төшерде. Күпчелек – сары төс. «У вас самая высокая шкала (ступень) духовности», – диде азактан. Гомумән, сәламәтлегемне әйбәт дип тапты. Китәр алдыннан бу әйтеп салды: «Мин кешеләрне дәвалаганда, бик күп көч югалтам. Бик сирәк очракта үземә көч алам. Бүген иртәдән бирле кәефем начар, күңелем төшенке иде. Менә әле сезнең белән шөгыльләнгәннән соң, рухым күтәрелеп, көчем артып китте. Рәхмәт сезгә!»

Шул көннәрдә әткәй, Переделкинога килгәч башлаган «Кичке табын» дигән әсәрен тәмамлаган. Бик авыр языла дип әйтеп килгән иде. Сәбәбен язып бетергәч кенә аңлаган. «Мин бит аңнары чикләнгән, тупас кешеләр турында пьеса язарга дип тотынган идем. Баксаң, мин аларча уйлый белмим икән. Яза барган саен төп персонажларым, үзләренең бик үк фәкыйрь булмаган рухларын ача башладылар, хәтта күңел күркәмлекләрен күрсәттеләр. Тик пьеса барыбер күңелгә ятмый. Илһамсыз көннәргә тап булды ул».

## Гаилә мәзәгенә әверелгән хәл

Илле бишенче еллар тирәсендә була бу хәл. Чишмәдән Келәшкә барышлый әткәй Нажар абый белән Караякуп дигән авылга кымыз алырга керәләр. Анда Сания исемле бер апа эшләгән. Әткәй бу ападан:

– Кымыз бармы? – дип сорый.

– Кымыз бетте, юк, – ди теге апа.

Әткәй янындагы Нажар Нәҗми сүзгә кушыла.

– Якташыгыз, терәлеп торган күршегез – Мостай Кәрим өчен дә юкмыни? – ди.

– Куй, куй, юкны сөйләмә! Мостай Кәрим үзебезнең күз алдында үсте. Күреп тә беләбез, танып та беләбез! – Шуңа өстәп, Сания апа тезеп киткән: – Киләләр дә: «Мин – пракарур, кымыз бир!», «Мин – судья, кымыз бир!» – диләр. Хәзер килеп: «Мин – Мостай Кәрим», – дип, кымыз давайлыклыйсызмы? Мостай Кәримне без...

Шунда кымыз ясый торган җиргә бер яшь егет килеп кергән дә: «Саумысыз, Мостай агай!» – дип, әткәй белән ике куллап күрешкән.

Шуннан соң бу Сания апа аптырап карап торган да әткәйгә ташланган:

– Нигә телең юкмыни соң синең? Нигә башта ук үзең әйтмәдең шуны? Авыз ерып, тик торасың. Телдән язган икән берәү. Үзе язучы иштшу!

Шушы хәлдән соң Сания апа белән әткәйнең дуслыгы күрешкән саен ныгый гына барган.

## Күпердән кем төртте?

Элегрәк шундый гадәт бар иде. Хакимияткә ярамаган кешеләр өстеннән күмәк хат язу, шул хатлар аша аларны фаш итү. Язучылар арасында ул бигрәк тә еш күзәтелгән нәрсә иде. Мәсәлән, Пастернак, Солженицын кебек

күренекле шәхесләрне каралтырга кирәк булганда, хат астында танылган, билгеле кешеләрнең имзалары мондый хатларның саллылыгын күрсәтә иде. Шунысын әйтергә кирәк: Мостай Кәрим беркайчан андый коллектив хатларга үзенең имзасын куймады, кешеләрне каралту, аларга ябырылу кампанияләрендә катнашмады. Андый хатларның авторлары, әткәйне тота алмагач, безгә шалтыратып, аның имзасын алуда ярдәм сорыйлар иде. Ләкин әткәйнең безгә дә алдан әйтеп куйган сүзе бар иде: андый кешеләр өчен сорамагыз да, риза да булмагыз, бер сүздән үк кырт кисегез. Минем андый эшләр белән шөгыльләнмәвемне әйтегез.

Ләкин лаек кешене якларга кирәк булганда, әткәйнең абруе аңар хыянәт итми иде. Күп еллар СССР Язучылар берлегенең идарә әгъзасы булган Мостай Кәримнең абруе коллегалар каршысында гына түгел, ил җитәкчеләре каршында да югары була, аның фикере белән санлашалар. Бер талантлы язучы гадел булмаган җәбергә дучар була, «опала»га эләгә. Аны яклар дип уйлаган дуслары тегеннән читкә борыла. Шул вакытта Мостай Кәрим, мәсьәләнең нәрсәдә икәнлеген аңлатыр өчен, дустын бу гаделсезлектән аралар өчен, партиянең Үзәк комитетына бара. Аны кабул итәләр, тыңлыйлар, ышаналар.

– Ну, син – герой! – диләр аңар соңыннан, шаккатып, кулын кысалар.

– Ярарыгыз инде, нинди герой булыйм мин, намус кушканча эшләдем, шул гына, – ди тыйнак Мостай һәм бер анекдот сөйли: «Елгада бер бала бата башлаган, ди. Күпердә торучылар, ничегрәк итсәң, кайсы яктан сикерсәң, ярдәм итеп була дип, бәхәс куптарганнар. Шунда берәүне күпердән елгага төрткәннәр дә төшергәннәр. Нишләсен, төшкән-төшкән, баланы исән-имин көе судан алып чыгарга мәҗбүр булган».

Шуннан соң Мостай әйтеме килеп чыга: «Героен герой да, күпердән кем төртеп төшерде?»

– Сине беркем дә төртеп төшермәде бит! – диләр союзда.

– Ничек инде төшермәде? Мәскәүләрнең битарафлыгы төртеп төшерде! – дип, бәхәскә нокта куйган әткәй.

**Мостай әйткән:**

«Даһи үтереп, даһи булып булмый.
Патша үтереп, патша булалар,
Бу дөньяда шундый йолалар».
«Зур түрәгә көмеш бирсәң, хуп күрер,
Киңәш бирсәң – төкерер».

## Невзәт Үстүн

Әткәйне 10 елга хәмердән тыелырга этәргеч ясаган бер вакыйга турында искә алып китмәкче булам. Мин әле ул вакытта гаилә әгъзасы түгел, ләкин булачак каенатам белән таныш идем инде.

1968 елда Төркиянең Истанбул шәһәреннән Невзәт Үстүн исемле шагыйрь хатыны Шөкран белән Уфага әткәйләргә кунакка килә. Әткәй боларга Уфаны да, Башкортстанны да бик яхшылап күрсәтә, кунакларның күңелен күрә. Үз машинасында йөртә. Кайтыр юлда Кандракүл буенда туймазылылар бик матур итеп табын оештыра. Әткәй бу турыда үзенә

нисбәтле болай дип язган: «Мин чама белми эчтем бугай». Дачага кайткач, Невзәт белән икәү имән төбендә сөйләшеп утыралар. Невзәт – төрекчә, әткәй татарча сөйләшә. Башкортчага караганда, төрек шагыйре татарчаны җиңелрәк аңлый иде ди әткәй.

«Кунагым борчылып, сүз башлады:

– Турысын әйтәм, дустым, син мине хафага салдың. Күп эчәсең. Үзеңне харап итүең бар. Симонов, Твардовский шулай эшләсәләр дә, әйбәт түгел, әмма борчылуым ул тикле булмас иде. Бөек рус әдәбиятында бөек язучылар күп, әле дә бар алар. Башкорт әдәбиятында синең урының югары, бәлки иң югарысыдыр. Халкың да ярата, үзем күрдем. Үзеңне исраф итәргә синең хакың юк. Руста алар күп, ә башкортта андый байлык юктыр. Кунак хуҗаның өргән этенә дә тел тидерергә тиеш түгел. Мин сиңа йөзгә-йөз килеп әйтәм. Чөнки син минем өчен хуҗа гына түгел, яраткан дустым.

Кунагым шушы гамьнәрен белдерде, хәтта катырак та әйтте бугай. Үзәккә үтәрлек итеп әйтте. Мин кинәт кенә читкә тайпылып куйдым. Әйтерсең өстемә менә шушы йөзьяшәр имән ава башлады. Артык бер сүз дә әйтмәдем. Аңым яктырып киткәндәй булды. Җанымны чәнчү алды. Бу кеше мине нык якын күрмәсә, миңа әче хакыйкатьне әйтеп, үзен газапламас иде болай дип уйладым. Без бу темага кабат кайтмадык. Шулай итеп, мин кунагымнан каты сабак алдым. Ярты ел чамасы узгач, мин үзем өчен «коры закон» кабул иттем. Әлбәттә, Невзәт үгете белән түгел. Ләкин имән төбендә ике сәгать сөйләшеп утыру минем хәтеремә нык сеңде. 10 ел буе бу закон көчендә калды. Шуннан соң инде сабырлыгы өчен нәфесемне сирәк-мирәк кенә сыйлаштыргалый башладым».

Шушы хәлләрдән соң 3 ел вакыт узгач, әткәй ул Төркия язучысы гаиләсе белән Мәскәүдә очраша. Невзәт бәй белән Шөкран ханымның Швециядән кайтып килүләре булган. Кызганычка каршы, әткәйнең бу дуслары, инде Төркиягә кайткач, юл казасына эләгәләр. Невзәт шунда вафат була. Шөкран ханым бик нык имгәнә. Невзәткә әле илле дә тулмаган иде дип ачынып искә алды әткәй.

### Рәсүл Гамзатов

Авар язучысы, шагыйре Рәсүл Гамзатов әткәйнең иң якын дусларының берсе иде. Алар бер-берсенең юбилейларын да калдырмадылар. Мәскәүдә дә еш очрашалар иде. Җор сүзле, талантлы Гамзатов белән кызыклы гына вакыйгалар да булып тора иде. Кайбер кызыкларын әткәй безгә дә сөйли торган иде.

Алар Гамзатов белән 1947 елда яшь язучылар конференциясендә танышканнар. Анда әткәй Михаил Дудин, Кайсын Кулиев белән дә танышкан. Ул конференция аларның барысын да гомерлек дус иткән. Әткәй шагыйрьнең туган якларында да булган, өйләрендә дә аны кунак иткәннәр, ә менә Гамзатов әткәйләрдә бары тик 1969 елда аның юбилеена гына килә алган.

Әткәй шул елны үзе теләп хәмердән баш тарта. Безнең туйда да авызына бернинди исерткеч эчемлек алмады. Ә менә Рәсүлгә әткәйнең бу карары ошамый, әлбәттә, ләкин ул моны бик сиздерми, әткәйне рюмка күтәрергә

үгетләми дә. Ниһаять, Гамзатовның хатыны Патимат үгетли торгач, көннәрдән бер көнне ул да салуын ташлаган.

«Көтмәгәндә, Рәсүлдән телеграмма килеп төште, – дип сөйләде әткәй. – Куркып киттем, бер-бер хәл булдымы дип уйладым. Без аның белән телефоннан аралаша идек, ә монда – телеграмма! Шундый текст: «Җиде көн синең эздән атладым, ә менә сигезенче көнне абаландым да егылдым. Бу сукмак минем өчен түгел икән. Кочам үзеңне, Рәсүл».

Бер мәлне Рәсүл Гамзатов Кремль хастаханәсендә ята иде. Палатада телефоны да бар икән. Әткәй борчылып, моның хәлен белергә шалтырата. Әткәй әйтә, теле көрмәкләнә моның, котым алынды, ләкин тавышы бик көр чыга, ди.

– Нәрсә, тамагың шештеме әллә? – дигән әткәй, борчылып.

– Юк, төшердем, – дип әйтә ди Гамзатов.

– Кем белән? Дусларың килгән идемени?

– Юк.

– Якташларың килдеме әллә?

– Юк.

– Әллә давалаучы врачың беләнме? – дип сораган әткәй, тәмам аптырап. Элегрәк андый хәлләр дә булгалаган.

– Юк.

– Соң?

– Берүзем!

– Берүзең? Япа-ялгызмы?

– Япа-ялгыз.

– Ничек инде ул?

– Минем башка чарам юк иде, – дигән Рәсүл Гамзатов, авыр сулап.

### «Кызыгам сиңа»

Илдә каты үзгәрешләр башлангач, әткәй СССР Югары шурасына депутатлыкка тәкъдим ителсә дә, баш тарта, сайлауларда катнашмый. Беренче тапкыр баш тартуын аны депутатлыкка тәкъдим иткән язучылар пленумда кабул итмиләр. Икенче тапкыр күрсәтелгәч, ул тагы каршы чыгып баш тарта. «Мин инде җитмешне куам. Яшьләрне сайлыйк», – ди. Тора-бара аның белән килешәләр, ризалашалар. Рәсүл Гамзатов Дагыстаннан сайланган, каршы килмәгән. «Югары Советның эше тәртипсез, ыгы-зыгылы, мәгънәсез башланып китте. Оят-әдәп дигән нәрсә юкка чыкты, – дип искә ала әткәй. – Сессия барышында депутатлар талашалар, бер-берсен төрткәлиләр, мыскыл итәләр. Әле шуларның барысын да телевизордан күрсәтеп торалар».

Ара-тирә Рәсүл Гамазатов та күзгә чалынып ала. Ул бу тамашаны авыр кичерә, күрәсең. Бер көнне Рәсүлдән шундый телеграмма килеп төшә:

«Друг мой, ты мудрый человек, завидую тебе. Гамзатов».

**Мостай әйткән:** «Галимнәрен танымаган халыкның зиһене томаланыр, җырчыларын тыңламаган халыкның колагы саңгырауланыр, рәссамнарын тамаша кылмаган халыкның күзе сукыраер, ә шагыйрьләрен санга

сукмаган халыкның зиһене дә томаланыр, колагы да саңгыраулаiныр, күзе дә сукыраер, өстәвенә – йөрәге туңып, бозга әйләнер».

«Без, әлбәттә, «дус сатты» дип әрнибез. Дуслар гына сата да инде ул. Дошман исә ата гына. Дус сатар, дошман атар. Шушы ике арада яшибез инде».

## Кара елан

Әткәй Переделкинода иде. Һәрвакыттагыча Муса Гали белән. Аралашып, сөйләшеп йөрергә, фикер алышырга да бер-берсенә терәк. «Шушы көннәрдә, – дип яза әткәй, – «зур бер тарихи вакыйга» булды. Бирегә мине дошман күргән бер язучы килде. Безнең корпуска, минем астагы бүлмәгә урнашкан. Мусага: «Минем астагы бүлмәгә кара елан урнашты», – дим. «Су торбасы буйлап яки канализация тишегеннән керә күрмәсен, краннарыңны ябып йөр, канализация тишекләренә тычкан агуы куй. Ул агуны иртәгә табып китерермен», – диде Муса. Тычкан агуына гына бирешерме икән ул явыз? Безгә дә сырпаланырга маташа. Күрмибез дә үзен.

Әткәй үзе бу шигырьне «Шаяру» дип атаса да, бирегә бик туры килә дип уйлап куйдым әле:

«Йөрәгемдә җөй таптылар,
Кайчан чатнаган икән?
Мәхәббәт Алласы аңар
Угын атмаган микән?
Врач әйтә: «Бу охшаган
Елан чаккан эзгә, – ди. –
Берәр чак сыенмадымы
Шул хәшәрәт сезгә?» – ди.
Әйе, әйе, хәтерләем:
Чыксам да мин, керсәм дә,
Байтак ел бер кара елан
Уралды гел тирәмдә».

**Мостай әйткән:**

«Берәүләр күмелә кабергә,
Берәүләр күмелә хәтергә».

## Көндәлекләрдән

10.10.80. «Әле Туфанны укып утырдым. Коточкыч хәл бит: дөньяның иң хәвефле көннәрендә татарның ике олы шагыйре – Туфан һәм Җәлил тоткында җәфа чигә. Берсе – немец тоткынында, икенчесе үзебезнең тоткында газаплана. Шушы икәүнең фаҗигасе, бәхетсезлеге татар поэзиясенең бәхетенә килеп чыга. Шушы икәүнең батырлык һәм газап поэзиясе татар әдәбиятына күпме байлык өстәде, зур югарылыкка күтәрде».

20.03.81. «Мин Максим Горький исән чакта яза башладым. Иҗади яшьлегемне Фадеев, Твардовский кабул итте, аннан соң мине Симонов, Гамзатов, Кулиев дус дип таныды. Картлыгымда кемнәр минем фикерләремне уртаклашыр икән?»

**Мостай әйткән:** «Яхшылыкның чиге юк, яманлыкның төбе юк».

## Чит илләргә сәяхәт

Әткәй чит илләргә, бик еш булмаса да, баргалый иде. Ул вакытларда чит илләргә барып кайту үзе бер могҗизага тиң. Әткәй беркайчан да бүләксез кайтмый. Балаларга да үлчәмен туры китереп ала белә иде. Безнең балаларга гына түгел, туганнарын да, аларның балаларын да буш калдырмый иде. Хәтерлим: иң шаккатып кайткан иле Япония булды аның. Әткәй ул вакытта: «Мин беркайчан да «япошка» дигән сүзне әйтмәячәкмен. Алар гаҗәеп милләт икән. Яңа дөнья алардан башланачак», – дип сөйләгән иде. Ул аннан диктофон алып кайтты. Ул әйбернең эштә бик файдасы булды.

1965 елда әткәй Константин Симонов, Радий Фиш белән Кипр, Сүрия, Төркия илләрендә була. Сүриядә Пальмира, Шәм-Шәриф... Шәм-Шәрифнең данлыклы мәчетенә керәләр, Төркиянең Анкара, Истанбул шәһәрләрендә булып, күп төрле билгеле төрек язучылары белән танышып, очрашып кайталар. «Төркиядә батыр кешеләр белән очраштым. Мине күргән өчен генә дә аларны төрмәгә утыртырлар иде, алар безнең яныбызга килде! Мин үземне тикшердем шул чакта. Ә без, чынлап әйткәндә, бәләкәй генә дөреслекне әйтер өчен генә дә шикләнәбез», – дип язган ул.

Алар Истанбул университетында студентлар, журналистлар белән дә очраша. Иң мөһиме – Азиз Несинның кунагы булалар. «Ул мәҗлестә, – дип яза Мостай Кәрим, – Яшәр Кемаль, Орхан Кемаль, Кемаль Тахир, аларның хатыннары һәм яшь язучылар да бар иде. Язучылар союзының җитәкчесе өендә дә булдык. Проектор аппарат ярдәмендә ул безгә өендә Ибраһим Балабан дигән данлыклы рәссамның сурәтләрен күрсәтте». Ибраһим Балабан – Назыйм Хикмәт белән төрмәдә утырган рәссам. Аның иҗаты ул вакытта тыелган була.

Әткәйнең ул язучылар белән дуслыгы гомер буена дәвам итә. Бигрәк тә Азиз Несин белән. Алар әле Мәскәүдә дә очрашалар. 1982 елның декабре. Мостай Кәрим Азия-Африка комитетының утырышында төрекчәдән тәрҗемәче Вера Фионованы күрә, ул аңар: «Азиз Несин Пекин кунакханәсендә тукталды, кичә генә хастаханәдән чыкты», – дип әйтә.

Алар Азиз Несин янына баралар, кочаклашып күрешәләр. «Азизның чәче бөтенләй агарган, аңа бары тик 67 яшь! Үзе нык күренә, – дип яза әткәй. – Нәкъ 17 ел элек, Константин Симонов, Радий Фиш белән Истанбулга килгәч, без турыдан-туры Азиз Несинның өенә юнәлдек. Беренче күрешү. Безне тәбәнәк кенә, зур башлы, кап-кара чәчле кеше каршы алган иде».

Ә инде Мәскәүдәге бу очрашу бик моңсу булган. Азиз Несинны Төркиядә коммунистик пропагандада гаепләгән суд хөкеме көтә икән. Таныш язучылар турында сорашкач, күпләренең инде вафат булуларын да белгән әткәй. Орхан Кемаль – юк, Невзет Үстүн – юк, Сәхабетдин Әйб углы – юк...

Шунда Азиз Несин 1965 елда очрашкан вакытта сөйләмәгән, хәзер инде тарих булып калган бер кызыклы хәлне искә ала.

Төркиягә җыенган өч язучыга Төркия хөкүмәте, аларның Мәскәүдәге илчелеге виза бирми. СССРның Язучылар берлеге Азиз Несинга телеграмма суга, виза алырга ярдәм итүен сорый.

– Телеграмманы алдым да өстәлгә куйдым. Мин нәрсә эшли алам инде, хөкүмәттә кем минем сүзгә колак салсын, – ди Азиз Несин. – Бер көн ята

телеграмма, ике көн ята. Ә минем эч поша. Беркөнне бер иптәшем килде дә телеграмманы күргәч: «Ничектер кыймылдарга кирәк бит инде. Премьер-министр Демирельгә тәгаенләп телеграмма бир!» – диде. Бик исе китәр инде аның дим. Шулай да тәвәккәлләп, мондый телеграмма җибәрдем:

«Безнең илгә Советлар Союзыннан даннары, исемнәре бөтен дөньяга таралган өч язучы – Константин Симонов, Мостай Кәрим, Радий Фиш килергә тиеш. Шуларга Төркия хөкүмәте виза бирми. Илебез йөзенә кара яга торган оят, башбаштаклык бу...» Демирель әйткән: «Бөтен дөньяга даннары таралган ул өч язучыны укып түгел, ишетеп тә белмим. Шулай да виза бирсеннәр. Теге эте (ягъни Азиз Несин) барыбер тынгы бирмәс, туктаусыз өреп, мазаны алыр», – дигән.

Аерылышканда, Азиз Несин әткәйдән: «Төркиядән сиңа нәрсә җибәрим?» – дип сораган. Әткәй: «Имин хәбәр җибәр, башка берни дә кирәкми», – дигән.

Азиз Несин ул вакытта үз акчасына 70 ятимгә балалар йорты салдырган. Җире, мал-туары, яшелчә-җимеш бакчасы да бар. Балалар үз көннәрен үзләре күрә. Несиннан соң да бу йорт үз җае белән яши алачак. Шушы хакта Азиз аларны сагынып сөйләп утырды дигән иде әткәй. «Аерылыштык. Нәрсә көтә аны Ватанында? Үз иленә төрмәгә баргандай кайтып китте», – дип искә алды ул аны.

### Ак пуловер

1988 елның көз айларында без дә Илгиз белән Төркиядә булып кайттык. Ул СССР Язучылар берлегенең Интурист аша оештырган беренче сәяхәте булгандыр. Анда мәскәүлеләр генә түгел, байтак төбәкләрдән дә язучылар бар, 30 кешелек төркем иде ул.

Мәскәүдән Анкарага очтык. Ике атналык сәяхәт Анкарадан башланып китте. Без күп төрле шәһәрләрдә булдык: Сәлҗүкләрнең эзләре калган Урта Анадолуда, Диңгезледә, Пәри бажалары дип аталган кызыклы урыннары белән дан тоткан Каппадокиядә, Памуккаледа, тагы бик күп шәһәрләрдә. Октябрь ае булуга карамастан, яр буенда мамык шәлләргә төренеп утырган төрек апаларын шаккатырып, Эгей диңгезендә су коендык! Бигрәк тә истә калганы Конья шәһәре иде. Анда суфый шагыйрь Җәләлетдин Руминың төрбәсенә, музеена кердек. Ул төрекләрдә «Мәвләнә» дигән исем белән дә билгеле. Ак киемнәрдән биек фәсле «әйләнә торган» дәрвишләр дә шушы Конья шәһәрендә икән.

Төрбәнең диварына зур хәрефләр белән Руминың шигыре язылган:

> «Кил син, безнең янга кил!
> Мөселманмы син, христианмы, мәҗүсиме –
> Кем булсаң да, кил!
> Безнең динебез өметсезләр дине түгелдер,
> Мең мәртәбә гөнаһ кылсаң да, барыбер кил!»

Бу шигырьне 36 ел элек ничек исемдә калган, шулай яздым. Тәңгәллектә хилафлык тапсагыз, гафу итегез.

Шунысы истә калган: Мәвләнә музее янында әнисе белән җиде яшьләр тирәсендәге бер бала игътибарны җәлеп итте. Без аңар кабы белән Мәскәү конфетларын суздык. Бала нибары бер конфет алды. Аның тәрбияле

булуына шаккаттык. Исемен Нәзиф диде. Шулай итеп, мин, Төркиянең урта гасырларга охшаган борынгы шәһәрендә, ир бала булса да, адашымны очраттым. Ул сәяхәт турында башка сөйләп тормыйм, темам ул түгел.

Без ярты Төркияне иңләдек ул вакытта. Россиядән икәнлекне белгәч, халык «Горбачёв» дип кабатлый-кабатлый, безне яхшы кабул итте. Ни өчен бу сәяхәтне искә алдым: мин ул вакытта чит телләр китапханәсендә эшли идем. Эшләү дәверендә төрек телен өйрәндем. Азиз Несинның хикәяләрен тәрҗемә итә башладым. Ул китапханәдә телләр белгән кешегә өстәмә түләү дә каралган иде, шул да кызыктыргандыр инде. Тел белүем Төркиядә бик ярдәм итте. Мин Истанбул кибетләренең берсендә әткәйгә бик матур пуловер (кофта) сатып алдым. Ул тоташ йоннан, эшләнеше төрекнеке түгел, Англия малы иде. Әткәй бик яратты ул пуловерны. Үлчәме дә туры килде бит! Бик күп фотоларда ул шушы пуловердан. Хәтта Төрекмәнстанда махсус аның фоторәсемен төшереп, келәм сукканнар. Шул келәмдә дә әткәй без Төркиядән алып кайткан ак пуловердан. Без дә әткәй кебек, чит илләргә барсак, бүләксез кайтмый торган идек.

Кызганычка каршы, 1988 елда Төркиягә сәфәрдә без язучылар белән очрашмадык. Интурист безне нык саклады. Аерым, ялгыз йөрмәскә, җирле халык белән сөйләшмәскә һәм башка шундый нәсыйхәтләр булды. Азиз бәй үзе Мәскәүгә килгәч, аның тәрҗемәчесе Вера Фионова белән элемтәгә кереп, очрашу бәхете тәтеде. Ул «Президент» кунакханәсендә тукталган иде. Мине белмәсә дә, очрашырга ризалашты. Без аның белән төрекчә сөйләштек. Минем өчен бу бик зур бәхет иде! Ул тәрҗемәләр өчен рәхмәт әйтте. Тик тәрҗемәләр әле ул вакытта басылып чыкмаган иде. Бары тик 1991 елда гына «Эт койрыгы» дигән китап булып дөнья күрде. Кызганыч, китапны Азиз Несинның кулына тапшыра алмадым. Хикәяләрнең берничәсе Башкортстанда «Һәнәк» журналында басылып чыкты. Азиз Несин ул хакта хәбәрдар иде. Башта «Чаян»га биреп караган идем, әлбәттә, ләкин алар баш тартты. Авторга гонорарны доллар белән түлисе булачак, бездә андый мөмкинлекләр юк диделәр. Берәр айдан соң миңа Азиз Несиннан китаплар белән ике посылка килеп төште. Һәрбер китапта автограф. Бер посылка – әткәйгә, икенчесе минем өчен иде.

### Әткәй мине жәлләде

1984 ел. Чит телләр китапханәсендә эшләгән вакытым. Щепкин училищесында татар студиясе ачылачак икән дигән хәбәр ишеттем. Ишеткәч тә, шунда татар студентларына татар телен укытырга иде дип хыялланып алдым. Шул ук җәйдә Галиәсгар Камал театры Мәскәүгә гастрольләргә килде. Без бер спектакльне дә калдырмыйча карыйбыз, әлбәттә. Кайсы театрда икәнлеге истә калмаган инде. Беркөнне спектакльгә килсәм, бер төркем кешеләр арасында Камал театрының баш режиссёры Марсель Сәлимҗановны күреп алдым да янына килеп исәнләштем. Без бик үк таныш түгел идек аның белән, ләкин очрашкан бар иде.

Марсель абыйга әкрен генә:

– Щепкин училищесында татар студиясе ачыла дип ишеттем, татар теле укытучысы кирәк булса, мин укытырга риза, дипломым бар, – дидем.

Марсель абый миңа җилкәсе аша гына карады да:

– Укытучыларны безгә обком билгели, – дип кырт кисте.

Алай икән. Булмаса булмый икән базарда төче күмәч дип әйтте ди берәү. Казаннан чакырып китергәнче, мин монда гына да бит дип уйлаган идем беркатлы акылым белән.

Бу хакта мин әткәй белән киңәшергә уйладым, бәлки ул сөйләшеп карар, сүзе үтә бит. Ләкин әткәй минем бу эшемне хупламады. Бәлки гозерләр белән йөреп аргандыр. Ул миңа:

– Кызым, эшкә дә йөрисең, гаиләң дә бар. Нәрсәгә өсте өстенә эш алырга? Мин сиңа киңәш итмим, йөрмә! – диде.

Шул вакытта әле генә Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәбият курсларында укып, РСФСР Язучылар берлегендә эшкә калган шагыйрь Гәрәй Рәхимне бу эшкә билгеләүләрен ишеттем. Күрәсең, обком! Гәрәй – талантлы кеше, миңа караганда тәҗрибәлерәк тә. Шулай итеп, бу студия турында сүз шуның белән бетте дисәм, бетмәгән булып чыкты бит!

Бервакытны миңа Щепкин училищесыннан шалтыраталар: эшкә чакырулары! Үзләре! Курс җитәкчесе Владимир Смирнов вафат булган икән. Яңа җитәкче урыны өчен көрәш башланган. Шуның өстенә Гәрәй Рәхим дә киткән. Безнең татар студентлары гел ятим калганнар. Ничек кенә булмасын, шунда кемдер мине исенә төшергән. Ул вакытта ике урында эшләргә рөхсәт юк иде. Китапханәдән дә тулысы белән китә алмыйм, училищеда да эш сәгатьләп кенә. Китапханәдәге эшем сменалы булганга, училищеда эшли алырымны беләм, тик китапханә директоры рөхсәт бирми. Шуннан Щепкин училищесы ректоры Остальский, китапханәнең директорына шалтыратып, минем хакта сөйләшкән. Ул вакытта бездә (ВГБИЛ – Всесоюзная Государственная библиотека иностранной литературы) директор булып Косыгинның кызы Людмила Алексеевна Гвишиани эшли иде.

Ниһаять, миңа рөхсәт бирделәр! Әткәйгә бернәрсә дә әйтмәдек. «Йөрмә!» дигән саен аны тыңламасак, ул борчылачак иде. Илгиз бу очракта минем яклы иде. Мин өлгермәгәндә, өй эшләрен ул башкарды, зарланмады. Шулай итеп, без дә, ниһаять, мөстәкыйль карар кабул итәрлек булганбыз икән! Щепкин училищесында татар студентлары белән эшләү иң яраткан эшемә әйләнде. Дүртенче курста режиссёр диплом эше буларак, М.Горькийның «Мещане» пьесасын тәкъдим итте. Мин ул әсәрне татарчага тәрҗемә иттем. Икенче эш итеп, курс режиссёры язучы А.Миндадзеның «Смерть машиниста» дигән киносценариен алган. Мин анысын инсценировка ясап, тәрҗемә иттем. Студентлар өчен чит ил классиклары әсәрләреннән өзекләр дә тәрҗемә итәргә туры килә иде. Студентлар белән мин дә репетицияләрдә утырам. Кайбер көнне иртәдән кичкә кадәр. Режиссёрлар алышына, ә мин – юк. Курсның яңа җитәкчесе итеп, Малый театр артисты Верещенконы билгеләделәр. Ул барыбер укытучылар өчен дә, студентлар өчен дә чит булып калды, ябышып китә алмады. Барысы да вафат булган Смирновны сагынып искә ала иде.

Театр студиясе – башка мохит. Анда килеп, татар әдәбиятыннан сәгать ярым лекция укып китеп кенә булмый. Син һәрвакыт алар белән булырга тиеш. Текстны дөрес укыйлармы? Басымны урынына куяламы?..

Кайчагында өйгә килеп тә репетиция ясыйлар иде. Чөнки студентларның күбесе рус мәктәбен тәмамлаган, телне белүләре, сөйләм телләре чамалы, күбесендә акцент. Безнең татар студиясендә «Современник» театры артисткасы Тамара Дегтярёва, икенче режиссёр булып, танылган артист Георгий Жжёновның хатыны Лидия Петровна эшләде. Алар безнең студентларны бик ярата иде. Өйләреннән ашарга алып киләләр, спектакльләр өчен дә кемдә нәрсә бар – училищега ташыйлар. Эскәтер, савыт-саба, күлмәкләр, урындыклар, пәрдәләр, чаршаулар! Алар – студентларның әниләре дә, әтиләре дә! Спектакльләрне әзерләү миңа авыл клубында театр куюны хәтерләтә иде. Алар белән эшләгәндә, вакыт та, дөнья да онытыла.

Ә инде иң мөһим, дулкынландыргыч мизгелләр – Казаннан Марсель Сәлимҗанов җитәкчелегендәге 6-7 кешелек комиссиянең диплом спектакльләрен кабул итәргә килүе. Празат Исәнбәт, Туфан Миңнуллин, Равил Шәрәфиев, Әхмәт Гадел һәм башкалар бар иде ул комиссиядә. Әле мәскәүлеләрне дә кушсаң, байтак җыелдылар.

Комиссия спектакльләрне бик кызыксынып, яратып карады. «Мещане» спектаклендәге озын-озын монологларны ялгышмыйча, дөрес итеп сөйләүләрен күреп, ишетеп утырган Марсель Сәлимҗановның:

– Нәзифә килгәннән бирле болар танымаслык булып үскәннәр бит! Акцентлары беткән! – дигән сүзләре эшем өчен биргән иң югары бәя иде.

Барлык чыгыш ясаучылар, бигрәк тә Празат абый, студентларны да, мине дә мактадылар.

Шул вакыттан соң Марсель абый гастрольләр вакытында мине күрсә: «Урының бармы, билет кирәкме?» – дип сорый торган булды. Соңгы тапкыр без аның белән ул «Алтын битлек» премиясен алганнан соң күрештек. Мин аннан Мәскәү кунакханәсендә радио өчен интервью алган идем.

Бу теманы озакка сузмый, шуны гына әйтә алам: талантлы студентларым белән хәзер дә тыгыз аралашам, хезмәттәшлек итәм. Шуларның берсе – Кариев театрының баш режиссёры Ренат Әюпов. Ул театр сәхнәсендә минем тәрҗемә, инсценировка, үз әсәрләрем дә уйналды. Хәзер инде бакыйлыктагы артист, драматург Аманулла, Камал театры артисты Илдус Габдрахманов, Раушан Шәрипов, Айрат Арсланов, Илсөя Төхвәтуллина, Зөлфирә Зарипова, Мәрьям Йосыпова һәм башкалар минем студентларым иде. Мин аларның театрда гына түгел, кинодагы хезмәтләре белән дә горурланам.

Әткәйгә әйтмәсәк тә, әлбәттә, белгәндер инде минем студиядә укытуымны. Ләкин бу турыда кабат сүз булмады. Үткән эшкә – салават дигәндер.

## Күршеләр

Без Илгиз белән өйләнешкәннән соң Мәскәүдә бер бүлмәле фатирда яшәдек. Ул Илгизнең үз фатиры иде. Безнең катта дүрт фатир, өч күрше. Күршеләрне Аллаһ җибәрә диләр. Дөрес ул! Шуларның икесе белән беренче көннәрдән үк аралашып, дус яши башладык, ул дуслык бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Мәскәүдә күп тапкырлар башка фатирларга күченергә туры килсә дә, без югалтышмадык, гомер буе аралашып яшәдек. Алар чит илдә

дә эшләде. Хәбәрләшеп тордык. Хәзер инде олы буын юк, бездән азрак кына яшьрәк булсалар да, балалары белән аралашабыз. Ташлашмадык, күрешәбез, кунакка йөрешәбез. Алар турында язуым шуңа: эткәй-әнкәй дә аларны белә, сәлам әйтәләр иде. Яңа китабы чыкса, эткәй аларга да һичшиксез бүләк итеп бирә иде. Без яшәгән ул өй гадәти өй булмагандыр, күрәсең. Безнең белән бер подъездда, бер катка гына өстәрәк дирижёр Фуат Мансуров яшәде. Аның белән исәнләшеп йөри идек. Әнисе белән дә таныш идек. Терәлеп торган күршеләребезнең берсе генерал иде. Соңыннан армия белән командалык итә торган маршал исемен дә алды. Һава-десант гаскәрләре белән командалык итте. Соңгы елларында Оборона министрының кадрлар буенча урынбасары булып эшләде. Бүгенге көндә Белгород шәһәренең уртасында, туган илендә, аның мәһабәт һәйкәле тора. Кызының әйтүенә караганда, генерал Сухоруков һәйкәленең кулында Әфганстанга керү турында, ләкин ул ризалашмаган, шуңа йомарланып тоткан фәрман. Әйе, ул – бу приказга каршы, ләкин, ни кызганыч, аны үтәргә мәҗбүр булган кеше. «Безнең эти бүгенге көндә дә сугышта», – ди кызы. Бу айларда үзәк мәйданында генерал Сухоруков һәйкәле басып торган Белгородны Украина ягыннан һәр көнне утка тоталар. Икенче күршебез чит илләрдән кайтып керми торган, Тышкы эшләр министрлыгында эшләүче кеше иде. Ул үзенең нинди ведомствода эшләвен танышканнан соң 15 ел узгач кына әйтте. Бу инде, бераз соңрак булса да, аның безгә белдергән ышанычы иде.

Курск вокзалы янындагы менә шул кечкенә фатирда яшәгәндә, без яшь идек, ишекләребез дуслар өчен һәрвакытта да ачык иде. Кунакларсыз яшәгән булмады. Уфа, Казан, Минзәләдән генә түгел, дуслар, туганнар дөньяның төрле почмагыннан килеп тора иде. Илгиз эшкә киткәндә, киләсе кешеләр өчен ишеккә мондый язу кыстырып калдырырга да курыкмый иде: «Ишек ябылган кебек ачыла, ачкыч палас астында». Яшь чаклар турында сөйләшә башласак, Илгизнең ишеккә кыстырган бу язуын искә төшереп, хәзер дә көләбез. Вокзал якын булгач, чегәннәр дә йөри. Ләкин, Ходай рәхмәте, угрылар булмады, тора-бара подъезд төбендә ишек саклап утыручы да табылды.

Бервакыт безнең әле генә өйләнешкән чагыбызда эткәйдән хат килде. Күп вакыт хат икебезгә дә дип языла, җавапларны миңа язарга туры килә иде. Ә менә бу хатта Илгиз өчен генә булган юллар да бар иде. Хат каршымда булмаса да, ул сүзләр күңелемә уелып калды. Кызык, бәлки гомер буена Илгиз дә онытмагандыр дип уйлыйм. Анда эткәй: «Улым! Нәзифә – бик әйбәт кыз. Ул сиңа бик җиңел эләкте. Җиңел табылган әйбернең кадере булмый диләр. Минем сиңа киңәшем: сакла, хөрмәт ит, ярат! Ул – беркатлы, эчкерсез, самими кеше. Сиңа бик яхшы иптәш булачак» дип язган иде. Нигә шулай дип язды икән дип уйлыйм хәзер. Ул безнең мөнәсәбәтләрне белә, күрә, алардан бик риза иде. Бәлки Илгизгә аерым нәсыйхәт бирәсе килгәндер. Эткәй бит улын миңа караганда күбрәк белгән кеше. Шунысын да әйтим: эткәй киңәш, үгет-нәсыйхәт бирергә бик ярата иде. Уйлап карасаң, аңар ул вакытта нибары 50 яшь булган бит! Дөресен генә әйткәндә, без гомер буе аларның фикерен тыңлап, киңәшеп яшәдек. Хәзер инде уйлап куям, бәлки бу Илгизнең мөстәкыйльлегенә комачау да иткәндер. Тик шунысы ачык: эткәйнең абруе гаиләдә барысыннан да өстен иде.

Әткәй миңа карата булган бу фикерен гомер буе саклагандыр дип ышанасы килә. Гаиләдә төрле хәлләр булса да, Илгиз дә бу хакта бер тапкыр да онытмагандыр дип уйлыйм. 50 елга якын бергә яшәдек бит. Ярты гасыр, бер гомер шуңа шаһит...

## Безнең гаилә

Әткәй белән әнкәй, Әлфия белән Олег, аларның уллары Тимербулат һәм Илгиз, мин, кызым Айгөл, улым Нияз – без бер гаилә. Гомер буе әткәйнең кайгыртуын, җылысын, хәстәрен тоеп яшәсәк, бүгенге көндә боларның барысын да Тимербулат башкара. Ул – картатае урынына калган, башкарган эшләре белән хөрмәткә лаек шәхес. Үземнең балаларым, оныгым белән дә горурланам, тәүфыйклы, иманлы балалар булып үстеләр, намус белән тормыш итәләр. Алар беркайчан да картатайларының кем булуын онытмый, горурлана. Әти-әниләр инде бакыйлыкта булсалар да, барыбер балаларына гомер буе терәк булып кала икән. Без дә балаларыбызга, оныкларыбызга шундый үрнәк булсак идек.

## Сатира театры

1984 ел. «Диктаторга ат бирегез!» дигән фарс берничә театрда куелган иде инде. Әткәйгә кемдер Мәскәүдәге сатира театрына бирегез, анда һич тә куймый калмаслар дип киңәш иткән. Әткәй кулъязмасын театрның баш режиссёры Валентин Плучекка җибәргән. Беркавым вакыт узганнан соң, пьеса укылгач, әткәй театрга режиссёрның үзе янына килгән. Бу очрашу хакында ул болай дип сөйләгән иде: «Килдем бу Плучек янына. Бик матур кабул итте. Хәтта өстәлгә коньяк та чыгарып куйды. Мин моңа карап, кара, яхшы хәбәрне тиз генә әйтеп салмый, суза хәйләкәр яһүд дип уйлап куйдым. Шуннан Плучек телгә килде: «Бервакытны, күптән булган хәл, миңа Назыйм Хикмәт шалтырата (Назыйм Хикмәт – төрек язучысы, коммунист булганы өчен иленнән куылган шагыйрь, күп еллар Мәскәүдә яшәде. Мәскәүдә җирләнгән. 90нчы елларда аны туган иле яңадан ватандашы дип кабул итте. Ләкин Назыйм Хикмәт фани дөньяны ташлап киткән иде инде. – *Н.К.*). Назыйм әйтә:

– Плучек! Мин бер бик шәп, бөек пьеса язып ятам, – ди.

–Яз, Назыйм, яз, – дим. Бераз вакыт узгач, бу шалтырата:

– Плучек! Мин теге бөек пьесаны язып бетердем! – ди. «Китер!» – дидем. Китерде, укып чыктым. Тик ул бөтенләй бөек булып чыкмады. Кайтарып бирдем». Плучек шулай диде дә, миңа карамый гына, пьесамны кулыма тоттырды: «Мә, «Атыңны», үзеңә кире бирәм!» Кычкырып көлештек тә, тагы берәр рюмка коньяк эчкәннән соң, гомерлеккә аерылыштык», – диде әткәй, елмаеп.

Минемчә, әткәйнең моңа бик исе китмәгәндер. Тик, кем белә, зыялы кешенең эчендәге тышында булмый бит! Бәлки бераз гына эче пошкандыр. Ул аның иҗатының бик дәвамлы, уңышлы чоры иде. Борчылмагандыр әле дип тә уйлыйм.

**Мостай әйткән:** «Кайчагында без бер-беребезгә киңәш бирәбез, теге яки бу кабахәт, адәм актыгы белән дошманлашмаска киңәш итәбез. «Югарырак

бул, күрмә дә син аны, әгәр дә күрешергә кулын суза икән, кыс кулын, аның белән генә бернәрсәң дә кимемәс», – дибез. Ләкин кулыбызны сузабыз икән, без югары булып калмыйбыз, түбән тәгәрибез. Ә ул үзен иң кимендә синең белән тиң дип хис итә».

«Мине еш кына акыллыга исәплиләр. Үзем хакында мин шулай уйлыйм: мин күбесенчә ахмак сүзне сөйләүдән тыелып калам. (Ә андый сүзләр башка килә ул...) Шуңа күрә уйлап әйткән урынлы сүземне акыллыга чыгаралар. Кайчак, телдән чыгып ычкынмасын дип, мәгънәсез сүзне тыеп торам».

«Шундый китаплар бар, аларны укыгач, яңа тормышта яшәгән кешеләрнең дә бу дөньядан күңеле кайтуы, өмете югалуы ихтимал. Минем максатым – киресе: минем китапларымны укыгач, авыр яшәгән кешеләр тормышта җиңеллек тойсын, өмете ныгысын! Әле В.Астафьевның «Печальный детектив» дигән повестен укып утырам. Бер генә дә яктылык юк».

«Кеше Ватанын, Заманын, Әнисен сайлап тумый. Ә тугач инде, шуларның өчесе өчен дә җаваплы».

## Көзге урман

Әткәй табигатьне ярата иде. Елның һәр фасылында да матурлык та, җанына куаныч та таба, кеше күрә алмаган матурлыкны, аның асылын күрә белә иде ул. Ул бит шагыйрь. Аңа шулай тиеш. Ә инде безгә аның сөйләвен тыңлау рәхәт. Ел фасылларыннан аның иң яратканы – көзге урман. Сөйләгәне дә бар: «Көзге урманда йөрергә яратам. Яфракларның саргаюы, гөлләрнең шиңеп караюы күңелдә әллә ни пошыну да, сагыш та уятмый. Киресенчә, күңел тынычлыгын арттыра, күз карашын юата. Чөнки бит алар дөньяга матурлык бирүче, ямь калдырып китүче бизәкләр. Тик менә ялангач куак эчендә кош оясы, сайрар кош балаларыннан торып калган буш бишек очраса, тетрәнеп китәм. Кечкенә генә кошлар ташлап киткән кечкенә генә оя күңелемә шом сала, уйны борчый. Нигә шулай икән? Кайларда очалар икән алар? Нинди илләрдә очалар икән дип уйлыймдыр, ахрысы».

## Көндәлекләрдән

9.12.89. «Инәем 105кә чыкты. Хәзер эшли алмый. Ул әйтә: «Төшләремдә эшләп йөрим. Йә иелә-сыгыла иген урам, йә тәгәрәтеп печән җыям, йә сыер савам, йә киндер сугам. Шул тиклем рәхәт. Шушы рәхәтлектән уянып китәм».

## Замана этләре

«Бер кызык нәрсә күз алдына килде әле, – диде әткәй бервакыт. – Пушкин заманында этләр кешеләргә ташланмагандыр дип уйлыйм. Ерактан гына өргәннәрдер. Алар бит тәртипле, аристократ этләр. Тукай заманында этләр каршыга чыгып ташлангандыр. Безнең заманның этләре арттан посып кына килеп, балтырны умырып алалар да шунда ук алга чыгып: «Саумы, агай! Әле дә син бар...» – диләр.

## Свердлаудагы уйланулар

Свердлауның татар-башкорт оешмасы чакыруы белән әткәй 1989 елның декабрь урталарында шул шәһәрдә булып кайтты. Анда аны «Свердловск» дигән бик шәп кунакханәгә урнаштырганнар. «Шәплеге белән салкынлыгы бер чама иде», – дип искә алган иде әткәй.

«Шушы салкында утырганда, уйларымны бик гади фикерләр яулап алды. Кешенең үз-үзенә хөрмәте, аны башкалар хөрмәт итми башлагач бетәдер. Әгәр дә нормаль, намуслы, акылы башында булган кешене урынсыз, гаделсез түбәнсетә башласалар, ул да әкренләп, үз-үзен мескен итеп тоя башларга мөмкин.

Мин бу түбәнсетелгән хәлне, җәмәгатьчелекнең кайсыдыр бер өлешендә миңа булган хөрмәт какшаганрак булып күренгәч, башымнан кичергән идем. Соңгы вакытта мине еш кына җәберләргә тырышалар: кемдер мине Пиночет дип атый, кемдер ниндидер мафиози эшләр тагарга маташа. Болар барысы да кеше алдында, җыелышларда, җитәкчелек каршында, каләмдәшләр очрашуында эшләнә.

Башкортстан язучыларының соңгы съездында Мәскәүдән килгән шагыйрь Феликс Чуев, чыгышларны тыңлаганнан соң, трибунадан болай диде: «Иптәшләр! Әгәр дә мин Мостай Кәримнең иҗатын, кешелек сыйфатларын белмәгән булсам, сезнең чыгышлардан аны нинди начар язучы, нинди әшәке кеше дип уйлар идем.

Шул ук съездда обкомның идеология секретаре Әхнәф Дилмөхәммәтов, мәдәният бүлеге мөдире Тәлгать Сәгыйтов та булды. Дустым Муса Гали бу ялалардан мине яклап сүз алса да, аны тыңлаучы булмады. Хакимият вәкилләре дә яклап тешләрен дә агартмады.

Соңыннан мин менә нәрсәләр ишеттем: Учалы белән Бөрҗәндә ике мәктәптә туган тел кабинетында эленеп торган портретларымны алып атканнар. Шуның өстенә минем иске дустым Нажар «Кызыл таң» газетасында мине «татар теленә каршы килүче» дип язып чыккан. Мин аңар шул ук газета аша җавап бирдем, ә ул мине мәхкәмәгә бирде. Мәхкәмә, җинаятьчелектә гаепләрлек сәбәпләр юк дип, мине аклау хөкеме чыгарды.

Әгәр дә кунакханәдә җылырак булса, минем башыма күңеллерәк уйлар килер иде...» Әткәй бу истәлеген шушы сүзләр белән төгәлләгән.

## Нәнәй турында

«Инәй сөйли: «Сез тугач та (мин, Салисә, Ильяс, Госман), Олыинәең баланы коендырып, аның учына көмеш тәңкә йомарлата. Янәсе, күңеле көмеш кебек саф булсын, кулыннан мөлкәт китмәсен, юмарт булсын. – Шунда ук өстәп куя: – «Ходайга шөкер, бай булмасак та, ачлык күрмәдек, мыскыллык татымадык». Нинди тапкыр әйтелгән сүз. Ачлык белән хурлыктан да начаррак бәла юк».

## Хәби Мәмлиев

Әткәй бу кеше турында гомер буе онытмады, һәрвакыт рәхмәт белән искә ала иде.

«Китап нәшриятында Хәби Мәмлиев директор булып эшләгән чор иде. 1947 елда ул мине ачлык-ялангачлыктан коткару өчен турыдан-туры җинаятькә барды. Эш болай: 1947 елның декабрендә акча реформасы булды. Кулдагы акчаны гына унга бер исәбенә түләделәр. Шуңа чаклы кемнеңдер, кайдандыр акча аласы булса, ул исәпкә алынмады. Мин «Шигырьләр һәм поэмалар» дигән китабыма күптән инде договор төзегән идем. Нәшрият бөтен сумманы түләргә тиеш булса да, бирә алмады. Акчасы юк иде бугай. Кыскасы, мин бөтенләй бөлеп калдым. Үзем туберкулёз белән каты авырыйм. Икенче группа инвалидмын. Пенсиям 550 сум. Менә Мәмлиев каршында утырам. Үзем буылып ютәллим дә кулъяулыгыма кан төкерәм. Директор башын иеп утыра. Мин кәефен кырдым, ахры. Юк. Ул башын күтәрде. Ике күзе тулы хәсрәт. Минем хәсрәт аңар күчкән. Өстәлдә торган звонокка басты бу. Секретаре Елизавета Прейс йөгереп керде.

– Лиза, – диде, – Мостай Кәримнең договорын табып китер әле. – Лиза договорны китерде. Хәби агай алды да договорны башта буйга, аннары аркылы ертып, кире бирде. – Мә, ташла. Бу автор белән иртәгесе көннән датасын куеп, яңа документлар эшләгез. Искеләренең эзе дә калмасын.

Мин моның Мәмлиев өчен подсудный эш икәнен аңлап, куркып киттем.

– Бүтән төрле эшләп булмыймы? Болай бит әле...

– Булмый, – дип кырт кисте ул.

Бу «җинаять» ачылмый калды. Мәмлиев миңа якын кеше дә түгел, үзен моңача нибары ике-өч тапкыр гына күрдем. Болай сентименталь затка да охшамаган. Әле уйлап, хәйраннар калам. Чирле, гарип фронтовикны бөтенләй аяктан екмас өчен адәм дәүләт алдында үз өстенә нинди гөнаһлы эшне алган. Бүгенге «әхлак тәртипләре» турында уйласаң, ул хәлләрдән уелып китәрлек. Бүгенге берәр түрә дә шундый эшне кылыр иде бәлки, әмма ярты гонорарны үзенә талап алыр иде. Ким дигәндә...

Минем гомеремдә очраган тәвәккәл, фидакарь кешеләрнең берсе булган икән Хәби Мәмлиев».

## Депутатларга!

«Дәүләт Думасы депутатларына карата бер мөрәҗәгать уйлап таптым әле.

Кыйммәтле, бик кыйммәтле әрәмтамаклар!

Мин бу дөньяда күп нәрсә күрдем, әрәмтамакларны да байтак кына күрергә туры килде. Тик менә шушындый кыйммәтлеләрне әлегә кадәр күрергә туры килгәне юк иде. Сез илгә, Русиянең халкына үтә кыйммәткә төшәсез бит. Безнең бик кыйммәтле депутатларыбыз!»

## Кесәле чалбар

Әткәй соңгы елларда үзенең бәләкәй чагын еш искә ала иде. Күрәсең, барысын да уйлап утыргандыр.

«...Мөгаен, миңа 5-6 яшьләр тирәсе булгандыр. Миңа кесәле чалбар тектерделәр. Мине киендерделәр. Олыинәем хәтта бер такмак та әйтеп бирде:

Ай улы да вай улы,
Кесәләре каюлы.
Кесәсенә кулын тыгып
Сызгырадыр бай улы.

Мин ул җырны шунда ук отып алдым. Урамга чыгып, капка төбенә бастым. Ике кулымны кесәмә тыктым да «фи-у, фи-у» дип сызгырган булдым. Берәү дә моны күрмәде дә, ишетмәде дә. Кабатлап карыйм: «Ай улы, вай улы...» Ишетүче юк. Хәтерем нык калды. Бәләкәй чакта мин шәп сызгыра идем. Ярый әле, гомер буе сызгырып яшәмәгәнмен.

...Аптырагач, яңа киемнәремне котлатырга Кәюп агайларга киттем. Алар, ичмасам, баллап чәй эчертәләр».

## Твардовский турында

05.02.77. Әткәй Твардовскийның сүзләрен искә ала: «Язар өчен тынгылык запасы кирәк». Һәм үзеннән өстәп дәвам итә: «Мин дә якынча шулайрак уйлыйм: язар өчен беркемгә дә, бернәрсәгә дә буйсынмый торган үзеңнең эчке вакытың булырга тиеш. Александр Трифонович Твардовский әле безне һаман да сынаулы төбәлгән карашыннан яздырмый. Ә бит җиде ел вакыт узган да киткән...

1976 елның декабрендә Язучыларның үзәк йортында шигърият кичәсе узды. Мин рәислек иттем. Залдан шундый сорау килде: «Белдерүләрдә Евтушенко күрсәтелгән иде. Бүген аны кем алыштыра?»

Мин болай дип җавап бирдем:

– Евтушенконы беркем дә алыштыра алмый. Бүген генә түгел, беркайчан да. Шунысы яхшы, кешелекнең бер шагыйрьне икенчесе белән алыштыра торган куркыныч камиллеккә килеп ирешкәне юк әле. Таза ризыклар булмаса, аны консервылар алыштыра. Ә менә шагыйрьләрне алыштырырга ярамый.

Ул кичәдә минем белән рәттән Григорий Бакланов утырган иде. Ул минем колагыма болай дип пышылдады: «Твардовский киткәч, күпләр үзләренең оятсыз эшләреннән үкенмәделәр, оялмадылар да».

Никадәр дөрес әйтелгән сүзләр. Тормышта Твардовский кебек кешеләрнең булуы, хәтта бик әшәкеләрне дә начар эшләрдән тыеп тора.

Твардовский мактау сүзләренә саран иде. Шулай да ул бер тапкыр мине мактады. 1963 елда мине РСФСР Югары Шурасы Президиумы Рәисенең урынбасары итеп сайладылар. Твардовский белән тәнәфес вакытында Кремльләр сараеның фойесында очраштык. Ул Смоленск өлкәсеннән депутат иде. Шунда әйтте: «Сезнең сайлануга мин бик шат. РСФСР җитәкчелеге тагы бер әйбәт кешегә артты». Миңа уңайсыз булып китте. Ләкин мин каршы килмәдем. Каршы килергә батырчылык итмәдем».

**Мостай әйткән:**

«Бу дөньяның һәр төбәге
Хатирәле.
Исән чакта хатирәләр
Хәтәр әле».

«Колакка кергән салкын сүз, йөрәккә җиткәч, боз булыр».

«Акылны кирәк чакта яшереп була, ахмаклыкны гына яшереп булмый».

## Көндәлекләрдән (русчадан тәрҗемә)

2.11.82. «Мин үзебезнең милли интеллигенция язмышы өчен бик борчылам. Аларда үз-үзеңне тану, анализлау да, үз-үзеңне тәнкыйтьләү дә юк. Алар үзләрен, бигрәк тә милләткә кагылышлысын мөкәммәл дип, сукырларча күкрәк кага. Алар милләттә элек-электән үк булган дип, уйлап чыгарылган казанышлар өсти, әйтерсең Октябрь инкыйлабы булмаган, ул безнең милләт өчен очраклы, гади бер күренеш кенә. Сукырларча үз-үзеңне генә сөю, тәкәбберлек милләтне, интеллигенцияне рухи яктан бөлгенлеккә төшерергә мөмкин. Интеллигенция үз милләтен башкалардан үзенчәлекле, өстен, искиткеч дип дәлилләргә тырышып, үзенең аңын томалый икән – милләтчелек шуннан башлана».

## Малеевка

14.01.82. Әткәй Малеевкада. Ул бирегә яңа әсәр, «Ярлыкау»ны язарга килгән. Ләкин озак кына башлый алмый интекте. «Әллә ничә тапкыр башлап карадым, күңелгә ятмый», – диде ул. Ничек язылса язылыр, шулай башлыйм да китәм диде бу темага соңгы сөйләшүдә....

«...Бүген Айдар Хәлим килде. Ул миңа бик әйбәт киңәш бирде. «Автобиграфиядән арынырга кирәк», – диде.

Бу вакытта Айдар Хәлим әткәй белән дустанә мөнәсәбәттә. 90нчы елларга күп калмаган. Айдар инде ул елларда күрсәтә әткәйгә үзенең кем икәнен. Әткәйне тәмам дошманга әверелдерә. Шул ук көнне әткәй болай дип тә әйткән иде:

«Бүген Татарстан егетләре белән сөйләшеп утырдык. Мансур Вәлиев дигән күзлекле озын егет ошады миңа. Ихлас күңелле кеше. Үзе тәнкыйтьче икән. Рәхмәт Хисмәтуллин исемле мыеклы юантык егет гел авызын ачып тыңлый. Айдарның «Ул елда» дигән бик әйбәт поэмасын тыңладык. 1946 ел турында».

## Көндәлекләрдән

18.02.83. «Ниләр булды миңа?.. Ниләр генә булды?... Сәбәпсез эчем поша. Күңелемдә таш ята сыман, авыр. Өченче каттан тәрәзәдән карап торам. Башым белән тәрәзәне ватып, тышка ташланырдай булам... Тиз генә киенеп, урманга чыгарга кирәк... Чыкмадым. Чәй куеп эчтем. Җиңелрәк булып китте. Тышта җил күтәрелде, карагайлар тирбәлә. Буран куба.

Хәзер миңа 64 яшь. Күп булса, ун ел гомерем калгандыр. Тимербулатка азрак аң кергәнче яшәргә иде.

Чынлап та, күпме эчке кичерешләр үткәрдем мин. Сугыш, авыр яра, сугыштан соңгы каты чирләр. Үлем белән ничә тапкыр күзгә-күз караштым. Аерым тору елларында Раузаны сагынып Мәҗнүндәй булдым. Дуслардан күңел кайтулар, яман затларның гел өреп торулары, җанымның бүлгәләнүе, табигать биргән талантның яртысын да файдалана алмый җилгә җилкетеп гомер үткәрүләр, җыен эшкә ашмас кешеләр өчен соранып йөрүләр, җыен юньсезне яклап йөрүләр ярты гомеремне алды. Елларымның байтак өлеше заяга үтте. Куркып яшәдем. Начар булудан курыктым, намус югалтудан курыктым, адәм рәнҗетүдән курыктым. Намуссызлар,

явызлар, бәгырьсезләр шул вакытта үз мәнфәгатьләре өчен мине эшкә җикте. Эшләгәнем, язганым тагы нәрсә? Бөтенесен бергә кушсаң, биш көлтә чыкмас. Ә бит миңа кибән өяргә вакыт. Арыдым, йончыдым, хәтта елыйсым килә...»

Ә мин елыйм бу юлларны язганда, әткәйне жәлләп елыйм. Әткәйнең бу йөрәк монологын көндәлегендә ничек язылса – шулай, тулысы белән бирдем. Әле бит аңар ул вакытта нибары 64 кенә яшь. Бу язмадан соң ул әле безнең бәхеткә тагы 22 елга якын яшәде. Ләкин ул үзе яшәү бәхетен тулысы белән тоя алдымы икән? Ул еллар аңар тормышының кайгы-хәсрәтләре аша үтәр өчен, иминлеге өчен көрәшкән, төзегән иленең җимерелүен күрер өчен, үзенә ябырылуларны, дусларының хыянәтен, әнкәйнең үлемен кичерүе өчен, шуларның барысын да үз йөрәгеннән үткәрер өчен бирелде микәнни? Боларга ничек чыдарга? Әткәй чыдады.

## Солженицын

27.10.93. Әткәйнең көндәлекләреннән алынган бу язма утыз ел элек язылган булса да, бүген дә актуаль дип уйлыйм. Ул безнең милләтләргә кагыла. Ул рус телендә язылган, аны татарчага тәрҗемә итеп бирәм:

«Кичә телевизордан Солженицын белән әңгәмә күрсәттеләр. Ул милли республикаларны бетереп, алардан губерния ясарга дигән өндәү белән чыкты. Ул халыкларны – аларның мәдәниятен саклап калырга, ләкин шул ук вакытта аларны икътисади һәм территориаль мөстәкыйльлектән мәхрүм итәргә чакыра. Бу – ялган, халыкларны резервацияләргә куып кертеп, утарларга ябып кую – бу империячел теләк. Имеш, шулай итеп, аларга рухи азатлык бирәләр! Резервация – азатлык бишеге! Очланган шовинист Солженицын беркайчан да, беркем турында да, шул исәптән халыклар хакында яхшы сүз әйткән кеше түгел. Халыкларның тормышы турында нәрсә белә соң ул? Аның аңына шундый фикер салганнар: РФ республикаларында (Башкортстанда, Татарстанда ) туземецлар (титул милләт ) башка халыклар белән командалык итмәкче?! Халык белән халык командалык итми, халык белән кешеләр җитәкчелек итә. Әгәр дә алар лаек булырдай кешеләр икән – бу бәхет. Әлбәттә, җитәкче кадрлар мәсьәләсендә чама һәм төпле баланс сакланырга тиеш.

Солженицын турында тагы шуны әйтәм: «Иван Денисовичның бер көне» дигән әсәрен Ленин премиясенә тәкъдим иткәч, күпчелек булмасак та, мин комитетта аның кандидатурасына теләктәшлек белдерүче әгъзалар арасында идем. Солженицын илдән куып чыгарылганда, күп кенә язучылар аның артыннан матбугат, телевидение аша каһәрле сүзләре кычкырды. «Правда» корреспонденты бу хәлгә минем бәя бирүемне дә бик үтенеп сораган иде. Мин бирмәдем. Мин аларга: «Миңа аның әсәрләрен бирегез, укып чыккач, үз фикеремне әйтеп, газетагызга мәкалә язармын. Болай гына язучыны гаепли алмыйм», – дидем. Әлбәттә, язмаганыма үкенмим. Мин үзем аңлаганча эшләдем. Кызганыч, аннан гуманист язучы чыкмады».

***

«Урак белән кылыч гомер бакый
Алышканнар. Каннар түгелгән.

Алмас кылыч бер чак шартлап сынган,
Тимер урак бары бөгелгән».

***

«Әйе, булды: вак-вак язык кылдым –
Үкенергә хәзер сәбәбе бар.
Ә шулай да тәүбә итүләрнең
Иманлы бер изге сәгате бар».

## Көндәш, айдаш, елдаш

Әткәй үзенең ике әнисе булганын, олыинәй белән кечеинәй дип сөйләгәндә, «көндәш» дигән сүзгә бик кызыклы аңлатма биргән иде.

– «Көндәш» дигән сүздә бик тирән мәгънә ятканын беләсезме? – дип сорады ул бервакыт. – Ул бит «уртак көн» күрүчеләр дигән сүз. Көндәш, айдаш, елдаш. Чөнки аның әниләре 19 ел бергә көндәш булып яшәгән. Әткәй әйтә: «Үземнең күзәтүем, кечеинәйнең сөйләвенә караганда, алар бит көндәш, гомердәш кенә түгел, җандаш, рухташ та булганнар. Бу үзе бер могҗиза бит! «Көндәш» дигән трагик сүз эчендә нинди илаһи бөек мәгънә ята. Тик ул илаһи җаннар өчен генә. Мин ике инәемнең мөнәсәбәтләренә әйләнеп кайта-кайта хәйран калам.

Әткәй шулай дип сөйләгән иде: «1928 елның кышында олыинәем белән атаемнең уртак балалары булган Мортаза агай кәләш алды. Җиңгәбез Серсә урамының Томанай очындагы Камалетдин кызы иде. Үз улының туена олыинәем бармады, үзе урынына кечеинәемне җибәрде: «Син, Вазифа, яшьсең, чибәрсең. Туйны ямьләп йөрерсең. Аталарын үзем күндерермен». Моны инәем миңа картайгач кына әйтте. Мин дә яхшы хәтерлим ул туйны. Туйга атаем кечеинәем белән барды, ике яшьлек энем Ильясны да үзләре белән алдылар. Салисә сеңлем, мин, олыинәй белән калдык. Йола саклаптыр инде, алар атнага якын кунак булдылар. Бер урамда торсак та, өйгә кайтып күренмәделәр. Малтуарны Салих абыем карады. Ул – кечеинәемнең артыннан килгән улы».

Йортның, ыруның үз йолаларын, үз гадәтләрен, кагыйдәләрен белә башлагач, аны үзеңнеке итеп кабул иткәч кенә, үзеңне, чынлап та, шул гаилә кешесе итеп тоя башлыйсың икән. Җиде буынга барып җитмәсәм дә, бу гаилә миңа рухташ та, җандаш та, фикердәш тә булды – гомумән алганда, үземнеке. Тик шунысын да әйтим: минем яктан көнчелек дигән нәрсә булмады. Көнчелек читләр өчен хас. Ә мин бу гаиләдә чит булмадым. Әткәй әйтмешли, өйгә генә кермәдем, ул гаиләнең күңел түрләренә кереп утырдым.

**Мостай әйткән:** «Үземчә бер күзәтү: мин болай табигатем буенча алдакчы түгелмен. Кулыма каләм алып, әсәр яза башласам, алдакчы булам да китәм».

«Кайгысын яшерә белгән кешене яратам, шатлыгын яшергән кешедән куркам».

## Көндәлекләрдән

«Язып утырам. Бик әйбәт образ күз алдыма, тапкыр сүз тел очыма килде. Шуны кәгазьгә төшерергә куркам. Шуның тәмен озаграк тоясым килә. Бала чакта кулга тәмле нәрсә эләксә (прәннек, алма, өрек), ашарга кызганып йөрисең бит. Әле дә шулайрак менә».

## Телефонның күзе юк

Әткәйнең каядыр барырга җыенганын күреп, каенсеңлем Әлфия:

– Әткәй, кая җыендың? Кичә генә тын бетүдән азапландың бит! – ди.

– Министр белән очрашырга сөйләшкән идек. Машина җибәрәм диде. Бер якташым гозере хакында сөйләшим дигән идем. Ул әйбәт кеше, эшендә таләпчән, гаиләсендә дә тәртип.

– Сиңа бит шалтыратырга гына кушканнар иде. Телефоннан барысын да әйтер идең! – дигән Әлфия.

– Телефонның күзе дә, җаны да юк. Әгәр дә мин сорап барам икән, мин аның күзләрен күрергә тиеш, йә булмаса инде бернәрсә дә сорамаска, – дигән әткәй.

Хәзер инде Әлфия үзе берәр кеше өчен сорарга кирәк булса, әткәйнең шул сүзләрен исемә төшерәм ди.

## Преферанс

Мостай Кәримнең преферанс уйнарга яратканын күпләр белә. Әткәй әле яшь чагында ук Достоевскийның «Игрок» әсәрен укып бик тетрәнгән. Күңеленә уелып калган. Шушы әсәрне укыганнан соң әткәй преферанс уйнарга өйрәнеп ала. Уфада преферанс сөючеләрнең клуб шикелле нәрсәләре була. Ул уенга галимнәр, инженерлар, укытучылар, гомумән, интеллигенция йөри. Соңыннан инде аларга язучылардан да берәү – Мостай Кәрим дә килеп кушыла. Бигрәк тә 80-90нчы елларда бу «оешма» еш җыела торган була, Уфада чакта әткәй бу очрашуларны калдырмаска тырыша. Әткәйнең бу мавыгуына әнкәйнең бик исе китми. Бервакытны Әлфия әткәйдән:

– Әткәй, сез нәрсә, ул клубыгызда әллә акчага уйныйсызмы? – дип сораган.

– Шырпыга түгел бит инде! – дип җавап биргән әткәй.

## Пенсия

Әткәй пенсиягә чыгыуын бик авыр кичерде. Хәтта пенсия таныкламасын алырга да яше җитеп бер ел узгач кына барды. Ул болай дип сөйләгән иде:

«Кичә пенсия книжкамны алып кайттым. Авыр кичерәм шушы хәлне. Әйтерсең үземә картлык хөкеме чыгардым. Менә миңа да 61 яшь тулды. Барысы да чагыштырмача килеп чыга. Күз төбәп торган нәрсәм – шушы 170 сум акчам булса, ташламаларын да кушсаң, шатлык чиктән ашар иде. «Калган гомерне тыныч кына яшәп бетерәсе калды», – дияр идем. Әллә туеп сикерәм инде... Ләкин бөтен нәрсәгә ачыграк карарга тырышам. Алайга китсә, хәзер картлыкны яшәп бетерәсе калды...

...Ике көннән оныгым Тимербулатка 6 яшь тула. Арабызда 55 ел гомер ята. Ул – мине бу дөнья белән бәйләп торучы җепләрнең берсе. Аның белән тагы күпме гомер яшисе калды икән. Бәлки биш елдыр, бәлки 15 елдыр. Уйлап карасаң, уелып китәрлек. Тимербулаттан сорыйм:

– Тагы синең белән күпме яшәрбез икән?

– Күп эшләсәң, тиз үлмәссең! – дип юата мине бәләкәй философ».

Күпме гомерем калды икән, күпме яшәрмен икән дигән сорауны әткәй еш бирә иде. Ничә тапкыр үлем алдында калган кешегә аның шулай озак яшәве үзенә дә гаҗәп тоелгандыр, мөгаен. Тимербулат белән шушы сөйләшүдән соң, әле ул 24 ел яшәде. Тимербулатны өйләндереп кенә калмады, аның балаларын да күрде. Ул яктан әткәйнең күңеле тыныч булгандыр дип уйлыйм.

***

Әткәйнең фәлсәфи кичерешләрен китерәсем килә. «Курку белән иҗат үзара сыешмый, – ди торган иде әткәй. – Куркакның иҗат кешесе булырга хакы юк. Ул эпигон – иярчен булырга мөмкин. Көнкүреш авырлыкларыннан, бөлүдән, төрле сырхау-авырулардан, хакимият башында торучыларның кырын карашыннан, усалларның гайбәтеннән, хатынының үпкәләвеннән курка икән – димәк, бу хәл иҗат энергиясен зәгыйфьләндерүгә, параличка китерәчәк. Мин герой түгел. Үземнең бәйсезлегемне күрсәтеп йөрмәдем. Ләкин ул бәйсезлек миндә бар иде. Мин нәрсәне булса да югалтырмын дип, беркайчан да калтырап төшмәдем. Шулай булса, бернәрсә дә эшли алмаган булыр идем».

## Молотов белән очрашу

1966 елның язында КПССның XXIII съезды була. Бу съездга ике шагыйрь – Мостай Кәрим белән Рәсүл Гамзатов делегат итеп сайланганнар. Иртәгә съезд башланасы көнне Гамзатов дустына ул замандагы хакимияткә яраксыз дигән ярлык сугылган Молотовның хәлен белеп кайтырга тәкъдим итә. Алдан шалтыратып-нитеп тормый, ике шагыйрь СССРның элекке җитәкчелегендә икенче кеше булган Молотовның фатирына юнәлә. Бу фатирда Рәсүл Гамзатов булгаласа да, әткәйнең беренче тапкыр килүе икән. Һәм ул фатирның бик тыйнак җиһазлануына игътибар итә. Хуҗабикә өстәл кора, табынга шәраб та, коньяк та куела. Сөйләшә башлыйлар. Молотов сүзгә саран, бик ачылып китми. Артык сүз ычкындырмаска тырыша. Ләкин шагыйрьләр чишелеп, шапырынып китәләр, берсен-берсе уздырып «беренче номерлы ленинчы» Молотовка багышлап, тостлар әйтәләр.

...Ә инде иртәгесен иртән Мостай янына Обкомның беренче секретаре Зыя Нуриев килә дә пешерә генә моны:

– Менә Хуҗа Насретдиннар! Утыралар, кем ленинчы номер бер, кем ленинчы номер биш дип, сүз куерталар. Кич белән бөтен делегацияне җыеп, сезнең тәртипне тикшерергә кирәк булачак.

Шагыйрьләр булачак күңелсез хәлләргә әзерләнәләр. Ләкин кичкә чаклы аларның баш очындагы кара болытлар Брежневның катнашуы аркасында тарала да китә. Ул вакыттагы КГБ җитәкчесенең рапортыннан бу хәл турында белгәч, Брежнев Семичастныйга:

– Әллә, чынлап та, шул ике шагыйрьнең кунакта булуын тикшерүдән дә мөһимрәк эшләрең юкмы синең?! – ди.

## Төреп бир!

Әткәй Кабарда-Балкарда Кайсын Кулиевта кунакта була. Дусты аны Чегем шарлавыгын күрсәтергә тауларга алып бара.

– Мостай! Мин сиңа шушы шарлавыкны, шушы матурлыкны бүләк итәм! – ди, Кайсын шагыйрьләрчә ике кулын колачлап җәеп.

Мостай Кәрим елмая да шул ук рухта үзенекен әйтә:

– Төреп бир!

### Дон Кихот

Әткәйнең эш өстәлендә өстәл лампасы янында бронзадан ясалган Дон Кихотның кечкенә генә сыны бар иде. Әткәй ярата иде Сервантесның ул героен.

Бервакыт аннан: «Язучылар китап укыйлармы, аларның укулары башка китап укучыларныкына охшамаган дип әйтәләр, бу дөресме?» – дип сораганнар.

– Хәтта әтәчләр дә бер-берсен көнләшеп тыңлый. Бер генә җырчы да бу хисләрдән азат түгел. Минем укуым – профессиональ уку. Мин – бик беркатлы укучы. Язылган бар нәрсәгә дә ышанам. Минем өчен иң дөрес китап – «Дон Кихот». Тик акыл белән уйлап карасаң, анда бер генә дә дөрес нәрсә юк. Ләкин безнең һәрберебездә дә, әз генә булса да, Дон Кихот утыра. Монысы инде чын дөресе.

### Айгөл иле

Кызыбыз Айгөл, әткәйнең беренче оныгы, 1971 елның 5 маенда туды. Әткәй ул вакытта Украинада иде. Аның «Айгөл иле» исемле пьесасын, Львовта дип хәтерлим, Леся Украинка исемендәге театрда куйганнар, ул премьерага киткән иде. Әткәй премьераны карап, Мәскәүгә кайткан вакытта мин әле бала тудыру йортында идем. Алар Илгиз белән икесе хәл белергә килгәннәр, мин алар белән ачык тәрәзә аша сөйләштем. Көннәр җылы иде инде. Алар миңа карап, нәрсә әйтергә белми торалар. Беренче булып, мин сүз куштым:

– Әткәй, премьера ничек узды?

– Әйбәт, – диде ул. – Миңа ошады.

– Минем дә премьера әйбәт булды, – дидем мин. – Айгөл исемле бер онык алып кайттым үзегезгә!

– Безне сөендердең! – диде әткәй, елмаеп. – Дәвамлы булсын!

Дәвамлы булды. Нәкъ 8 елдан, бу юлы инде 5 апрельдә улыбыз туды. Без озак кына исем таба алмадык. Әткәй тәкъдим итте. «Нияз дип куйсагыз, ничек булыр?» – дип сорады. Без ризалаштык. Менә шулай.

Айгөл тугач, безгә миңа ярдәм итәргә дип каенанай Мәскәүгә килгән иде. Баланы коендырырга ярдәм итте, биләргә өйрәтте. Нияз тугач та килде, калдырмады. Шунда әнкәй миңа: «Бездә ир бала тапкан хатынны уңган хатын диләр, ә инде кыз бала тапкын хатынны изге хатын диләр. Син безнең уңган да, изге дә булып чыктың бит әле!» – дигән иде.

### Прометей

1978 елда Башкортстанның курчак театрында Мостай Кәримнең «Ташлама утны, Прометей!» дигән пьесасын театрның баш режиссёры,

танылган Владимир Штейн сәхнәләштергән иде. Шунысы кызыклы: авторны да гаҗәпләндереп, бу пьесаны сәхнәгә куяр өчен байтак вакыт юл бирмәделәр. Әткәй үзе дә аптыраган иде бу хәлгә. Чөнки аның һәр язган әйберен күтәреп алалар иде. Спектакль, пьесаларын көтеп торалар. Ә монда цензорлар сәяси проблема күргән. Имеш, Зевс персонажында ул заманда хакимияттә утыручы җитәкче белән охшашлык бар дип тапканнар, куярга ярамый дигәннәр. Ниһаять, курчак театрына рөхсәт бирелгән. Курчаклар гына бит, әйдә, уйнасыннар! Ләкин бу спектакльдә Зевсны да, Прометейны да курчаклар түгел, тере артистлар башкарган.

Ул көнне театрда аншлаг. Антик дәвер персонажлары әйткән сүзләрдә бүгенге заманның проблемалары яңгыраганны тамашачылар аңлый. Тамашачылар арасында Обкомның идеология буенча өченче секретаре Таһир Ахунҗанов та була. Ул бик бирелеп, бер сүзне дә игътибарыннан читкә җибәрми карый спектакльне.

Спектакль тәмамлангач, тамашачы артистларны аягүрә басып алкышлый. Бу алкышларга Ахунҗановның да кушылмый чарасы юк.

Ул әткәй янына килеп, аның кулын кыса һәм болай ди:

– Рисковый кеше дә инде үзең! Курыкмыйсың!

– Таһир Исмагилович! Бу алкышларга кушылып, син дә батырлык күрсәттең бит әле! – дигән Мостай Кәрим.

## Казан кунаклары шагыйрь янында

Горбачёвның эчкечелеккә каршы кампаниясенең иң кызган вакытында, искерткеч эчемлекләр бик тыелган заманда, Уфага Татарстан кунаклары килеп төшә. Ул Башкортстанда Татарстан көннәре белән бәйле чара булуы белән дә истә калган. Делегация башында Обкомның беренче секретаре Гомәр Усманов, шулай ук хөкүмәт рәисе Минтимер Шәймиев та була. Килгән-килгән, Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим белән очрашырга телиләр. Икесе дә хәләл җефетләре белән, делегациядә шулай ук язучылар да була.

Әлбәттә, Мостай Кәрим гаиләсендә бу дәрәҗәле кунакларның килүе турында беләләр, әзерләнәләр. Бер генә сорауга җавап таба алмыйлар. Өстәлгә исерткеч эчемлекләр куяргамы, юкмы? Куйсаң да – ярамый, куймасаң да – уңайсыз. Кунаклар килгәнче бу мәсьәлә чишелмичә кала...

...Кунаклар килгәннәр, күрешкәннәр, кочаклашканнар. Алар әле табынга утырганчы, әткәйнең эш бүлмәсенә – кабинетка кергәннәр. Кунакларны кабинетның бәләкәй булуы гаҗәпләндергән.

– Мостафа Сафич, – дигән Шәймиев. – Сезнең эш бүлмәгез бигрәк бәләкәй икән бит. Минем шагыйрьләр шигырьләрен язганчы, өстәл тирәсендә байтак кына әйләнеп йөриләр, шуннан соң гына шигырьләре туа дип ишеткәнем бар иде.

– Андый язучылар да бардыр, юк димим. Кемгәдер зур заллар кирәктер. Мине шушы кечкенә кабинетым тулысы белән канәгатьләндерә. Мин бит шигырьне республика буенча йөргәндә язам. Ә безнең республика бик зур, Швейцариядән өч тапкыр зуррак дип әйтәләр, матурлыгы турында әйтеп тә торасы юк! – дигән әткәй.

Язучының кабинетын караганнан соң кунакларны табынга чакырганнар.

Өстәл тулы ризык, ни генә юк! Безнең әнкәй аш-суга бик оста иде. Андый чакта ярдәмчеләре дә була торган иде аның. Ризык – җаның ни тели, ләкин сөйләшү һич җанланып китә алмый икән, чөнки партия кушуы буенча табында «коры закон». Шунда Минтимер Шәрипович түзмәгән, торып баскан да:

– Сез мине гафу итегез, хөрмәтле җәмәгать, дуслар! Бу болай булмый инде. Мин 600 чакрым юлны үтеп, Мостай Кәрим янына килгәнмен икән, аның сәламәтлеге, гаиләсенең иминлеге өчен тост әйтми китә алмыйм инде, – дигән.

Ул әйтеп бетерергә дә өлгермәгән, биш йолдызлы әрмән коньягын күтәреп, горур адымнар белән әнкәй килеп кергән.

Бу тәкъдимгә бик сөенгән әткәй, коньякны бокалларга койган да:

– Минтимер, синең тәвәккәл йөрәкле кеше булуыңны белә идем. Син би-и-ик кыю кеше дә булып чыктың бит әле! – дигән.

## Башкортстан күге

Бервакытны әткәйне Мәскәүгә партиянең Үзәк Комитетына чакыралар. Ул азрак каушап, билгеләнгән сәгатькә КПССның ҮК секретаре Николай Петрович Поспелов янына килеп җитә. Исәнләшәләр, күрешәләр. Андый чакларда әйтелә торган сүзләр әйтелә. Партия начальнигы Башкортстан язучылары арасындагы иҗади атмосфера белән дә кызыксынып ала. Аннан соң инде турыдан-туры үзенең планнарын ачып сала.

– Җитәкчелектә сезне Мәскәүгә эшкә чакырып, РСФСР Язучылар берлеге секретаре итеп кую нияте бар. Фатир мәсьәләсе хәл ителәчәк, сез моңа ничек карыйсыз? – дигән.

– Ә сез Башкортстан күген Мәскәүгә күчерә аласызмы? Шигырьләрем тусын өчен мин көн дә күккә карыйм бит! – дигән Мостай Кәрим.

Поспеловның әйтер сүзе калмаган. Шулай саубуллашканнар.

## Автограф

Әткәй китап кибетләрен ярата иде. Иске китаплар сатыла торган букинист кибетләрендә дә булгалый иде. Бервакыт Уфада Ленин урамы белән Коммунистическая урамы кисешкән йорттагы иске китаплар кибетендә әткәй үзенең китабын күреп ала. Ачып караса, автографы да бар. Мостай Кәрим бүләк иткән китап.

Ул бу китапны сатып ала да, өйгә кайткач, танышларына шалтыратып, бу китапны бүләк итеп биргән кешенең адресын эзләтә. Адресны табып бирәләр. Әткәй адрес буенча китапны хуҗасына җибәрергә ниятли. Өйдәгеләр каршы килә: уңайсыз бит инде, ул синең китапны кибеткә сатарга куйган, ә син аны кире җибәрәсең диешкәннәр.

Әткәй бу карарында катгый була.

– Кеше турында алай начар уйламагыз әле. Бәлки аның хәле мөшкелләнгәндер, тиз генә акча кирәк булгандыр. Ул китапның үземә туры килүенә мин бик шат, димәк, мин аны хуҗасына тапшырырга тиеш. Мин моны, беренче тапкыр автограф белән биргән вакыттагы кебек, чын күңелемнән эшлим, – дигән әткәй.

## Шөкер ит

– Бик озак еллар күзәтүдән соң, шуны ачыкладым, – диде әткәй беркөнне. – Рәхмәтсез кеше, ягъни рәхмәт әйтә белмәгән кеше, барыбер игелек күрми. Игелек күргән чагында да, ул шөкер итә белмәве аркасында, ризасызлык күрсәтә, үзенә кагылган һәр нәрсәнең тик кире ягын уйлый. Мәсәлән, йөз сумлык файда күргәндә дә, моңа кадәр биш сумлык зыян күргәнен онытмый, шуны уйлап, зар елый. Икенче бер кеше йөз сумлык зыян күргәндә дә: «И-и, нигә пошынырга, әнә теге көнне ун сум файда алган идем бит», – ди. Мин икенчеләр исәбендә. Шөкер, әлегәчә бөлеп калмадым.

## Хәрәкәттә – бәрәкәт

Әткәй көндәлекләренә еш мөрәҗәгать итәм. Биредә аның кәефе дә, фикере дә, вакыйгаларга мөнәсәбәте дә бар. Әйтерсең ул тере, ул үзе минем белән бу хакта сөйләшә, бәхәсләшә, минем сүзгә дә колак сала кебек. Ул тыңлый белә торган кеше иде. Мин дә аннан тыңларга өйрәндем, ләкин сабырсызлыгым аркасында зирәклек миннән һаман читтә йөри. Шуңа күрә бәхәсләрдә аның фикере һәрвакыт җиңеп чыга.

## Көндәлекләрдән

19.09.96. «Икенче көн инде чирләп ятам, – дип яза әткәй. Температурам 38гә җитте. Чирләү алама, әлбәттә. Ләкин адәм баласына чирләп алырга кирәк кайчагында. Дөньяның кадерен белер өчен бик кирәк эш. Иң хәерлесе, мөгаен, ике чир белән алмаш-тилмәш чирләүдер.

Шаяруын шаярам да, чирем озаккарак китте. Ә миңа иртәгә Мәскәүгә китәргә кирәк. Тәвәккәлләргә туры килә инде. Иң начары – күңел төшенкелеге. Менә бу җырдагы шикелле:

«Күтәрелми күңелләрем
Томанлы көннәр кебек».

Шулай да китәргә булдым. Мәскәүдә шәбәермен дип уйладым. Әле хәтеремә килеп төште. Миңа 6-7 яшьләр булгандыр. Әллә кызамык чыгарам инде, байтак кына чирләп яттым. Бер көнне атаем Чишмәгә барырга җыена. Мине киендерергә кушты.

– Чирле бит әле, – диде олыинәем, – өзлегүе бар.

– Өзлекмәс, юлда терелер генә. Кеше юлда авырмый ул, – диде атаем.

Кичкә әйләнеп кайтуга тәмам савыктым. Чишмә станциясендә атаем паровоз кранын ачып су алды. Шуңа шаккаттым. Моңарчы җир тетрәтеп узып киткән паровозларны гына күргәнем бар иде.

...Ә менә бу юлы үзем берсен дә тыңламадым, тискәреләнеп юлга чыктым. Хәрәкәттә – бәрәкәт. Хәрәкәт итәргә кирәк. Югыйсә өч нәрсәгә килеп төртелдем: дару, кан басымын үлчи торган аппарат, градусник. Атаем сүзенә таяндым: юлда терелермен әле.

Мәскәүгә килдем килүем, тик чирләүдән туктамадым. 12 көн буе чирләп яткач кына кайтып киттем Уфага. Җиде яшьлек бала юлда терелсә дә,

77 яшьлек карт савыкмады. Торуым Илгизләрдә булды. Нәзифә өйдә юк, Чехиядә командировкада иде. Илгиз Динора Гаяновнага шалтыратты.

Мин Илгизгә әйтәм: «Улым, – дим, – миңа кырынырга әзерлә әле. Үлеп китсәм, болай килешмәс, адәм алдында оят».

(Бәлки Динора Гаяновнага кырынмыйча күренәсе килмәгәндер. Әткәй һәрвакыт егет кеше булып кала белде. Динора Гаяновна – гаилә дусты. Заманында СССР Мәдәният министрлыгында театрлар бүлеген җитәкләгән. Аның бабасы – Гатаулла Баязитов, Петербургта татар телендә басылган беренче вакытлы матбугат – «Нур» газетасын чыгаручы, татар матбугатына нигез салучы шәхес буларак билгеле. Динора Гаяновна дарулар китергән. – *Н.К.*)

«Бүген (9.12.96) озак көттергән кар яуды, – дип язган әткәй. – Дөнья яктырып киткәндәй булды.

Илгиз миңа әйтә: «Әткәй, үзеңне сакла, йөрәгеңне кызган», – ди. «Курыкма, улым. Мин үлгәч, минем йөрәгем өч көн тибеп ятар әле», – дим аңар».

Әткәйнең җорлыгы беркайчан да югалмады. Бигрәк тә аның шаяртуын аңлаганнар янында. Шаяртуны аңламаучылар да бар бит ул.

**Мостай әйткән:** «Үз гомерләрендә кешеләр бер-берсенә күп нәрсәне әйтергә өлгерми калалар. Йә тартыналар, йә шартлары туры килми. Шуларның иң үкенечлесе: әйтелмәгән рәхмәт белән әйтелмәгән мәхәббәт».

«Ниндидер бер яман, явыз закончалык. 20-30нчы елларда иң куркыныч дәһриләр (сугышчан Алласызлар) мулла балалары иде. Хәзер кичә генә ата коммунист булып йөргәннәр хаҗга баралар, мәчет юлын таптыйлар, мулла булырга да хыялланалар».

## Көндәлекләрдән

15.10.97. «Бу атнада Ромен Роланның «Истәлекләр»ен, Фёдор Шаляпинның «Гомер турында повесть» китабын, Зәки Вәлидинең «Хатирәләр»ен караштыргалап утырдым. Әгәр дә 30-40 еллар элек бу китапларны тырышып өйрәнгән булсам, шул ук вакытта шушы бөек шәхесләрнең эшләгән эшләренең күләмен һәм эчтәлеген күз алдыма китерә алсам, үтә кыйммәтле сабаклар үзләштерер идем. Хәзер үз-үземә шелтә генә ишетәм. Извлёк бы урок, теперь извлекаю укор. Укор за то, насколько тощ и хил итог моих усилий, своего труда. Обидно! Биш көннән соң миңа 78 тула».

**Мостай әйткән:** «Народ России верит двум вещам: сплетням о высшей власти и обещаниям, лживым посулам той же власти. Без веры не живём!»

16.02.98. «Без кичерешләрдән, күңел тетрәнүләреннән сакланырга тырышабыз, гомеребезне саклыйбыз, янәсе. Ә бит сәламәт агачларның яфраклары давылларга да бирешмиләр, хәтта ныгыйлар. Ул яфракларны кортлар гына һәлак итә ала. Адәмне кичерешләр түгел, үкенечләр какшата.

Әй, агалар гамьсез кар сулары,
Әй, куана сабый елгачыклар,
Әйтерсең лә алар гомерлеккә,
Хәтта мәңгелеккә юлга чыккан.

Мин дә шулай бастым сукмагыма,
Юлның очы юк дип, имештер дә...
Юл башланган икән, азагы бар,
Кирәк шуның белән килешергә».

## Туган тел һәм хакимият

Милли республикаларда ил башлыгы үзенең туган телен белергә тиешме? Бу турыда бәхәсләр дә бара, каршылар да бар. Милли телне белүнең бернинди әһәмияте дә юк диючеләр күбәя. Алга таба милли республикаларның нигезенә салыначак нәрсә түгелме бу? Шуның хакында әткәй, тарихи чынбарлыкны китереп, үз фикерен белдерергә омтыла:

«1714 елда Англиядә патша итеп куярлык кеше тапмыйлар. Шуннан алар тәхеткә немец кешесен китереп утырталар да аңар Георг I дигән исем бирәләр. Ул инглизчә бер авыз сүз дә белмәгән, өйрәнергә дә теләмәгән. Бу хакта үзенең «Бөтендөнья тарихына караш» дигән китабында Җавахарлал Неру: «Англия патшасы инглиз телен белми!» дип шакката. Аның улы Георг II дә инглиз телен чак кына аңлаган. Хәзерге заман теле белән әйтсәк, сүзлек белән генә. Ул патшаларның халыкта эше булмаган, халык та аларны бар дип тә белмәгән. Бу – Урта гасырлар тарихы. Хәзер бездә тәхеткә үрмәләүчеләр, ягъни Башкортстан президенты урынына дәгъва итүчеләр – тел, мәдәният, республиканың төп халкының психологик тормыш рәвешен белү ягыннан телсез дә, саңгырау да».

## Заманча җырларга караш

Каенатай тормышның һәр чагылышына үз бизмәне белән бәя бирә торган иде. Бәлки кемнәрдер аның белән килешеп бетмәс. Ләкин мин аның күзләре белән күрергә өйрәндем. Минем үземнең дә бизмән бар, ләкин акыллы үрнәк булганда, үлчәү җиңелрәк.

Заман җырлары турында никадәр тәнкыйть! Ләкин андый җырлар бетми, күбәя генә. Җырчылар турында әйтеп тә торасы юк. Әткәй болай дип язган: «Заман җырлары турында уйланам. Ә күңелемдә «Биеш», «Сәлимәкәй», «Буранбай», «Колый кантон», «Сандугач», «Түрәкәй», «Сибай», «Таштугай», «Ашказар» һ.б. Татар, рус җырлары да колагымда яңгырый. «Тәфтиләү», «Уел», «Кара урман», «Сарман», «Степь да степь кругом», «Есть на Волге утёс», «Славное море священный Байкал». Бу җырларның сыны, гәүдәләнеше исе, төсе, хәйран калырлык моңы бар. Һәрберсенең асылында тирән драматизм ята. Бөтенесе дә күз алдына килеп баса.

Хәзерге җырларның күпчелеген тыңлау – төбе тишек бокалдан шәраб эчү шикелле. Шәрабны сосып аласың, авызыңа җиткәнче түгелеп бетә. Әлеге җырлар да күңелгә җиткәнче һавада шартлап юк була.

Андый җырларның ике генә сүзе бар:

Беренчесе: яратам, яратам, яратам, яра, яр...

Икенчесе: әниемне сагынам, сагынам, сагынам, сагын...

Кешеләрне бер-берсе белән якынайта, оештыра торган җырлар бетеп бара. Әгәр дә мәйданда, табында яшь-җилкенчәк бер-берсенә кушылып җырлый икән, алар ихтыярдан бер-берсенә теләктәшлек, якынлык күрсәтә. Ягъни аларның күңелләрен моң берләштерә».

**Мостай әйткән:** «Поэзия – это как балет. К ней поздно приходить нельзя, просто невозможно. Поэзия – это удел молодости, даже юности. Только с той разницей, пришедший в поэзию в юности, там может остаться на долго. В балете – нет».

### Халык шагыйре

10.05.02. «Аралбаев шалтырата. Киңәш сорады. Рәми Гариповның «Китап» нәшриятында чыгып яткан әсәрләр җыентыгында шундый раслау бар икән: «Мостай Кәрим ул башкорт халык шагыйре түгел, аңа «Башкортстанның халык шагыйре» дигән исемне дөрес биргәннәр, «Башкорт халык шагыйре» дигән исемне алыр кешегә өметебез бар», – дигән икән. Әйбәт өмет.

Кадим әйтә: «Бу нәрсә четерекле түгелме?» – ди. Мин шунда җавап бирдем: «Минем нинди шагыйрь, кем шагыйре булуым турында фикер бар икән, шулай калсын. Әйтүеңчә, китапның баш редакторы шушы текстны калдыру ягында икән, димәк, минем турында бүген дә фикер төрлелеге бар. Син дә икеләнәсең... Шулай калсын», – дип кабатладым. Киләчәктәге урынымны билгеләү минем хәстәрем түгел. Бу инде башкорт җәмәгатьчелегенең, зыялыларның интеллектуаль дәрәҗәсенә, нинди карашлар, нинди бәһаләр һәм үлчәүләр белән хөкем йөрүенә бәйләнгән. Бәлки ул чакта безнең фәлән-фәләннәр югары өлгедә исәпләнер. Моңа дәгъва итүчеләр байтак. Ул рух, акыл, талант биеклеген, шушы бәһа бирүчеләрнең дәрәҗәсенә тап килүе бик ихтимал. Талант талантсызлыкны бервакытта да күккә күтәрми, сыйпаса, аркасыннан сыйпап куя, ә талантсызлар талантсызлыкны күккә чөя, ул моның белән үзен дә чөя, үзен раслый».

***

Әткәйнең XXI гасыр башлангач язган көндәлекләрендә рус телле язмалар ешрак күзгә ташлана. Күрәсең, теге яки бу язманы планлаштырганда, ул русча уйлагандыр. Мин аларның берничәсен тәрҗемә итеп бирсәм дә, кайберләрен ничек язса, шулай калдырырга булдым. Чөнки бер язучы дустым: «Хәзер инде русча укымаган, аңламаган кеше юк. Калсын рус телендә», – дип киңәш итте.

### Көндәлекләрдән

7.09.01. «Боже! Как потрясающе сказал однажды Фазиль Искандер: «Совесть – это реальность Бога». Я всю свою сознательную жизнь поклонялся этой реальности Бога. Ибо оно, это божество во мне. С ним я обращаюсь без посредников. Посредники нужны тем, кто убог и ущербный духом. В этом отношении я себя убогим не считаю».

### Дача чәчәкләре

Каенанам шактый вакыт урын өстендә авырып ятты. Кайвакытта иң якыннарын да танымый башлады. Әткәйнең шуңа йөрәге сызлана иде. Кайчагында әнкәй, ачылып китеп, берәр нәрсә сөйләсә, әткәй чиктән ашып куана иде. Көндәлектән бер өзек:

7.09.01. «Олег (кияү) белән дачага барып кайттык. Анда кот юк. Чөнки

анда без юк. Әле коелырга өлгермәгән кура җиләген бер стакан җыеп алдым, әле шиңәргә өлгермәгән соңгы чәчәкләрдән букет ясадым. Кайткач, чәчәкләрне Раузага тоттырып, иснәтеп карадым. Озак иснәп торды. Шуннан җиләкләрне каптырдым. Байтак капты да болай диде: «Син мине бик зурладың бит әле. Рәхмәт».

Кичә шаярып аңар: «Син минем княгиням бит», – дидем. Ул да җавапсыз калмады: «Әгәр сиңа кияүгә чыкмасам, княгиня була алмас идем», – диде. Аңы шулай кайсы вакыт ачылып китә. Шул чакта сүзе гаҗәеп мәгънәле була».

## Язучы һәм театр

Әткәйнең көндәлекләрендә хастаханәдә ятканда язган истәлекләре байтак кына. Күрәсең, беркая барасы түгел, вакыт та бар, сәламәтлеге авыр булса да, чыдарлык булгандыр инде. 30.10.01 язган истәлекләре. Датага караганда, әле яңа гына аның туган көне узып киткән көннәр икән...

«Минем палатага Нурия Ирсаева – М.Гафури исемендәге театрның бик талантлы артисткасы (прима) кереп утырды. Зарлана. «Театрның хәле әйбәт түгел», – ди. Мин уйланып калдым. Театрның бу көнгә төшүе Исрафиловтан башланды. Беренче елларда бик әйбәт, талантлы спектакльләр куйды. Үзен зур художник итеп раслады. Соңгы елларда ваклана төште, вак кәмит, «шаккатыргыч» тамаша белән мавыкты. Башкаларның фикере белән исәпләшмәс булды.

Шулай да Исрафилов белән Хановны кире кайтарырга иде театрга. Әгәр алар, мәсәлән, хоккеистлар булса, зур акчалар түгеп кайтарырлар иде. Артистның бәһасе түбән шул. Шашкада уйнап, чемпион булган бер кыз бала турында доклад саен сөйлиләр, әдәбият, музыка, живопись, театр турында бер сүз дә юк. Шундый заманага җиттек, күрәсең. Хәер, бу җәһәттән Мәскәү бөтенләй мәгарәдә яши. Ризык табулары да мәгарәдәгечә – көпә-көндез аталар, шартлаталар, яндыралар, үтерәләр».

## Көлмәч

«Нурия сөйләгән бер көлмәчне (анекдотны) язып калдырмый ярамас. Менә ул», – дип тәкъдим иткән әткәй. «Көлмәч» сүзе миңа бик ошады әле.

«...Бик алдынгы сыер савучыны диңгез буена ялга, курортка җибәргәннәр. Урап кайткач, ире сорый икән:

– Син анда, Фаягөл, ир-ат белән чуалып йөрмәдеңме? Ул курорт дигәне адәмне station аздыра икән диләр...

– Кит моннан! Ничек башыңа шундый уй килә дә телеңнән шундый сүз чыга! Оятың бармы чак кына? Рәнҗеттең нахакка! – дип, ирен өтеп ала хатын.

Ире гафу үтенә. Кич була. Балалар йоклап китә. Болар түшәккә ята. Татлы мәхәббәт минутларын кичерәләр. Шуннан Фаягөл дөньясын онытып әйтеп сала:

– Иии... Үзеңнекенә җитәме соң инде!..»

Халык сүзе – Аллаһ сүзе түгел...

«Халык сүзе – Аллаһ сүзе» дип әйтүчеләрне тыңларга кирәкми. Чөнки халык төркеме тилеләр белән бер.

Авторы: Алкуин (735–804), Англия тарихчысы.

Тулысы белән килешәм: Мостай Кәрим (1919 –...)

«Халык төркеменә йогынты ясыйсы килгән кеше шарлатанның шар яруына мохтаҗ».

Генрих Гейне (1797–1856).

Бу, күрәсең, безнең В.В.Жириновский турында аның чыгышларына кадәр 150 ел алдан әйтелгән.

**Мостай әйткән:** «Миннән еш кына «Синең хәтер начар түгел. Нәрсәдән икән?» дип сорыйлар. Нәрсәдән түгел, нәрсә өчен дим эчемнән генә. Миңа үземнең тумышым белән бары тик Чишмә районыннан икәнлегемне онытырга ярамый. Соңгы елларны мин моны ныграк сизә башладым. Үземә карата гына түгел, күп нәрсәгә карата шулай».

## Ялганламасаң – ышанмыйлар!

Бервакыт Чишмә Сабан туенда Келәшнең бәйрәм шаукымы белән бераз кызып алган бер төркем ирләре Мостай Кәрим янына килгәннәр.

– Без – синең якташларың! Танымыйсыңмы әллә? Мин – Талип малае. Син аның турында язган идең. Ә ул – Әсгать улы. Синең белән ачыктан-ачык сөйләшергә булдык әле. Син безне мыскыл итеп язгансың бит. Нигә инде безнең гаиләне ярлы, фәкыйрь, ачлы-туклы яшәгәннәр дип язарга иде? Син бит Келәш турында барысын да бутап бетергәнсең. Сугышлар инде башка урамда булган иде ул чакта. Сукыр карчык гел икенче тыкрыкта яшәде.

Авылдашлар берәм-берәм үзләренең ризасызлыкларын белдерә башлаган. Авыл совете рәисе бу хәлләрне күреп, әткәйгә ярдәмгә омтылган.

– Әйтсеннәр, әйтсеннәр, туктатма, – дип тынычландырган аны әткәй. Аннан соң авылдашларына борылып: – Егетләр! Минем язмаларда уйлап чыгарылганы да, булмаганы да бик күп. Әгәр дә мин аларны уйлап чыгармасам, укучы миңа ышанмас иде. Шулай итеп, язучыларга алдашырга да туры килә. Гаепләмәгез... – дигән.

## Көндәлекләрдән

30.03.01. «Апрель килеп җиттеме, татар язучыларының (шагыйрьләрнең бигрәк тә) миңа булган мәхәббәтләре кабына да китә. Менә язның көче нинди илһамлы! Яз тылсымы күңелләрне шулай җилкетә икән дисәм... Апрель аенда Казанда Тукай премиясенә бәйге башлана икән! Карасаң, әлеге мәхәббәт бәйгедә катнашучыларда уяна икән. Алар турында бер кәлимә сүземне Комитетка язып җибәрүгә ишарә ясыйлар. Бөтенләй томана түгелбез, ишарәне аңлыйбыз. Күңелемә ошаган әсәрләр турында фикеремне йә Тукай комитетына, йә Шәймиевка язып җибәрәм. Быел да ишарә ясаучы булды».

## Уфа йортлары

Көндәлекләрендәге бер язмасында әткәй Уфада үзе яшәгән фатирлар турында язып, анда килгән кунакларны, данлыклы шәхесләрне, вакыйгаларны да искә алып китә. Шундый гади нәрсәләр турында язылган бу истәлек ни өчендер рус телендә. Минем аны укучыга татар телендә тәкъдим итәсем килде. Ул фатирларның барысы да миңа да бик якын,

ирем үскән, ирем торган, үзем килен булып төшкән урыннар. Димәк, анда минем дә җан җылысы калган. Алар тарих. Әткәй белән әнкәйнең танышкан йорты – ул минем өчен дә газиз. Анда тормасам да. Мин ул йорт хакында күпме ишеткән, күпме язган. Мин тормаган, ишетеп кенә белгәне Свердлов урамы, 49 йорт. Шул йортта ирем белән бергә уйнап үскән малайлар гомер буе безнең дусларыбыз булды. Әткәй язмасы:

«Кинәт кенә Уфада үзем яшәгән йортларны искә төшерә башладым. 1928 елда авылдашларда кунганым бар иде. Егор Сазонов исемендәге урамның 113нче йорты иде ул. 1935–1937 елларда педрабфакта укыганда, Карл Маркс урамындагы 31нче йортка урнашкан тулай торакта яшәгән идем. Аста ипи кибете иде. Инде пединститутта укыганда, Гоголь урамындагы 11 йортта бер ел тулай торакта яшәдем. 1938 елның августында Вәли Нафиков белән Достоевский урамындагы 47 йортка фатирга күчтек. Ул ике катлы агач өй иде. Без икенче катта яшәдек. Хәзер ул йорт юк инде. Без Рауза белән шул өйдә таныштык, 1941 елның апрелендә шул ук йортта өйләнештек. Безнең фатир хуҗасы Һәдия апа Раузаның әтисе белән бертуган иде. Шул йорттан мин фронтка киттем. Сугыштан соң да мин шул йортта яшәдем. 1947 елның сентябрендә безгә өч бүлмәле фатирның ике бүлмәсен бирделәр. Бараклар шикелле төзелгән, Свердлов урамындагы 49нчы йорт иде ул. Хәзер инде ул йорт та юк. 1953 елның декабрендә хөкүмәт безгә Ленин урамындагы 65нче йорттан өч бүлмәлене бирде. 1958 елның ноябрендә Обкомның беренче секретаре З.Н.Нуриевның турыдан-туры фәрманы белән безгә дүрт бүлмәле фатир бирделәр. Аның зур залы гына 35 квадрат метр иде. Нуриев шул чакта болай дигән иде: «Күп кенә күренекле мәдәният, әдәбият эшлеклеләре Уфага килгәндә, синдә кунак булалар. Синең йортың иркен булырга тиеш». Без анда төп-төгәл 40 ел яшәдек. Ул йортның стеналары минем күп кенә дусларымның, дәрәҗәле кунакларның тавышларын, шәүләләрен саклый торгандыр. Анда Константин Симонов, Рәсүл Гамзатов, Чыңгыз Айтматов, Сабит Муканов, Кайсын Кулиев, Хәсән Туфан, Давид Көгелтдинов, Әсхать Мөхтәр, Зөлфия, Сергей Михалков, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Әбдиҗәмил Нурпеисов, Михаил Дудин, Мирзо Турсун-Заде, Дмитрий Павлычко, Геворг Эмин, Яков Ухсай, Татарстан президенты Минтимер Шәймиев, Шукрулло, Лев Константинович Богуш (академик) төркем-төркем булып татар, украин, чуваш, азәрбайҗан, таулы алтай, казакъ, Ленинград язучылары киләләр иде. Чит илләрдән дә килгәләделәр, бәлки алай атказанган булмасалар да, күренекле мәдәният һәм әдәбият эшлеклеләре иде.

1999 елның гыйнварында без Әлфияләргә якын булыр өчен Энгельс урамындагы 5нче йортка күчендек. Раузаның авыруыннан соң (инде 5 ел) үземә генә көнкүрешне алып бару авырайды, Әлфиягә бигрәк тә. Яңа фатирга әкренләп ияләнәбез. Иске фатирыбызда 40 ел гомеребез торып калды, дуслар белән аралашу рухы калды. Биредә андый мохит юк. Стеналары салкын, алар минем дусларымның күңел, җан җылысы, рухлары белән җылытылмаган шул.

Мин Раузаның күңелен күрер өчен еш кына җыр чыгарып, аңар әйтәм:

Агыйделнең аръягында
Көтү-көтү боландыр.

Көн-төн сине уйлый-уйлый,
Диваналар буламдыр».

## Көндәлекләрдән

20.10.99. Әткәйгә 80 яшь тулган көн. Мин аның ул юбилеенда була алмадым. Чит илдә командировкада идем. Әткәйне котларга соңрак кайттым. Ул туган көне турында көндәлекләрендә язма калдырган.

«Менә айдан артык инде ыгы-зыгылы яшим. Октябрьнең 22сендә тантаналы җыелыш. Ә Рауза реанимациядә ята. Күңелдә бәйрәм юк. Радио, телевидение, гәҗитләр шаулый. Нык шаулый. Әйтерсең лә минем белән хушлашырга ашыгалар. Бу эшләр ихлас күңелдән эшләнәдер дим. Әмма мондый шау-шулар, кешеләрнең колакларын тондырып, миннән биздереп куймагае дип куркам. Ходай да (мөселман Ходае) торатaшка әйләнсә, бәсен югалтыр иде».

5.11.99. «Больницага яттым. Рауза янында булыйм дидем. Ул әле һаман реанимациядә. Җаныма урын таба алмаудан «История древней Греции» дигән китапны укый башладым. Аристофанның шундый юлларына тап булдым:

«Ведь демогогом быть – не дело грамотных,
Не дело граждан честных и порядочных,
Но неучей, негодных».

Без ничәмә дистә еллар бәйрәм иткән Бөек Октябрь бәйрәме көне. Ләкин бу бәйрәм юк инде. Әткәй үзенең көндәлекләрендә бу көнне билгеләми китмәгән. Алар әле һаман больницада.

7.11.99. «Бу көннең нинди бөек, нинди тарихи икәнен хәзер акыл гына бәяли, ә күпме генә теләсәм дә, әүвәлгечә рухи канатландыручы, җанны ямьләндерүче яктылык, җылылык тоя алмыйм. Бәйрәмне урладылар, бәйрәмне талап алдылар явызлар.

Рауза икенче катта. Сәгать саен янына төшәм, кулларыннан тотам. Тынычлана, хәтта куана. Ул сабый шикелле, беспомощная. Фикере нык бутала. Күңелдә борчу гына түгел, газап. Ни көтә безне?»

## Көнчелек турында

2002 елның 10 мартында көндәлегенә кергән сүзләрен әткәйнең үз авызыннан ишеткәнем бар иде. Биредә миңа сөйләгәннәрдән азрак кына аермалы җирләре дә бар икән. Шуңа күрә көндәлек мәгълүматларын да алдым бераз. Көндәлекләргә ул рус телендә кергән, мин тәрҗемәдә бирәм:

«Озын гына гомеремдә үземне көнчелек белән җәфалаганымны хәтерләмим. Ак көнчелекме ул, кара көнчелекме. Шулай килеп чыкты инде, соңгы 50 елда – мин аны хәйләсез, ялган тыйнаклыксыз әйтә алам – безнең, гомумән алганда, ярыйсы гына әйбәт булган әдәби мохиттә, миңа җитди көнләшерлек бирәү дә юк иде. Мин инде үземне табигатьтән шундый беркатлы кеше дип санамыйм, ләкин бу тарафтан үземне андый сынаулар алдына куярлык сәбәпләр булмады.

Мин искиткеч язучылар арасында булдым, ләкин безнең башкорт нормалары буенча алар миннән өстен түгел иде.

Инде көнкүрешнең матди якларыннан карасак, бу тарафтан безнең беребез дә көнчелек объекты була алмады. Бик бай яшәмәсәк тә, хәерче дә булмадык.

Ләкин минем хәтеремдә гомергә калган бер очрак булды.

Мин сугыштан үпкә чире белән кайттым, йөткергән саен кан төкерә идем. Бу чир балага йокмасын дип, Илгизне тәүлекле балалар бакчасында тоттык. Рауза кайчагында мине кулымнан тотып, урамга йөрергә алып чыга. Социалистическая урамы буйлап барабыз (без Социалистическая белән белән Достоевский урамнары киселешендәге йортта Раузаның апасында яшәдек.)

Бер өй янында туктап калдык. Ул йорт әле һаман да тора, исән. Без аякларбызга тиеп торган тәрәзәдән, подвалдагы фатирда гаҗәеп матур тормыш күрдек. Өстәл тора. Өстәлдә самавыр, чынаяклар куелган, стена кырыенда карават (тимер!), караватта чигелгән чәчәкле мендәрләр. Карават үзе корама юрган белән ябылган. Ә почмакта кулъюгыч эленеп тора. Аның астында – тазыяк. Карап торсаң, санап китәрлек әйберләр күп иде анда. Яшиләр бит кешеләр!

Үзләренең караваты, үзләренең өстәле, үзләренең урындыклары, үзләренең кулъюгычлары! Барысы да үзләренеке. «Менә шулай итеп яшәргә иде!» дип көнләшеп уйладым мин шул чакта.

Көннән-көнгә боегамын һаман
Сүнә барам.
Кызганычка каршы, сүнүемә
Күнә барам,
Күнә барам».

## Заманча тәрбия

20.02.05. Әткәйнең вафатына әле җиде ай вакыт бар. Аның гаме – тормышта, борчылуларында – милләт язмышы. Ул аларны күңеленнән көндәлекләренә күчергән. Мине гаҗәпләндергәне: соңгы еллардагы язмаларының күбесе рус телендә. Көндәлекләр булып басылганда, алар шулай калыр да. Ә монда минем аларны татар телендә бирәсем килә. Бүгенге көн белән бу язма арасында 19 ел вакыт узган. Үзгәрешләр бармы дип сорыйсы килә.

Әткәйнең җан ачысы: «Телевизордан тапшыру булды: «Тәрбия советлар вакытында әйбәт булганмы, әллә хәзерме?» дигән сорауга тавыш бирәләр. 52 процент кеше элек дип тавыш биргән. Ләкин тапшыруны алып баручы Швыдкой бәхәсләшә: советлар заманындагы казённый тәрбия – октябрёнек, пионер, комсомоллар, аның фикеренчә, бик начар. Тик менә үзе хәзерге вакытта яшьләргә нинди тәрбия бирергә кирәклеге хакында әйтмәде. Дискотекаларда, подъездларда, урам фонарьлары астында тәрбия алалармыни? Эх, Михаил Ефимович, хәйләлисең син! Театрга мөнәсәбәтле кеше буларак, син минем иптәшем идең. Хәзер алдашасың! «Яхшы укуның кирәге юк! Менә Наполеон да, Эйнштейн да мәктәптә начар укыган», – дисең. Син шул рәвешле наполеоннарны, эйнштейннарны тәрбияләргә тәкъдим итәсеңме? Шундый эшкә алынгансың, дөресрәге, халыкны

наданлатыр өчен нәзек коралга тотынгансың. Бу сиңа теләгән җимешләрне бирә торгандыр инде.

Илдә мәдәният белән җитәкчелек итә торган кеше шундый хәлгә барып җитсен әле! Менә күрербез әле, берничә елдан ул илне ташлап чыгып китәчәк. Тик Израильгә түгел, АКШка. Аның бүгенге көндәге хезмәте Американың безгә мөнәсәбәтле таләпләренә туры килә.

Туракларга икән, туракларга Россияне. Соңгы җебенә кадәр чишендерергә.

Нигә мин бу турыда кычкырмыйммы? Файдасыз! Мине беркем дә ишетмәячәк. Әле адәм көлкесенә калдырачаклар. Бар иде заманнар, үзәк матбугат чараларында сүзем үтә иде.

Үзәк телевидениедән еш кына бизнестагы уңышлары белән караклар, жуликлар, проституткалар мактана. Бигрәк тә проституткалар».

22.02.05.

## Яз хәбәре

«Тәүге тамчы тамды түбәдән...
Ә Җир шары шундый түгәрәк,
Унда океан, унда диңгезләр,
Таулар биек, чүлләр тигезләр.

Бөркет оча ашып кыяны,
Кояш тора күккә таянып,
Тик ерак бу тирә-әйләнәм,
Күзем күрә, күңелем шәйләми.

Тәүге тамчы тамды түбәдән,
Канат какты тик бер күбәләк.
...Ә Җир шары ерак – түгәрәк...»

## Дачада яңа өй

Мин Уфадагы дача турында байтак кына яздым. Дачага кайтырга ярата идек. Җәй көннәрендә балаларның да иң яраткан урыны иде дача. Ике катлы кирпеч йорт иде ул. Яшьрәк чакта бик зур булып күренгән йорт соңгы кайтканымда бик кечкенә тоелды. Сутыйлары чама белән 16 тирәсе иде бугай. Берничә төп карлыган белән чия агачын санамаганда, калганнары каен иде. Шунысын да әйтергә кирәк: дача уртасында биек, мәһабәт имән агачы бар иде. Без кайткан 70-80нче елларда ул каеннар әле яшь, бәләкәй булып, дачаны бизәп тора иделәр. Бизәп дигәннән, әнкәй өйгә керә торган баскыч төбенә ике яклап чәчәкләр утырта иде. Җәй буе хуш ис таратып торган флоксларны, әнкәй төсе дип, хәзер инде авылда үз бакчамда үстерәм. Әнкәйнең яз башында лаләләре белән ирислары чәчәк ата иде. Алар бетүгә сукмакларның ике ягында зур-зур ап-ак ромашкалар үсеп чыга иде. Җиләге дә, кыяр-помидорлары да үсә иде әнкәйнең. Җәй көне чәйне һәрвакыт карлыган яфрагы белән эчә идек. Әнкәй агачка зыян китерми генә, ул яфракларны ничек өзәргә кирәклекне дә өйрәтә иде. Чөнки аның һәр җирендә тәртип булырга тиеш, хәтта агач яфракларында да.

Ничәнче еллар булды икән, соңгы елларда инде, шушы ике катлы кирпеч өй янында бәләкәй генә мич ягып җылытыла торган агач өй дә барлыкка килде. Яздан килеп, олы өйне җылытканчы, эткәйгә эшләргә урын булсын

дип салганнар иде ул өйне. Анда бары тик бер бүлмә. Шул бүлмәдә бер карават, эш өстәле, өй уртасында мич – шулар гына сыйды да инде анда. Бәлки кулъюгыч, аның астында тазыягы да булгандыр. Аларын хәтерләмим. Әле әткәй белән әнкәй өйләнгәч тә, кеше тәрәзәсеннән күреп кызыккан фатирның күчермәсе булмады микән ул йорт дип уйлыйм хәзер. Хыялны тормышка ашырулары шул булгандыр, бәлки.

Бу кечкенә дачаның идән такталары шомартылмыйча гына салынган иде. Әткәй төзүчеләрне кызганып, мәшәкатьләндерәсе килмәгәнме, әллә дачага ярамаган тагы дип уйлаганмы, белмим. Бүрәнәләрне такта итеп ярганнар да, струклап-нитеп тормыйча җәеп тә куйганнар. Эшчеләр эшләп бетергәнче, ул идәннең карар җирен дә калдырмый пычратып бетергәннәр. Һаман да исемдә, без ике килен, әнкәйнең энесе Фуат абый хатыны Рәүфә апа белән ничә юкә мунчаланы чүбеккә әйләндергәнче шул идәннәрне юып, эш иткән идек. Әнкәй дә ул вакытта әткәйне битәрләп алды: «Нигә инде ул такталарны шомартмыйча салдырдың?» – диде. Мин шунда: «Ике тиле эшчән килен булганда, нигә шомартырга? Без әткәй хакына аларны тешебез белән тигезләп чыгарга да риза!» – дигәч, әткәй елмаеп: «Сезнең уңганлык бар инде, ну, телең тешеңә караганда да үткен синең!» – дип көлгән иде. Харап инде, телем үткен булсамы? Юк, юк әткәй монда ялгышкан!

Бик матур ул йорт дачада һаман тора әле. Ә инде иң гаҗәбе: йөзьяшәр, берничә колачка сыярлык имән агачы да тора! Аның янына озын өстәл, имән тирәли арка терәп утырырлык утыргычлар да ясалган. Әткәй килгән саен ул имән белән кул биреп исәнләшә, ягъни сыйпап үтә иде. Җәйләрен көн матур булса, өйлә ашын имән янында ашасак, иртәнге ашка махсус аш бүлмәсендә йә булмаса верандада утыра идек.

### Йоматау – дача урыны

3.09.92. Әткәй сөйләде: «Нәкъ 28 ел элек шушы йортта яши башладык. Башта Рауза белән килеп урынын сайладык. Бәләкәй генә алан уртасында матур түгәрәк имән. Аланның тирә-ягында 4-5 метр биеклегендә генә яшь каеннар. Бу җирдән Акманай күле, Кызлар тавы, Чагыл тавы, Бурсык тавы, Чытырлы, Бүләк, Юкәле күл урманнары күренә. Авылга (Келәшкә) иң якыны – Юкәле күл. Бала чакта йөгереп кенә шунда бара торган идек. Бу җирдән Келәш үзе күренми. Акманай авылының бер очы күзгә чак кына эләгеп кала. Өй каршындагы каеннар биек булып үсте. Яшь вакытта алар мине сокландыра иде, хәзер мине туган ягымнан аердылар. Шундый хәлләр килеп чыкты. Мин бит бу урында һәр көн саен туган кырларымны, тауларымны, урманнарымны – кыскасы, мине тирбәткән бишегемне күреп, намусымның чисталыгын, уй-фигыльләремнең, язган язмаларымның дөреслеген барлармын дип уйлаган идем. Шулай булыр дип ихлас инанган идем.

Имән дә исән. Әмма былтыр нык авырды, җәй уртасында кабыгы ярылып, суты ага башлады, түбәнге ботаклары саргаеп корыды. Киявем Олег аның ярасын сылап дәвалады. Байтак еллар әүвәл имәнгә әйткән идем: «Нык бул, дус, әгәр сиңа яшен кагылса яки каты суыклар туңдырса, мин дә имгәнеп һәлак булырмын. Бирешмә, картлач! Мин дә яшәргә телим бит», –

дигән идем. Хәер, кайсы чакта уйлап та куям шунда: «Вакыт җиткәч, бер яшен икебезне дә яндырсын иде», – дим. Әйткәндәй, бер тапкыр язгы яшен бераз шаяртып алды. Ләкин егарлык сукмады.

Менә шундый хәлләр. Бу йортка беренче тапкыр кергәч, мин күп нәрсәләр турында уйладым. Тик менә бу каеннар шулай биек, куе булып үсәрләр дә туган төягемне миннән ышыкларлар дип башыма да килмәде».

Имән әле һаман да исән. Әткәй белән әнкәй, Илгиз генә юк. Әгәр дә бу имән телгә килсә, күпме истәлекләр сөйләр иде...

## Имән

Өй алдымда минем имәнем бар –
Йөз яшәгән имән.
Чирек гасыр бергә көн итәбез,
Имән, синең белән.
Тәүге күрешүдә икебез дә
Ир-егетләр идек.
Картлык яки әҗәл уебызга
Чыкмады да иңеп.
Мин шатландым: һәр яз сыерчыклар
Синдә оя корды.
Син куандың, күләгәңдә тату
Табын гөрләп торды.
Синең белән мине заманалар
Әмма аямады.
Без нәрсә ул?! Ишелеп төште күпме
Дөнья кыялары.
Агач башына төшкән бәлаләрне
Азмы син үткәрдең,
Адәм башына төшкән казаларны
Күпме мин үткәрдем.
Мин әрнесәм, синең яфракларга
Кара кайгы кунды,
Күңелемне минем сындырсалар,
Ботакларың сынды.
Бер чак сиңа яшен сугылып китте,
Мин төбеңдә идем,
Без янмадык: «Болай булгач әле,
Без яшибез...» – дидем.
Ә шулай да безнең затларыбыз
Бик сабырдан бугай.
Синең белән, имән, икәвебез
Бер тамырдан бугай.
Менә икәү калдык. Табын тынды,
Китте сыерчыклар.
Икебезнең йөздә күпме бирчә,
Күпме җыерчыклар.
Мин китәрмен. Мине яндырырлар
Әүвәл(е)рәк синнән,
Дөнья бит ул, төрле чак булгандыр,
Рәнҗеп калма, имән».

## Банкир сыйлый

1.05.92. «26 апрельдә бөтен фронтовикларны, янә берничә язучыны банкир Кадыйров «Башкирия» ресторанына алып кереп сыйлаган. Бишәр

мең сум акча да биргән. Шакир Янбаев миңа да чакыруны җиткергән иде, биш мең сум турында да хәбәр салган иде. Ә минем тәннәрем чымырдап китте. Димәк, президентлыкка төбәп йөргән банкир язучылардан команда төзергә маташа. Безнең язучылар шул тиклем дә вак, мескен микәнни? Бөтенесе дә ачыктан-ачык күренеп тора бит! Сатып алалар боларны. Нишләп шуны аңламыйлар «каләм осталары»? Рамазан Өметбаев белән алдан көрешкән идек. Бармаска булган иде – барган! Ничава шәхесләр! Афәрин!

Кызганыч, минем дустым Муса да катнашкан. Нажар Нәҗми, Хәким Гыйләҗев, Равил Бикбаев бармаган».

### Спектакль

24.10.92. «Кичә театрда сезон ачылды. «Ай тотылган төндә»не күрсәттеләр. Халык ифрат күп иде. Гомум кәеф тә югары булды. Исрафилов башта минем сүз әйтүемне сорады. Мин театрның Октябрь җимеше икәнлеген, рухи дөньябызның җимешләре ишле икәнлеген халыкның хәтеренә төшердем. Без – тарих балалары, без – Ватан-әни балалары. Әнинең балаларын иркәләгән чагы да, каккан-суккан чагы да була. Имансыз, вөҗдансыз балалар әнкәйнең рәнҗеткән чагын гына хәтерләр, игелекле, иманлы, намуслы балалар әниләренең яраткан, иркәләгән, җылыткан чакларын истә тоталар. Без дә Ватаныбызга карата иманлы, рәхимле, рәхмәтле булыйк. Бу очракта аңар явызлар таш ата дип таш атмыйк. Гөнаһка батмыйк. Менә шуларны әйттем. Тамашачы дәррәү кул чапты».

2.12.93

## Беренче кар

«– Бу дөньяданиләр бар?
– Күктә болыт, җирдә кар.
– Ниләр бар бу дөньяда?
– Бүген дөнья йон яза».

### Башкортстанга эндәшү

«Башкортстан! Сине яратам дип сөрән салып та үзләрен генә яратучыларга ышанма. Җиләнеңнең ике чабуын ике якка тартып, ике иңеңне ике якка аерып ертырга тырышучыларга карата сак бул. Төрле-төрле дебетләрдән (мамык) тукылган бизәкле тукыма син. Берәүләр шушы тукыманың буйлыгын, икенчеләре аркылысын суырып сүтәргә омтылалар, уяу бул!

Син минеке, мин синеке, Башкортстан! Минем өчен Дим дә, Агыйдел дә, Сакмар да, Җаек та, Танып та, Ык та – зәмзәм чишмәләреннән изгерәк сулар. Урал сандугачлары минем өчен Келәш басуларындагы сабан тургайларына кушылып сайрый. Башкорт моңына, башкорт сүзенә татар моңы, татар сүзе иш килде, икесе бергә куш булды. Йөзәр ел буенча рус, украин, чуваш, мари, мордва, удмурт моңы колакларыбызга ятты, рухларыбызга иңде. Рус теле аша дөнья белән аралашабыз, уй-фикерләребезне кешелеккә җиткерәбез,

Башкортстан! Җитмеш елдан артык синең мөкатдәс туфрагыңа басып йөримен. Сәгате суккач, синең куеныңа сыенырга насыйп булсын дип теләкләр телим үземә. Сине яклаучы яугирең дә, сине данлаучы җырчың да булдым. Яраның (якының) булдым, тик ялагаең булмадым.

Калганы барысы да – ыгы-зыгы. Син генә төп асылыбыз, Башкортстан! Илгә яу ябырылганда, туган төяккә бәла-каза килгәндә, үзара бәхәсне онытып, кешеләр, ырулар, милләтләр бер булганнар. Заман яудан да, бәлаләрдән дә яманрак сынаулар китерә. Һәммәбез бергә булыйк, бергә укмашыйк дим мин. Башкортстанның ышанычлы, мәрхәмәтле канаты астында. Сине эчтән кимерүчеләргә ышанма, Башкортстан! Алардан сак бул!»

## Әткәй сөйләгәннәрдән

«Милләттәшләрем кайсы вакыт минем билгеле бер ырудан булмавыма ишарә ясаштыра. (Элегрәк язганымча, хәтта күренекле бер әдип миңа: «Синең нәрсәң бар? Минем халкым бар!» – дип битәрләде.) Әллә ни искитәрлек нәрсә түгел инде бу. Халыкның миңа булган яхшы мөнәсәбәтен нык аңлыйм һәм шуңа бик куанам.

Перестройка башында хәтта бер рус журналисты, төрттермәкче булып, миннән сорый: «Вы кто – башкир или татарин?» «Я – Мустай Карим. Это вас устраивает?» – дидем. Эндәшмәде.

Сүзем икенче нәрсә турындарак. Әгәр дә берәүнең миңа йомышы төшсә, сүз уңаенда әнисенең яки килененең, киявенең татар икәнен белдереп үтә. Ә бу минем кәефне кыра. Әйтерсең мин шуңа карап эш кылырга тиеш. Аның әнисе, хатыны, килене, кияве кем булуына карамастан, кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә әзермен. Кызык инде. Атаклы бер җырчыбыз Салават премиясенә тәкъдим ителгән икән. Урамда очрашып сөйләшеп торганда, миннән ярдәм өмет итүен аңлатты, бер уңайдан хатынының Чишмә типтәре, киявенең шәп татар булуын да белдерде. Үзе бик ихлас күңелле, милләт аермый торган зат».

**Мостай әйткән:** «Төрле йөзле дөреслек – ул ялган»

## Көндәлекләрдән

25.04.93. Чын шагыйрьне даһи дип әйтәләр. Даһилык – ул могҗиза. Могҗиза булмаса, шагыйрь дә булмас иде. Минем ике шагыйрьнең сөйләшүен ишеткәнем бар. Берсе әйтә: «Бер кечкенә даһига ярдәм итәсе иде. Талантларга ярдәм итәргә кирәк, талантсызлар болай да әрсез!» – ди. Кечкенә даһины кайгыртучы олы шагыйрь анда могҗиза күреп алган. Әткәй дә шундый даһиларны тиз күреп ала иде.

Каенатайга сәясәт тә чит нәрсә түгел. Иҗади хезмәт белән бергә 20 ел буе депутатлык хезмәте дә бар. Аның вакытындагы депутатлар нәрсә булса да эшли иде. «Перестройка» чорында әткәйне Югары Советка сайланырга никадәр кыстасалар да, ул ризалашмады, баш тартты, вакытында китә белде. Чөнки аның заманы узды. Ул аның өчен чит булган заманда хәтта үзе белгән сәяси эш белән дә шөгыльләнәсе килмәде. Ләкин ул сәясәттән китте дигән сүз түгел. Әткәй илдәге хәлләрне гади кеше булып кына түгел, шәхес

буларак йөрәге аша кичерде. Ельцинны сайларга чакырган референдум турында Мостай Кәрим болай ди:

«Референдум узды. Хәерлегә булсын. Ельцин күп тавыш алыр сыман. Чөнки халык моннан да яманрак көннәр килүдән курка. Илнең бөлүе турында уйламый да. Хәер, элек-электән иле, халкы нинди – башлыгы шундый.

Бу референдум халыкның күпчелеге өметсез рәвештә ахмакка калганын күрсәтте. Бу куркыныч. Референдум алдыннан телевизордан кыска гына бер әңгәмә күрсәттеләр. Кыяфәтсез чырайлы берәү – башкача әйтеп тә булмый – бик җитди итеп: «Мин Ельцинны яклап тавыш бирәчәкмен. Ул – үзебезнеке. Салырга ярата», – диде. Менә рус кешесенә, рус халкына, рус патшасына нинди сыйфат иң мөһиме икән. Сизелеп тора, телевидение кешеләре бу җавапка шат. Бөтен рус булганны түбәнсетеп, яманга сөенәләр».

## Сайлаулар мәшәкате

12.12.93. «Кичә сайлаулар үтте. Россиягә депутатлар һәм үзебезгә Президент сайладык. Кичә көн буе шомланып, борчылып йөрелде. Төнен рәтле йокы булмады. Чөнки Кадыйров халыкның башын нык бутап өлгерде. Рәхимовка күп пычраклар ташлады, бөтенләй шашынып, алга омтылды. Пычрак чаралар белән эш итеп, адәмнәрне ышандырырга тырышты. Сәгать сигездә Рәхимовка шалтыраттым. Шөкер, бөтенесе дә әйбәт. Президентны котладым, ул миңа рәхмәт әйтте: «Ярдәмегез зур булды», – диде. Башкортстан халкы үзен аңсыз итеп күрсәтмәде. Әгәр дүрт миллион халыкның күпчелеге шул шаукымлы тиле банкир артыннан иярсә, халык шагыйре булып яшәвемнең мәгънәсе кимер иде. Мин андый халыктан бизәр идем. Мин халык турында: «Син сарык көтүенә охшап, теләсә кемгә, теләсә нинди әйдәүгә буйсынып китмәссеңме икән?» дип борчыла башлаган идем. Шушы уем өчен кичерегез мине, туфракташларым.

Шулай да бер мәл хәвефлегә әйләнде. Безнең бөтенебезнең дә гамьсезлегеннән файдаланып, Кадыйров, әйткәнемчә, әллә нинди явызлыклар эшләүгә барып җитте. Хәтта җыен әтрәк-әләмне яллап, көчле микрофоннар аша урамнарда акыртып йөретте: «Кадыйров – нам родной отец, голосуйте за него!» – дип кычкырдылар. Шуларның да тәэсире булды. Бәгъзе адәми затларның шундый йомшак ягы бар: дөреслек белән изгелеккә ышанмыйлар, ялган белән явызлыкка ышанып баралар. Кадыйров әнә шул икенче чараны сайлады.

Рәхимов җиңде, шатлыгыбыз зур. Әгәр дә икенче төрлерәк булса, Башкортстанның асты өскә килер иде, милләтара ыгы-зыгы китәр иде, илдә кот бетәр иде. Экономика гына түгел, әдәбият, сәнгать, гомумән, мәдәният һәм мәгариф авыр хәлдә калыр иде».

Рәхимов җиңгәнгә сөенгән әткәй инаугурациядә һичшиксез чыгыш ясарга уйлый. Уйлый гына түгел, Президент та сорый аның чыгыш ясавын. Чыгыш язганда килеп чыккан кызык ялгышы турында әткәй рус телендә болай дип язган:

23.12.93. «Когда переписывал текст своего выступления на инаугурации Президента, я в слове «корыстолюбие» нечаянно пропустил букву «С» и

получилось «корытолюбие». (В тексте речь идет о том, что в окружении Президента не должно быть корыстолюбия, угодничества и т.д.) Вдруг понял: смысл-то один – «корыстолюбие» и есть «корытолюбие», любовь к корыте, кормушке».

## Сайлаулардан соң

21.03.95. «Бүген Башкортстан халык Корылтаеның беренче сессиясе үтте. Мине дә чакырдылар. Өйләгә чаклы булдым. Рәхимов чыгыш ясады. Тәнәфес вакытында аның янына котларга дип килдем. Ул – минем Президент. Мин беренче булып аның янына килергә тиеш. Ул үзенең югары властьле кулын үтә һавалылык белән миңа сузды. Анысына да рәхмәт. Менә шулай.

Ә менә бер ел элек, әле Президент булмаганда, булырга бик теләгән чагында, мине өстәл артыннан чыгып, кабинетының уртасында каршылый иде, Мостай агай дип, чәй эчертә иде. Ә хәзер мин – «Мустафа Сафич». Бер елда агай булудан туктадым.

Әле бит 13.12.1993 тә иртән шалтыратып, сайлануы белән котлагач, «Сезнең ярдәм белән» дигән иде. Күрәсең, аның кандидатурасын яклап, бер сәгатьтән артык телевидениедән сөйләвемне, аның өчен тавыш бирәчәкмен дигән башка чыгышларымны күз алдында тотып әйткәндер инде. Мин аның өчен Салаватта, Туймазыда агитация ясадым. Аннан соң миңа гел таныш булмаган гади халыктан: «Сезнең аның өчен тавыш бирүегез безнеке дә булды», – дигән сүзләрне ишеттем. Ә хәзер минем аның яклы булуымның әһәмияте юк. Юкка шулай итенә. Әгәр дә мин бер тапкыр аңа теләктәшлек белдергәнмен икән, алга таба да аннан баш тартмаячакмын. Кайчан да булса тәлинкә тотучылары аңар ташлана икән, мин ул вакытта да аның яклы булачакмын. Мин 1987 елда Обком пленумында ялагайлары таптый башлаган Мидхәт Шакировтан да баш тартмадым. Ул миңа мөнәсәбәтендә бик ягымлы булмаса да, минем фикер белән исәпләшә иде.

Менә бүген шундый моңсу тәэссоратлар кичердем әле мин».

Каенатай шатлыгын да, кайгысын да, үпкәсен дә, әйтергә теләп тә әйтми калдырган сүз-фикерләрен дә көндәлегенә теркәгән. Чираттагы язмасы 1995 елның 15 маенда язылган:

«Бу арада күп вакыйгалар булды. Җиңүнең 50 еллыгын билгеләдек. Бик күп очрашуларга бардым. Шулай да бәйрәм шатлыгы күңелгә ургылып тулмады. Без бит мондый көннәрне күрер өчен сугышып җиңмәдек. Ельцин Указы белән мине «За заслуги перед Отечеством III степени» ордены белән бүләкләделәр. Куанычы шулай ук әллә ни булмады. Нинди Ватан? Кайсы Ватан алдында? Шулай да мин аны Ельцин бүләге итеп түгел, ә Рәсәй бүләге, Туган ил бүләге, Башкортстан бүләге дип кабул кылдым. Алтын Йолдыз да Брежнев бүләге, Ленин премиясе дә – Черненко рәхиме түгел, ә хезмәтемә бәһа.

Кичә Тимербулат шалтыратты. Экзаменнарын әйбәт биргән, бер айга эшкә кала икән. Бар акыл-зиһенен саклап, шулай камилләштерә барса иде. Иң зур куанычым: Рауза арулана. Алтмыш еллык иҗади гомеремдә

кулдан килгәне эшләнде бугай. Калган гомеремне Раузаны тәрбияләп тотуга багышласам да, заяга булмас. Ул миңа ирек бирде, рухымны бумады. Күңел азатлыгы белән иҗат иттем. Йөрер җирләремә йөрдем, күрер нәрсәләрне күрдем. Көнләшеп тә, ваклашып та җанга тимәде. Әмма өйрәтте инде. Мәсәлән, Мәскәүгә киткәндә әйтә торды: «Син анда марҗалар белән чуалып йөрмә», – диде. «Ярар, йөрмәм», – дисең инде, антлар итмәсәң дә.

## Фетка ияреп

Көндәлекләрдә бүгенге көн хәбәрләре генә түгел. Узган, күптән тарих булган елларның, көннәрнең ялтыраган энҗеләре булып, көндәлек тәсбихына тезелгән.

9.06.95. «Көн җылы. Кояшлы. Кошлар да сайрашып туймый. Күке кычкыра. Карлыгачлар бала очыра. Кичә матур гына яңгыр яуган иде. Дөнья бүген ямь-яшел. Күңел дә күшекми. Моннан нәкъ 57 ел элек язылган «Беренче тамчылар» дигән шигырем исемә төште. Аны Фетка ияреп язган идем. Башта «Фетка ияреп» дигән аңлатма да бар иде. Хәзер хәтерләмим инде, кайсыдыр редактор ул аңлатманы алып ташлады, ләкин аның китергән дәлиле исемдә калган: «Нишләп сиңа беркем белмәгән, беркем күрмәгән Фетка ияреп йөрергә? – диде. – Җитмәсә, берәр боярдыр әле. Комсомол башың белән шуңа ияреп йөрергә сиңа ни калган? Үзең алдан барып, бүтәннәрне иятергә тиешсең син. Фетыңны сызып ташла». Сызып ташладык. Бу турыда онытып йөрдем, хәзер искә төште. Уңайсыз булып китте, хилаф эш кылгандай сиздем үземне. Әле биш томлыкны әзерләгәндә төзәтим дигән идем, кул селтәдем. Шул тикле гомердән соң төзәтү аңлашылмас та. Хәер, ул шигырьдә Фетның шаукымыннан башка әллә ни юк. Шулай да «тегендә» баргач, үзеннән гафу сорарга туры килер».

Әткәй дачаны бик ярата иде дип бер генә тапкыр әйтмәдем инде. Икенче катта каминлы бүлмә – әткәйнең кабинеты иде. Ләкин мин аның без барда ул кабинетта язып утырганын хәтерләмим. Күбрәк верандада эшли иде. Икенче катта китапханә, бала-чагалар шаулаша, шуңа күрә аулаграк урын сайлагандыр инде. Ә икенче каттан, чынлап та, гүзәл манзара ачыла. Ерактарак Келәш яклары булса, якындарак ак каен урманы, гүзәллек. Алар мәңге онытылмаслык, аңга уелып, үзгәрмәслек пейзаж булып истә калган.

## Наҗар турында уйланулар

16.07.95. «Тышта бик озак йөрдем. Соңгы карлыган, кура җиләге, чия бөртекләрен өзеп каптым. Сәер уй килде. Тагы бер елсыз мин аларны агачларыннан, куакларыннан өзеп ала алмаячакмын... Наҗар Нәҗми Җиңү бәйрәме көннәрендә Союзга ветераннар җыелышына йөрми иде. Быел килде. Минем яныма утырды, чак кына эчте дә: «Быел килдем әле, – диде боегып. – Ихтимал, соңгысы булыр». Мин әле чия җимешләрен өзгәндә, Наҗарның шул сүзләрен хәтерләдем. Хәзер инде гомерләр озын-озак еллар белән исәпләнмәячәк. Бу хәл өркетми дә, хафага да салмый. Дөньяның фанилыгы күптән мәгълүм инде».

## Нәҗар абый

Әткәй көндәлегендә Нәҗар абыйны да искә алган... Минем дә аның белән очрашу келт итеп искә төште.

Мин соңгы тапкыр Нәҗар абый белән Казанда очрашкан идем. Бөтендөнья татар конгрессы оештырган чараларның берсе иде ул. Фәннәр академиясендә узган ул очрашуда халык бик күп иде, фойеда аны уратып алган делегатлар арасында Нәҗар абыйны күреп алдым. Ул вакытта каенатай белән аның арасындагы низаг суына төшкән иде шикелле. Мин аны ерактан ук күреп исәнләштем. Таныды кебек. Ләкин аның күзләрендә мине танып сөенү шатлыгын күрмәдем. Миңа да үпкәсе бар микәнни дип уйладым да, баскычтан икенче катка менеп китим дисәм, арттан Нәҗар абый кычкыра:

– Нәзифә, синме ул, нигә минем белән исәнләшмисең? – ди.

Баскычтан кире төшеп, аның янына килдем.

– Исәнләшкән идем, Нәҗар абый, сез минем белән исәнләшмәдегез кебек тоелды, – дидем.

– Ничек инде исәнләшмим ди! – дип, Нәҗар абый мине кочаклап алды да аңа гына генә хас көлүе белән кеткелдәп көлеп җибәрде. Илгизне, балаларны сорашты.

Кабат миңа аның белән очрашырга туры килмәде. Каенатай белән Нәҗар абый арасындагы аңлашылмаучанлык байтакка китсә дә, яшь чактан бирле килгән дуслыкның алай тиз генә юкка чыкмасын мин сизенә идем, әлбәттә. Анда бит бер кеше гомере узган. Нәҗар абый соңрак, сугыштан соң өйләнгән. Аларның ничек өйләнүләре, туйлары турында каенанамның да сөйләгәне бар иде. Нәҗар абый белән Флорида апаның баш кодасы булган кеше Мостай Кәрим. Зәп-зәңгәр күзле, сары чәчле, бик акыллы кызлары Алсуны без бик ярата идек. Хәзер дә яратабыз, аралашабыз. Әткәйнең хәтта кечкенә Алсуга багышлап язган шигыре дә бар. Берәү генә дә түгел, берничә.

23.03.98. «Нәҗарның 80 яшьлек юбилеена барырга җыенам, ихлас барам, бергә уздырган еллар, тату, дус яшәгән еллар хакына (алар нәкъ 50). Ямансу, үкенечле, әлбәттә. Канатланып, очып барыр идем бит, әүвәлгечә булса».

## Иң сүгелгән кеше

«Минем тарафтан иң еш сүгелгән кеше – мин үзем, – ди торган иде каенатай. – Башкортча да, урысча да сүгенмим. Халыкара телдәге бер сүзне әйтәм: «Идиот!» Аны ычкындырыр өчен сәбәпләр чыгып тора. Әмма кеше алдында ычкындырмыйм. Үземә ачуым нык килсә дә, тыелам. Ышанып куюларыннан шүрлим».

Дөрес эшләгән бит. Дошманнарга да эш калдырырга кирәк. Барысын да үзең эшләп бетерергә димәгән.

**Мостай әйткән:** «Если правители и политики будут строить заборы между странами, то поэты должны прорубить хотя бы лазейки, коли они не смогут предотворить деяния правителей».

## Кем шагыйрьрәк?

Әткәйнең көндәлекләрендә язган дата белән язылган вакыйгалар арасында дистәләрчә ел узган булуы мөмкин. Элегрәк булган вакыйгалар бүген искә төшеп, күңелне шул заманнарга кайтара.

18.09.95. «Мине Язучылар союзына 1939 елның февралендә алдылар. Безнең буын күмәк идек. Өлкәнрәкләрдән – Мәлих Харис, Вәли Нәфиков, Нажар Нәҗми, Якуп Колмый, Зиннәт Котип, кечерәкләрдән – Гали Ибраһимов, Рәис Габдрахманов, Кәтибә Кинйәбулатова, Фәүзия Рәхимколова, Сабир Кинякәй... Шулар арасыннан бер мине аерып алдылар. Мөгаен, «шагыйрь» дигән төшенчәгә якынрак булганмындыр. Күрәсең, шигырь язган өчен генә түгел, шагыйрь булырга өмете бар кешене Союзга тәкъдим иткәннәрдер. Әмма ул чакта да, хәзер дә үземне иң шәбе булганмындыр дип уйламыйм.

Парадокс булса да әйтим, минем иҗатымны кабул иткән кешеләр генә түгел, миңа кырын күз белән караган әдипләр дә миңа ярдәм итте. Беренчеләре мине дәртләндерде, икенчеләре җилкендерде. Икенчеләре рәтендә Зәйнәп Биишева белән Әнвәр Бикчәнтәевка мин ихлас рәхмәтлемен».

**Мостай әйткән:** «Сначала люди создают Богов, приносят им жертвы, потом приходят обыватели, приносят Богов себе в жертву. Так всегда».

«Шундый җыр бар:

«Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.
Сандугач баласы кебек
Шат яшәек дөньяда».

Сандугач – моңлы кош. Шуңа күрә шат түгелдер димен. Моңлы затлар шат булмый».

## Михаил Дудин – дядя Миша

Фронтовик, Ленинград шагыйре Михаил Дудин белән Мостай Кәрим 1947 елда, Мәскәүдә яшь язучылар киңәшмәсендә таныша. Ул форум аларның күпләре өчен язмышларын билгеләгән очрашу булып чыга. Мостай анда Рәсүл Гамзатов, Вероника Тушнова, Геворг Эмин белән беренче тапкыр очраша, үзенең тәрҗемәчеләре булачак Елена Николаевская, Ирина Снегова белән таныша. Фронтовик Михаил Дудин белән алар бер-берсенә магнит кебек тартылалар. Кочаклашып күрешәләр. Шунда Дудин: «Аңламыйм, нигә дип мине бирегә чакырдылар икән? Миңа бит инде 30 яшь», – ди. Чөнки күбесенә 22-27 яшь була.

Дудин фронтны үткән башкорт шагыйренең җитди авыру икәнлеген аңлап ала. Мостайның үпкәсендәге мина кыйпылчыгы үпкә чирен китереп чыгаруга сәбәпче була. Шул вакыт Дудин, бөтен эшен ташлап, Мостайның шигырьләрен тәрҗемә итәргә тотына. Автор белән киңәшеп эшләр өчен Михаил Дудин Ленинградтан Келәшкә килә, әткәйләрдә яши. Гаиләдә бу турыда еш искә алалар, бер кызыклы хәл турында да сөйләгәннәре бар иде.

Җәй көне була бу. Дудин үзенә йокларга урынны сәндерәдә печән өстенә җәяргә сорый. Беркөнне иртән Михаил Дудин колагына ниндидер бөҗәк кергәнне сизеп уянып китә. Тиз генә сәндерәдән төшә дә, бөҗәкне

чыгарырга ниятләп, башын янтайтып, бер аягында сикерергә тотына. Бу хәлне күргән нәнәй куркып кала. Йөгереп өйгә керә дә эткәйне уятырга тотына:

– Мостафа, Мостафа дим, тор әле! Урысың котырган бит!

Шул тикле сикерүгә бөҗәк колакта калмый, дядя Миша бөҗәктән котыла, ләкин көлеп сөйләрлек маҗара кала.

Михаил Дудин шигырьләрне тәрҗемә итеп бетерә һәм ул «Цветы на камне» дигән исем белән 1949 елда дөнья күрә.

– Син бигрәк тиз тәрҗемә иттең, – дип гаҗәпләнә Мостай, – ничек шулай булдыра алдың?

– Мин синең өчен курыктым. Китабыңны күрми калырсың дип уйладым, шуңа ашыктым, – ди Михаил Дудин.

– Рәхмәт, дустым, – дигән Мостай Кәрим. – Син ашыкмасаң, доктор Богуш тәвәккәлләмәсә, китеп баруым да ихтимал иде шул.

Эткәйнең «Өченче көн тоташ кар ява» дигән шигырен дә рус теленә Михаил Дудин тәрҗемә иткән:

«...Тяжёлый снег идёт три дня.
И ноет рана у меня.
И с ним осколок заодно,
Он превратился в боль давно».

Михаил Дудин Уфага 1954 елда тагы килә. Һәрвакыттагыча башкорт шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итә. Чөнки Башкортстан 1954 елда Мәскәүдә булачак башкорт әдәбияты һәм мәдәнияте декадасына әзерлек башлый.

Ул вакытта каенанай хастаханәдә була. Аның кайтуына бөтен гаилә белән, әлбәттә, дядя Миша катнашында, «Татлы хыяллар» («Грёзы») дип аталган махсус стенгазета чыгаралар. Анда эткәй шигырьләре, Михаил Дудин такмаклары, соңгы хәбәрләр, фотолар урын ала. 37 елдан соң, каенанайның 70 еллыгын, эткәй белән әнкәйнең алтын туйларын котлап, оныклары – Тимербулат белән Нияз бу стенгазетаның икенче санын чыгардылар. Монысы 1991 елның 1 мартында чыкты, ул «Яңа татлы хыяллар» («Новые грёзы») дип аталган иде. Димәк, гаилә традициясе дәвам итә...

### Сөенче!

Рәсүл Гамзатовны дуслары «бәхетле язмышлы» дип әйтә торган булганнар. Аңар нәрсә эшләсә дә, килешкән. Ул үзе дә моны кире какмаган. Көлкегә калырлык, малайлыктан чыкмаган гамәлләре белән дусларын шаккатырырга яраткан. Мәскәүдә кунакханәдә бергә утырганда, Михаил Дудин:

– Минем тәрҗемәдә Мостайның рус телендәге беренче шигырьләр китабы иртәгә дөнья күрәчәк! – дип әйтеп куйган.

Мостай Кәрим ул вакытта Мәскәү больницаларының берсендә үпкәсенә операциядән соң дәваланып яткан була. Бу хәбәрне ишетүгә, Рәсүл Гамзатов, Кавказ егетләренә хас дәрт белән атылып-бәрелеп, кунакханәдән чыгып йөгергән. Аның Мостайга бу хәбәрне беренче булып җиткерәсе килгән.

Такси белән больницага килсә, анда беркемне дә кертмиләр, көндезге йокы сәгате икән. Ике дә уйлап тормыйча, Гамзатов ачык тәрәзәдән сикереп тә кергән, палатага авыруның хәлен белергә кергән докторга килеп тә бәрелгән! Бу егетнең тәрәзәдән сикереп керүенә сүз әйтерлек хәлләре дә калмый, өчесе дә көләргә тотынган. Доктор чыгып киткәч, Рәсүл:

– Өлгердем! – дигән, бәхетле елмаеп.

– Нәрсәгә шулай ашыктың? – дип сораган аптыраган Мостай.

– Сөенче! Иртәгә китабың чыга! Дудиннан алданрак әйтәсем килде! – дигән дусты өчен шатланган Рәсүл.

## Ау мылтыгы һәм дүрт папирос

Фронтта вакытта әткәйнең якташлары белән очраклы очрашу мизгелләре дә булган. Венгрия өчен барган сугышларда 3нче Украина фронтына кергән 57нче армиянең хәрби советында, Башкортстаннан генерал Галиян Галиев та була. Бу хакта беренчеләрдән булып Габдулла Әхмәтшин белеп алган. (Габдулла абый да – язучы, Мостай Кәрим белән сугышта, фронт газетасында бергә эшләгән якын дусты.)

Яңгырлы кичләрнең берсендә алгы сызыктан кайткан Мостай Кәрим штабта куныя калырга ниятли. Һәм ул якташ генерал белән танышып та ала. Хәрби корреспондентны яхшы гына ашаталар, эчәргә тәкъдим итүче булмады дип искә алды әткәй. Иртәгесен Кәримов генералдан тәмәке сорарга батырчылык итә. Тегесе башланмаган «Казбек» тартмасын ача да, дүрт папиросны алып калып, калганын якташына суза:

– Юлга җитеп торыр!

«Юлга җитүен җитәр, дусларга да калуы икеле» дип уйлап куя журналист. Шулай да рәхмәт әйтеп ала да редакциягә юл тота.

...Күп гомерләр узгач, сугыштан соң алар тагы очраша. Монысында да шул Габдулла абый генералның өй адресын табып алган була. Алар Мостай белән икесе, алдан хәбәр итми-нитми, өйлә алдыннан генералның ишеген кагалар.

Генерал инде ул вакытта отставкага чыккан була, обкомда инструктор булып эшли. Табын коралар, өстәлгә тәмле әйберләр чыга. Җиңү өчен тостлар да әйтелә. Шагыйрьләр шигырьләрен укый. Хуҗаның күңеле гел йомшап китә. Ул аларның икесенә дә бүләкләр чыгара. Габдуллага менә дигән генерал каешы эләгә, Мостайга трофей табышы – винчестер – ау мылтыгын суза генерал.

– Мин аучы булмасам да, шундый кыйммәтле бүләкне башымны иеп кабул итәм, – ди шагыйрь, рәхмәтләр әйтә. Ләкин китәр алдыннан генералга болай ди:

– Хәзер көпә-көндез урамда мылтык күтәреп йөрү уңайсыз, иртәгә кич килеп алырмын.

– Ихтыярың, – ди генерал, – тик башта шалтырат.

Икенче көнне, кичне көтеп алган Мостай, генералга шалтырата.

– Кичә алырга кирәк иде! – ди генерал. – Бүген инде мин кире уйладым. Поэмаңны язгач әйтерсең, ул вакытта сөйләшербез, – ди ул.

– Әһә, дүрт папирос... – дип уйлап куя шагыйрь.

## Әнкәй бакыйлыкка күчте

Минем каенанай 2002 елның 15 декабрендә бакыйлыкка күчте. Әткәй аны бик авыр кичерде.

«Кайгың авыр, әмма еламыйсың,
Синең кебек түзем ир сирәк.
Еламавым сабырлыктан түгел,
Еларга да, дустым, көч кирәк...»

Әткәй бу куплетны әнкәйнең вафатыннан соң 10 көн узгач язган.

## Әткәй төше

08.02.03. «Күпме вакыт бу дәфтәргә кагылмадым, – дип яза әткәй көндәлекләрендә. – Рауза киткәннән соң вакыйгаларның, төрле хәлләрнең мәгънәсе кимеде. Шуңа күрә кулга каләм алу авырлашты. Каләм түгел, әйтерсең тимер казык күтәрәм.

Узган төнне беренче тапкыр Рауза төшемә керде. Нindидер урман аланында очраштык. Ул шундый тыныч, мин дә борчуларсыз, эчемдә сагыш кына, имеш. Ул миңа гади бер хәбәр әйткән кебек әйтә куйды:

– Мостай, мин бит икенче иргә чыктым, – ди.

Мин дә артык хафаланмый гына сорыйм:

– Әйбәт кешеме?

– Әйбәт кеше. Подполковник, – ди.

– Бәлки кире кайтырсың?

– Юк инде, Мостай, миннән башка гына яшәргә тырышыгыз, – ди.

Мин урман буйлап киттем. Өстемдә – солдат шинеле. Эссе. Яшь чагыбыз, имеш. Ир белән хатын икәнебезне дә беләбез.

Бераз баргач, мин яңадан аңар тап булдым. Тагы чакырдым.

– Юк инде, – диде.

Башкача сүз булмады. Елау-сыктаусыз аерылыштык.

Кайчандыр Прометей авызыннан әйттергән сүзләрнең мәгънәсе яңадан аңыма килде:

«Көннәремнең канатлары сынды,
Сүнде безнең оя,
Йолдызлар да җем-җем нурлар түгел,
Йомма яшьләр коя».

## Көндәлекләрдә соңгы язма

20.04.05. «Бу көннәрдә Бельгиядән Чыңгыз Айтматов шалтыратты. Кәефе бик әйбәттән түгел шикелле. Миннән сорый: «Ничек яшисең?» – ди. Җаваплыйм: «Бик дәртле түгел. Башлыча хезмәт иярәренең күп санлы үтенечләре белән генә дөнья көтәм», – дидем. Чыңгыз көлмәде».

Димәк, Чыңгыз Айтматов әткәйнең хәлен аңлаган.

## Шагыйрь сере...

Каенатам Мостай Кәрим турында истәлекләр язганда, ул үзе дә янымда булды сыман. Мин тагы бер мәртәбә аның колачка сыймаслык иҗатын иңләргә омтылдым, аның хисләре белән хисләндем, аның халәтенә кереп,

уй-фикерләрен, хәсрәт-кайгыларын, шатлык-сөюләрен күңелем аша үткәрдем. Ләкин аның таланты серенә дә, күңел тирәнлегенә дә төшенеп җитә алмадым. Барыбер аның күпмесендер үзе белән алып китүе дөрестер дә. 85 яшьлек юбилеен уздырганда, үзенең чыгышында әткәй болай дигән иде: «Кешедә, җаны күкләр белән тоташкандай, дөньяларны яктыртып җибәргән гаҗәеп бер мизгел булып ала. Шул мизгел бәхет дип атала. Мин инде шундый яшькә җиттем, вәгъдәләр үз урынын васыятьләргә тапшыра. Ләкин мин һәрвакытта да Башкортстанга, Россиягә һәм үземә тугры калачакмын дип вәгъдә бирәм. Һәрбер мөртәтлек үзеңә хыянәттән башлана. Бу хакыйкатьне мин бик иртә үзләштердем. Шуңа күрә артка борылып карасам да, минем оят булырдай гамәлем юк... юк диярлек...»

Берничә көннән, кунакларны озатканнан соң, каенсеңлем Әлфия әткәйдән:

– Нишләп чыгышыңда «юк диярлек» дип әйттең? – дип сорады.

– Минем бөтен серемне белергә телисезмени? Анысы инде барып чыкмас – мин бит шагыйрь! Серләремне үзем белән алып китәрмен...

Шулай итеп, иҗатына төшенеп беттек дип уйласак та, серләренә төшенеп бетеп булмый шагыйрьнең. Һәм ул кирәк тә түгел. Ул безгә серлелеге белән кадерле. Бәлки киләчәк буыннар, аның иҗатын, тормыш юлын, кешеләргә булган мөнәсәбәтен өйрәнеп, серләрен ачар... Шагыйрь Мостай Кәрим дә киләчәк кешесе дип уйлыйм. Аның иҗат серләрен ачу – киләчәк эше. Ә ул үзенең хәйләле, мөлаем елмаюы, кайгыртучанлыгы, саф күңеле, искиткеч кешелеклелеге белән без исән чагында һәрвакыт безнең белән булачак. Безнең күңелләрдә мәңге яшәячәк кадерле әткәебез, картатаебыз.

«И шагыйрем,
Син үләннән түбән!
И шагыйрем,
Таудан олысың!
Заманыңның зирәк хәкиме син,
Заманыңның сукыр колы син.

И замана,
Туган балаңмын мин.
И дөньякай, ятим кешеңмен.
...Гомер ахшамына җиткән чакта
Шушы дөреслеккә төшендем».



Алисә
Зарипова

# КЫШКЫ САЛКЫННАРНЫ ЯЗ НАЗЫНА ТӨРЕП...

## Сөю фасыллары

Ел саен күңелгә берничә яз килә,
Елмаеп, моңаеп, яндыра-көйдерә.
Елдагыча йөрәк сөюдән исерә,
Күзләрдә янәдән җөйләрен тектерә.

Ел саен күңелгә берничә кыш килә,
Карларны сихерләп, зур таулар өйдерә,
Йөрәкне бәллүрдәй боз белән төрдерә,
Күңелне мамыктай йокыга күндерә.

Ел килә, ел китә, ә күңел гел көтә,
Йөрәген киң ачып, җилләрне дә кертә,
Ялкынлы йөрәкне тыялмый ничек тә.
Яшәргә тели ул сөеп тә, көеп тә!

## Кышкы мәхәббәтем

Сабыр гына ак кышларны көтәм,
Йөрәк тулы сиңа мәхәббәт.
Урап яуган ак карлардан атлап
Йөрик әле икәү без кабат!

Эзләр салыйк парлап икәү бергә
Карлы сукмакларга яңадан!
Җибәрмәм мин синең кулны кулдан,
Ятлар үтмәс безнең арадан.

---

Алисә ЗАРИПОВА (1988) – *шагыйрә. Шигырьләре «Әллүки», «Яңа гасыр тавышы», «Күңелгә илһам килә» исемле күмәк җыентыкларда басылды. Быел тәүге китабы – «Синле кыш» дөнья күрде. Казанда яши.*

## Синле кыш

Язга кергән төсле керәм быел кышка,
Йөрәгемдә тәүге сөю гөле шыта.
Салкыннарга бирешмәсен өчен хисем,
Кат-кат назга төрәм, куеп бөтен көчем.

Язга кергән төсле кышка керәм быел,
Салкын бураннардан саклый синең куен.
Мең кат рәхмәт безне кавыштырган көзгә,
Тормыш гамен таптым синең нурлы йөздә.

Язга кергән төсле быел кышка керәм,
Синле хыяллардан киләчәгем үрәм,
Бу уртак кыш безгә бәхет алып килсен,
Алда безне парлы озын гомер көтсен!

## Сөйгән ярга

*(романс)*

Кышкы салкыннарны яз назына төреп,
Күңелемдә урын алдың син.
Тәүге мәхәббәтем, сөйгән ярым минем,
Гомерлеккә бул тик миңа тиң!

Син – минем бәхетем, күкләрдә язылган,
Гел бергә, мәңгегә дип ата һәрбер таң.

Синең назлы караш, серле елмаюың
Әсир итте минем күңелне,
Кулны-кулга куеп, күзгә-күз карашып,
Үткәрик лә бергә гомерне!

## Кышкы теләк

Карлар оча бөртек-бөртек,
Минем күңелемдә китек –
Төшә карлар керфегемә,
Син кермисең төшләремә.

Керсәң иде бер елмаеп,
Кар-бураннардан коткарып,
Дәшсәң иде бер назлы сүз,
Кыссаң иде, ичмасам, күз...

Дөньяларны ямьләндереп,
Кышка җәй сулышы өреп,
Өннәремдә килсәң иде,
«Сөям сине», – дисәң иде.

## Кыш сафлыгы

Оча карлар, күбәләктәй ап-ак карлар,
Дөньядагы бар афәттән алар пакьләр.
Оча, куна, сафлык белән төрә алар,
Бар җиһанны явызлыктан саклар алар.

Могҗизалар көтеп яши Җир-Анабыз,
Кыш бабайлар, Кар кызлары, бармы соң сез?
Пакьлек белән алыштырып борчуларны,
Ап-ак карлар, явыгыз соң, явыгыз сез!

## Түгел

Бүген мин үземә хыялый булырга юл куйдым!
Хыяллар дөньясы беркатлы була алмый – тәм тойдым!..
Мәхәббәт, сөюгә тоткынлык шаукымы хас түгел...
Мин – бер көй, син – аның асылы, син – күңел!..
Ак карга чәчелгән миләштәй... Йөрәгемә түгел!

## Хыянәт

Быел язлар кабатланып, кабаланып килер төсле,
Су өстеннән ташулар да тиз-тиз генә үтәр төсле.
Төсләр җыелмасын бер тамчыда туплап, ләйсән ява,
Тәүге тамчы иңнәремә төшә – сала алмый дәва.
Кышкы зәмһәрир салкыннар яз башында кабатлана,
Көтмәдем лә хыянәтең... Йөрәгемә яңгыр ява.

## Нәсыйхәт

Уяндым йокыдан, бүгеннән беркемгә берни исбатламыйм,
Аңладым тормышны, үткәндә кылган хатаны кабатламыйм.
Үз юлын тапканнар аңларлар, ясалма хыяллар – тик рәшә,
Максатлар куелган, күңелнең асыл хисләре алга дәшә.
Абынгач торганнар, дөньяны бик нечкә тойганнар – мин сафта,
Гамәлләр сүзләрдән калышмасынга вөҗданым сакта.
Тормышның сынавын үткәндә үзеңне югалтмау – мәслихәт,
Тәҗрибә тупладым, иртәге көнемә бүгенем – нәсыйхәт.

***

Кура җиләкләрен үзе җыйды әнкәй,
Кызларын шул көтә алмады,
Сәгать телләрендә җәй уртасы иде,
«Кайтыгыз» дип хатлар салмады.

Кызлар үсеп бер-бер артлы читкә очты,
Шәһәр шавын алар үз итте,
Кура җиләкләрен коеп куаклардан,
Сиздермичә, әнкәй, көз җитте.

Син кызларың көттең, кураларың кипте,
Әллә синең сагыну көйдерде,
Теләмәдек, әнкәй, тормыш әллә ничек,
Чит куаклар безгә сөйдерде.

Кураларны күрә идек без төшләрдә,
Күпме чакты безне кычыткан,
Синнән ерак киткәч, кураларың рәнҗеп,
Бәхет безгә юлын онытткан.

Көткәнсеңдер, әнкәй, озак көткәнсеңдер,
Кайттык менә без дә җыелып,
Кураларың кайда дип сорагач, әнкәй,
Ник карыйсың болай боегып?

Кышлар җиткән...
Ә без сизмәгәнбез икән,
Чит куаклар безне үз иткән,
Бәхет эзләп чит җирләрдә озак йөргәч,
Кураларны кар күмеп киткән.
Ярый әле, безне бәлалардан йолып,
Дога булып, йөрәгең типкән.

## Тап

Күбәләккә тимәгез сез, очсын әле!
Үтсен әле караңгыны, бар диварны.
Үз кояшын табар өчен туа һәркем
Бәхетенә таба сала сукмакларны.

Кояшына очкан мәлдә томырылып,
Күбәләккә лампа уты төште кинәт.
Кояш диеп алданды ул – беркатлы җан,
Очып барып бәрелде дә янды канат.

Яшәвенә дәлил булып бер тап калды,
Булалмады күбәләккәй кояш ише.
Берәү килеп килешсезне сөртеп алды,
Гүя таплар калдырмаска тиеш кеше.

## Тормыш дәресләре

Тормыш дәресләрен үткән чакта
Горур тот та башың син атла,
Беркемнән дә күчерү юк анда,
Көн дә яңа кагыйдә ятла!

Киңәш сорап бара аласың дуска,
Дошманыңнан өйрән һич юкта,
Остазыңны бик җентекләп сайла,
Туры юлдан чыкмаска чатка!

Каралама юк бу дәресләрдә,
Һәр мизгелең акка языла,
Хата кылсаң тормыш дәфтәреңдә,
Шул хәл кабат килә каршыңа.

Һәр очраган кеше – укытучы,
Билге куючысы – син үзең,
Гомер азагында имтиханда
Кызармасын бары тик йөзең!

Зиннур
Хөснияр

# ӘЛЛҮКИ*

РОМАН*

## Пал Палыч

Рәимов шофёрына машинаны туп-туры Пал Палыч капкасына таба борырга кушты. Теге чакта авылдан шәһәргә күчкән уннан артык гаиләне Пал Палыч ярдәме белән кире кайтара алдылар. Дөрес, алар калада төпләнеп өлгермәгәннәр, кемдер вакытлыча тулай торакка урнашкан, кайсыдыр туган-тумачасына сыенган.

Русин заманында иң һәйбәт урында урнашкан авыл булган. Якында гына мул сулы һәм күп балыклы Русалка елгасы җәйрәп ята, аның аргы ягында калын урманнар башланып китә. Андагы җиләкне җәй башыннан алып августка кадәр җыеп бетермәслек иде. Аннан соң гөмбә чоры башлана. Балык тоту исә җәен генә түгел, кышын да өзелеп тормый. Бер заманны Русин урманына кайсыдыр оешма агулы калдыкларын яшереп күмгән. Урман күзгә күренеп корый башлады һәм урманнан соң Агымсуга коючы Русалка да саега, кибә барды. Нәкъ шул елларда елгада балык кимегәч, гөмбә беткәч, авыл халкы шәһәр ягына карый башлады. Завод ачылуга, тизәккә җыелган чебеннәр кебек тагын Касыймга килеп тулдылар.

Рәимовлар яңарыш дип йөргән чакта, Пал Палыч авылдан халык китә дип тормады, монда төпләнде. Дөресрәге, остазы һәм ватандашы Френк шулай теләде. Ул аларның сиксәненче еллар уртасында башланган уртак эшен дәвам иттерергә тиеш иде. Данил Френк сүзенә каршы килә алмады Пауль Вольфганг – Рәсәйдә Павел Павловичка, аннары Пал Палычка үзгәргән шымчы.

Тик һаман аңышып җитә алмый әле: алар монда нефть эзләргә тиешме, төрки-татарның тарихына кагылышлы тарихи документлармы, әллә Коммунистлар партиясенең яшерен алтын запасларынмы? Бәлки, барысы бергәдер?..

Буталды Пал Палыч. Дөресрәге, Рәсәйдәге соңгы еллардагы томанлы вазгыять бутады бугай аны. Хәер, әлеге томанның артында ул башы-аягы белән гашыйк булган гүзәл Сарби да бар түгелме соң?!

Ниятләрнең кайсы да күбрәк ышандыра, немец милләттәшләре юк белән йөрмәс – алтындыр төп максат... Өстәвенә Френкның үзеннән тиз арада яңа күрсәтмәләр алырга тиеш иде ул.

---

* Журнал варианты

*Дәвамы. Башы 10, 11нче саннарда.*

Элек Русалка биләгән дымлы, ләмле җирләрдә күп итеп кәбестә чәчтерде Пал Палыч. Завод салыныр алдыннан булды бу хәл. «Йокыдагы» агент буларак, аңа көтәргә куштылар.

Әлегә ни теләсә, шуның белән шөгыльләнсен, утыртсын, үстерсен, чучка асрасын, тик уяу булсын, һәр нәрсәдән хәбәрдар булсын, күргән-белгәнен, ишеткәнен теркәп барсын. Уянгач, һәммәсе дә кирәк булыр.

Мәгълүм ки, теге чакта ук Френк тәкъдиме белән Россия немецын Алмания разведкасы үз штатына алса да, мондагы КГБ исә Пал Палычны «үзенеке» иткәч, Сарби аңа шаяртып, «двойной» агент дигән була. Белми ул Пал Палычның «тройной» икәнлеген. Әлбәттә, монысы ул махмырдан баш төзәтә торган «Тройной» одеколон белән бәйле түгел... Итальян галиме әлеге одеколонны составында өч төрле компонент булганы өчен шулай дип атаган: лимон, бергамот һәм нероль дигән матдәләрдән тора «Тройной».

Россиядә һаман да шул «өч борын» күздә тотыла.

Агентлыгының өченче тармагы шәхси мәнфәгать белән бәйле. Җае чыгуга, барысын да төп башына утыртып, Сарби һәм хәзинә белән ерак чит илгә качарга ниятли ул. Иранны сайлады. Анда ЦРУ да, МИ-6 да бик борын тыга алмый.

Өстәвенә, Сарби әнисен бик сагына иде.

Төсле кәбестә үстерә башлау фикерен Пал Палыч конспирация өчен махсус уйлап чыгарды. Чын ниятен, ягъни өченче яшерен максатын беркем дә белергә тиеш түгел.

Күзгә күренеп кибә барган елга буйларына теплицалар куйдылар, анда кыяр, помидор, борыч яшелчәләр үстерергә керештеләр. Ә төсле кәбестә исә заманында алтын коючы һөнәрен үзләштергән Павел Павловичны, чыннан да, алтынга күмеп ташлады! Әлбәттә, зирәк Павел үзе шундый хәбәр таратты. Мәгълүм булганча, чын «бизнесын» яшерү өчен... Кыскасы, яман шешкә каршы шәп дәва булып чыкты ул кәбестәләр. Баштарак аны патшалар сые буларак кына күпләп ала башлаганнар иде, яман шеш дәвасы икәнлеген белүгә, кәбестәгә сорау бермә-бер артты.

Авыл халкы да рәхәт тормышта гомер итә башлады...

Әлеге бизнес хакында күрше-тирә бистә-шәһәрләрдә ишетеп алдылар. Бер көнне таң белән Пал Палычның ике катлы коттеджы каршысына пароход хәтле озын «Мерседес» килеп туктады. Аннан беренче булып ак халатлы юан түти төште, аның артыннан күзлекле ябык ир-ат чыкты.

Касыйм янындагы Русинда тыныч тормыш бетте диярлек. Икенче көнне авыл кырыенда атышлар булды. Мондагы җирләрнең яңа хуҗасы Паратов белән бандит Ермолай кешеләре атышкан дип сөйләделәр.

Пал Палыч «Урлап кына мантып була икән бу илдә!» дигән алтын фикер белән «бакыр кою» заводыннан алтын чәлдерү эшен активлаштырды. Бабасыннан өйрәнгән металл кою һөнәре бик уңай булды әле. Алтынны яңа калыпларга салган чакта аңа күп итеп бакыр куша, коелманың авырлыгы үзгәрми, ә «артып» калган алтыннан яңа «кирпеч-коелмалар» ясый һәм аны итәк астыннан гына шудыра. Бу коелмалар – саф алтын!.. Иң кызыгы шул: тикшерүчеләр дә угрының бу серен белмиләр, һәр тикшерү нәтиҗәсе завод өчен уңай тәмамлана иде!..

Тик ул чын алтын коелмалар белән бу илдә берни майтара алмыйсың. Пал Палычның башы отыры котырып эшләде. Ул коелмаларны үзләре

качачак илгә – Иранга озатырга! Аннан соң үзләре дә койрыкларын сыртка салырлар. КГБны да, «үзенеке»ләрне дә төп башына утыртыр «Тройной»! Тик Сарби гына карышмасын инде. Әгәр ул китәбез дисә, Пал Палыч бу илдә бер көн дә тормаячак!.. Йә, йә, Палыч, эшләт башыңны. «Талант не пропьёшь» дип руслар бик дөрес әйтә. Димәк, син әле акылыңны эчмәгән. Френк кушкан тагын бер эше уңышлы булырга тора Пал Палычның: ул әйткән фольклорның эзенә төште, аның килеп чыгышы Ханкала шәһәре янындагы авыллар белән бәйле. Табышмак очы тәгаен шунда булырга охшаган иде. Солтан Хәйдәров аның мәгънәсен русчага тәрҗемә итеп бирде: «Татар говорит «бисмилла», это слово из молитвы, а у русского – «помилуй» то же самое». Тик Пал Палыч әлегә төшенеп бетми: нинди хәзинәгә ачкыч икән бу юллар? Френк булгач, әлбәттә, сүз тарихи документлар турында бара торгандыр, төркиләр тарихына бәйле кулъязмалардыр әле. Теге чакта Рәимов үз акчасына аны кызы Бану белән Ханкала якларына җибәрде, ул да кулына шундый ук такмак тоттырган иде түгелме соң?! Һәм нигә аның бер очы аларның Касыймы белән бәйләнгән?.. Ә бабасының васыятенә боларның нинди катнашы булыр икән?

Мондагы тормыш гел шундый сорау-табышмаклардан тора. Бер табышмакны ул хәзер үк чишәргә ниятләде һәм төн ката чиркәүгә китте. Сарби сөйләп торды, имеш, Хәтмулла көтүче белән Тукаш чиркәү астыннан килеп чыккан табылдыкларының бер өлешен бүген шунда бикләп калдырганнар. Үзенең төрки телләр галиме икәнлеген беркайчан да онытканы юк иде Пауль Вольфгангның. Бу фәнне өйрәнү теләге бабасы белән бәйле икәнлеге мәгълүм инде. Гитлер белән бергә СССРга каршы сугышта катнашкан аның Рудольф бабасы. Ул оныгына гел сөйли торган иде, Йоханнар (Иваннар) илендә татар дигән халык яши. Аның васыятьнамәсендә дә сүз нәкъ шул хакта бара булып чыкты! «Алар белән төшеңдә дә көрешергә язмасын! Шундый куркусыз, кыю халык!» дип башланып китә иде ул. Менә шул халыкның менталитетын өйрәнәсе иде дә балаларыңны да шулар үрнәгендә тәрбиялисе иде! Шулай итсә, киләчәктә Германия бөтен дөньяны яулап алачак, имеш... Йоханнар иленә нәфрәт уятырга теләгән бабасы оныгында андагы төрки-татар кавеменә карата мәхәббәт кенә уятты. Пауль бабасының татарлар турында язган җөмләсен немец матбугатына да бастырып чыгарды, шуннан соң әлеге гыйбарә Рудольф Вольфганг авторлыгында дөнья буйлап таралды... Галим-тюрколог Данил Френк исә аспирантында төрки-татар теленә карата мәхәббәт уятты. Френк – аның остазы гына түгел, ул Паульның мәхәббәте Сарбиның әтисе дә. Хатыны Сарбиназ белән хәзер Иранда яшиләр, Френк Иранның биниһая бай китапханәсендә казына, төрки-татар кавеме хакында яңа хезмәт яза. Иранга китүләренең дә төп сәбәбе шул иде.

Касыйм чиркәве астына яшерелгән тарихи документлар да төрки-татар тарихы белән бәйле икәнлеген ишетте Пауль-Пал Палыч. Аның диссертациясенә шәп материаллар бик тә кирәк иде. Айныган чакларында уйлады ул моны. Һәм шулчак башы капылт аязды: таярга кирәк моннан! Металл коючы кулдашы Клещёв дәвам итсен аның эшен, серләрен ул аңа өйрәтеп калдырыр! Бандит Ермолайга да шулай дип әйтер, Клещёв белән таныштырыр. Заводтан алтын урлауның сере ярдәмчемдә дияр...

Пал Палычның иң сөенгәне галим Фазыл Шәриф белән танышу булды. Менә ичмасам күзен ачты аның археолог! Пауль Панкрац-Вольфганг язган докторлык диссертациясе белән бар төрки дөнья кызыксына икән! Монысын ук көтмәгән иде ул.

Пал Палычның башындагы «алтын фикерләре» 999,9 пробалы алтыннар кебек башына бәла алып килмәячәге дә аксиома иде. Дөньяда фәнни гыйлем бик көчле хәзер, моны беркайда да кире какмаячаклар, бу Пауль Вольфгангка – алтын металлын коючы остага, тюрколог галимгә шөһрәт кенә алып киләчәк!

Пауль Вольфганг кызу-кызу атлап, чиркәүгә таба китте. Бистә читендә моңаеп утырган лютеран чиркәве яныннан узганда, шул диндәге Пауль куырылып килде, һәм бу халәте аның киләчәк ниятләрен бөтенләй икенче юлдан борып җибәрәчәк иде әле. Башына яңа фикер килде, һәм ул күңеле булып елмаеп куйды; шуның белән аяк атлаулары да җиңеләйде, җирдән очып бара башлады. Кичтән аракы чөмермәгәч, баш чиста, акылы саф иде. Хәер, моннан соң аракыны башка авызына да алмаячак инде ул… Монысы тәгаен, чөнки тәртипкә күнеккән немец гадәтләре, кан тамырлары буйлап аккан арийлык мәсләге аңа ирек куймас. Тик чиркәүгә барганчы Тукашны эзләп табарга ниятләде. Язучы бит ул. Аңа кирәкле мәгълүматны, бәлки, ул белә торгандыр?..

## Абрар Паратов игезәк сыңарын эзли

«Пётр Беренченең кәефе нилектән бүген болай яхшы икәнлеген Меньшиков яхшы белә: яңа кораб патшага аеруча ошады. Әнә ул очлы борыны белән Аксу елгасының дулкыннарын ничек ярып бара; кәеф шәплекнең дә сәбәбе шул. Коломна пристаненда патшага кушылган генерал-адмирал Апраксин да, кенәз Кантимер дә нәкъ шул фикердәдер. Тик бер патшабикә Екатерина Алексеевна гына дәшми, акчарлаклар тавышын тыңлый-тыңлый, үз алдына елмаеп бара чибәр хатын. Чөнки генераллардан аермалы буларак, аның үз фикере: тиздән иренә илле яшь тула, ни әйтсәң дә, түгәрәк дата. Кәеф күтәренкелекнең дә сәбәбе шул дип фаразлый ул. Тик патша инде байтактан дәшми-сөйләшми, карашын әле яр буенда калган шәһәр-авылларга төбәп уйланып бара, әле күзләре кораб бортын чыбыклаган дулкыннарга төбәлә. Патша вакыт-вакыт үз алдына елмаеп куя. Яраннары һәм хатыны аның кәефе шунлыктан шәп дип уйлыйлар. Менә Пётр капылт сискәнеп китте һәм, ерактан ук Касыйм шәһәрен матурлап, зурлап торган мәчетне күргәч, ашыгып чукынырга кереште. «Господи, прибежище был еси нам в род и род. Прежде даже горам не быти и создатися земли и вселенней, и от века, и до века Ты еси». Апраксин белән Кантимер бу хәлдән телсез-авызсыз калдылар, Меньшиков, күрәсең, моңа игътибар итмәгән иде, ул кораб борынындагы озын кәнәфидә тыныч кына ни турындадыр патшабикә белән гәпләшеп утыра. Иделгә төшеп, Ханкалага барып җиткән көннәрендә Пётрга нәкъ илле яшь тула. Күрәсең, бәйрәмне ни рәвешле оештыру хакында сөйләшәләр. Меньшиков, әңгәмәсен бүлеп, Апраксинга нидер әйтмәкче иде, тегенең патша янында агарынып-күгәренеп басып торганлыгын күргәч, патшабикәдән гафу сорап, алар янына ашыкты. Апраксин, ниһаять, телгә килде, тик барыбер юньләп

кенә ни булса да аңлата алмады. Меньшиков шулай ук багана булып каткан Кантимергә борылды. Тегесе каушавыннан һәм куркуыннан патша да ишетерлек итеп:

– Всемилостивейший Государь, чиркәү дип уйлап, ялгыш мәчеткә карап чукынды! – диде ул, бу хәлгә беренче нәүбәттә үзен гаепле санагандай.

Моны белеп алган Пётр бармагын тешләде һәм беравыктан ачу белән тамагын кырып алды да аты-юлы белән сүгенеп:

– Немедленно уничтожить это... сооружение! – дип кычкырды. Яраннары корылган пушканы мәчеткә таба бордылар...»

Тукаш Усман хикәясенең шушы урынында нокта куйды да каләмен өстәл өстенә тәгәрәтте. Пётр Беренче турында (татар журналисты буларак, ни яманнан, ни яхшыдан әйтерлек сүз юк!) язасы килми, каләме үк карыша хәтта! Бәлки Хәтмулла шәкерт хакында, аның башыннан кичкәннәре турында берәр очерк сырларгадыр?! Тукаш ошбу фикереннән үзе дә җанланып китте, кыюлык инде егеткә. Тик шул мизгелдә үк күңелен яңа курку алды: обком Абтюк шуның өчен аны эзәрлекли башласа? Өстәвенә Хәтмулланың кайда качып ятканлыгы да фаш ителәчәк! Шәкертне Паратовлар малае эзли. Әгәр ул Денис Паратов кулына төшсә, барысының да эшләре харап булачак...

Әүвәл Хәтмулланың үзе белән киңәшмичә булмас дигән катгый фикергә килде ул бу юлы һәм дивар кырыендагы үзенә дигән сәкегә сузылып ятты да түшәмгә карап тын калды. Бар гәүдәсе сызлый бүген, төнлә күп эшләнгән, чиркәүнең ярты нигезен казып бетерә язды бит! Җен көчләре бар икән үзендә! Нигез кирпечләрен казып чыгару бер нәрсә, аны чокырга ташып яшереп тә куйды, өстен балчык белән каплады да бит әле. Күз кабаклары авырайганнан-авырая бара, үтереп йокысы килә. Тиздән Хәтмулла шәкерт төшке ашка кайтырга тиеш. Әнә, еракта чучка куган тавыш ишетелә. Тукаш үз алдына көлеп куйды: вәт тиле димә инде син аны, дуңгыз көтүен чыбыркы белән көтмәсә! Озын таяк аларга, юан башлы озын таяк. Хәер, суксаң да, сизми бит аны дуңгыз хайваны, катырак итеп танавына төртсәң генә инде.

Аптыраганнан Пётр патшаның татарга кылган яманлыкларын исенә төшерде. Яшьтәше Сәрдәрдән күрмәкче ул да тарих өйрәнергә керешкән иде. Борынгы төркиләр тарихыннан башлады. Һуннардан алып. Баһадур, безнең эрага кадәр икенче гасырда Төньяк Кытайда дәүләт төзегән, ул тирәдәге халыкны, бигрәк тә кытайларны, дер селкетеп торган. Аннан соң Атилла. Аның баһадир бабасы римлыларны тезләндергән. Аларның гади халкын коллыктан азат иткән! Аурупага дин биргән! Ләкин бүгенгә таба килгән саен, бигрәк тә унбишенче гасырдан соң, татарның тарихы данлы түгел. Явыз Иван, Пётр Беренче җелеген суырган төрки-татарның. Пётр биш мең татарны Петербург каласын төзергә җибәрү турында махсус указ чыгара. Сазлыкка, коточкыч авыр хезмәткә, үлемгә җибәрүгә тиң указ. Шуннан өркегән илле мең татар калмык, башкорт далаларына качып киткән. Тагын да арырак мөселман татарны чукындыру хакында указ чыга. Күпме челпәрәмә килгән язмышлар, күпме күз яше! Казанда флот төзегән дип мактыйлар ул канечкеч һәм авыру патшаны. Соң, мактамый ни, ул анда тагын илле мең татарны мәҗбүриләп эшләтә бит! Күбесе шунда кырылып бетә. Лашманчылары әле тагын өстәвенә...

Сәрдәр, тарихны яхшы белсә дә, шыр тиле, шул канечкеч патшага Ташкалада һәйкәл куярга дигән фикер белән янып йөргән булды. Сарматыннан торып, болгатмакчы була татар дөньясын! Анда Кирилл белән сугышып ятулары җитмәгән! Тукаш алар хакында мактап, очерк язарга барган иде. Сыйныфташларының үзара ничек талашуларын күргәч, тизрәк аннан таю ягын карады. Солтан күптән Касыймга чакыра инде. Алар Рәимов белән Башкаладан ерак түгел генә зур эшләр маташтырып ятканга охшаган. Шуларга көч-куәт биреп торыр ичмаса!.. Хәйдәровның адресын исә Ясминә белә икән. Солтан исемен ишетүгә, Гафият тузынып алган иде башта, бигрәк тә аның ачуын әллә кайдагы, әллә кайчангы Солтанның адресы хатыны Ясминәдә булуы чыгырыннан чыгарды. Тик Ясминә аптырап калмады, тиз суытты. «Рәимовның кызы Бануны беләсең бит инде, шуннан сорармын дигән идем. Әтисенең адресын гына белә торгандыр әле, – дип куйды. – Солтан белән бергә эшлиләр бит!» – диде.

Гафият, Бану сүзен ишетүгә, телен тешләде. Ясминәсе, Марижан дип тә төрттерсә, бөтенләй харап буласын сизде, кысылмауны яхшырак күрде.

Тукаш Касыймга килгәч, яңа маҗарага тап булды. Дөресрәге, Хәтмулладан мәчет нигезенә салынган чиркәү хакында ишетте дә шуның нигезендәге гарәпчә догалар язылган ташларны булса да казып алырга уйлады. Язып әлегә әллә ни майтарганы юк, ичмасам, дөнья шаулатырлык берәр җүнле гамәл кылыр. Аннан соң бу хакта Ханкала матбугатында зур мәкалә бастырыр. Даны дөнья буйлап китәр! Шул рәвешле танылырга уйлаган Ханкала журналисты иде Тукаш Усманов.

Тукаш бу бер генә бүлмәдән торган бәләкәй йортның галанка миче янында яткан плакатка текәлеп торды да аны урам якка, йортның стенасына кадаклап кую нияте белән урыныннан кузгалтмакчы булды. «Да здравствует новая Великая Россия!» дигән озынча ак тасма аңа килгәннән бирле тынгылык бирми, плакатның идәндә буш буяу банкалары, балта, чүкеч кебек эш кораллары, юынтык чиләге, юылмаган кәстрүл, табалар янында аунап ятуына баядан бирле эче поша. Батып барган кояшның кызгылт нурлары бердәнбер сыңар тәрәзәдән плакатның язуларына төшкәч, андагы язу тагын да ачылып, елык-елык килеп тора. Күрәсең, күптән түгел язылган, беркавым урамда эленеп торганга да охшаган, чөнки дүрт читендә әле күгәрергә дә өлгермәгән кадаклар да тырпаешып тора. Беркөнне Хәтмуллага: «Әйдә, кадаклап куйыйк моны ферма өе каршысына!» – дигән иде, тегесе кул гына селтәде һәм беравыктан әйтеп куйды: «Дөрес язылмаган дип, клубтан куптарып алып кайтып ташладылар аны», – диде. Сүзләренә ачыклык та кертте: «Россия» урынына «Российская Федерация!» – дип язарга кирәк булган икән. Сарби Даниловна рәссам малайга шундый текст биргән дә булган. Тегесе, урын җитмәде дип, үз белдеге белән кыскарткан, кыскасы, «Федерация»гә урын калмаган», – дип өстәде.

«Хаталы икән шул», – дип көрсенеп куйды Тукаш. Югыйсә хәзер адым саен, сүз саен «федерация», яңача тормыш-яшәеш дип сөйләшәләр. Регионнарны федерациядән аерылып чыкмагыз дип кыстыйлар, төрле вәгъдәләр бирәләр.

Чыбыркы шартлаткан тавыш якынайганнан-якыная барды. Тукаш Хәтмулла кергәндә йоклаганга салышып ятарга уйлаган иде, тик тегесе ишек катында ук булып чыкты, күзләрен дә йомарга өлгермәде. Ул, башын

күтәреп: «Хәтмулла, Хәтмулла шәкерт, синме ул анда?» – дип сорамакчы булган иде, ләкин кинәт исенә төшеп:

– Хотя, ты што ли? – диде.

Хәтмулла монда урыс булып санала, аның татар икәнлеген беркем дә белергә тиеш түгел. Моның үзенең җитди сәбәбе бар. Татар башы белән нигә чучка көтеп йөри дигән кызыксыну уяныргa мөмкин, ә болай читләрнең башына татар чучка көтәр дигән фикер килмәс һәм качкын Хәтмулланың монда икәнлеген шайтаным да белмәс. Кече Паратов эзләтә аны. Хәтмулла шәкертне шул иблис эзәрлекли. «Менә кем язмышы хакында язарга кирәк!» – дип сөенеп уйлады Тукаш, капылт урыныннан сикереп торып. Мизгел эчендә йокысы да качты.

– Мин, мин, тагы кем булсын инде, – дип җаваплады Хәтмулла керә-керешкә. – Мә, менә Сарби Даниловна ашарга биреп җибәрде.

Ул кәгазьле төргәкне өстәлгә куйды.

– Чучка ите булса, ашамыйм түлке!

Хәтмулла киемен салып чөйгә элә-элә:

– Чучка бүген Сарбиның үзеннән дә артмас, кунагы бар, – диде ул аңа каршы.

– Нинди кунак тагы, ментлар түгелдер бит?

– Поп, яңа поп җибәргәннәр Русинга. Шуны кунак итә Сарби Даниловна.

Әлеге хәбәр Тукашны ток суккандай итте: чиркәү нигезен казып бетерә алмый, кирпечләрне чыгарырга өлгерми дигән сүз бит бу!

Хәтмулла шәкерт аның куркулы карашыннан ни уйлаганын белде һәм тыныч тавыш белән:

– Кара төндә чиркәүдә нишләсен ул? Бер яшь кенә нәрсә шунда поп дигәннәре. Төнлә чыгып йөрергә курка да торгандыр әле! – дип тынычландырды. – Аннары үзе үк, әлеге сүзләренә каршы килгәндәй, «хәер, бүген төнлә чиркәү эчендә нәрсәдер бик каты кыштырдады, дөбердәде, куркуымнан арбаны ташлап, чак качып китмәдем. Күселәр дигән уй гына тынычландырды күңелне», – дип, вәсвәсә салды.

Тукаш, хуҗа янында болай кырын ятуны яхшысынмыйча, торып утырды да сыңар конфоркалы газ плитәсенә калай чәйнек утыртты.

– Син, чынлап та, алтынчы бабаңнан ары шәҗәрәңне белмисеңме, Хәтмулла? – дип сорады, өстәлгә Сарби биргән нигъмәтләрне тезә башлаган өйдәшеннән.

– Хотя! Хотя! Бернинди мулла да, Хәтмулла да юк!

– Ник котың алынды ул хәтле, эт тә юк бит монда?!

Нәкъ шулчак урамда Хәтмулланың эте өреп куйды, икесе дә сагайдылар.

– Әнә, күрәсең, эт бар бит! Эт булгач, башкасы да булыр. Белмим шул алтынчы бабамны. Бишеченсе Вәкъкас атлы, безнең Туксабага Саба ягыннанмы, әле Себердәнме кайтып төпләнгән бугай.

– Син бит мулла, башка бабаларың да имамнар булгандыр инде? Гадәттә шулай була...

– Була пычагым, әти гап-гади тракторчы иде минем. Хәтмулла бераз тын торды, аннары авыр сулап: – Ну түлке үзе башлы кеше иде. Укыган булса мәгәр. Заманында мәктәп тә эләккән булса диюем! Сугыш вакыты шул. Барысы да тамак кайгыртып йөргән.

Урамда эт өргән тавыш кабатланды.

– Әллә, чынлап та, кемдер йөри инде? Кыс әле тизрәк лампаның филтәсен, ә! Җәһәтрәк бул инде!

Өй эчендә караңгылана төште, эт өргән тавыш тынды.

– Син минем шәҗәрәне эшләп бирерсең бит инде, име? – дип куйды Хәтмулла, болай да тонык тавышын тагын да сүндерә-кыса төшеп.

– Миутын оста аңа, – дип куйды Тукаш. – Чуракан укытучыны әйтәм.

Хәтмулла әлеге хәбәргә бик сөенде:

– Бүген-иртәгә килә ул монда! – диде ул шатлыгын яшермичә. Чуракан исеме Тукашның ачуын кабартты.

– Укытучы дип тормыйм, йөзенә бәреп әйтәм әле мин аның!

– Кызмале! – диде Хәтмулла аның бу сүзенә каршы. – Зөләйха апа үзе киткән ди бит аннан. Балалары юк. Нишләсеннәр.

Ләкин Тукаш һаман бирешергә уйламый.

– Солтан күзенә ничек күренер икән ул монда? – диде. Бу Хәтмулла бер дә ачулана белми. Тагын җайларга тырыша:

– Сәрвәр үзе гашыйк булган ди ул Чураканга! Зөләйха апасы авыр чагында аны сыендырган! Миргалидән аерылгач, бусагасыннан уздырган! Ә ул!

– Ышан син туганыңа!

– Туганлык галәмәтләрен аңлап бетереп буламы соң? Ни дисәң дә, кан кан шул инде...

– Сәрвәр белән Зөләйха кан туганнар түгел ди Чуракан.

– Ул Чураканны да чакыртыйк әле монда, – дип куйды Хәтмулла шәкерт. – Аның остазы да бар, гел шуның белән киңәшеп тора ул, – дип өстәде.

– Беләм, Фазыл Шәриф дигән олуг тарихчы хакында әйтүең. Мин каршы түгел, – диде Тукаш.

## Табышмак очы табыла...

Касыймнан хәбәр килүгә, тиз генә җыенып, юлга чыгып китте Чуракан. Бу хакта остазы Фазыл Шәрифкә әйтүне дә кирәк тапты. Зөләйхасы турындагы авыр уйларыннан да котылып торыр. Шуның артыннан ук: «Сәясәтчеләр – сәясәт белән, физиклар – физика кануннары, ә тарихчылар тарих белән шөгыльләнергә тиеш!» дип уйлады Чуракан, күптән мәгълүм хакыйкатьне үзалдына тагын бер кат кабатлап. Һәм тиз тотып университетта Казан тарихы буенча курслар укыган укытучысына шалтыратты. Академик Шәриф Фазыл аңа куанып сәлам бирде:

– Гомерең озын булыр, мин үзем дә сиңа хәбәргә чыгарга тора идем әле, – димәсенме күренекле галим! Чуракан колакларын торгызды. – Худяковны укып чыктым әле тагын бер кат. Йөзенче мәртәбәдер инде. Беләсеңме, моңарчы аеруча игътибар итмәгән җөмләсенә юлыктым. Менә тыңла әле: «Чиркәү йортын салыр өчен нигез казыганда, аның йорты каршында, чыннан да, җир астында татар кульязмалары белән тулы бинага юлыкканнар». Худяктовтан бу, аның сүзләре, аның җөмләсе! Моңа өстәп тагын бер версиямне әйтәм, Ханкалага соңгы яу белән килер алдыннан да, аңарчы да, укымышлы зыялы кешеләр барысы хакында төптән уйлаган. Алар, ул-бу була калса дип, барлык тарихи кульязмаларны подвалларга яшергән булган! Бу эшнең башында атаклы имам Кол Шәриф торган

булса кирәк! Аларның бу гамәлләре – аксиома. Кем дә шулай итәр иде афәт килгәндә. Хан китапханәсенең бер өлеше дә шул рәвешле яшерелгән булган, димәк. Әмма барысын да урнаштырып өлгермәгәннәр, Кирмәнне явыз дошман алырга җөрьәт итмәс дип ышанганнар.

Чуракан түзеп тора алмады, тегесенең тын алган вакытын көтеп торды да, шуннан файдаланып, остазының сүзләрен куәтләп әйтеп куйды:

– Кол Шәрифнең туганнан туганы Кирмән диварының тышкы ягында татарларга каршы көрәшкән! Мондый ук хыянәтне көтмәгәннәр инде алар. Китапханә язмышы турында ныклап уйланганнар инде, алайса...

– Гаҗәеп зур китапханә булган ул, андагы тарихи мәгълүматлар шул рәвешле дөнья буйлап сибелгән. Бигрәк тә чиркәү нигезләреннән эзләргә кирәк, – диде галим. Чуракан гаҗәпләнде:

– Чиркәү нигезе? – дип аптырап сорады да әле.

– Мин аларны поплар махсус яшергәндер димим. Киресенчә, татарлар үзләредер. Чөнки, рус үз чиркәвен беркайчан да җимермәячәк дип уйлагандыр Кол Шәриф шәкертләре. Бер карасаң, чыннан да, иң кулай урын, иң ышанычлы урын чиркәү нигезләре бит инде! Ә большевиклар, мәчеткә кадәр үк, әүвәл чиркәүләрне юк итәргә керештеләр...

Чураканны ток суккандай булды. Шунда ук теге такмак исенә төште. Куырылып килде Чуракан. Күкрәгенә күп итеп һава алды һәм:

– Менә сиңа «Памилуй»! – дип куйды.

Үзен бүлдерүне ошатмады бугай остаз, аның сүзләрен колагына да элмичә дәвам итте:

– Тик барысы бер урынга түгел, аерым-аерым төрле җирләргә! Берсен тапсалар, икенчесе исән калыр киләчәк буыннар өчен дип уйлаганнары мантыйклы бит инде! Менә шул... Димәк, китапханәдәге тарихи кульязмалар, шәҗәрәләр тагын берничә шәһәрдә яшерелгән булырга тиеш. Башкаланың борын астында, мәсәлән. Чөнки аннан эзләргә берәүнең дә башына килмәячәк һәм Макарий җитәкчелегендәге поплар аны юкка чыгара алмаячак дигән уй белән. Син хаклы, көтмәгән татарлар хыянәтне, бигрәк тә милләттәшләреннән көтмәгән бу эшне.

Үпкәләмәгән икән Академик үзен бүлдерүгә; бик затлы интеллигент шул ул, эчке тәрбиясе йөзенә бәреп чыккан! Чуракан остазына тагын бер мәртәбә сокланып куйды. Кинәт шунда Фазыл Шәриф кызыклы фикер әйтте:

– Син миңа Касыйм шәһәре турында әйткән идең. Менә шунда түгелме икән безнең тарихның бер өлеше?!

– Мәчет нигезендә, мәсәлән, Фазыл абый?

– Мантыйкның җебен алга таба сузыйк. Әйтәм бит, мәчет астына яшерергә батырчылык итмәгәннәрдер, чөнки Явыз Иван кабахәт Макарий киңәше белән мәчетләрне юкка чыгарта. Кабатлап әйтәм, Макарий моны патша кулы белән эшләтә! Беләсеңме, бу попның исеме татар тарихына кара хәрефләр белән язылып куелырга тиеш! Бернинди толерантлыкка да урын юк монда! Искедә актарынып, конфессияләр дуслыгына зыян килә диючеләрнең сасы авызларына сугарга да аннан соң тегеп куярга кирәк! Тарихны белү бернинди һәлакәткә дә китерми! Белмәү китерә!

Чуракан тагын сүз кыстырырга уйлады, сүз генә түгел, тулы бер монолог сөйләргә иде бугай исәбе. Дөресен әйтә галим, бүген шул тарихны инкарь итү, нәсел шәҗәрәсен тәгаен белмәү аркасында дөньяны физик гарипләр

генә түгел, рухи гарипләр басып алды. Татар милләте сыегая, элеккеге талантларның оныкларының оныклары акыл ягыннан уртакул дәрәҗәсендә! Каннар буталу аркасында бу! Болар һәрдаим бер-берсен сатарга, әләкләргә тора. Болар, җае чыккан саен, хөсетлектән бер-берсен юкка чыгарырга, сәләтле кардәшләренә аяк чалырга әзер! Мәгәр үзләренә кирәк булса, кайбер милли патриотлар барысын да «патрахасы» белән сатып җибәрер иде!

***

Уй-фикерләрен башка якка борып җибәрү уңай булды әле Чураканга. Соңгы арада Зөләйха күзенә дә бик чалынасы килми. Йөрәге авырта, сулкылдапмы-сулкылдый йөрәк дигәне.

Алар аерылышалар. Тик моны берәүгә дә сиздермәскә тырыштылар. Юкка борчылдылар, чөнки алар кебек дустанә аерылышу башка була алмый торгандыр ул, булса да, бик сирәк булыр. Әүвәл Чуракан Зөләйхасын «киләчәккә хатлар» аркасында гына дулый торгандыр дип уйлады. Зөләйха бу хакта белүгә, башта Чуракан белән атна буе сөйләшмәде, аннан соң гына күтәрелеп бәрелде: «Ни хакың бар иде! Ник казып алдың ул хатларны?!» – дип, тетмәсен тетте. Зөлфәкар эше икәнлегең белгәч, ярсуы артты гына: «Ни йөзең белән психик яктан авыру баланың башын әйләндердең?!» – дип сүкте.

Чуракан Зөлфәкарнең башын әйләндермәде. Ул шулай бервакыт Тәкә буена балыкка барды. Беркавымнан яр буенда Зөлфәкар пәйда булды. Нигә килгәнлеген дә әйтеп салды. «Киләчәккә хатлар»ны казып алам да үземнекен юк итәм!» – ди, Чуракан башта берни дә аңламады, тегесе төшендереп биргәч: «Зөлфәкар, нишләп алай итәргә булдың әле?» – дип сорады. Тегесе анык кына җавап бирмәде, соңгы вакытта егетнең авыруы көчәйгән, ул кайчакта ялгыш сүзләр дә сөйли иде. Чуракан аның бу гамәленә каршы ни дип әйтергә дә белми торганда, Зөлфәкар артына яшерелгән тартманы күрсәтте. Казып алган булган икән инде ул аны. Егет бер уч кәгазь кисәкләрен учына алды һәм: «Буш алар барысы да», – дип куйды. – Мин дә язмаган идем».

Шул көнне кич Зөлфәкарнең елгада батып үлгәнлеге хакындагы хәбәр авылны янә сискәндереп куйды. Бик озак елады авыл хатыннары гөнаһсыз егетне җәлләп. Чуракан исә «киләчәккә хатлары» хакында беркемгә дә әйтмәде. Зөлфәкарнең исемен төрләндерүләрен теләмәде бугай ул. Өстәвенә буш кәгазь кисәкләре иде бит.

Беренче сүзне Зөләйха үзе башлады:

– Чуракан, – диде ул иренә йошмак бәрхет тавышы белән. – Синең аркада мин мәхәббәтнең ни икәнлеген аңладым. Үзең дә яхшы беләсең, мәхәббәт хисенең дәвамы ул – балалар. Нишләтим, безнең булмады бит инде. Аерылышыйк та, вакыт узып соңга калганчы, икебез дә яңадан парлашыйк... – диде. Шуңа өстәп: «Мин – гап-гади бер татар хатыны, гаилә бишегендә баласын тирбәтергә хыялланган гап-гади хатын», – димәкче иде. Монысы китап сүзләре кебек килеп чыгар дип дәшми калды.

Чуракан хатынның әлеге сүзләреннән тетрәнеп китте. Ничек тыныч әйтә бу сүзләрне Зөләйхасы! Әйтерсең бер атнага гына аерым торырга уйлый. Әүвәл аңа күтәрелеп бәрелмәкче иде, тик вакытында үзен кулга алып өлгерде һәм аннан да тынычрак булырга тырышып:

– Ашыйкмыйк, Зөләйха, – диде. Тавыш күтәрәсе, юкны сөйләмә дип сүгеп атасы калган икән, бу сүзләрдән Зөләйхага да бик авыр булды, шунда ук күзләренә яшь килеп бөялде, түзә алмады, үксеп еларга кереште. Чуракан аны кочагына алды, тик ни дип юатырга да белмәде. Башка чак булса, андый сүзләр табылыр иде. Ә хәзер ни дисең бу сөйкемле, күптән җан түрендә урын алган гүзәл затка?!

Зөләйха йөрәк түрендәге генә түгел, зирәк хатыны – аның якын киңәшчесе дә. Баш-аягы белән тарихка кереп чумды лабаса. Атлаган саен хатыны белән киңәш-табыш итеп тора. Чү! Аның тарих белән кызыксынуы, шәҗәрәләр дип йөрүе үзенә үк кире яктан китереп суга түгелме соң! Без – якын кардәшләр, безнең каннар бер үк күзәнәкләрдән дип Зөләйхага үзе тәкрарлый түгелме соң?! Имеш, балалары да шуның аркасында юк. Булсалар да, гарип туарлар иде дип үзе үк сөйли түгелме соң Зөләйха?! Бу кәгазьгә дә язылмаган бер теория генә бит! Кем раслый ала аның хаклыгын? Чуракан аны, милләттәшләрен, миләре каткан замандашларын уйландыру өчен генә, алар артка да әйләнеп карасыннар өчен генә әйтә ләбаса! Бүгенге татар кешесенә: «Син тарихны белергә тиеш!» – дисәң, ул сиңа гаҗәпләнеп караячак. Гаиләдә, аннан соң мәктәптә булмаган «тарих» турында уйлармы ул? Ә менә баласы, оныклары дигәч, башын кашыячак! Уйланачак!.. Әмма бу фикерне хатынның башыннан берничек тә кире бәреп чыгарып булмый иде инде. Җитмәсә, Мисырда күргәннәре моны тагын ныгытты гына. Сафарига бардылар. Аларга шунда асаба Мисырның бедуиннар тормышын күрсәттеләр. Аяклары кәкре, куллары озын, йөзләре ямьсез озынча, кыскасы, гарипләр иде алар. Гид моның сәбәбен боларның туганнары белән кан катнаштыру аркасында дип аңлатты. Хәер, кем дә белә инде монысын гына. Фәндә күптән ачыкланган. Ибраһим диннәре дә шулай ди. Геннар белән шаярырга ярамый! Алар аяусыз, аларның үз кануннары бар. Әдип әйткәнчә, тагын да шул ук бер сүз инде: иң караңгы кануннар алар Кан законнары!.. Зөләйханы шушы хәл – Мисырда күргәннәре ул чакта да тетрәндергән иде! Бүген шул хисләре аерым бер фикер карары булып тышка чыга. Зөләйханың бәби табасы килә! Барлык хатын-кыз кебек үк сабыен сөясе, нәсел дәвам итәсе килә. Чү! Мәхәббәтнең асыл нигезендә дә шул инстинкт, ошбу бөек ният ята түгелме соң?! Мәхәббәт һәм шуның белән бергә бала табу Ходайның җан ияләренә биргән тылсымы ләбаса! Алайса, Мәхәббәтнең бар миссиясе нәсел дәвам итүгә кайтып кала! Кешеләр бу төшенчәне әлеге миссиядән аерып алганнар. Шуның аркасында килеп чыга бар аңлашылмаучанлык...

– Асрамага алырбыз! – диде Чураканы, катгый итеп.

– Юк, алмыйбыз! Мин беләм, сиңа үзеңнеке кирәк булачак, Чуракан! – Хатынның сүзләре аныкына караганда да катгыйрак яңгырады.

– Өченче-дүртенче туган өйләнешсә генә, килеп чыгарга мөмкин проблема дип аңлата фән, Зөләйха!

– Ә син дүренче буыныңның кайларда яшәгәнлекләрен, кем булганнарын беләсеңме соң? Яхшы, син беләсең дә ди. Мин дә беләм. Бәлки, безнең бишенче туганнарыбыз бер нәселдән булгандыр?!

Чуракан тиз генә исәпләде. Ата белән ул арасында утыз яшь. Биш буын арасында йөз илле ел. Җиде буын дип сөйләшәбез? Әллә фән дә ялгышамы?!

– Әкият бу, Зөләйха! – диде Чуракан.

– Без шул әкиятне башкаларга чын итеп кабул итегез дип тукыйбыз. Үзебезгә килеп терәлгәч, әкият, имеш!

Чуракан хатынны тынычландырмакчы булды. Әмма тегесе өзми дә, куймый да, һаман үзенекен тукый. Ахырда ул түзмәде, моңарчы Чураканы белмәгән бер яңалык әйтеп салды:

– Сәрвәр үле бала тапкан!

– Соң... Ташлап китмәскә иде аңа роддомны! Ул юклы-барлы әбиләргә ышанып!

– Мирсәет абый кире озаткан аны роддомга. Кендек әбисе белән бергә икесен утыртып. Роддомда тапкан ул баланы, – диде дә янә үксергә кереште.

Сәрвәр исемен ишетүгә, Чуракан сискәнеп китте. Беләме Зөйләха аның Сәрвәргә күзе төшкәнен, әллә кыек атып туры тидерүеме? Әйтергә кирәк Зөйләхага дип уйлады Чуракан. Кешедән ишетсә, авыр булачак, иң яхшысы аның үзеннән белүе...

Чуракан үзен бик белдеклегә санаса да, Зөйләйха аерылышу карарына салкын карады. Бик аптырады моңа Чуракан. Әмма бу озакка сузылмады, шул кичне ул Зөләйханың мич артында мышык-мышык елап утырганын ишетте. Остазы Фазыл Шәрифне озатып кына кергән иде. Зөләйха ишек тавышын ишетмәде, ул такмаклый-такмаклый елый иде. «Йа Ходам! Нигә мондый авыр сынау бирәсең бәндәңә? Мин бит – бар гореф-гадәтләрне саклап, сине хаклап яшәүче бер гади татар хатыны!.. Нигә мине аерасың иремнән?!» – дигән сүзләрен әүвәл ялгыш ишетәм, ахрысы, дип уйлады. Өстәл артындагы урындыкка килеп утырды, чөнки аяк буыннары хәлсезләнә башлаган иде. Зөләйха һаман эчендәгесен тәкрарлый, хәтта бермәлне хатын үзе белән сөйләшә, ахрысы, дип уйлады Чуракан. Аның сүзләренә, сорауларына җавап бирергә кирәктер бит инде!

Зөләйха:

– Беләм мин хатын-кыз җилкәсенә нинди йөк салганыңны. Әйе, мин нәселне дәвам иттерергә тиеш, әйе, мин бала табарга тиеш. Бу синең миңа биргән миссияң! Беләм мин моны.

Чуракан хатынның бу соравына үзе җавап кылмыйча түзә алмады:

– Күз яшеңне түкмә алай, хатын-кыз! Дөрес аңлыйсың син, синең миссияң – нәсел дәвам итү. Мин сине фани дөньяга шул ният белән яралттым. Ләкин балалар белән синең һәр көнең бәхет эчендә узачак, мин анысын да кайгырттым.

– Чуракансыз нинди бәхет ди инде ул?

– Хатынның иренә булган мәхәббәте, тагын да көчәеп, балаларына күчә! Чураканны Мулланур алыштырыр. Син моны әлегә үзең дә белмисең. Хатын-кызның баласына карата мәхәббәтен берни белән дә чагыштырып булмый. Ул – иң көчле мәхәббәт!..

– Мулланур турында мин менә күпме гомер уйламаска тырыша идем. Чит ир турында уйлау гөнаһ булыр дип уйлый идем. Чуракан да үпкәләр инде миңа...

– Син Чураканның Сәрвәр белән кушылуына каршы килмә. Сәрвәр синең кан туганың түгел. Кушылсыннар. Күп итеп балалар тудырсыннар. Сезнең бу язмышыгыз – минем ихтыярым. Ә мин барысын да алдан белеп торам...

Чуракан үз тавышын үзе танымады. Саташа иде бугай ул, әллә шул рәвешле Зөләйха белән хыялында сөйләшүеме? Дөресрәге, үз-үзе белән сөйләште бугай ул... Бу аны бик куркытты. Тиз генә ишегалдына чыкты. Башын тимер кисмәктәге салкын суга тыкты. Җибәрде бераз, баш эчендә нидер шатыр-шотыр килде һәм шуннан соң уйлары аязган сыман булды. Ашыгып тагын өйгә керде. Зөләйха мич артыннан чыккан, кояштай елмая, кичке аш әзерләп йөри иртәгә аерылышасы хатыны! Моны күргән Чуракан өнсез кала язды. Әле генә үкси-үкси еламаган да кебек... Ни арада үзгәргән Зөләйха? Нигә елмая ул матур итеп?..

Уф Алла! Кодрәтең зур, хикмәтләрең биниһая күп синең!..

Чуракан, тынычланып, урындыкка килеп утырды. Аның болай гына бирешергә исәбе юк иде. Бу сөйләшүгә ныклап әзерләнде ул. Шуңа күрә тыныч тавыш белән дәвам итте, дәлилләр китерде:

– Пушкинның атасы нәселнең якын туганы була, өченче буындагы сеңлесенә өйләнә ул.

Зөләйханың моңа да җавабы әзер:

– Димәк, андый никахтан йә гений туа, йә...

– Йә тиле дисең инде...

– Чарльз Дарвинның хатыны туганнан туган сеңлесе була. Аларның ун баласы туа!

– Ә безнең берәү дә булмады.

Соңгы сөйләшүләре менә шул рухтарак булды. Ахырда Чуракан ризалашты, чөнки нәкъ шул чакта аны тагын сискәндереп куйган хәл булды, һәм ул бу хакта кат-кат уйланды, әмма билгеле бер нәтиҗәгә килә алмады; чөнки ул «хәл»не шәрехләп тә булмый.

Сәрвәрне беренче күрүендә ток суккандай булган иде. Бу энергия аны юкка чыгармады, куырмады, киресенчә, бар гәүдәсен рәхәт пешереп кенә алды, йөрәк турысында моңарчы үзләрен сиздермәгән яңа күзәнәкләре уянды, бар гәүдәсе буйлап җылы кан таралды, әгәр мөмкин булса, Чуракан шул мизгелдә үк хатынны чишендереп атар иде!.. Әйе, әйе, оят булса да, ул моны үзеннән «яшерми», чөнки чынлап та шундый теләк уянды. Хәтта ул аны үзенчә аңлата ала: адәм баласының, һәр җан иясенең асыл нияте нәселне дәвам итү!.. Барлык хайвани затлар, барлык җан ияләре кебек үк!.. Нинди гаебе бар соң моның?!

Шуның белән бергә ошбу «фәлсәфәнең» икенче ягы да ялтырап күренә: мәгәр Адәми затка Аң, Рух бирелмәгән булса, ул бу мәсьәләдә нәкъ хайван кебек тотар иде үзен. Аннан соң җәмәгатьчелек фикере дигән нәрсә дә тәэсир итә. Ходай бар ягын да кайгырткан, Акыл һәм Рух биргән адәмнәренә. Дин белән исә моны ныгыткан. Әдәбият-сәнгать белән беркеткән...

Ярый хуш, шул рәвешле үзен юата да алсын, ди. Шуннан ни? Шуннан соң «ни» булганын тормыш үзе хәл итте: Зөләйханың Мулланур белән очрашкач ничек кабынып киткәнен, күзләренең ничек янганын, бит алмаларында кабынган кызыллыкка кадәр үз күзләре белән күрде. Әлбәттә, Зөләйха моны сиздермәскә тырыша, хәтта яшермәкче була. Тик күпме тырышыбрак яшерсә, әлеге халәте шулчаклы ачыграк сизелә. Бу хакта Зөләйхага бер сүз әйтмәде Чуракан, чөнки ул вакытта аның үз күкрәге эчендә икенче бер асыл кош сайрарга керешкән иде...

Зөләйханың үз уйлары иде. Өстәвенә, аны теге чакта сыйныфташларның «киләчәккә хатлар» урынына буш кәгазьләр салуы тетрәндерде. Югыйсә алай булырга тиеш түгел иде. Хатны барысы да язды бит! Татар теле дәресләре бетә дигәч, борчылган иде яшьләр, киләчәккә ышанычлары сүнеп алган вакыт булгандыр. Ышанычсыз киләчәккә нәрсә дип хат язасың? Аның эшсез калуына да борчылган булырга тиешләр. Зөләйха эшсез калмады, аңа әдәбият урынына тарих дәресләре бирделәр, Чуракан белән бергә читтән торып институт тәмамлады, икенче диплом алды.

«Чибәр кыз Марижанга» хат рәвешендә язучы да булмаган. Хәер, алар бу хакта шаяртып кына сөйләштеләр бугай. Марижан яртылаш кына марҗа, паспорттагы исеме «Маһижан» булып, каладан кунакка кайтып йөрүче кыз аны шул рәвешле үзе үзгәрткән... Кызына татарча исем кушкан әтисе Степан каршы килмәгән. Татарның бүгенге тарихында бу сирәк очрактыр!.. Югыйсә татар кызы руска кияүгә чыкса, иреннән дә уздырып чукынырга керешә... Гавриловлар малае үзен тотып көчләгәч, Марижан бауга менә яза. Бәхетенә, нәкъ шул чакта йөрәгендә чын мәхәббәт уты кабына: моңарчы да таныш булмаган Миргалине «күрә» кыз! Ут каба йөрәгенә... Әлеге көчле ут кызны коткарып кала. Исем янә «Маһижанга»га әйләнә... Әлеге ут хуҗасы Мирсәетнең олы малае Миргали, Сәрвәрдән соң кибәне янган кеше кебек боегып йөрсә дә, Маһи хәзер инде Миргалинең үзендә ут дөрләтеп җибәрә!.. Моңа, беренче чиратта, Мирсәет белән Мәдинә сөенеп бетә алмый. Мәдинә сүз саен кабатлый: «Маһи тәгаен безнең шәҗәрә агачыннан түгел, башымны катырма бүтән нәсел дип!»

Мирәсәет каршы дәшми, хатыны белән килешә. Тик әлеге бәхет озак бармый, Маһи туй алдыннан бик каты авырып китә...

Зөләйха әнә шуларны тагын бер кат башыннан гына түгел, күңеленнән дә уздырды һәм кинәт сискәнеп китте... Чураканның Туксабага кайтуының беренче көнендә үк мондагы сөйләмнең үз ягындагы диалектка охшатуы кереп калган булган бит башына!.. Җирле сүзләр уртак булач, димәк, алар бик якындыр?.. Тугандыр да әле?! Бу сорау Зөләйханың хәтер шүрлегенә кереп оялады һәм «онытылды» да.

Исенә төшерде ул инде күптән башына бер кереп чыккан шикле уйларны. Уйлар бер-берсен этә-төртә башлады, бер-берсен кысрыкларга кереште һәм ахыр чиктә башына яңа хәерсез фикер килде: ире Чураканнан бала таба алмаячак ул! Күп вакыт та кирәк булмады, әлеге уй хатынның психикасын тора-бара үзенә буйсындырды...

Икенче яктан, Мулланур белән яңадан күрешү иләс-миләс күңелен янә какшатты: яшьлектәге гыйшык хиссиятенең уты шулай ук сүнеп җитмәгән булган, күрәсең...

Әлбәттә, Зөләйха укытучы бик белдекле, бик зирәк хатын булса да, үзенең татар кавеменең кайчакта, бер-берсеннән бик еракта яшәсә дә, телләренең уртаклыгы, хәтта сөйләшләренең охшашлыгы аларның кайчандыр ярты Җир шарын биләп торган бердәм, иң куәтле кавем булуына бер мисал, гади генә бер ишарә икәнлеген төшенеп җиткермәде. Төрки-татар һәм дөньядагы барлык төрки халык, беренче чиратта, үзара якын рухи туганнар, олуг тарих һәм мәдәни кыйммәтләр белән аерылгысыз булып бәйләнгән, РУХ туганнары иде. Кан туганнары да. Уртак геннары бар.

Моның хаклыгын күптән түгел табылган хәзинә – Ханкала китапханәсенең бер нәни кыйпылчыгы булган ХӘЗИНӘ – андагы тарихи дәлилләр тагын бер кат расларга тиеш иде...

### Хәзинә

Русиндагы чиркәү артында казылган зур чокырны иң беренче булып Сарби Даниловна күрде. Күрде дә гаҗәпләнү-аптыраудан шул чокырга чак төшеп китмәде. Өйләдән соң ул монда экскурсиягә кунаклар (Пауль да, ул да төрле эштә эшлиләр иде) алып килергә тиеш. Иртән эшкә барышлый, маршрутны билгеләү өчен шул тирәләрне бер кат әйләнеп чыгу нияте белән генә килгән иде югыйсә... Шаккатмалы тамашага тап булды хатын һәм, чиркәүдә капкасыннан таң белән чыгып киткән Григорий атакайны да күрмәгәч, туп-туры ферма өенә таба йөгерде. «Аюлар»ның берничәсе өтермәннән качкан дигән хәбәр йөри иде, шулар эшедер дип уйлады: алтыннарын монда яшергән булып, менә хәзер алырга килгәннәр, байлыклары күмелгән урынны төне буе казыган бандослар! Заводтан алтын урлаучыларны Башкала тикшерүчеләре атна буе эзли иде инде. Моңа кадәр очына чыга алмадылар: заводтан көн дә килолап алтын югала, тик гаеплене таба алмыйлар. Югыйсә каравыл да бик көчле, һәр эшче, һәрбер металл коючы энә күзеннән үткәрелә, бинада бернинди яшерен почмак калмады, һәр кирпечне капшап чыктылар, һәммәсен «әйләндерделәр», әмма алтын көн саен каядыр шуа!.. Тәмам аптырады тикшерүчеләр! Бар бистә аякка басты...

Сарби ферма йортына килеп керсә, янә артына ава язды: көтүче Хотя, журналист Тукаш, өй буенча ниндидер балчыкка каткан тартмалар, кәгазьләр таратып салганнар. Һәммәсе гади генә кәгазьләр дә түгел әле, араларында ниндидер язулы катыргылар да бар! Тик аларның берсе дә алтын түгел бит?! Кулына тагын бер тартма тотып, менә аның атакае да килеп керде. Барысының авызлары ерылган, һәммәсе дә шат!

Григорий атакай, бу күренешкә аптырап, таң калып, ишек төбендә тораташ булып катып басып торган хатынны иплэп кочаклап, өстәл кырыендагы артсыз урындыкка утыртты. Хатынны күргәч, Хотя да, эшеннән аерылып, башын күтәрде һәм кулларын җәеп:

– Менә, Сарби Даниловна! Нинди хәзинә таптык! – дип авызын ерды. Хатын һаман тораташ кебек иде әле, сүзен дә әйтә алмыйча, тик аптырап карап утыра. Тегеләр, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләргә, аңлатырга керештеләр. Беренче булып журналист Тукаш сүз башлады:

– Чиркәү астында Шаһгали ханның хәзинәсе яшерелгән булган. Бу хакта Хотя чит илдә укыган чагында архивлардан очраклы рәвештә кечкенә генә бер мәгълүмат тапкан...

Аңлата торгач, акрынлап, Сарби Даниловнага да барып җитә башлады: көтүче Хотя бөтенләй көтүче Хотя түгел, югары дин белеме алучы Хәтмулла шәкерт икән! Дөрес, Тукашы чын журналист булып чыкты, кенәгәсе бар.

Сарби Даниловнаның теге чактагы шиге яңарып, отыры көчәйде: татарлар Башкаланың борын төбендә үк хөкүмәткә каршы ниндидер этлек кылырга уйлый! Тиз генә өенә кайтып, бу хакта тиешле урынга

(элемтә калган иде әле) шалтыратырга кирәк! Үзләренә бирелгән элемтә компаниясенең торбасы өйдә саклана. Аны урамда бары рөхсәт кәгазе белән генә файдаланырга мөмкин. Шулай ашыгып атлаганда ул, каршысына килеп чыккан Солтанны күрмичә, аның кочагына ук килеп керә язды.

– Ни булды? Кая чабуың болай, Сарби? – дип сорады Солтан. Сарби Даниловна, ни дип җавап бирергә белмәгәннән, бары җилкәсен генә сикертеп куйды, күзеннән яшьләре сытылып чыкты. – Әәә, аңладым, алайса, үзең дә белдең, – дип, Солтан хатынны кочагына ук алды. – Менә бит дөньялар кайсы якка таба бара!

Сарби Даниловна тын гына:

– Ә кая таба? – дип сорамыйча булдыра алмады.

– Тарихи документлар таптык. Шәҗәрләр дә бар. Теләсәң, Хәтмулла шәкерт синең нәсел турындагы информацияне табарга мөмкин! Әниең ягыннан бабаларыңны Ханкала ягыннан дигән идең бит. Бар алар, бар. Синең шәҗәрәң дә шундадыр. Хәтмулла әйтмәдемени?

– Юк, әйтмәде шул, – диде Сарби, пышылдап. Аннары аңына килеп: «Ә минем әни ягыннан шәҗәрәне кем кайдан тапкан?» – дип уйлап куйды. Бу соравын Солтанга биреп тормады. Әнисе хакында читләр белән сөйләшәсе килми. Үзе дә яхшы белә, әнисе Сәрбиназ Ханкала артындагы бер авылдан. Яшь чакта аннан качып киткән. Нимес галименә кияүгә чыккан. Берничә ел элек кенә алар әтисе Даниил Френк белән әүвәл Германиягә, аннан Иранга күченеп киттеләр. Әнисе белән еш аралашып торалар. Тиздән Сарби үзе дә шулар янына китәргә әзерләнә. Солтан бу хакта белми, белергә дә тиеш түгел иде.

– Әллә борынгы ханлык чорындагы документларда якын буыннар турында да мәгълүмат бармы? – дип көлемсерәде хатын. Монысы эчтәге уйларын Солтанга белдермәс өчен үзенчә шаярту иде. Ләкин Солтан бу сүзләрне бик җитди кабул итте:

– И шунда ук, чиркәү астындагы яшерен таш сейфта, революциягә кадәрге татарларның нәсел шәҗәрәләре бар. Дөресрәге, революция башлангач, чиркәүне туздырганда, кемдер тапкан әлеге сейфны. Бәлки, анда булган алтыннарны яисә асылташларны үзенә алгандыр, ләкин шунысы әһәмиятле: ул алар янына соңгы гасырлар ревизия комиссиясе язмаларын да салып, яшереп куйган. Җеп очын большевиклар белмәсен дигәндер инде. Бу яктагы берәр бай татар булгандыр?.. Хәер, галимнәр ачыклар анысын. Әнә, күрәсеңме?

Алар артына зур автобус килеп туктады, һәм аннан тарихчылар, археологлар, башка белгечләр коела башлады.

– Институт кадәр институтны алып килдем! – дип көлде Солтан, янә шул якка таба ымлап. Боларның иганәчесе Паратов икәнлеген хатынга әйтәсе килмәде.

Сарби Даниловна шулай кыланса да, бу вакыйга аның күңеленә бик хуш килде. Тюркология буенча моңарчы булмаган материаллар кулына керәчәк бит! Бу хакта шундук Пал Палычка хәбәр итте. Пауль Вольфганг белән аның «командировкалары» да шуның белән бәйле ләбаса!.. Паратов дигән эшмәкәр аларга иганәче булды. Тик анысы соңгы вакытларда бу тирәдә никтер күзгә чалынмый.

***

...Денис Паратов, Солтан белән соңгы тапкыр күрешкәннән соң, оешмасының салымын яшереп калдырганы өчен үзен тотып ябасыларын сизенеп булса кирәк, чит илгә командировка китү сылтавы белән Касыймнан юкка чыкты. Һәркайда яраннары калды, алар аның күзләре, колаклары иде. Шулай ук Хәтмулла шәкертне эзләүне дә туктатмады. Аларның нәсел шәҗәрәсе шәкерт кулында булырга тиеш ди бит! Сизә Денис: әтисе аннан нидер яшерә. Әлбәттә, яман ният белән түгел, Денисны бәлаләрдән саклый бугай картлач. Башкала ягындагы «бурзайлар»ы Дениска шәкертнең эзенә төшүләре хакында хәбәр иттеләр. Аларга эзләүне көчәйтергә дигән күрсәтмә җибәрелде. Бу шәкерт кирәк, бик кирәк иде аңа. Чит ил китапханә-архивларында чакта ул Ханкала ханлыгының китапханәсе турындагы мәгълүматка – зур хәзинә белән бергә булгандыр! – юлыккан дигән хәбәр килде. Кече Паратовка ул шәкертнең телен чиштерергә уйлады. Шулай итсә, нәсел шәҗәрәсен тәгаен беләчәк иде кече Паратов... Тик тегесе качып котылды. (Кыйммәтле документларны теләсә кем кулына тапшырасы килмәде Хәтмулла шәкертнең. Чыннан да, Паратов юкка шикләнмәгән, кәгазьләр арасында теге такмакның серен ача торган мәгълүмат та бар иде. Паратовның Паратов булмыйча, инкыйлабка кадәр алтын приисклары тоткан атаклы Рәимовлар нәселеннән икәнлеге ачыкланды! Тик бу хакта әлегә аларның үзләренә белдерергә ярамый. Алар, ай-ваеңа карамыйча, бар табылдыкны тартып алачаклар һәм кыйммәтле хәзинә юкка чыгарга мөмкин...)

Хәтмулла шәкерт Абтюковлар фамилиясенә дә юлыкты. Уналтынчы гасырга кадәр булган шәҗәрәләре бар. Алары Шаһгали хан токымыннан булып чыкты. Унҗиденче гасырда, чукындырудан качып, мулла бабасы Пермь якларына киткән. Анда Абдулов фамилиясе алган. Унсигезенче гасыр ахырында, Абдуловларның Ильяс атлысы, үз теләге белән православие диненә күчеп, Абтюков булган! Чөнки нәкъ шул вакытта армиягә чакырыла Абдулов Ильяс, фамилиясен үзгәртү сәбәпле, унтер-офицер чинына кадәр үсеп житә. Унтер-офицер исерек килеш бер кешене атып үтерә. Аны жандармнар эзәрлекли. Аннан татар кызы булган хатыны фамилиясен алып, Ханкала ягына качалар. Абдуллинны эзләүче булмый, чөнки җинаятьне андый фамилияле кеше кылмаган. Бик кызык язмышлы нәсел бу! Моны хәтта уйлап та чыгарып булмый, язмыш шаяртуы, күрәсең. Илдә инкыйлаб башланып, дөньялар кабат үзгәргәч, болар тагын Абтюк фамилиясен ала, кавемдәге кайбер гаиләләр үзләрен рус милләтеннән дип яздыралар, чөнки рус булып партия баскычлары буенча күтәрелү ансатрак була. Тик Хәлиф Абтюков кына, фамилиясен үзгәртсә дә, ни сәбәпледер паспортта татар дигән тамганы саклап кала.

Хәтмулла шәкерт әлеге документларның күчермәсен белгән кешеләре аша өлкән Абтюковка җибәрде. Тегесе исә тиз генә малайга хәбәр итеп, нәселләре белән яңадан Абдулов фамилиясенә кайттылар; чөнки нәкъ шул көннәрдә малае наркотиклар белән тотылып, хөкем ителергә тиеш иде. Малай «эзен» суытты. Хәер, аны башка эзләп тә тормадылар, илдә болай да

болгавыр вакытлар. Өстәвенә бернинди җинаять кылмаган «Абдулов»ның кемгә кирәге булсын, ди!.. Аның каравы, Абтюков Хәтмулла шәкерткә гомерлек бурычлы булып калды һәм Туксабада мәчет яңарту өчен аңа күп итеп акча да вәгъдә итте. Авыл көне бәйрәмендә әлеге иганә акчасын Абтюков-Абдулов энесе, элеккеге участок милиционеры Салихҗан, имам булып билгеләнергә тиешле Туксаба мәчетенә тапшырырга ният иткән!.. Бу хакта Хәтмулла шәкерт хәбәрдар, ул каршы килмәгән, үз урынын бирергә риза, ди.

Каһирәдә укыганда Хәтмулла шәкерт махсус рәвештә Иранга барды, андагы архивларда утырды. Ханкала хәзинәсе хакындагы мәгълүматка юлыккач, гомерен шуны эзләп табуга багышларга, шуңарчы, укуын тәмам кылса да, хәтта указ да алмыйча торырга ант итте. Шул көннәрдә серле төш керде егеткә. Имеш, ул, чучкага атланып, сират күпере дигән күпергә кереп бара икән. Менә фәрештәләр аның юлын бүлә. Ул аларга бик тырышып, үзенең гомер буе изге ниятгә булганлыгын аңлатып карый, төшендерергә тырыша икән, тик тегеләре һаман күпергә якын да җибәрмиләр, ди. Чучкаңны атка алыштырып кил, шуннан соң бәлки кереп карарсың диләр икән, ди. Хәтмулла кире китеп бара. Чучкага атланып, дала буенча бик озак йөри. Чучка әлсерәп җан тәслим кыла инде далада. Шуннан соң аңа уйнап торган гарәп аты бирә кемдер. Хәтмулла шул ат белән янә сират күперенә таба юл ала. Юлында очраган фәрештә аңа: «Иманың нык түгел бит әле, шәкерт!» – дип кире бора.

Шуннан ул бик баш вата икән, иманны ничек ныгытып була? Бәлки, фәрештә ялгыша торгандыр? Иманы ныктыр, шулай булмаса ничек итеп дин юлына кереп китәр иде шәкерт?!

Фәрештә аны бер йортка алып керә. Ул йорт яшь балалар белән тулы икән. Кайсы бишектә генә ди әле.

– Менә болар тугач та бишек җыры ишетүдән мәхрүм булганнар. Үскәч, синең кебек иманнарын ныгыта алмыйча интегәчәкләр. Шуңа күрә монда аларга Әллү көен, бишек көен ишеттереп, җаннарын иман яңартуга әзерлибез, – ди икән!

Дөрестән дә, Хәтмулланың үз анасы аны тапканда җан тәслим кылган була. Ул үги әни белән үсә. Күрәсең, үги ана сабыйга бишек җыруы көйли алмагандыр. Димәк, фәрештә хаклы. Әмма фәрештә аның ни уйлаганына кадәр белеп тора икән. Ул:

– Әллү көйләре сабыйның канын сафландыра! – дип, тагын ачыклык кертә әле.

Хәтмулла шулчак сабыйга әверелә һәм аны теге фәрештә йорттагы бер бишеккә сала.

Үсеп җиткәч, тагын юлга чыга ул. Бу юлы атта бара. Менә тагын теге күпер янына килеп җитә. Һаман шул ук фәрештә:

– И мөэмин мөселман, и егет, ул күпергә барып җиткәнче юлың бик ерак, аңынчы дистә еллар узачак әле, ашыкмыйча бар, тирә-ягыңдагы аллы-гөлле чәчәкләрнең исләрен иснәп хозурлан, юлыңда очраган зәмзәм суларыннан авыз ит, фани дөньяның кадерен бел, тик иманыңнан тайпылма! – дип кисәткән. Иманнан тайпылмау ул асабаңны белү икән.

Шул төштән соң ханлык китапханәсен табарга ант кылган да инде

Хәтмулла шәкерт. Китапханә үзе үк табылмаса да, әнә күпме шәҗәрә килеп чыкты! Тулы бер тарих, чынлап та, зур хәзинә иде бу! Ниләр генә юк алар арасында! Һәр кәгазь, һәр катыргы үзенә күрә бер кыйммәтле китапка торырлык! Ул җай белән аларны укырга, өйрәнергә кереште. Әүвәл кемдер язып калдырган васыятьнамәдән башлады. Колмөхәммәт дигән татар кешесе, үзе ул Ханкала ягыннан булган, улынамы, әллә бар нәселенәме үгет-нәсыйхәтләре белән бергә васыятьнамә дә калдырган... Ханкала ханлыгы чорына караганлыктан, аеруча кызыклы алар, зур гыйбрәт алырлык хәл-вакыйгалар теркәлгән иде аларда. Хәтмулла шәкерт табылдыкның барысын да карарга өлгермәде. Шулай да, ни хакында икәнлекләрен аңлар өчен күбесенә күз салып чыккан иде. Алар арасында Ханкала ханлыгы турысындагы хәбәрләр дә, Куликово сугышы вакытында булган чын хәлләр тарихы да бар. Иң кызыгы Идел Болгарында татарлар яшәгәнлеге хакындагы документ булгандыр, мөгаен!

Боларны, язуларына карап, бары галим Фазыл Шәриф кенә кире җыя алачак. Язуларны да ул укып бирер. Шуңа күрә аның килгәнен көтәргә кирәк. Чүлмәктәге язуларда тагын кызыклы мәгълүмат барлыгына тамчы да шиге юк шәкертнең... Теге чакта ук Чураканга чиркәү асларында тарихи хәзинәләр булырга мөминлеге хакында Фазыл Шәриф әйткән иде бит.

Җеп очы Худяковта ук булган, тик нишләптер моңарчы ул игътибар белән генә укылмаган.

Хәтмулла шәкерт Иранда чакта бер кызыклы язу тапты. Такмак рәвешендә язылган иде ул. Исен-акылын китергәне шул булды: ул Паратов кулында да булган, әйтүе буенча, аңа аны Макай биргән. Анда ачыктан ачык Иван Грозный талаган Казан ханлыгы китапханәсенең бер өлеше Касыймда икәнлеге әйтелә! Аннан соң бүгенге Россия җире «Ханкала патшалыгы» дип йөртелгән! «Печать царства Ханкалы» дип язылган табылдык раслый моны! Россия патшасының мөһере була бит инде бу! Элек бар Россия «Ханкала патшалыгы» дип аталган. Чөнки Аурупа илләре вак-төяк рус кенәзлекләрен санга сукмый, бары Ханкала белән эш итәргә тели! Элек булса, бу мәгълүматны дөньяга чыгару мөмкин булмас, шунда ук койрыгыңа басарлар иде.

Күптән түгел КГБдан ФСБга әйләнгән оешма хәзер хакыйкатьне ачарга үзе үк ярдәм итәм дип тора, журналистларны яшерен архивларына кертә. Шулай булмый хәле юк, чөнки хәзер Россиянен Алтын Урда варисы икәнлеге хакында ачыктан-ачык иң дәү җитәкчеләр әйтә! Бу – кире каккысыз факт! Моннан куркасы юк, киресенчә, бу хакта белгән чит илләр, – Янки – Аурупа илләре – калтырап торачак Россиядән! Шулай булгач, бәлки, алар Россиягә каршы көрәшүнең мәгънәсезлек икәнлеген аңларлар, ике арада тыныч сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырлар. «Рус баш»лар, төрле вак-төяк шовинистлар, ниһаять, халыкларның туган телләрен өйрәнүнең Россия өчен куркыныч түгел икәнлеген аңлар! Коммунистлар милли телләрне юк итүне максат итеп куйганнар иде бит! Үзләре утырган ботакка балта чаба башлаган иде мәхлуклар!.. Максатлары, беренче чиратта, бөек Пушкин телен юкка чыгару иде...

## Көтү

Бу арада Солтан үзе дә очынып йөри, аңа үзе беренче булып Бану шалтыратты, күрешергә тәкъдим ясады. Моңарчы Русинны, Баһадурны аякка бастырам дип көн-төн чапканда да, ниндидер робот кебек йөрде ул, ал димәде, ял димәде, аруның ни икәнлеген дә белмәде. Инде булды дигәндә генә «Аюлар» мафиясе, «түбә» булам дип, шактый акчалар таләп итә генә түгел, талый ук башлагач (Баһадур фермасындагы җиде баш үгезне көпә-көндез килеп төяп киттеләр!), эшләр хөртиләнде, тик Солтан барыбер чигенмәде. Баш «Аю» белән очрашуга да ялгызы барырга булды. Югыйсә Рәимов каты гына кисәткән, «омон» бирәм дигән иде. Солтанның исә зурдан кубып, тавыш-гауга чыгарып йөрисе килмәде. Йөз илле килограммлы гәүдәсе өчен «Аю» кушаматы алган Ермолай аны урманга чакырды. Солтан моны да ишетеп белә: урманда алар шактый эшкуарның башына җитеп, бизнесларына хуҗа булдылар. Хөкемгә тартып карасалар да, бандослар шартлы срок белән генә котылалар иде. Әүвәл бик геройланса да, «стрелка»га берәр сәгать вакыт калгач, Солтан никтер югалып калды, моңарчы бик сирәк кенә исенә төшергән Бану килде күз алдына (әллә телефоннан сүз алышу сәбәпче булды инде?); йөрәге дөп-дөп тибәргә кереште, шулчак ул үзенең кызны бик тә юксынуын аңлады. Менә нинди тойгы йөргән булган икән йөрәгенең иң тирән бер почмагында, шул аны хәрәкәтләндергән, зур эшләргә өндәгән, кыскасы, көч биреп торган! Әгәр урманда аның башына җитсәләр! Бу хакта ишеткәч, беренче чиратта, Бану кара кайгыга калыр кебек тоелды аңа... Кызык инде, күптән аралашмаган да, күрмәгән дә килеш, әллә кайчангы хатын-кыз, имеш, нәкъ менә хәзер генә аны уйлап, янып яши, ди, сиңа! Сәер хис иде бу. Ләкин шулай да Солтанга яңа көч өстәде ул... Әллә икесе арасында теге чактан серле биотоклар урнашып калып, шулар кымырҗый башладымы? Солтан беренче мәртәбә Бануны бик нык сагынуын тойды, бик тә, бик тә кыз белән күрешәсе килеп китте аның.

– Кан! – диде Чуракан, бу хакта ишеткәч.

«Үзен аклый инде бу ләгънәт Миутын!» дип уйлап куйды Солтан. Белми иде әле ул Чураканның нигә юлыкканын… «Сине дә кан тарттымы безнең киленгә?!» – дип, әүвәл пыр туздырмакчы иде, әмма күптән түгел генә ишетте, аерылышу Зөләйха апа фикере булган икән. Хәер, яраткан укытучысын яклавын яклый да ул, тик анысы да Гафиятнең абыйсы белән кушылырга йөри, ди, түгелме соң?! Мулланур хатынын аерган да хәзер Зөләйха белән бергә булырга ниятли икән... Чыннан да, каннандыр бу бәлки? Мәхәббәт дигәннәре дә шул ук кан хикмәте микәнни? Бануга булган хисләре аның да әүвәл канында кайнагандыр әле?!

Бануны эзләп табарга да, күрешергә дә вакыт юк иде! Вакыт бөтенләй юк иде... Солтан, машинасына ике граната һәм бер «калаш» салып, үзе генә рульгә утырды. Югыйсә, шофёры: «Мин дә барам, каршы килсәгез, артыгыздан яшеренеп булса да иярәм», – дип, алдан ук әйтеп куйган иде. Аннан да качу җаен тапты Солтан. Шофёр егетнең күптән түгел генә баласы туган иде, аның харап булуын теләмәде. Ә үзе «үлем кочагына» атлыгып тора! Күңеленә ник бер тамчы курку хисе килсен! Мондый сәер

халәт үзенә дә аңлашылмый, хәер, ул аны аңларга теләмәде дә, ул хакта уйлап та кармады. Һәр ир-егетнең үз гомерендә бер мәртәбә булса да, үлем турында да уйламыйча, батырлык кыласы килә торгандыр инде ул... Бигрәк тә матурлыкка сусаган чагында. Батырлык бары тик Матурлык хакына гына кылына ала...

Яшьтәшләренең оныклары бар инде, ә ул һаман ялгыз ата каз кебек каңгырап йөри. Бәлки, Ходай моны алдан махсус шулай ниятләгәндер, бу җүләр баш ялгызы урманга «стрелка»га баргач, барыбер һәлак булачак, нигә гаиләне кайгыга салырга дип, мәсәлән?! Солтан бу уйларыннан үзе дә көлеп куйды һәм моңа кадәр җанында булган киеренкелекне йомшартып җибәрде, ул тагын битараф бер «утын агачы»на әйләнеп калды. «Аю» белән барыбер көрешәсе инде, чөнки шунсыз монда бернинди якты киләчәк күрәсе юк. Ә ул Рәимовка гына түгел, Ак кирмәндә утырган зур түрә абзыйга да монда үрнәк хуҗалыклар, яңа бистәләр булдырабыз дип вәгъдә итте. Өстәвенә мәчетне тергезергә рөхсәт бирәселәр, татар мәктәпләре ачарга рәсми ризалыкны алды инде. Ханкалада да туган телдә укыта торган гимназияләр йөздән артып китәчәк дип Үзе әйтте ләбаса...

Җиһанда 1997 елның ямьле язы, алда әле зур эшләр тора. Шуңа күрә нindидер «бандослар» кулыннан һәлак булып, чебен гөмбәләре арасында башыңны салу – үзе хурлык!

Пал Палыч пейджерына, «ашыгыч көрешәсе бар» дигән хәбәр салган. Ләкин Солтанның вакыты юк иде; әлбәттә, чамалый, сизенә ул: Пал Палыч монда күптән яшәгәнлектән, «бандос»ларны белә дип ишеттергәннәр дә иде. Мондый хәбәрне юкка гына җибәрмәгәндер? «Соң инде, алданрак кирәк иде, Пал Палыч», – дип көрсенеп куйды ул. «Стрелка»га барасын Рәимов белә, шул җиткән дигән уй тынычландырды аны. Бик ялгышты Солтан, Пал Палыч белән көрешәсе калган икән. Икеле-сикеле йөргән немец галиме, бәлки, аның белән киңәшмәкче булгандыр. Үзенең уйлары хакында уртаклашырга теләгәндер? Шуннан соң, тарихи документларның бик кыйммәтлеләрен үзе белән алып, суга төшкәндәй юкка чыкты Пауль Вольфганг – Пал Палыч...

Әлбәттә, чын дөресен Солтан белми иде. Сарби, яшь попка ияреп, Ташкалга ягына китеп баргач, үзенә урын таба алмады Пал Палыч. Сарби үзенә хыянәт итә дип уйлады. Көнчелеге күкрәк читлеген җимерә язды, ни кылганын үзе белмәде. Чиркәү астыннан килеп чыккан табылдыкларның бер өлешен алып, Башкалага китте. Төркиягә очучы беренче самолётка билет алды. Солтан пейджерына шуннан хәбәр салуы иде немец галименең.

Сарби, яшь попка ияреп, аның атасының туган якларына кайтып киткәч, Пал Палыч өй түбәсеннән сикерә язды! Хурлык, көнчелектән генә түгел бу, бу ачыш иде!.. Пал Палыч Сарбины ярата икән бит ләбаса! Белми йөргән, ияләнгән, күнеккән.

Инде асыл максатларга ирештек (төрки-татар турындагы тарихи документларның беришесе табылу) дигәндә генә, шуңа таянып язылган гыйльми эше белән остазы Френкны шаккатырабыз дип хыялланганда гына!.. Каян килеп чыкты соң әле бу майлы күзле, селәгәе агып торган поп кисәге?! Теге чакта Рудольф бабасының татарлардан коты алынып торган, хәзер аны бер рус попы җиңдеме?

...Ермолай урманның кеше-кара йөрми торган аулак җирен сайлаган. Монда сәвит заманында Башкаланың ярдәмче совхозы булган, экологик чиста ит, сөт һәм башка азык-төлекне Кирмән ашханәсенә туп-туры шушыннан озата торган булганнар. Партия таралу белән элеккеге зур совхоз да хәрабә хәленә килгән. Солтан анда Баһадурдагы ун мең баш чучканы, биш йөз «Лимузинская» токымлы ит үгезләрен күчерергә дип хыяллана. Бер ел элек күп итеп атлар үрчетә башлаганнар иде.

Тик нишләп Ермолай бу урынны сайлаган соң әле? Мөгаен, монда ат фермасы барлыгын ишетмәгән булгандыр әле? Белеп эшлиме, күз алдында атларын төяп, аны мыскыл итәргә ниятлиме бу бандослар?! Шундый уйлар белән Солтан урман авызына килеп җитте. Зур урман түгел бу, аның аргы ягында иде очрашуга билгеләнгән җир дә, элеккеге элит-совхоз хәрабәләре дә күренеп тора. Урманга кергәч, агачлар арасында аерым-аерым торган берничә кара джипка күзе төште: «Аю» үзем генә булам дип алдаган. Солтан, бардачоктан гранталарны алып, алгы утыргычка салды.

Чыннан да, ауган наратта Ермолай ялгыз гына утырып тора иде. Ул, Солтанны күрүгә, киң тешләрен күрсәтеп ыржайды һәм ике кулын югары күтәргән булды. Ул коралсыз, янәсе. Тик көн шактый кызу булуга карамастан, Ермолай нигәдер кыска балтырлы күнитек кигән, балтырында пычагы барлыгын әллә кайдан сизеп алды Солтан. Аның пычак белән оста эш итүен ишеткәне бар иде. Ул гранаталарның берсен, иелеп, агач төбенә куйды, «калаш»ны чирәмгә ташлады.

– Син дә пычагыңны ташла, Ермолай! – дип кычкырды аңа Солтан. Тегесе әүвәл аңламаганга салышып торды һәм аннан соң, янә киң тешләрен ыржайтып, елмайган кыяфәт чыгарды һәм итек балтырыннан суырып алган пычагын чирәмгә ташлаган кебек булды. Ташламады, бик оста хәрәкәт белән җиң очына шудырды, мәлгунь! Тик сатулашып торырга ара юк, Солтан да «чирмеш ыштаны» кимәгән, хәстәрен алдан күрде; менә аның каршысына ук диярлек килеп җитте, арада ун-унбиш метр ара калгандыр. Җиң очындагы граната сизелмәсен дип, ул «Аю» кебек кулларын күтәреп тормады. Ермолай, арты белән борылып, күлмәген күтәреп күрсәтергә кушты. Аның белән бергә диярлек үзе дә шулай эшләде: имеш, алар икесе дә коралсыз.

– Тебя спасло только одно, морда, что ты – татарин. А у меня на зоне татарин был лучшим другом. Память о нём я храню вечно, поэтому решил с тобой сам встретиться. – Ермолай шулай диде дә шаркылдап көләргә кереште һәм: – Память о тебе я тоже вечно хранить буду! – дип, агач башына ымлады. Анда, мылтыгын Солтанга төбәп, Ермолай снайперы утыра иде.

– Ты, Медведь, не мужчина! Это не честно! – дип кычкырды Солтан. Тик соң, бик соң иде. Ул, алданганына гарьләнеп, тешләрен кысты. Шулчак Ермолай сискәнеп китте: Солтан артында ук шарт-шорт берничә мәртәбә мылтыктан аттылар. Солтан үзе дә борылып карады, чыннан да, аның артында, агачлар артында кемнәрдер бар. Тик кемнәр булыр икән? Ул ялгызы килде ләбаса? Агачлар артыннан әлеге кешеләр үзләре күренми. Ермолайның ыржаюлы кыяфәте шунда ук курку алды.

– Ты тоже не лыком шит, оказывается, татарин! – дип кычкырды. Ул гына да түгел, Аксу елгасы ягында шарт-шорт ботаклар сынган, җир дөпелдәгән

тавышлар ишетелде. Бер генә ботак түгел, берьюлы йөз, мең ботак шартлап сынды бугай. Шуның артыннан ук үкергән, ухылдаган авазлар ишетелергә кереште. Әйтерсең Касыйм хан үз кавемен якларга бар гаскәрен туплап килә иде!..

Баһадурдан бүген Хәтмулла таң белән монда күчергән һәркайсы берәр тонналы биш йөз баш үгез көтүе булып чыкты ул! Шәкерт моны белеп эшләде. Мәгълүм ки, хайваннар, кошлар гыйбадәт тә кыла. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә: «Һәр мәхлук Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла, тәсбих әйтә. Тик сез аларның тәсбихларын аңламыйсыз гына», – ди. Берсендә Сөләйман галәйһиссәлам вакытында яңгыр яумый. Халык кырга чыгып намаз укырга тели. Шулчак Сөләйман галәйһиссәлам: «Булды, укып тормагыз. Бер кырмыска чыгып, ике кулын күтәреп, сезнең өчен яңгыр сорады. Аллаһы Тәгалә аның догасына җавап кайтарды. Тиздән яңгыр явачак», – ди.

Ул да булмады, аланга йөз, мең, юк, тагын да күбрәк хайваннар чабышып чыкты да, кая барырга белмичә, төрлесе-төрле якка таралышты, алан, урман җан ияләре белән тулды. Снайпер куркуыннан агач башыннан егылып төште. Әлбәттә, ул аларның гади йорт хайваннары икәнлеген аңларлык хәлдә түгел иде. Шулчак Солтан Ермолай кулында нидер ялтырап киткәнен күрде, ләкин сакланырга соң иде инде, тегесе пычакны аңа таба атты. Мизгел эчендә ике арада ак каен агачы кебек Бану «үсеп» чыкты, пычак аңа килеп тиде. Бу вакытта үгез көтүе, агач артына яшерелгән машиналарны сытып-изеп, аланга җитеп килә иде... Ермолай, башын ике кулы белән каплап, җиргә сузылып ятты һәм ямьсез тавыш белән акыра-бакыра, кычкыра башлады:

– Сдаюсь, сдаюсь! Остановите их!

Аланга «ОМОН» вертолёты төшеп утырды. Вертолёт тавышыннан өркеп, кире якка чабыша башлаган көтүләрне Хәтмулла тиз генә җыярга кереште. Аңа каяндыр пәйда булган Гафият белән Тукаш булыштылар...

– Көтү, бер купса, нәкъ ташкын кебек. Аңа бернинди көч каршы тора алмый: сарык көтүеме ул, халык көтүеме – мөһим түгел! – дип тел шартлатты Тукаш, Гафият ягына карап. Тегесе бу сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәде бугай: аптырап, сыйныфташына карады. Ләкин Тукаш шәрехләп тормады, бары эчтән: «Һәр тимерчегә һәм һәрбер игенчегә моны аңлау мәҗбүри түгел. Әмма күрү, белү зарур!» – дип куйды.

Таң ата да кич була, шатлык белән кайгы чиратлашып килә тора... Хәтмулла шәкерт Русин чиркәве нигезеннән табылган тарих-шәҗәрә турындагы язмалар белән бергә кемнеңдер иренмичә, кулдан төпләнгән дәфтәрләргә ихластан язып куйган сүзләрен дә бик бирелеп укыды. Ни өчен язган, тормышның иң ачы мизгелләрен ни сәбәпле теркәп барган бу адәм? Күрәсең, билгесез бер әдип булгандыр. Кол Гали, Мөхәммәдъяр һәм тагын берничә каләм иясеннән ары тагы кемне беләбез соң без? Югалган бит алар!.. Хәер, Тукай әйтмешли, халык – үзе әдип ул. Чынлап та, һәрберсе бер китаплык. Күңелгә тияләр, туп-туры җанга барып кадала сүзләре: «Өч көнлек дөньяда яшибез икән, Ходаем! Әле кичә генә җир җимертеп йөргән иде эти. Бүген өйлә вакытында: «Кызыл яр чишмәсенең салкын суын

эчәсем килә, улым!» – дип, күзгә карап ятты да, чишмә суы алып кайтып биргәч, бер генә йотып куйды, аннары күзләрен йомды һәм: «Бишек җыруы ишетәм, кем җырлый икән аны?» – дип сорады. Бу аның соңгы сүзләре булды. Йөзендә чишмә суы эчкән чагында чыккан рәхәтлектән балкыган шатлыгы ниндидер бер нур, яктылык булып катып калды. И әти, әти, әле моннан бер атна элек кенә, бәрәңге алганда, күрше Габдулның буразнасында сибелеп яткан тавык күкәе хәтле бәрәңгеләрен күреп сөенгән идең. Безнеке, әнә, һәрберсе чәйнек кадәрле бар дип шатланган идең. Шул чәйнек чаклы бәрәңгеңне дә тәгам итә алмыйсың инде хәзер. Бер йотым чишмә суы да җитте сиңа. Әйтерсең кеше гомере буе атыла-бәрелә яши, бер-берсен уздырырга тырыша, көнләшә, кеше уңышын күреп, кара яна, хөсетлек утында көя, ә үзе гомеренең соңгы минутларында бер йотым чишмә суы йотып кую өчен яшәгән кебек кенә килеп чыга? Һәм дөньяга килгәндәге кебек шул ук бишек җыры көенә мәңгелек йокыга тала...»

«Йа Алла! Моннан ничәмә ничә гасыр элек язылган сүзләр бит болар!» – дип шаккатты шәкерт.

Хәтмулла икенче кәгазьне кулына ала һәм тузаннарын сөрткәләп укырга азаплана, бу язманың хәрефләре начар танылa, күрәсең, читтә яшәгән берәр галим кебек кеше язгандыр. Баштагы өлешен исә бөтенләй укырлык түгел, хәрефләр вакыт узу белән агарып, җуелып беткән. Шулай да нидер аңлап була кебек: «...Тора-бара бу җирләрне, Ханкала белән янәшә генә булса да, «Бөек Ту биләмәләре» дип атаганнар. Бөек ханның Туы, ягъни Байрагы шушы биләмәләрдәге ныгытмада баһадир ирләр тарафыннан күз карасыдай сакланган. Мәңге таркалмас имән сандыкларда бу як асаба халкының, шул исәптән Туксаба – Тугыз абыз нәселеннән килгән татар халкының шәҗәрәсе дә акка кара белән теркәлгән...»

Бөек Ту... Бөек байрак... Бөек Тау.... Биектау... Кайчакта сүз-атаманың этимологиясе өстә генә ярылып ята, кайвакыт нык яшеренгән була ул. Туксаба атамасының асылы исә бөтенләй шаклар катарлык. Хәер, наданга, алар кебек үз тарихын белмичә интеккәннәргә шулайдыр. Туксабалар, ягъни тугызынчы гасыр ахырында яшәгән Кимәк ханлыгы вакытындагы татар (!) кабиләләре монда борын-борыннан хәят иткән! Болгар ханлыгының асылын да шул татарлар тәшкил иткән! Менә сиңа без татар түгел, без болгар дип йөр син!..

Туксаба – бары «тугыз абыз»дан кыскарган сүзтезмә...

«Күлтәк» дигәне «Күл Тәгин»нән кыскарган, бу хакта Орхон-Енисей язмаларында да бар: Кул Тәгин. Бүгенге күл исеме дә шуннан килә. Мөгаен, чыганакларда хата киткәндер; Кул Тәгин түгел, Кол Тәгин булгандыр чын дөресе. Кол Шәриф һәм шуның ише башка исемнәр тулып ашкан бит төрки-татарда?.. Алла колы дигәнне аңлата ул. «Тәген» төркиләрнең хан малайлары исемнәренә өстәлгән...

### Авыл

Пал Палыч тарихи документлар белән качып киткәч, Хәтмулла Туксабага кайтты. Солтанның яшьтәшләре җыелачак иде анда. Алар мәктәп тәмамлаганда, «киләчәккә хатлар» язып, Күлтәк буенда күмгән булганнар, хәзер менә шуларны алып укыр вакыт җиткән, ди.

Хәтмулла, мавыгып, кулына кергән кәгазьләрне актарып утырганда, ишек кыңгыравына бастылар. Ул әүвәл кәгазьләрен җыеп куймакчы иде, ахырда кире уйлап, тагын күпме яшереп сакларга була инде боларны дигәндәй, әлеге фикереннән кире кайтты һәм ныклы адымнар белән ишек ачарга китте.

Бусага төбендә Русиндагы Григорий атакай басып тора иде. Ул нидер әйтмәкче булып авыз ачарга өлгергәнче, тегесе сүз башлады:

– Хәтмулла хәзрәт, сине Солтан абый чакыра, – диде. – Хәзер үк. Җыела башладылар инде. – Ул нидер әйтмәкче булып авыз ачарга өлгергәнче, тегесе сүз кыстырдып өлгерде: – Гайнан мин, Сәрдәр малае. Туксабаның Сәрдәр, Сарматтагы Ләисов Сәрдәр малае. Аңлатырмын әле соңыннан. Әйдә, хәзер үк, тизрәк килергә куштылар.

«Гайнан дигән була?.. Сәрдәр малае... Ниткән Сәрдәр малае ди син?! Григорий атакай ләбаса син? Нишләп йөрүең бу якларда?!.» Хәтмулла, монда Русин попын күрүенә бик гаҗәпләнсә дә, уендагын тышка чыгармады. Бәлки, охшаган гынадыр?.. Атаңа охшаган рус күп була дигәндәй... Ул киткәч, Русинга попны эзләп килүчеләр булганын да әйтмәде. Яхшы машиналарда такыр башлы кәчүкләр иде ул. Берсе мәктәптә бергә укыган сыйныфташы, имеш, Касыймга эш белән килгәннәр дә, аны күрергә дип, Русинга кагылганнар, янәсе. Шикле кешеләр иде алар. Үзләре Григорийның Ханкала ягына киткәнен дә, атасы авыр хәлдә булгач, ашыгыч кузгалганын да әйтәләр. Күрәсең, әлеге хәбәрне тагын бер кат тикшерергә уйлаганнардыр. Бәлки, чынлап та, атакайның дусларыдыр? Сармат ерак түгел бит моннан. Әнә бит, мәгълүмат шактый боларда: Григорийның Сарматтагы атасының да ашыгыч рәвештә Ханкала ягына киткәнлеген белеп торалар?.. Үзара чышын-пышын нииндидер хәзинә турында сөйләшәләр, «клад», «клад» диләр... Әллә чиркәү асты казылганны беләләр микән, бәлки, болар «аю»ларның әшнәләредер; чиркәү нигезеннән хәзинә чыккан дигән хәбәргә адарынып йөрүләре түгел микән? Хәтмулла пошаманга төште һәм шул көнне үк Ханкала ягына чыгып киткән иде.

«Сәрдәр малае» шуннан ары башка берсүз әйтмәде. Югыйсә Хәтмулла көткән иде, Русинда күрешүләре хакында мондагыларга сиздерә күрмә, зинһар, дип гозерләнүен көткән иде... Тик беркавымнан бу уйларыннан үзе дә көлеп җибәрде: соң, бәлеш баш, үзең дә чучка көттең ләбаса анда; беренче чиратта, бу егеттән серне чишмәвен син үтенергә тиеш түгелме соң?! Мондагы мәхәллә каршында, милләт өчен, халык өчен кирәк иде дип кенә аклана алмыйсың! Барыбер аңламаячаклар. Чөнки заманасы шундыйга китте. Милләт, халык өчен дип, бары үз ягын кайгыртучылар белән тулды татар дөньясы. Шул нисбәтле Хәтмулланың башында яңа уй-ниятләр туды. Ул эчтән генә янәшәсендә атлаган егет ягына карап: «Рәхмәт, кем Григорий... Гайнан!» – дип куйды эченнән. Дуңгыз көтүчесе мулла була аламы? Лаекмы ул ошбу дәрәҗәгә?! Әлеге фикергә нәкъ менә шушы егет этәрде бит. Андый фикер тудырганы өчен бәндәгә рәхмәтле була белергә кирәк... Тик ул фикер-сүзне кайчан һәм ничекләр итеп мондагыларга әйтәсе булыр?.. Белгертмичә дә булмас, югыйсә Тукайны искә алучы табылыр да, әйтерләр аннары йөзеңә бәреп: «Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган; Кибән чалма кибәк башта: ишан булган имеш, хайван! Шуңа өстәп: «Харам мулла!» – диярләр...

Уй-фикерләр бер-берсе белән талаша, хәтта ызгыша да иде. Әле берсе өстен чыга кебек, әле икенчесе калка. Ул харам мулла түгел, ул хак мулла, ул – Хәтмулла – хакмулла.

## Китап. Ирләр

Элеккеге нигез күршесендәге хуҗасыз калган йортны сатып алып, аны яхшылап сипләттерде Солтан. Әүвәл андый уе юк иде, Бануның теләге шундый булды: «Мондый гаҗәеп таулар янында җәйләрен берәр ай яшәп китү үзе бер рәхәт», – диде хатын. Бануның андый хыялы булу яхшы, әлбәттә. Тик бу эшне башкарып чыгасы бар бит әле. Аны акча мәсьәләсе борчымаса да, барыбер күпме артыннан йөрергә кирәк! Рәхмәт яугыры, вак-төяк оештыру эшләреннән авылда яшәп яткан Гафият коткарды аны. Тукашның «Урман» кооперативы бригадиры кирәк булган саен такта һәм башка төзелеш кирәк-яраклары китереп аудара. Сәрдәр акча бирә. Кириллның әтисе Кирьян абый Путанайдан эшчеләр алып килде.

Бану буйга узган иде, элегрәк тауларда калын ботинка киеп йөргән геолог кыз искиткеч матур һәм мәхәббәт йөзле чын татар хатынына охшап калды. Чак кына соңлабрак килсә дә, Солтанның зур бәхете иде Бану. Якташлары белән киңәш-табыш җыенын да Бану теләге белән алар өендә уздыралар. Бу иске йортны яңартуда бар авылның ярдәме тиде, Солтан акчага мохтаҗ кеше булмаса да, һәркем өмә вакытында үзеннән хәл кадәренчә өлеш кертергә тырышты. Инде күптән онытылып бара торган өмәнең кабат яңаруы барысының да күңеленә хуш килде, күрәсең. Солтан хәтерли, элгәре шушы нигездә колхоз рәисе Барый абзый яши иде, дин тыелган заманда бу нигездә гает намазларын җыелып укый торган иде әтиләре.

Хәтмулла белән Гайнан ишектән кергәндә, киләсе кеше җыелып беткән иде, шуңа күрә алар күренүгә, Солтан: «Башлыйк, җәмәгать», – диде. Ни хакында сүз барачагын монда килгәннәрнең берсе дә белми иде әле; күрше Путанай, Шөмлән, Муҗым һәм Шумбраттан да кешеләр күренә, хәтта обком Абтюк та бар. Сыйныфташлар, яшьтәшләр бер җиргәрәк утырган, Гафият, Тукаш, Сәрдәр сөйләшеп туя алмыйлар. Солтан түрдә бу яклар танымаган чит кеше белән өстәл башында урын алган. Таныштырып алганнан соң, сүз шул кешегә бирелде.

– Академик Мөслим әфәнде Хәлилов. Бу якларны, бигрәк тә безнең тауларны күптәннән яхшылап өйрәнгән геолог-нефтьче, – дигәч, нурлы йөзле, мәһабәт кеше Мөслим Хәлилов торып басты да тагын бер мәртәбә өйдәгеләргә баш какты һәм, тамагын кырып, сүзен башлады:

– Иптәшләр, – диде ул, шул мизгелдә урнашкан тынлыкны бозып. – Бу җыен безнең особо әһәмиятле, әмма шул ук вакытта яшерен дә ул. Озакка сузып тормыйча турысын әйтәм, Ислемай тавында бик күп нефть запаслары булганлыгы ачыкланды. Бу инде өлгергән нефть, бүген үк буровой утыртып, аны ала башларга мөмкин. Әмма бу хакта әле берәү дә белми, – диде. Аннары обком Абтюк ягына борылып: – Әллә беләме? – дип сорап куйды.

Обком Абтюк инде күптән пенсиядә булса да, хәзер дә актив, һәр төрле эшләрдә башлап йөрергә ярата, төбәкнең ветераннар советы рәисе булып тора, үзенең шәҗәрәсе ачыкланып, бигрәк тә шуның аркасында бердәнбер

улы Артём өтерманнан котылгач, тагын да гайрәт белән йөри башлаган иде. Сорауның үзенә икәнлеген чамалагач, ул әүвәл баш какты, аннары:

– Бу хакта миңа билгеле, – дип куйды. – Хәйдәров Солтанның хатыны да белә бит! Рәимов кызы.

Академик аның сүзләренә игътибар да итмәде, дәвам иттерде:

– Без монда нефть барлыгын Башкаладан яшереп тә калдыра алабыз, чөнки Ханкала вилаять болай да дистә еллар буе бөтен Советлар Союзын үз нефть белән тукландырып торды. Ханкала ашатты Советларны, татарлар туендырды Башкаланы!

– Ә нигә яшерәбез соң әле без үзебезнең байлыкны?! Бар дөньяга кычкырырга, без бай дип мактанырга кирәк! – дип, Сәрдәр дә сүзгә кушылды. – Мин поддреживаю! – дип куйды ят тавыш белән.

Әүвәл ул сүз әйтергәме, юкмы икән дип, бик озак аптырап утырды, аннан соң монда этисеннән калган егерме биш кишәрлек һәм шуңа өстәп, пай җирләре дә барлыгын искә төшерде; ул гына да түгел, чыбык очы туганнары да яши ич әле Туксабада; шулар исеменнән дә фикер белдерергә хакы бар. Инде килеп, ул, Сәрдәр Вәисов, татарлар белән бер телдәге, уртак диндәге болгар халкы вәкиле дә бит әле! Ләкин бу хакта җәелеп сөйләргә шүрләде, белми иде әле ул аның зур эшләренә якташларының мөнәсәбәтен; Касыймда күрешкәч, Солтан якасыннан алды бит! Тукаш та каныкты, баштарак кул да бирмәде сыйныфташлары. Әмма Сәрдәрнең холкы шундый иде, ул һәрчак кычытмаган җирне кашырга яраткан гадәтеннән хәзер генә ваз кичә алмый бит инде?! Аның нәкъ менә шушы сүзләрен әйтүен генә көтеп торгандай, йорт эче кинәт гөлт итеп кабынып китте. Бер-берсен тупас рәвештә бүлдермәсәләр дә, ямьсез сүзләр әйтешмәсәләр дә, һәркайсы үз фикерен әйтергә ашыкты. Туксабаларга тиз арада ул нефтьне чыгара башларга кирәк, яхшы юллар булса, тормышыбыз тагын да яхшырса, начар булмас дигән фикердә торды. Кемдер киләчәк буынга калдырыйк, мәгәр ул хәзинәне барыбер Башкала үзенә суырып бетерәчәк диде. Икенче төркем нефть чыгара башлау мондагы искиткеч гүзәл табигатьне бетерәчәк бит дигән шик белдерде. Солтан, җыенны алып баручы буларак, һәркемнең сүзенә карата фикерен әйтергә тырышты.

– Мин дә авылдашлар яклы! Әйдәгез, нефть турында беразга онытып торыйк дип әйтимме соң. Төптәнрәк уйлыйк әле. Башкала безгә зур мөмкинлекләр бирде, киләчәктә дә Ханкаланың үзендә үк яңа татар гимназияләре ачылачак. Алар хәзер анда дистәләгән инде. Икегә аерылса да, безнең Туксаба – әле дә бик зур авыл. Мин районда белештем, яңа, шәп татар гимназиясе сала башларга проект төзелгән, ләкин финанс юклыгы гына тоткарлап тора икән эшне. Әгәр акча булса, райүзәктә берничә татар гимназиясе ачылачак. Монда безнең күршеләр дә бар, шуңа күрә алар өчен дә әйтәм, Шөмләндә, Муҗымда, Шумбратта да яңа клуб, яңа мәктәп, дөресрәге, милли телдә укытучы гимназияләр төзү планлаштырыла. Мәсәлән, мин Шөмлән урыс гимназиясенең проектын үз күзләрем белән күрдем. Андый гимназия тирә-якта юк! Якташлар, дуслар, авылдашлар! Үзегез аңлыйсыз инде, боларның барысына да зур акчалар кирәк. Ә нефть ул – акча! – диде. Тавышы бу юлы тагын да ышанычлы чыкты. – Күршеләрдә чиркәүләр, Туксабада берьюлы ике мәчет торгызырга вәгъдә бирәләр, – дип өстәде соңыннан.

Ханкаладагы Төбәк Комитетында этисенең элеккеге таныш инструкторы бар, ул аңа алдан күрсәтмә биреп куйган иде. Солтан бу хакта бүген бер авыз сүз әйтмәде, үз фикерен сөйләгән кебек әйтте. Дөрес, аңа кадәр Тукаш белән дә киңәшеп алды алар. Тегесе аяк терәп каршы тора: «Син нәрсә, ул Башкаланы күпме ашатырга мөмкин?!» – дип чәчрәп чыкты. Тукаш Касыймда табылган хәзинә хакында Төбәк матбугатында зур гына хәбәр бастырган иде. «Ханлыгыбыз китапханәсе табылды!» дип аталган әлеге язма шактый шау-шу кузгатты, Тукаш исеме күпләргә мәгълүм булып, соңгы көннәрдә абруе үсеп киткән иде каләм иясенең. Тик шулай да соңгы көннәрдә аның үз-үзенә ышанычы югалып тора, хатыны Мәликә «хәлләре» аны тәмам чыгарыннан чыгарган, шул сәбәпле җаны тотрыклы түгел, ә бу исә акылны да чуалта иде. Тукаш, Солтанны шаккатырып, аны якларга керешмәсенме! Әйтерсең Солтанның күзләрендәге өмет ялкыны Тукашны да кузгалтып җибәрде:

– Иң беренче булып, монда нефть чыгаруга, үзегез яхшы беләсез, мин каршы килергә тиеш идем, чөнки урман бетсә, минем пилорамалар да туктап кала, «Урман» фирмасын, бизнесымны да ябарга туры киләчәк. Әмма мин шуны әйтәм: әйдәгез, яшермик бездә шундый хәзинә барлыгын. Без гомер буе Башкаланы поддержать итеп яшәдек! Барыбызга да яхшырак булачак бит! – диде ул һәм Солтан ягына карады.

Солтан урынына Гафият сүзгә кушылды. Яшьтәше Тукаш – хәзер атаклы кеше, каләм иясе, китап кадәр китап яза торган кеше, ә китап сүзе аның өчен зур сүз иде. Баштарак үзенең Ислемай тавы итәгендәге «Тимер» кооперативы язмышы өчен борчылса да, хатыны Ясминә: «Солтан нәрсә ди?» – дип сорады иреннән. Гафият башта тузынмакчы иде, минем үз сүзем юкмыни дип кәҗәләнмәкче иде, хатынның кырыс тавышы сискәндереп куйды. Нәрсә ди бит: «Көнләштең инде шул Солтаннан тәмам! Сез, Әлли ягының берничә бөртек малае, гомер буе бер-берегездән көнләшеп яшисез! Гәрчә бер имән тамыры кебек бергә үссәгез дә! Халык мәнфәгате хакында сүз барганда булса да, бер сүздә булыгыз инде!» – ди бит!.. Хак сүзләр сөйли Ясминә. Шуңа күрә ул хәзер башы-аягы белән яшьтәшләрен якларга әзер тора иде.

– Мин дә яклыйм! – дип куйды ул.

Шулчак Чуракан сикереп торды һәм беркавым карашы белән хәзер инде якташларына әверелеп бетә язган халыкны сөзеп чыкты да:

– Дүрәк сез! Дүр-р-рәк без! – диде һәм җыелышны ташлап чыгып китте.

Академик шул урында сүз кыстыруны кирәк тапты:

– Тау артын буровойлар тишмәячәк бит. Ә бар урман шул якта, – диде ул. – Тик ашыкмыйк, уйлап бетерик. Башта ук әйтеп китим әле, Ханкаладагы җитәкчелек тә искитмәле зур запасаларны әлегә Башкалага күрсәтмәү ягында.

Ләкин аның бу сүзләрен ни өчендер игътибарга алучы булмады. Югыйсә якты көн кебек аңлашыла, әгәр югары җитәкчелекнең фикере шундый икән, димәк, алар карар иткәнчә булачак; сирәк ялгыша Ханкала җитәкчеләре... Ялгышсалар, берәгәйле була хаталары... Тик Ислемай тавы нәкъ менә аларның авыллары янында булганлыктан, һәр кеше үзен бу мәсьәләне хәл итүдә җаваплы дип саный иде.

– Мин дә Солтан белән Тукашның фикерен, Сәрдәрнекен дә хуплыйм.

Астыңдагы байлыкны яшереп ятудан ни файда?! – дип, Гафият тагын кушыласы итте. – Башкала беркайчан да безгә аяк чалмады. Сәвит заманнарын искә алып тормыйк инде, ул узды, үтеп китте, бетте. Коммунизмны да күрә алмадык. Мәгәр нефть чыга башласа, бәлки, монда чын коммунизм килеп җитәр! Аннан соң, Тукаш дөрес әйтә, без, татарлар, һәрчак Башкаланың ышанычлы терәге булдык! Кирьян, ник дәшмисең? Әллә шәҗәрәңдә татар тамырлары табылгач, руслыгыңны капылт оныттыңмы? – дип, ул Путанайдан килгән якын белешенә таба борылды. Кирьян, үз исемен ишеткәч, кыймылдап куйды һәм аннары торып басты:

– Менә монда минем малай Кирилл да килде. Ул Сарматта яши, без чакыргач кайтты. Ул әйтә, Сарматта да хәзер күпләп милли мәктәпләр ачыла. Татарча концертлар куялар, Сабан туйлары уздыра башладылар, ди. – Кирилл, йә, ни әйтерсең?

Кирилл бу вакытта янәшәсендә утырган Сәрдәрнең колагына кызу-кызу нидер пышылдый иде, әтисенең сүзеннән соң ул торып басты:

– Бану, Ясминә һәм Мәликә, сезгә яшисе, якташлар, үзегез хәл итегез. Мин ни әйтим ди. Әйтергә дә могу, кирәк дисәгез. Әгәр Сарматта трактор заводы булмаса, халык анда эшсезлектән күптән аягын сузачак. Хәзер завод та юньләп эшли алмый. Ашыкмаска кирәк Башкалага нефть турында хәбәр итәргә дим.

Ул шулай диюгә, янәшәсендәге Сәрдәр торып ук басты:

– Кирилл, син нәрсә?! Авылда юл, мәдәни учаклар, мәктәп булмасынмы?!

– Мин клуб салмыйк димим бит, мәктәпне яңартмыйк дип тә әйтмәдем.

– Күреп торасың бит, беренче булып, рус авыллары юкка чыгып бара. Авыл борын-борыннан рус кешесенең канында кара кан булып укмашкан. Ашау – байдан, үлем – Ходайдан диме әле татар?! Крепостное право вакытында укмашкан ул кара кан. Авыл кешесенә эш булдырырга кирәк, ул канны куып таратыр өчен. Мин моңа да каршы килмим. Бары үзебезнең җирдәге байлыкны мондагы халык өчен файдаланырга ирек бирмәячәкләр диюем. Рус качып бетте бит инде авылдан! – дип, Сәрдәр аңа төрттереп алды. Әмма тегесе бу юлы күтәрелеп бәрелмәде, этләшмәде, бары:

– Мин монда бүген халыкны төрле милләтләргә аерып сөйләшмим. Халыкмы – халык, кешеләрме – кешеләр. Миңа шунысы мөһим! – диде.

– Нефть чыга башласа, эш була бит инде кешегә! – диде Сәрдәр тагын Кирилльның сүзләренә каршы. Аның бу сүзләре Кирилльның отыры ачуын китерде. Ул Сәрдәр яныннан читкәрәк күчеп утырды. Кычкырып әйтмәсә дә, аның: «Бетте ни, бетмәде ни сиңа татарың. Син бит Болгар халкы вәкиле!» – дип мыгырдаганын Сәрдәр аермачык ишетте. Сүзне Кирьян дәвам иттерде:

– Солтанның милли мәктәпләр дию әйбәт. Милли мәктәпләр ачарлык кына байлык бар бездә. Башкалага озатабыз бит, һаман раскулачивание дигән нәрсә дәвам итә, үзебезнекен үзебезгә күбрәк калдырырга вакыт. Солтан, син, җай чыккан саен, өстәге түрәләр кебек милли мәсьәләне кузгалтма. Кеше авызын ачса, үпкәсе күренеп тора, ләкин алар ул сүз кузгалганда һаман милли ди, азатлык, ирек ди. Синең мәрхүм бабаң белән без ул сүзнең нәрсә икәнлеген дә белми идек. Мин атаң Мирсәет белән тагын да дусрак булу өчен татарча өйрәндем. Яшь чакта тел өйрәнүнең бер дә авырлыгы юк аның.

Хатыннар, ирләрнең барыбер уртак бер фикергә килә алмаячакларына инангандай, өчесе берьюлы ишек янына килеп бастылар. Мәликә Тукашның сөйләгәнен бик игътибар белән тыңлап торган иде. Хатын беркавымга аптырап калды. Ни сөйли бу Ямаш-Тукаш? Әйе, Ямаш булып сөйли. Ә нишләп Тукаш булып сөйләми әле? Мәликә, калганнарга сиздермичә генә, Тукашка ым какты, монда таба кара һәм мине тыңла, янәсе. Аның бик тә бу җыендагылар арасында Тукашын аерып күрсәтәсе килә иде. Хатын-кыз башы белән ирләр арасына кереп сүз әйтү турында уйларга да ярамый. Тик ничек итеп аңа бер ишарә генә булса да ясыйсы соң?

Бәхеткә, Тукаш алар басып торган ишек ягына таба башын борды, Мәликәне күреп алды. Хатын тиз генә аңа әүвәл ияге, аннары куллары белән ишарәләр ясарга кереште. Тукаш гаҗәпкә калып, тик карап тора. Мәликәнең үзенә әйтер сүзе барлыгын аңлады аңлавын. Мәликә, аптыргач, бармаклары белән түгәрәк ясап күрсәтте. Күкәй дигәнне аңлата иде бу хәрәкәте. Әмма Тукаш һаман төшенеп җитми. Мәликә куллары белән тавык булып та күрсәтте, канат каккандай кулларын җилпеде. Ниһаять, аңлады Тукаш! Хәзер Мәликә аннан җавап көтә: йә, ничек, ни эшләргә уйлыйсың янәсе? Тукаш, аптырап, иңбашын сикертте. Мәликәнең күз карашы ирне өтеп алгандай итте. Тегесе түзә алмады, кыймылдап куйды һәм торып басты да:

– Җәмәгать, бары бер минут, зинһар! Мин бая әйтүен әйттем дә. Әле минем менә монда кыска шигырем дә бар. Укыйм, – диде һәм укырга кереште:

Ата казың күкәй саламы дип сора...
Безнекеләр түгел, Башкаланың сала!
Өлешенә тигән көмеше ни дисәң? –
Ханкалага күкәй кабыклары кала...

Бу юлларны ишеткән ирләр тетрәнеп китте. Тынлык урнашты. Авыр тынлык иде бу. Тик шуңа да карамастан, кешеләрнең күбесе җиңел сулап куйды. Хәзер, шушы форсаттан файдаланып, тәнәфес сыман нәрсә ясарга кирәк иде. Бану:

– Әллә, булмаса, чәй чыгарыйкмы, Солтан? – дип, иренә карады. Солтан дерт итеп куйды. Өй тулы ир-ат янында хатынының сүз кыстырырга батырчылык итүен өнәмичә, тамак кырып алды. Әмма Бану аның киная-сенә төшенмәде. Чөнки моңарчы Солтанның беркайчан аның «ирегән» чикләгәне юк, хәтта моннан да зуррак җыелышларда да ул, теләсә, беренче булып сүзен әйтә ала иде; шуңа күрә кисәтүне аңлап җиткермәде. Әмма Мәликә белән Ясминә яхшы аңлаганнар иде. Алар икенче мәртәбә авыз ачарга ирек бирмәделәр, Ясминә җайлап кына аның беләгенә кагылып, кухня ягына әйдәде. Мәликә дә, авылдашын хуплагандай, Бануның алдына чыгып басты, һәм ни арада хатыннар күздән дә югалдылар. Үзен кухняга төртеп кертүләренә Бану, бик аптырап, әүвәл авызын турсайтты, канәгатьсезлек белдереп, өйдәш хатыннарга карады.

– Өй тулы ир-ат янына яланбаш чыгып басмасаң! – диде Ясминә аңа дорфа гына. Мәликә, гадәтенчә, сыйныфташының сүзләрен йомшартырга ашыкты:

– Үзләре әйтерләр әле тамаклары кипсә, – дигән булды, шуның белән үзара

сизелер-сизелмәс һәм капылт кына килеп чыккан аңлашылмаучанлыкны җайларга теләве иде бу.

Алар байтактан кухняда медер-медер сөйләшә-сөйләшә, дустанә чәй хәстәрләсәләр дә, сизелеп тора: Туксаба хатыннары Бануны читләтәләр, аны өнәп бетермиләр, бәлки, көнләшәләрдер дә әле. Ни әйтсәң дә, Солтан хатыны бит! Бану моны тоеп тора, хуҗа буларак та, итагатьлек саклап та сиздермәскә тырыша. Тик аның өй уртасына чыгып басып: «Нишләвегез бу, эти, Солтан! Нефть – кара алтын бит ул! Башкала гомер буе бу яктан суырып яткан алтын! Балалар турында уйларга кирәк!» – диясе килә. Әйтерсең, бу аның үз фикере генә түгел, йөрәк астында типкән бәбинең дә теләге, аның да ризасызлыгы. Ясминә белән Мәликә дә аның яклы, әмма алар бу рәвешле ирләр сүзенә кысылуны әдәпсезлек дип исәпли һәм, авызларын яулык читләре белән капламасалар да, кала хатынының тыйнаксызлыгын, оят саклый белмәвен кабул итә алмыйлар. Гәрчә, бу өч хатын ирләр урынында булса, мәсьәләне күптән һәм бертавыштан: «Юк!» дип хәл иткән булырлар иде. Хатын-кыз, беренче чиратта, балалары турында, аларның киләчәген уйлый дигән фәлсәфәдән ерак булсалар да, нәкъ менә шундый катгый карарга килгән булырлар иде. Ирләр ялгыша, ирләр хаталана.

Бану әле күптән түгел танышкан хатыннарга үпкәләвен сиздермәскә тырышты, сәбәп тапкан булып, өйалдына чыкты. Ачык ишектән ургылып кергән кичке авыл һавасы айнытып җибәрде, баядан бирле кендек турысында кыймылдаган җан да ничектер тынычланып калгандай. Үпкәсе шундук юкка чыкты. Акылы белән кабул итмәсә дә, күңеле, татар хатыннарына хас эчке тавышы хаталанганын тойды бугай.

Ул ишегалдына ук чыкты, капкага таба китте һәм тау итәгендә, авылдан шактый читтә туктап калган машиналарны күреп, шомланып, кире өйгә таба ашыкты. Әлеге машиналар бая эңгер-меңгер вакытында ук шул урынга килеп туктаганнар иде. Аучыларга да, балыкчыларга да охшамаган үзләре, чөнки машина янында да, аннан ары да кайнашкан кешеләр күренми, кемнәрдер машина тәрәзәләреннән бик бирелеп авылны, аларның иң кырыйдагы йортын күзәтәләр кебек иде.

Бану, өй ишеге ачылган тавышка сагаеп, капылт артына борылып карады; бусага төбендә иңенә ак шәл япкан Ясминә басып тора. Баш миен: «Солтан бүләк иткән Ырымбур шәле!» дигән уй кыздырып узды. Нәкъ аныкы кебек затлы шәл! Көнләшүдән хатынның эче яна башлады. «Ата мәче! Бу хатын да аның яшьлек мәгъшукасы булган, күрәсең!» Тик бу халәт озак бармады, йөрәк астындагы җан кыймылдап куйды, һәм ул тирән итеп күкрәгенә һава алды, тынычланырга тырышты.

Ясминәнең исә үз уйлары иде. Бануны беренче күрүдә йөрәге тасырдап алса да, тора-бара хисләре суынып, җаны урынына утырды. Беренче күргән көнне хатын-кыз гадәте буенча ул Солтанның яшь хатынын энә күзеннән үткәргән иде. Шәһәр хатыны Бануның тауда йөри торган ботинкалы аякларыннан күзен алмады, мыскыллы карашы бораулапмы бораулый иде Солтан бичәсен. «Шәһәр хатыны исеме күтәреп йөргән булалар тагы... Ә үзе матур туфли дә кия алмаган!» Аннан соң ул үзенең матур туфлиләренә карап куя. Гафияте аңа әйтте: «Кеше янына чәчәк кебек киенеп бар, әнисе», – диде. Кеше янына бер хәл. Соңгы араларда кибеткә махсус алып барып, өйдәге халатын да берничә пар алдыртты. «Минем сине ертык халаттан

күрәсем килми», – ди. Менә бит ул, тора-бара мәхәббәт дигәнең матур халатка, иреңнең сиңа булган игътибарына әйләнеп куя икән. Җырлар җырлап, ихахай-михахай килеп йөрү яшь чакта гына килешә ул. Яратам, имеш… Ул җырлаганны исенә төшереп, сагынам дип, авыз ачкан булып, күз яшьләре түк, имеш... Мондый матур, тигез тормыштан акылы чалшая башлаган хатын-кыз гына йөз чөерер, тәмен белмәс, аңламас дип, белеп әйтәләр андыйлар турында, үз маена чыдаша алмый дип... Түшәмдә әллә ниткән сурәтләр күренүе аңа да баш китүгә бер хәбәр булды түгелме соң? Мәхәббәт, имеш... Бар ул мәхәббәт, юк дип әйтүе түгел. Әмма яши торгач, ул башкача була. Татар хатынының йөрәге тулып ашкан була мәхәббәттән, яшенә дә карамыйча. Бәхет шулдыр инде ул, күрәсең. Тәмле, татлы бәхет... Элек аягына егылырга әзер буган Солтаннан, хатынына матур туфли алып кидерә алмаган ирдән мыскыллы көләсе килә хәзер. Шул уйлардан аңа бик рәхәт була. Бу мизгелләрдә бик бәхетле иде хатын. Бүген исә Солтан хатыны күзенә бик күркәм күренде, башына салган ак Ырымбур шарфы аны патша кызлары кебек иткән. Кавказ хатыннарына тартым озын кара керфекләре, кара тутлы йөзе балкып тора. Чибәр икән тагын үзе.

Ә Бануга бер күрүдә ошады Ясминә атлы бу авыл хатыны. Үзенең дәрәҗәсен дә белә, борынын да артык чөйми. Итагатьле, гаилә терәге, ир терәге... Ходай махсус шулай ярата кыз-хатынны: иң зур бәхет – ул ирең янында... Бану әлеге уйлардан үзе дә уфтанып куйды: ул бу хакыйкатьне соң аңлады бугай, әнисе сүзен тыңламады кыз чакта. Соң булса да, уң булсын инде...

Бану Ясминәгә авыл кырыендагы таллар артына поскан шикле машиналар турында әйтеп тормады. Бүген райүзәктән дә түрәләр бар. Шулар утырып килгән машиналардыр дип уйлап куйды үзалдына. Алар өйгә керделәр. Ирләр иртәгә кабат очрашырга сүз куешып таралыша башлады. Әгәр тагын бераз утырсалар, тәгаен туксабалар белән путанайлар якага-яка килерләр кебек иде. Әүвәл суынырга булдылар. Путанайдан Осьмуша, Дубыня, Путята, Кирилл, Кирьян артыннан ияреп, үзләре утырып килгән янгын сүндерү машинасына таба киттеләр. Шофёр кузгалгач, нигәдер сиренасын кушты, кабина түбәсендәге утларны яндырып куйды. Гүя авылларына ут капкан да, янгын сүндерергә ашыгалар иде. Гафиятләр өе янына килеп җиткәч кенә, сиренасын сүндерде. Аларны капка төбендә бригадир Дубыняның хатыны Евлампия көтеп тора иде.

Күрше авылларны озата чыккан яшьтәшләр алар артыннан сүгенеп озатып калдылар. Өстәвенә янгын сүндерү машинасын юри шулай кычкырталар кебек тоелды. Солтан Гафият алып килгән ау мылтыгыннан һавага атып җибәрде. Ислемай тавы артына кереп бара торган кызгылт ай мылтык тавышыннан калтыранып куйды. Таллыклар артында посып торган машинада йокымсырап утырган шикле кешеләр уянып киткәндәй булды. Аларның берсе пистолетын чыгарды да, үзләренә һөҗүм итәләр дип уйлап, куркуыннан, ачык тәрәзәдән берьюлы ике мәртәбә атты. Туксабалар ату тавышының кай яктан икәнлеген тәгаен чамаламады, Гафият, путанайлар җавап бирә дип уйлап, Солтан кулындагы мылтыкны тартып алды да ачудан һәм җавап йөзеннән бер-бер артлы шарт-шорт дөпелдәтергә кереште.

Таллыклар артындагы чит кешеләр мондый һөҗүмне һич көтмәгән иде. Ике машина берьюлы кузгалып, Путанай ягына элдерде. Алдагы

машинаның арткы утыргычына чүмәшкән Сармат мафиясе башлыгы Никита-Кит һәм Касыймнан Ермолай үзләренең ялгышканын шунда гына аңлап алдылар, бу мәчетле авылда нишләсен поп калдыгы, әнә алда чиркәү гөмбәзе шәйләнә һәм алар эзләгән поп та нәкъ менә шунда качып ятарга тиеш ләбаса! Алар авылны хәзер үк камап алырга уйладылар.

Касыйм чиркәве астындагы хәзинәне яңа поп урлаган дигән хәбәр җиткергән иде аларга Пал Палыч һәм аның Ханкалага кайтып киткәнлеген әйтте. Әлбәттә, минем Сарбины ияртеп киткән димәде, аннан шуның үчен дә алыгыз дип, дөресен чишмәде, бар нәрсәне хәзинәгә кайтарып калдырды. Ул урлап киткән табылдыклар арасында Ханлык китапханәсенең бер өлеше нәкъ Путанай чиркәве нигезендә диелгән иде; хак сүзләр сөйләде Пал Палыч. Хәзинә дигәне бандитларга бары алтын сурәтендә иде, шуңа күрә алар бу сүзләргә тиз ышанды. Ике чиркәү астыннан чыккан хәзинәне берьюлы эләктерү исәбе иде бандосларның.

Пал Палыч, ягъни Пауль Вольфганг, күз яшьләрен көч-хәл белән тыеп, Төркиягә очты. Уйлары икеле-микеле иде, Сарби кирәкме миңа, әллә кулындагы тарихи документлар мөһимрәкме дип, бик озак баш ватты ул. Һәм соңыннан, бер карарга килеп, качып китте.

Яңа килгән яшь поптан да көнләшә иде ул. Моңарчы алар ир белән хатын кебек яшәмәсәләр дә, араларында мәхәббәт уты кабынып, икесен дә газапларга салмады бугай; тора-бара күнегелгән дип уйлап йөргән Пал Палыч Сарби Даниловнаны чынлап яратуын белде! Һәм бу аны аяктан ега язды, ир уртасы кешенең йөрәк турысында нидер кыймылдый башласа, эшләр яман булачак, Пал Палыч баштарак бернигә дә карамыйча Сарбины кире кайтарыга тиешлеген аңлады. Шул рәвешле Пал Палыч ярдәме белән бандослар Григорий атакайның эзенә бик тиз төштеләр, хәтта Гайнанның күптән түгел әтисенең туган ягына киткәнлеген дә беләләр иде. Чиркәү асты казылып, анда да хәзинә табылгандыр дигән татлы уй аларны шул төнне үк Ханкала ягына поп артыннан куды.

Дубыня үзләре артыннан шикле машиналар ияргәнен ян көзгедән күреп алды, чөнки тегеләр шарт-шорт ата ук башлады. Путанайлар машинасы авыл кырыендагы калкулыктагы янгын сүндерүчеләр йортының биек капкалы ишегалдына кереп качарга өлгерде. Яшьтәшләр, бу хәлгә исләре китеп, һаман капка төбендә басып торалар иде. Таллыклар артыннан кинәт пәйда булган ике кара машина, пистолеттан ут чәчә-чәчә, путанайлар артыннан ыргылды. Сәрдәр, аптырап, пейджерыннан Кириллга хәбәр язды, тегесе исә өзек-төзек җөмләләр белән булса да, әле үзе дә аңлап бетермәгән хәлне кыскача сурәтли алды.

Туксабалар, капылт кузгалып, ут капкандай, тиз генә өйләренә таралды һәм ау мылтыкларын алдылар; Солтан машинасы яшен тизлегендә Путанай тарафына кузгалды. Алда чын сугыш, алда кан кою көтелә дип уйлады алар. Ләкин бандосларның, үз артларыннан ияргән ишле халыкны күргәч, фикерләре тиз үзгәрде, шулардан күреп, калганнар да күтәрелеп чыкса, аларны чебен урынына кырачаклар бит дип шүрләде Ермолай һәм машиналарны Ханкала ягына борырга кушты. Касыймга юл Ханкала аша иде.

*(Ахыры киләсе санда.)*



Галимҗан
Гыйльманов

# БҮЛӘККӘ – ӘТИ

ХИКӘЯ

Сәлим быел Яңа ел бәйрәмен каршыларга ныклап әзерләнде. Аңа инде биш яшь тулды, һәм ул хәзер Яңа елның, Кыш бабайның мавыктыргыч әкият кенә түгеллеген бик яхшы аңлый.

«Каян белә соң ул, каян барысын да аңлый, аның әтисе юк бит?» – дисезме? Белә шул. Бүген һушлы, зиһенле бала булып үсү өчен әтиең булу мәҗбүри түгел. Әниең бик җиткән. Әтиләр урынына акыллы аппаратлар, компьютерлар уйлап тапканнар. Сәлим дә өч яшеннән компьютерда утыра, «Интернет» дигән җирдә яши. Дөрес, аның әнисе бар, ләкин ул «бизнес» дигән бик җитди эштә эшли, улы белән аралашырга вакыты да калмый. Балалар бакчасына барганда-кайтканда гына рәхәтләнеп сөйләшеп, уйнашып, көлешеп алалар...

Яңа елга керәсе кичне Сәлим әнисе янына бәйрәм табынына җыйналган кунаклардан сөйдереп чыкты да, үз бүлмәсенә кереп, йомшак түшәгенә чумды, аннары, алдан ук уйлап куйган теләкләрен тели башлады...

«Кыш бабай, әйбәт бабай, беләм, синең тылсымың бар, миңа әтиемне табып бирсәң иде... Бүтән бер бүләк тә сорамыйм, нәрсә теләсәм – әнием шуны алып бирә... Ә менә әтиемне табып бирә алмый. «Әтиең еракта, дөнья читендә үк», – ди... Менә шушы фотосын гына саклап тота... Беләм, әнием дә оныта алмый аны, кайчакта елап та ала... Әтиемне сагынып елый ул. Мин дә сагынам, күргәнем булмаса да, сагынам... Табып бир миңа әтиемне, ә?»

Иртән Сәлимне әнисенең ягымлы тавышы уятты.

– Яңа ел котлы булсын, улым, бәрәкәт, бәхет алып килсен!.. Тор, әйдә, тор, бәйрәм коймаклары җитеште...

Гел шулай: Яңа ел бәйрәменнән соң әнисе коймак пешерә. Бөтен танышлары пилмән пешергән була, ә менә аның әнисе коймак белән сыйлый. Өйләрендә коймак пешмәсә, бәйрәм кебек тә түгел аларда... Әнә инде тәмле исләр зал ягына чакырып тора...

Тик Сәлимнең торасы килми. Йокысы да туйган инде югыйсә... Әйе, аның үзе генә белгән серле уйларын уйлап куясы бар. Әтисе хакындагы уйлар ул. Сәлим инде белә: Кыш бабай гына кайтара алмаячак аның әтисен. Андый тылсым әле уйлап табылмаган... Ләкин барыбер рәхәт. Яңа ел алдыннан әтисе хакында уйлау, матур теләкләр теләү аның кечкенә йөрәгенә җылылык биреп тора. Хәтта бераз гына бәхетле дә итә...

Әтисе бар бит аның! Дөнья читендә булса да, әтисе бар. Әйбәттер ул – әйбәт булмаса, әнисе елап та тормас иде... Иң мөһиме – бар бит ул. Ә булгач, кайчан да булса кайтачак. Азрак үссен генә Сәлим. Кыш бабай эшли алмаганны эшләячәк ул – үзе барып табачак әтисен. «Әйдә, кайтыйк инде, өйдә әни көтә», – дип әйтәчәк...

– Улым!.. Чыгасыңмы инде?.. Коймак суына...

Бу юлы да тиз генә торып китә алмады Сәлим. Татлы уйларыннан бүленәсе килмәде аның... Әтисе турындагы уй-хыялларыннан...

«Бар, улым, бар, әниеңне көттермә... Ул анда, бер тәгам ризык та капмыйча, сине өзелеп көтеп тора...»

Әллә каян, ерак-еректан колагына килеп ирешкән яңгыравык тавышка баштарак игътибар итмәде Сәлим. Бу таныш түгел ирләр тавышы аның күреп онытылган төшеннән дә, күрше-күләннәрдән төн буе яңгырап торган музыка аһәңе булып ирешергә дә мөмкин иде... Тик... «улым» диде бит ул! Матур итеп әйтте, ягымлы итеп эндәште... Чын әниләр кебек, юк ла, әтиләр кебек итеп...

«Улым, әниең көтә... Ул инде сиңа әйтер теләкләрен дә, Яңа ел бүләкләрен дә әзерләп куйды...»

– Син кем?  Әй!.. – Бу юлы Сәлим каушап тормады, торып ук утырды, тирә-ягына карана-карана, баягы серле тавышның иясен эзләде. Аның карашы өстәлдә торган компьютерга төште. Әллә ул сүндерелмәгән килеш калганмы? Юк...

– Әй, дим... Син кем?.. – Бу юлы Сәлим сагаеп, пышылдап кына сорады.

«Улым... Бу мин... Синең әтиең...»

– Әтием? Ничек инде – әтием?.. Мин сине күрмим... Кайда соң син?

«Мин монда. Синең янда. Тик син мине күрмисең...»

– Ә син мине күрәсеңме?

«Күрәм. Син миңа охшагансың...»

– Әни дә шулай ди... Тик син бит еракта, дөнья читендә. Кайчан кайттың? Ник безгә кермисең?

«Бүген кайттым. Мине синең янга Кыш бабай дәшеп алды. «Бик зирәк улың бар, нишләп йөрисең җир читендә?» – диде».

– Алайса, ул минем теләкне җиткерде?

«Яңа елда барлык теләкләр дә кабул була, улым...»

– Рәхмәт Кыш бабайга, сиңа да рәхмәт... Син... Син...

«Нәрсә, улым?»

– Син – җенме?

«Белмим... Юктыр... Җен түгелдер, мин күбрәк җандыр...»

– Исемең ничек?

«Җан. Исемем дә Җан...»

– Матур исем... Чит илдә сине Джон диярләр иде.

«Ә син миңа «Җан» дип дәш. Без бит татарлар...»

– Җан... «Әти-җан» буласыңмы?

«Әйе, шулай булып чыга... Ә син әниең хакында бөтенләй оныттың әле, аның коймаклары суына бит...»

– Чыгармын әле, минем синең белән сөйләшәсем килә...

«Юк, алай ярамый. Бар, әниең янына чык. Мин бит беркая китмим. Ә син бар, әниеңне үпкәләтмә...»

– Ярый, мин тиз генә урап киләм... Тик син беркая да югалма, яме. Юкса мин сине ачуланырмын...

«Минем сиңа бер үтенечем бар, улым. Син минем хакта әниеңә әйтми тор, вакыты җиткәч, ул үзе белер...»

– Ярар, әйтмәм... Бик әйтәсе килә дә...

«Син вәгъдә бирдең. Егет сүзе бер була, шулаймы?»

– Аңладым бит инде... Әйтмим дигәч, әйтмим... Син үзең дә сүз бирдең...

«Вәгъдә – иман!»

Сәлим, бәхет кошы тоткан кебек куанычыннан сикергәли-сикергәли, залга чыгып китте. Чыга-чыгышка табын янында басып торучы әнисен кочаклап алды.

– Әнием!

– Бәйрәм белән, Яңа ел белән, улым!..

– Яңа ел белән, әнием!

– Әйдә, улым, бүләкләр карыйбыз. Кыш бабай нәрсә алып килде икән быел?

– Әнием, Кыш бабай миңа бүләк бирде инде... Ой!

– Нинди бүләк ул, улым?

– Нинди дип... – Сәлим, әтисенә биргән вәгъдәсен боза язып калуын чамалап, шундук сүзне икенчегә борды. – Менә сине бирде ул, аннары... коймакларны...

– Ярый, шулай да булсын ди... Сер саклый беләсең тагы... Бер әйтмәсәң, бер әйтерсең әле, яме?

– Ярый... Тик бүген түгел, әнием, ярыймы?

Алар озак кына бүләк карадылар. Сәлим махсус санап чыкты: кичәге кунаклардан дүрт машина, өч «конструктор», ике барабан калган иде. Әнисе кесә телефоны бүләк итте. Чып-чын телефон! Ике генә төймәсе бар. Берсе – әнисенә шалтыратыр өчен, икенчесе... Икенчесенә басып, кемгә шалтыратачагын да белә Сәлим. Тик бу хакта әлегә әнисенә әйтергә ярамый...

Тәмләп чәй эчтеләр. Чәй табыны артында Сәлим уйчан иде. Юк ла, уйчан буласы килми аның. Әнисе белән шаярып-көлеп сөйләшәсе килә. Тик берни дә эшли алмый. Ниндидер хикмәт белән пәйда булган әтисенең күк катыннан яңгырап торган тавышы исенә килә дә төшә... Җитмәсә, әнисе гел сорап интектерә: «Нәрсә булды, улым, бу кадәр ни уйлыйсың син?» – ди.

Ниһаять, Сәлим җаен тапты. Бүләкләр карауны сәбәп итеп, ялтыравык кәгазьләргә төрелгән эреле-ваклы капларны кочагына җыйды да үз бүлмәсенә кереп китте.

– Алло! Син кайда?.. Әти-җан!..

«Мин монда... Мин дә синең белән чыгып кердем. Сез чәй эчкәндә,

мин дә шунда идем... Әниең һаман шулай матур килеш... Мин гашыйк булгандагы кебек... Күз читләрендәге ике бөртек җыерчык кына бераз өлкәнәйтеп тора...»

– Әнием матур шул минем. Мин аны бик яратам. Ул да мине бик-бик ярата!.. Ә син аны яратасыңмы?

«Белмим... Алты ел үткән бит инде безнең аерылышуыбызга...»

– Юк... Син әйт: яратасыңмы? Әйтмәсәң, мин синең белән дус булмыйм...

«Яратамдыр... Чөнки мин аны бервакытта да онытмадым... Бу бит ярату, шулаймы?»

– Яратудыр, мин дә бит аны бервакытта да онытмыйм... Тәртип бозасы килгәндә дә, бозмый калам, әни искә төшә... Ә син мине яратасыңмы?

«Белмим... Мин бит сине бөтенләй белмим... Мин синең якты дөньяга туганыңны да, матур, зирәк малай булып үсеп килүеңне дә белмәдем... Кыш бабай булмаса, белмәс тә идем... Бу яклап мин синең алда бик гаепле...»

– Ничек инде – гаепле?..

«Шулай, гаепле... Мин сине белергә тиеш идем... Әниеңне югалтмаска тиеш идем... Сине без икәү бергәләп үстерергә тиеш идек... Аңладыңмы?»

– Хәзер аңладым. Тик... Гаепле булсаң да, минем сиңа бер ачуым килми. Син миңа ошыйсың... Миңа ошагач, әниемә дә ошаячаксың... Менә күрерсең дә торырсың...

«Ошатыр дисеңме? Ул мине оныткандыр инде...»

– Юк-юк, онытмады! Ул синең сурәтеңне гел үзе белән йөртә, кич йокларга ятканда сыйпап та ала әле... Ә менә кичә кич югалткандыр, чөнки мин сине үзем белән алган идем. Кыш бабайга күрсәтергә... Шул сурәтеңә карап таныгандыр да әле ул сине...

– Улым, нишлисең син?

Ишектән кинәт килеп кергән әнисе алдында Сәлим тәмам каушап төште. Алдап-хәйләләп тотырга вакыт юк иде.

– Мин... Сөйләшәм...

– Кем белән сөйләшәсең? Беркем дә юк бит монда...

– Бар.

– Кайда? Кем?

– Ул күренми, әнием...

– Кем – ул?

– Әтием... Әти-җан...

– Әтиең?..

– Әйе, мин аны ишетәм.

– И-и балам, шулкадәр хыялый булмасаң!.. Бөтенләй башың әйләнгән ләса синең!.. Әйләнер дә. Күптән сөйләшкәнебез юк шул әтиең турында. Бик беләсең киләмени соң?

– Әйе, бик-бик!

– Нәрсә сөйлим соң?

– Нинди иде ул? Матурмы? Батырмы?

– Анысын кем белә инде. Яраткач, матурлыгын да, батырлыгын да карап тормыйсың икән... Бик яраттым мин аны. Ул да яратты...

– Ул әле дә ярата сине, әнием...

– Шулай дисеңме? Синең барлыгыңны белсә, тагын да ныграк яратыр иде, әйе бит?

– Ул мине белә...

– Ә? Карале, син, чынлап та, хыялга бирелгәнсең бит, балам... Бу хыялың шаукымлы гына булмасын иде берүк...

– Әнием, нигә без монда, ә ул... еракта?

– Себергә нефть чыгарырга киткән җиреннән кайтмады әтиең... Чакырып та караган иде, бармадым... Мин бит сине каршы алырга хәзерләнә идем ул вакытта. «Үзең кайт» дип яздым. Ул тагын чакырды, тагын, тагын... Мин җавап бирмәдем. Артык горур булдыммы шунда... Яшьлек галәмәте булдымы?.. Шулай арабыз өзелде. Мәхәббәтебезнең татлы җимеше булып син калдың... Матур хатирәләр калды, матур хисләр калды... Беләсеңме, улым, мин аны яшәгән саен ныграк яратам кебек. Шулай да була икән бу тормышта...

Әнисенең күңеле тулды. Әллә каян гына пәйда булган кулъяулык, ак канат булып, аның йөз читендә кагынып тора башлады... Менә ул Сәлимне куенына алып сөйде дә, күз яшьләреннән юылган йөзен читкә алып, зал ягына чыгып китте. Малай бүлмә уртасында тагын япа-ялгызы торып калды...

– Әй! Син мондамы?

Таныш тавыш җавап бирмәде.

– Үпкәләдеңме? Әнигә синең хакта әйткәнгә ачуландыңмы?

«Юк, ачуланмадым.»

– Алдыйсың... Үпкәләдең... Сөйләшмисең бит...

«Әниеңнең сүзләреннән күңелем тулды, хәтта елыйсым килде...»

– Егетләр елый димени?!

«Елый, улым, елый... Кеше үзенең мәхәббәтеннән, сөенеченнән дә елый ала...»

– Ә син ничек елыйсың, син бит тавыш кына?

«Юк, мин тавыш кына түгел. Мин – җан... Җан! Ә җаннар елый, беләсеңме шуны?.. Кеше үзе еламый, аның җаны елый...

– Ә син елама, кайт монда, бергә яшәрбез...

«Бик кайтыр идем дә... Иң элек тәнемә, җисмемә кайтып, аны терелтәсе, ышандырасы бар. Ә ул... ай-һай, тискәре, киребеткән минем... »

– Ышандыр син аны, яме.

«Ышандырам. Ходай язган булса, озакламый кайтып та җитәрбез – мин сиңа сүз бирәм!»

– Кайтсаң... каян табарга сине?

Тавыш Сәлимнең соңгы соравына көттереп кенә җавап бирде.

«Бу шәһәрдә хәзер минем беркемем дә юк... Сезгә каршы чатта гына, биек тупыл янында ике катлы йорт бар. Әнә шул йортның икенче катында тордык без. Хәзер анда беркем дә яшәми. Әни үлгәч, күршеләр күз-колак булып тора аңа... Кайтсам – шунда кайтам. – Бераз тын калып торганнан соң, тавыш дәвам итте: – Хәзер миңа юлга җыена башларга кирәк. Ә син әниең янына кер. Аның сиңа әйтер сүзе бар...»

Белә Сәлим ул йортны, бик яхшы белә. Балалар бакчасының тәрәзәсеннән аермачык булып күренеп тора ул. Моннан соң Сәлим ул йорт яныннан узып йөриячәк, тукталып, күзәтеп тә торачак әле... Чынлап та, әтисе кайтып керсә? Аны эзләп йөрсә?.. Әтисеннән эзләткәнче, иң шәбе – үзе барып табачак...

Күпме чакырып караса да, бүлмәдә әтисенең тавышы бүтән ишетелмәде. Сәлимгә шундук ямансу булып китте. Шулкадәр моңсу-ямансу иде, хәтта коймак пешереп көтеп утырган әнисе янына да керергә теләмәде. Кабат түшәгенә барып ятты да дымлана башлаган күзләрен йомды...

Сәлим бөтен көченә әтисен күзалларга тырышып карады. Әмма берни дә килеп чыкмады. Һәм ул, әтисенең тоныклана башлаган сурәтен күкрәгенә кысып, юрганын баш очына тартты...

***

– Яңа ел котлы булсын, улым, бәрәкәт, бәхет алып килсен! Тор, улым, тор, бәйрәм коймаклары җитеште...

Гел шулай: Яңа ел бәйрәменнән соң Сәлимнең әнисе коймак пешерә. Өйләрендә коймак пешмәсә, бәйрәм кебек тә түгел аларда.

Тик Сәлимнең торасы килми. Йоклап та туйган инде югыйсә... Ә торырга кирәк, әтисенең тавышы да сагындырды...

Тукта! Бу бер булды бит инде! Әнисе уятты... Әтисе белән сөйләште...

Сәлим ничек сикереп торганын сизми дә калды. Атылып-бәрелеп, залга – әнисе янына чыкты.

– Әнием, ни бу?

– Улым, нигә алай дисең?.. Ни булды? Йөзләрең чытылган димме?..

– Әнием, без бүген коймак ашадык бит инде...

– Кайчан? Табын артына утырабыз гына ласа...

– Оныттыңмыни? Без күптән уяндык бит инде... – Бераз тын калып торганнан соң, тотлыга-тотлыга сорап куйды: – Ә-ә... Әтиебез кайда?

– Улым, нишләп әтиең хакында сорыйсың әле?

– Ул бит әле генә монда иде...

– Юкны сөйләмә, улым, ул бик еракта – Себердә яши.

– Үзен әйтмим лә мин, аның тавышы монда иде... Җаны... Күрмәдеңме? Әй лә... Ишетмәдеңме?

– Юк, балакаем, бер тавыш та ишетмәдем... Нәрсә булды соң сиңа, авырмагансыңдыр бит?.. Әйдәле, температураңны үлчибез...

– Юк, авырмыйм мин! Әтине генә югалттым...

– И бала, бала... Төшеңә кергәндер ул Хода бәндәсе... Төшеңдә эндәшкәндер... – Ана кеше, ах-ух килеп, бермәл урынында таптанып торды да үзалдына сөйләнә-сөйләнә, өстәл хәстәрләргә кереште: – Йөрәге тоеп, күңеле сизеп, бер кайтып килсә, ни була инде анысына да?!

Шул көнне үк Сәлим әтисе әйткән йорт янына барып килде. Яңа елны каршы алган шәһәр тирән йокыда иде. Берән-сәрән генә кешеләр узып тора. Сәлимдә аларның кайгысы юк. Аларның әтиләре бардыр шул. Шулай да бүген Сәлим алар белән баш күтәреп сөйләшә ала: ул үз әтисен тапты, аның белән сөйләште, хәтта аңлашты да инде... Очрашасы гына калды...

Ләкин калын пәрдәләр белән томаланган тәрәзә өлгеләре артында җан әсәре сизелмәде. Бу минутта Сәлимнең күңелендә озын гомер яшәгән өлкәннәр йөрәгендә генә була торган олы сагыш туып килә иде. Әтисе белән төштә генә очрашты дисәң, менә ул йорт, нәкъ әтисе әйткәнчә, үз урынында. Тупыл агачы да шунда ук. Моңаеп хуҗасын көтә... Анысы шулай шулаен, тик кайда соң ул үзе – әтисе? Юк ул, юк! Татлы төш булып кына

калды. Төштә нәрсә булмас!.. Әнә – өске катка алып менә торган баскыч ишегендә олы йозак эленеп тора... Менә монысы төш түгел инде, чып-чын өн. Малайларның әтиле булуларына каршы булган язмыш өне...

Бу йорт хакында әнисенә әйтергә теләмәде Сәлим. Көләчәк кенә. Өстәвенә... нык борчылачак. Теге вакытта әйткәч тә күне буе күзен сөрткәләп йөрде...

Кичләрен бик үтенеп, ялварып чакырып караса да, Сәлим әтисенең тавышын бүтән ишетмәде. Төнлә уянып та, иртән торгач та, «әтисе» белән сөйләшергә тырышып карады ул, ләкин Яңа ел бәйрәмендә пәйда булган серле аһәң аның бүлмәсендә кабат яңгырамады...

Кышкы ялдан соң балалар бакчасына йөри башлагач, иртә-кичен Сәлим әтисенең җансыз йортына карый-карый уза торган булды. Бакчада чакта да, тәрәзә янына килеп, сәгатьләр буе шушы моңсу йортны күзәтте. Әтисе күренмәсә дә, шушы йортка, бигрәк тә аның өске каттагы тәрәзәләренә карап торган чаклар Сәлимгә рәхәтлек бирә иде. Гүя әтисе бар аның, шушы йортта яши, тик... әлегә ул эшенә китеп барган, озакламый кайтып җитәчәк кебек... Кайтыр да балалар бакчасына улын алырга килер...

Ә беркөнне Сәлим «әтисе йорты»ның икенче катындагы тәрәзәләрдән калын пәрдәләрнең алып ташланганын күрде. Иртән әнисе белән бакчага барганда искә алды бу үзгәрешне. Ләкин тукталып торырга һич вакытлары юк иде. Ана кеше каерыла-каерыла чит-ят йортка карап барган малаен җилтерәтеп бакча капкасына алып кереп китте.

– Атлыйсыңмы, юкмы инде син, ә? Эшкә соңга калам бит, малай актыгы!.. – Аннары өстәп куйды. – Тәртип бозып йөрмә анда, яме. Тәрәзә төбенә дә менмә! Кара аны!..

Менмәсәң, күренми шул... Тәрбиячеләр сизмәгәндә, бүген дә менеп төшкәләде Сәлим тәрәзә төбенә. Һаман шул йортны күзәтте. Бер караганда, өске каттагы тәрәзәләр ачык иде. Менә аларны кемнеңдер куллары килеп япты, аннары тәрәзә төбенә кар кебек ап-ак чәчәкле гөл урнаштырды... Шулвакыт Сәлимнең нәни генә йөрәге кысылып куйды, аның бик тә, бик тә шушы кулларның, шушы гөлләрнең иясен күрәсе килде!

Озаклап уйланып торырга вакыты юк иде аның. Малае табылмаса, әтисе үзенең Себеренә кире китеп баруы бар бит... Аннары инде ул, Сәлимгә үпкәләп, бөтенләй дә кайтмаячак...

Бу минутта Сәлимнең башында бер шәп план өлгереп җиткән иде.

Балалар бакчасына «йокы сәгате» керүгә Сәлим, тәрбиячеләрнең күрше бүлмәгә чәй эчәргә кереп китүен генә көтеп торды да, җылы юрган астыннан чыгып, кием шкафлары тезелеп киткән ян бүлмәгә чыкты. Тиз генә киенде, аннары аяк очларына гына басып, беренче катка төште, тышкы коридорга чыкты...

Урамда беркем дә юк иде. Берән-сәрән генә кар бөртекләре оча. Ап-ак тынлык. Гүя бөтен дөнья, табигать Сәлим яклы иде бүген. Аның уе, теләге, хыялы яклы иде.

Таныш йортка барып җиткәнче аңа беркем дә очрамады, хәтта, бакча капкасыннан чыкканда, малайлардан тәм-том өмет итеп утыручы Акбай да әллә кая китеп югалган иде.

Әтисенең ике катлы йорты янында да кеше-мазар күренмәде. Мондый тынлык бераздан Сәлимне сагайтып җибәрде. Әмма ул сер бирмәскә

тырышты. Кышкы тынлыкта моңга, шомга күмелеп утырган йорт буенда арлы-бирле йөренергә кереште. Шулай шактый вакыт таптанып торды ул. Бу минутта аның кечкенә йөрәгендә зур давыл уянып килә иде...

Бая күренеп киткән кеше кем булды соң? Әтисеме? «Кайтам!» – диде бит ул. «Юлга җыенам», – диде. Әнә, тәрәзәләрдәге пәрдәләр дә ачып куелган. Ишек төбендәге кар көрәлгән... Хәтта йортның бу ягы яктырып, җылынып киткән кебек...

Өске катка алып менә торган баскычка аяк баскач та, Сәлим бераз тукталып, уйланып торды. Нәрсә дип әйтер соң ул әтисенә? «Бу мин – синең малаең», – диярме? Аңламый торса: «Нигә, Яңа елда төшеңдә күргән малай... Безне Кыш бабай очраштырган иде», – дип әйтер.

Әтисе аны таныса ярый ла... Ә оныткан булса?.. Төш тиз онытыла бит ул, Сәлим моны үз төшләреннән белә... Алай дисәң... Әтисен бер минутка да онытмады бит ул...

Ул арада өске катта ишек ачылган тавыш ишетелде. Сәлим, берничә баскыч күтәрелгән килеш, тукталып калды, аннары сикереп, кабат карлы җиргә төште. Каршыдагы тупыл агачының артына качарга теләгән иде дә, ниндидер көч аны чабуыннан тарткан кебек тотып калды. Бу көчнең исеме әтисен күрү, әтиле булырга теләү тойгысы иде...

Ишектән килеп чыккан кеше Сәлимнең әтисенә бөтенләй дә охшамаган булып чыкты. Гади генә киенгән, ирен читләренә, күз тирәләренә җыерчык куна башлаган ир затын Сәлимнең күңеле баштарак ятсынып кабул итте.

Күзләре!.. Карашлары!.. Ә менә күз карашлары Сәлимгә шундук ошады. Аларда ниндидер мөлаемлык, җылылык, ягымлылык, туганлык нурлары чагыла иде. Аннары тавышы... Яңа ел төненнән үк колагында яңгырап торган бу моңлы тавыш таныш иде...

– Син... мине көтәсеңме?

– Юк-юк... Әйе...

– Туктале... Кая-кая... Таныйм бит мин сине. Яңа ел кичендә минем төшемә кереп йөргән зирәк малай бит син, шулаймы? Син идең бит ул? Мин ул вакытта бик каты авырып, саташып ята идем. Каты буран чыгып, ерак буровойда ике атнага бүленеп калдык, вертолёт та очып керә алмады... Менә шунда салкын тидергәнмен. Яңа елда төшемә кереп, сөйләштермәгән булсаң, теге дөньяга ычкына идем, билләһи газыйм... Рәхмәт сиңа... кем... Исемең ничек әле? Мин Җан булам. Исемем шундый...

Әтисе булырга тиеш кешенең аның алдына тезләнеп, исем сорап торуына малайның кечкенә йөрәге түзмәде, ул тын гына елап җибәрде...

– Сәли-и-им...

– Чү-чү, егеткәй... Алайса, хәзер мин дә елап җибәрәм. Әйдә, еламыйк... Менә бит – очраштык... Хыялларыбызны Кыш бабай, ә бәлки Аллаһы Тәгаләдер, тормышка ашырды... Тик... әниең беләме соң монда икәнеңне? Исеме Камилә бит?

– Әйе-е-е...

– Камилә... Матур исем... Камилә... Ул үзе дә матур, әйеме? Мин аны белгәндә, бик матур иде. Хәзер дә матурмы?

– Мату-у-ур...

Сәлим һаман әле елавыннан туктый алмый тора иде. Ләкин йөрәге тынычланып өлгергән иде инде.

– Яле, күзләреңне сөртик... Менә шулай... Сәлим... Сәлим Жанович... Жанович бит?

– Әйе-е-е...

Сәлим күңеленнән генә үртәлеп тә куйды. Нигә сорап торган була инде ул? Болай да аңлашыла бит – әтисенең исеме Жан булганга аны «Жанович» дип йөртәләр...

– Ну, нишлибез инде, ә, Сәлим Жанович?

– Белмим... Син дә белмисеңме?

– Беләм, ник белмәскә?! Иң элек туганнарча күрешәбез. Бир әле бишне... Менә шулай... Аннары кочаклашабыз... Кил әле монда...

Сәлим карышмады, шундук әтисенең кочагына менеп кунаклады. Әтисе булырга тиеш кеше аның күзләрендәге яшь бөртекләрен сөрткәләде. Шунда Сәлим тагын бер мәртәбә күрде – бик матур иде аның әтисе, бигрәк тә күзләре яратып, якын итеп карыйлар иде...

Әтисенең сүзе бетмәгән икән әле.

– Ә хәзер әниеңне эзләп китәбез. Син аның кайда икәнен беләсеңме? Тукта-тукта... Син нишләп үзең генә урамда йөрисең әле? Әниең беләме бу хакта?

– Юк... – Сәлимгә алдап-хәйләләп торырга мөмкинлек калмаган иде. Аннары... әтисе белән беренче очрашуда ук ялганлыйсы килмәде аның. – Мин детсадтан качтым...

– Менә сиңа мә! Ник качтың?

– Синең янга. Күрәсе килде... Иртән садикка барганда ук синең кайтканыңны белдем бит мин...

– Әниеңә әйттеңме соң?

– Юк, әйтмәдем. Әйтсәң, тирги ул. Бик усал минем әни... Тик... әйбәт усал...

– Менә хәзер безгә, чынлап та, эләгәчәк, мин әйтте диярсең...

– Эләкмәячәк.

– Каян беләсең?

– Мин бит сине таптым. Әни моңа сөенәчәк...

– Шулай дисеңме?

– Әйе.

– Мин бит озак еллар сездән читтә яшәдем, синең барлыгыңны да белмәдем... Ярдәм дә итә алмадым...

– Безгә берни дә кирәкми, бездә барысы да бар... Әти генә юк. Юк иде...

– Хәзер бар инде...

– Хәзер бар. – Сәлим, үзе дә сизмәстән, әтисенең көчле, кытыршы кулларына кагылды.

– Бар... Ходайның рәхмәте белән... бар...

Әти-Жан үзе еламсырап сөйләшә башлады түгелме? Күңеле тулып киттеме шунда... Аны бала-Сәлим шундук тынычландырырга кереште:

– Курыкма, әни сине тиргәмәячәк. Мин аны беләм. Ул үзе генә калса, рәсемеңә карап, синең белән сөйләшеп йөри... Бер дә тиргәми, сөйләшә дә сөйләшә...

– И улым, рәсем бер нәрсә, тормыш бөтенләй икенче нәрсә шул...

Әйдә, тизрәк әниеңне эзләп табабыз, юкса минем йөрәгем хәзер урталай ярыла, билләһи!..

– Йөрәгең ярылса, үләсеңме?

– Йөрәк дигәннәре бәхеттән дә ярылырга мөмкин икән ул... Хәзер белдем инде...

Нәкъ шул минутта шатлыкларын кая куярга белмичә торган ата белән ул каршында ике хатын пәйда булды. Аларның берсе балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Сания Әхтәмовна булса, икенчесе Камилә иде. Иң беренче булып Камилә һушына килде:

– Җан?

– Камилә?

– Син каян?

– Менә кайттым... Сәлим чакырып кайтарды...

– Сәлим? Ә син, малай актыгы, ник качтың садиктан? Бөтен шәһәрне аякка бастырдың бит!..

– Әнием, мин әтием янына килдем... Мин аны Яңа елдан бирле көтәм...

Малайның җавабы Камиләне тәмам телсез калдырды. Ул, хәтта, тупыл агачына сөялеп, күзләрен йомды...

Җан да тупыл агачына килеп сөялде. Аннары балаларча акланган кебек сүз башлады:

– Камилә, барысы да тәртиптә... Мин улыбыз белән Яңа ел кичендә, авырып, саташып яткан чагымда, төшемдә таныштым. Аякка басып йөри башлауга юлга чыктым. Бик күрәсе килде үзегезне... Үткәннәр өчен ачуланма... Мин берни дә белмәдем...

Әнисенең һаман да дәшми торуын күреп, Сәлим әтисен якларга кереште:

– Әнием, мин аны беләм – әйбәт ул, әйдә, таныштырам...

Камилә, керфекләрен күтәреп, бер Җанга, бер Сәлимгә карады. Аннары, улы янына чүгәләп, аны кочагына алды.

– Улым, без күптән таныш инде... Шулкадәр таныш, шулкадәр таныш... Ансыз яшәү минем җан-бәгырьләремә үтте... Рәхмәт сиңа...

Шунда Сәлим үз җилкәсендә кемнеңдер көчле, әмма бик тә назлы кулларын тойды. Колакларын әтисенең җылы тыны иркәләде:

– Рәхмәт сиңа, улым...

Сәлим бер-берсенә сыенышып торган әтисе белән әнисенә күтәрелеп карады, аннары карашларын күк йөзенә күчерде. Ниндидер тылсым белән чистарынып калган аяз күктә йөзгән болытларның берсен Кыш бабайга охшатты ул. Һәм, беркемнән кыенсынмыйча, курыкмыйча, шул сихри болытка карап:

– Рәхмәт сиңа... Әтиемне биргән өчен рәхмәт, – дип пышылдады.



*Кыргыз шагыйре һәм тәрҗемәче Нурлан Калыбеков Кыргызстан Республикасы Аксы районының Аркыт авылында 1973 елның 21 сентябрендә дөньяга килә. Кыргыз дәүләт милли университетын тәмамлый. Мәскәүдә танылган совет шагыйре Юрий Кузнецов семинарларыннан белем эсти. 2018 елдан Кыргызстанның Язучылар берлеге рәисе була. Хәзерге көндә Кыргызстанның иҗади яшьләр оешмасын җитәкли. Ул кыргыз һәм рус телләрендә дөнья күргән дүрт шигырь китабы авторы; Кыргызстан Республикасының яшьләр премиясе лауреаты, Кыргызстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Нурлан
Калыбеков

# ТИРМӘМНЕҢ ЭЧЕ БАЛКЫЙ...

## Печән өсте

Сусыл куе үләннәрдә чык ята.
Чалгым җырлый яшел диңгез өстендә,
Ә офыкта сызылып кына таң ата.

Их чирәмем – гамьсез гүзәллек иле!
Үлем килде иркен илең өстенә –
Колач җиткән буйга чабамын сине!

Мин, әйтерсең канечкеч комсыз явыз –
Чиксез җанның башын кыйдым таң белән
Аллы-гөлле әрәмәдә, берьялгыз.

Әйтсеннәргә: «Шәп печәнче ул гына!»
Үткен чалгым кысып тотып кулыма,
Мин «башкисәр» данын алдым, шул гына…

Абайламый калганмын кызу эштә
Үләннәрнең зарлы кан-яшь түккәнен –
Канлы сутка манылганын мин һич тә.

Ә ахырдан чикерткәләр җыры да
Басылды күк ярымүле тынлыкта.
Печән исе аңкыды киң кырымда.

Шәрәләнгән әрәмәлек иләмсез:
Гамьсез илне кайгы басып алды күк,
Ятим калды мин узган юл – үләнсез...

Күк дәрьясы асларында үлән күп.

## Бөтенлек

Мин фани бу дөньяны
Бүлмимен ак-карага.
Ул хасил бөтенлектән,
Нур ага бу төнлектән
Һәркемгә тиеп тигез
Һәм янә күккә аша,
Сызылып йолдызгача.
Дөньяда ак вә кара
Әйтерсең ике игез.
Кем кайсын сайлый, шунда
Олага бирсен дибез –
Җәннәткә йә Тәмугка.
Тоймыйм эссе вә суык –
Хасил мин бөтенлектән.
Нур төшә дә төнлектән
Тирмәмнең эче балкый,
Без – фани, ә нур – бакый!

## Автопортрет

Кем син үзең? Кайдан килдең?
Кай тарафка барасың?
Синең өчен бар да гади...
Илаһига санап кемне,
Кем йөзенә багасың?
Юк синең идеалың...
Тәнең сазга баткан көе
Җаның ашкына күккә.
Син һавада очкан чакта
Тиеш наныңны талыйлар
Җиргә береккән күпләр.
Сөймисең гавам шаукымын,
Ялгызлыкта адашып,
Дәрвишлектә яши җаның –
Хыялыйлык адашы.
Күңелләрең ашкынадыр
Һималайның башына.
Кам шикелле баш иясең
Туган нигез туфрагына –
Ата-Йортың  ташына.
Ватаныңны түшәк итеп
Килә синең ятасың.
Яшькә тулган күзләр белән,
Үзеңне таныган сыман
Сукбайга күз атасың.
Шәрә килеш, сорыкортлар –
Бәкләр белән ханнарны,
Киң урамнан ким-хур итеп,
Күп әрәмтамакларны
Килә бер әйләндерәсең;
Бай-ярлыны тигезләп
Килә синең, җай бирелсә,
Үлчәүләргә тезәсең,
Булып гүяки казый.
Көндәлек гади тормыштан
Син һич түгелсең разый.
Кызыктырмый дөнья малы
Күз яуларын алучы.
Юк, узмыйсың юл-сукмактан
Юлбашчылар салучы.
Теләмисең үтәргә син
Алар салган эз аша.
Ходайны да эзләмисең,
Буйсынмыйсың кемгә дә...
Кандаладай кадаласың,
Юл куймый һич җөмлә дә.
Үз киреңә катып болай,
Белмим, кая барырсың?
Кем син? Уйлап кара соң?!

## Ялгызлык

Җан сөйгәнем, сиңа олуг хөрмәтем!
Синсез миңа дөньяның юк һиммәте!

Һич, һичкайчан аерылмасын уртак юл,
Без – куш йөрәк, минем кулда синең кул!

Тәкъдир миңа корды тозак, яманлык:
Кара мәче юл кискәнгә алдандык.

Шул чакларда тик үз җаен уйлашып
Йөрде гүя бар еланнар, сайрашып.

Кайберәүләр бик белгән гайрәт белән
Артыбызда атышты гайбәт белән.

Шул чакларда китми минем янымнан
Сыйпадың син башым түгел, җанымнан!

Шуңар беләм хак бәһаңне, алтыным!
Алмаштырмам сиңа дөнья алтынын!

Җан сөйгәнем, сиңа олуг хөрмәтем!
Синсез миңа дөньяның юк һиммәте!

## Ала-Арчада...

Кызык инде бу тәкъдир, кызык инде.
Арабызда хисебез җылы иде...

Җырлар яздык икәүләп, серләштек без,
Бәхетне уртаклашып гөрләштек без.

Мин Алыкүл сыман, ә син Ай булып
Йөзләреӊ балкып торды Айдай тулып...

Бара идек шагыйрьнеӊ каберенә,
Сокланып вә көенеп тәкъдиренә.

Йөзләреңә сокланды күргәннәр дә,
Торды гүя кабердән үлгәннәр дә.

Күрешергә башка җир булмаган күк
Суык кабер арасында очраштык күп.

Кояш нуры җылытмады каберне,
Безнеӊ сөю ул ташларга җан өрде.

Күзәтте безне гүя өрәкләр дә,
Ялт-йолт килде утлар да як-якларда.

Суык кабер төп йортыбыз булганчы,
Салкын әҗәл иреннәрен сузганчы...

Кайнар хисләр сүрелмәс дип уйладык,
Безнеӊ сөю мәңгелек дип юрадык.

Куш бәхетле киләчәк иде хыял.
Әйтүче булмады: «Хыялдан тыел!»

Хыял белән тукландымы өрәкләр?
Кем гаепле – киләчәк хак ачыклар...

Үкенечле канатланган хисләрем,
Үкенечле гүргә иңгән хисләрем...

Киләм бире ялгызым хәзер кайчак.
Узды инде мин Алыкүл, син Ай чак.

Кайчан да бер мин дә бире кайтырмын,
Өстә түгел, җир астында ятармын.

Тәтемәгән сөюләр җир өстендә
Һич кирәкмәс инде җирнең астында.

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре.*

# ХАТЛАРДА ДА БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

Моннан уналты ел элек (2008, 8нче сан) журналыбызда «Хатларда да безнең язмыш» дигән исем белән егермеләп хат-истәлек бастырып чыгарган идем. Алар укучыларыбызда мәгълүм бер кызыксыну уятты дип беләм. Авторга һәм редакциягә килгән кайтавазлар шуңа дәлил. Менә янәдән бер төргәк хатларны укучылар хөкеменә тәкъдим итмәкче булам. Ул чакта беренче басма хатларга кереш сүз дә язган идем. Шул язмадан кайбер җөмләләрен янә китереп үтмәкче булам. Чөнки алар бүгенге хатлар бәйләме өчен дә искермәгәннәр кебек. Исемне дә шул килеш калдырдым. «Хатларда да безнең язмыш».

...Соңгы елларда әкренләп кенә гомер буе җыелган папка-папка кәгазьләрне барлап утырам. Шигырьләр, мәкаләләр, чыгышлар, беркетмәләр, рәсми документлар, тәрҗемәләр, чакыру кәгазьләре, телеграммалар... Күрәсең, аларны беркадәр тәртипләргә миңа да вакыт җиткән. Архивым, әгәр аны архив дип әйтергә яраса, шактый бай (өлкән яшьтәге кешенең таянып йөргән таягыннан башка тагын берәр төрле байлыгы булырга тиештер инде!). Саргайганрак кәгазьләрне актарганда, «эт картайса, койрыгын сөйрәр, кеше картайса, үткәнен сөйләр» дигән шактый усал әйтем дә искә төшеп ала. «Үткән белән яшәгәннең киләчәге шикле» дигәне дә хәтергә килә. Хаклык юк түгел бу әйтемнәрдә. Әмма алда әйткәннәрдән дә саллырак тагын бер олы хакыйкать бар: Хәтерсез халык – бетүгә хөкем ителгән халык. Тикмәгәмени: баскынчылар яуланган халыкның җелеген суырган шикелле иң әүвәл Хәтерен бетерергә тырышалар. Хәтер ул – тарих («Хәтер көне» дигән иманлы төшенчә тикмәгә тумаган бит!). Ә тарихсыз шәхес тә, халык та, милләт тә була алмый.

Язмышка рәхмәт: гомерем буе күңел тарткан, яраткан эшем белән шөгыльләнергә мөмкинлегем булды. Бу яктан мин – бәхетле кеше. Исән-сау, сәламәт килеш инде җитмеш елга якын Әдәбиятта хезмәт итәм. Язу эшенә яшьли кереп, язучылар, гомумән, әдәбият-сәнгать дөньясының үзәгендә кайнарга насыйп булды. Күп дистә еллар буе Татарстан, СССР һәм РСФСР Язучылар союзларының идарәсендә булып, күп милләтле совет әдәбиятының байтак симпозиум-конференцияләр, әдәбият көннәре, пленумнар, юбилей тантаналары... Очрашулар, аралашулар күп булды. Идеология бер яклы катгый һәм хыялый булса да («Коммунизм»га килеп җитеш еллар бит!), әдәбиятның дәрәҗәсе һәм тәэсир итүе көчле иде. Кешеләр арасында ихлас мөнәсәбәт тә зур иде. Очрашуларга сыймаган хис-тойгылар бер-беребезгә хатлар аша җиткерелде. Заманында күп хат алышканбыз икән! Килгән хатларның якынча да исәбен әйтә алмыйм әлегә. Әйтик, рәссам Әхсән Фәтхетдиновның миңа юллаган хатларын җыйнап бастырсаң да, үзләре берничә калын китап булыр иде! (2 ел элек «Әхсән хатлары» дигән калын томлык булып басылып чыкты да. – *ред.*)

Хөрмәтле укучыларыбызга, шул елларның хатирәсе буларак, архивымда сакланган хатларның тагын бер өлешен тәкъдим итәм. Хат авторларының күбесе мәрхүмнәр инде. Әмма аларның исемнәре, хезмәтләре яңа буыннар күңелендә яши бирә. Хатларның адресаты мин булсам да, аларның байтагы, шәхси мәнфәгатьләргә караганда, күбрәк әдәби хәрәкәткә, иҗтимагый хәлләргә бәйләнешле. Аларны укып, шул чор (1960-1990нчы еллар) халәтен, атмосферасын, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен, әдәбиятка, рухи дөньяга карашларын беркадәр күз алдына китереп була шикелле. Әгәр хатларның башында «хөрмәтле Р., кадерле, уважаемый, дорогой» кебек сүзләр бар икән, зирәк укучыларыбыз аларны эпистоляр жанрның стиль үзенчәлеге итеп кабул итәр дип

уйлыйм. Тукайлар заманында да хат башлары гадәттә «хөрмәтле вә гыйззәтлебез» дип башланган бит. Бигайбә!

*Равил ФӘЙЗУЛЛИН.*
*30 октябрь, 2024 ел.*

## Гомәр Бәширов хатлары

*13 октябрь, 1970 ел.*

Хөрмәтле Равил хәзрәтләре!

Бик күп сәлам Казаннан, үзеңә генә түгел, Миңнурыйга да, Миңлебикәгә дә, андагы башка белеш-таныш иптәшләргә дә.

Шулай итеп, син мине ышандырдың – барырга булдык. Сибгат тә бара, шулай ук, синең белән сөйләшкәнчә, Хәсән агайны да күндердек. Мин инде аны Гарифтагы исемлеккә дә керттердем. Шулай итеп, ул инде башта ук уйлаган эш рәвешенә керде. Әле ул гынамы, мин аны җыелышта сөйләргә күндердем. Бик тә мач килә бит: ул Урал эскизларын язган кеше, татар әдәбиятына, хосусан, аның поэзиясенә, эшче һәм, гомумән, пролетариат образын ул алып керде дибез бит. Менә шул вакытлар хакында сөйләмәкче булды. Шигырен дә сипләп җибәрер шунда. Болай булганда, җыелышның эчтәлеге киңәя һәм тирәнәя. Шулай түгелме?

Инде тагын бер мәсьәлә. Монысын колагыңа гына әйтәм, үзең генә белеп калырлык булсын. Үзең беләсең, ул агайга декабрьнең 9ында 70 тула. Аңа төрлечәрәк карыйлар. Әмма кемгәрдер ошавына, ошамавына карамастан, ул – киләчәктә классикларның берсе булып әдәбиятта калачак шагыйрь. Бездә аңа игътибар җитенкерәми. Шундый бер изгелек эшләп булмасмы? Әйтик, юбилей вакытында ул анда яңадан барып йөри алмый инде. Шул барган чагында, форсатны ганимәт белеп, нефтьчеләр аңа утырышларның берсендә бирәр сувенир (дип әйтик инде) тапшыра алмасლармы? Сылтавы да бик һәйбәт бит! «Хәсән абый, менә без теге елларда син язган Минапларның варислары инде, фәлән-төгән, килүеңә рәхмәт...» һ.б. Үзең аңлыйсың, монда бүләкнең зур яки кечкенә булуында түгел хикмәт, бәлки игътибарда. Такташка шахёрлар бүләк иткән шахтёр лампасы пролетариат белән поэзиянең дуслык – элемтә символы буларак, ун еллар буена телдән төшмәде. Картны ул күкләргә күтәрәчәк, гомеренең иң якты истәлеге булып калачак. Ә ул аңа бик вә бик мохтаҗ. Шагыйрьләрне үзең беләсең бит. Безнең проза халкы әрсезрәк, алай нечкәләми. Үзенең авыр арбасына җигелә дә тарта бирә карт алаша кебек. Ара-тирә алдына солы салгаласалар, печән ыргыткаласалар...

Менә шул иде сиңа киңәш итәсе сүзем. Билгеле, әгәр мөмкин булса гына, тегендимондый сүзсез-фәләнсез, кайлардандыр рөхсәт-фәләннәр кирәк булмаса гына.

Бу минем башка килгән уй гына, бүтән беркем белән дә киңәшләшмәдем. Киңәшүнең кирәге дә юк. Син дә шулай ук үзең генә беләсең. Тиешле кешеләре белән сөйләшкәннән соң, була икән – бик хуп, булмый икән – нихәл итмәк кирәк? Була икән, аны утырышның ахырында сюрприз итеп кенә чыгарырга кирәк. Дәрәҗәлерәк кеше тапшырса, бигрәк тә һәйбәт.

Төрле хыялый нәмәстәкәйләр белән борчуым өчен чын күңелдән гафу үтенәм. Бигайбә.

*Бик күп сәламнәр белән, Гомәр Бәширов.*

*13 декабрь, 1971 ел.*
*Казан.*

Равил!

Мәскәүдән кайтып, як-якка карандым да сиңа хат язарга булдым әле. Синең белән күптән күрешкән дә юк, болай да киңәш-табыш итәрлек сәбәпләр чыгып тора. Дөнья бит куласа, гел әйләнеп кенә тора, үзең беләсең.

Иң беренче әйтәсе сүз шул: сиңа партиягә керү мәсьәләсен ашыктырырга кирәк түгелме икән? Вакыт байтак узды бит, уйлагансың, бер фикергә килгәнсең инде, шәт, шулай кирәгенә төшенгәнсеңдер. Әгәр бу җитди адымны атлау Равил Фәйзуллинның үзе өчен генә кирәк булып, ул аның шәхси бер вазифасы дип кенә исәпләнсә, шулай күздә тотылса, бәлки, бу хатны язарга ихтыяҗ да төшмәс иде. Минем инануымча, син галиҗәнап партия сафында халкыңа һәм үзеңнең сөекле әдәбиятыңа, димәк, шигъриятеңә, һичшиксез, күбрәк файда китерәчәксең. Мин инде сиңа карата өндәү-димләү эшләре алып бару һич тә кирәктер дип уйламыйм, тик шуны гына әйтим: син уй-фикерләрең, дөньяга карашың, якты хыялларың, матур уйларың белән болай да чын коммунист, тик менә шул хәлне мәгълүм бер формага кертү генә кирәк. Тагын шунысын да өстим: моны сиңа ярты гасырга якын партия сафында көрәшеп килгән кеше әйтә (Монысы бераз мактану сымаграк булып чыкты шикелле).

Менә шул. Мин синнән шушы арада ук хат көтәм. Шуны алу белән рекомендация җибәрәчәкмен.

...Аһ егетләр, менә картлык! Мин бит санаторийга китәр алдыннан гына синнән китап алган идем. Рәхмәт хаты яздыммы шунда, әллә юкмы, һич тә исемә төшми. Бик зур рәхмәт, Равил, чын күңелдән! Мин бит картларча акрын гына булса да, кыштыр-мыштыр гел укыштырып барам. Болай, күңел өчен, җылы азык эзләп, яшьлегемне озынайтасым килеп. Кайчакларны каш өстенә куйган куллар астыннан кысык күзләр белән хәйләкәр елмаеп, чамалап карау да бик кызык була: ничәнче кат күккә кадәр күтәрелә ала икән безнең малайлар?..

Бу китабың калынрак чыккан да, зарар юк, акрынлап мин моның да «башына» җитәрмен.

Шуның белән тәмамлыйм инде, мөхтәсәр кылдык.

Миңлебикәгә һәм үзеңә бик тә күп сәлам.

Иминлек һәм бәхет-сәгадәт теләп калам.

*Ихтирам белән, Гомәр Бәширов*

**P.S.** Яңа ел якынлашып килә ләбаса. Төкле аягы белән килсен! Котлы булсын, игелекле, бәхетле булсын Яңа ел! Амин!

*3 февраль, 1972 ел.*

Хөрмәтле Равил энекәш!

Казанда очрашырга җай килмәгәнлектән, хат аша сөйләшергә туры килде әле.

Сине идарә утырышына көткән идек. Әмма синең җитди мәшәкатьләрең чыккан икән. Мөхәммәт (Мәһдиев. – *ред.*) аларын әйтте. Мин исә, кабул итү комиссиясенә сайлану хакында килгәч, үзең белән киңәшермен дигән идем. Болай үзең югында сайлап кую бик үк әдәплелек булмады инде, демократия дигән нәмәкәй дә, бик аз гына булса да, бозылды. Идарә членнарының кайберләре белән мин алдан ук киңәшеп куйган идем. Бүтәннәре дә бу тәкъдимне бик хуп күреп каршы алдылар һәм бер канительсез тавыш бирделәр. Син дә, ура ук кычкырмасаң да, шулар шикелле үк алкышлап каршы алсаң икән!

Хикмәт нәрсәдә? Теге энекәш, ягъни Б. бик аумакай кеше булып чыкты, шуның өстенә бизмәне бик кечкенә. Анда бит, дәү абыйларга ярагач, миңа да ярый дип утыру гына җитми, төпле фикер, таләпчән караш кирәк. Юкса Союзны бер ел эчендә иҗат союзыннан әрәмтамаклар, нахаллар оешмасына әйләндерергә мөмкин.

Җитмәсә, без комиссиядә 4 прозаик булып киткәнбез. Ә.Исхакны исә классик шигырь вәкиле дип исәпләсәк, яшь поэзияне тирәнтен белүче бер генә член да юк, имеш, күбебез интуиция белән генә гамәл кылабыз. Комиссия членнары арасында хәзерге поэзиянең төрле агымнарын, юнәлешләрен һәйбәт белүче, һәр нюансны сизеп торучы сизгер шагыйрь кирәк иде. Безнең шигъриятне генә түгел, бөтен дөньяны белеп, сизеп торырга, шуннан чыгып эш итәргә кирәк була бит. Шүтке түгел.

Аннан соң, беләсең килсә, шундый әйбәт малай тудырган өчен, синең әниеңә дә бер яхшылык эшлисем килде. Ниндиме? Комиссиядә күп кенә әсәр укырга туры киләчәк. 3-4 айда бер генә булса да сиңа утырыш алдыннан 1-2 көн алдан Казанга килергә кирәк булачак. Әни кешегә шатлык түгелмени бу? Дөрес, икенче яктан, Миңлебикә монда бераз оттыра инде дә бит. Әйдә, ул – яшь кеше, аның белән әле сезнең бер дә башламаган 70-80 ел гомерегез бар.

Менә шулардан чыгып, «үзең югында өйләндереп» куюга, шәт, каршы килмәссең дип ышанам инде мин.

Һәммә ки иптәшләргә миннән күп сәлам. Сәлам шулай ук Миңлебикә белән Миңнурыйга (Әлмәт Язучылар берлеге хезмәткәре. – *ред.*).

Әйтәсе сүзең уңышлы чыксын иде дип, мин монда, Балтыйк буенда, хәер-догада калам.

*Ихтирам белән, Гомәр Бәширов.*

## Сибгат Хәким хатлары

*27 май, 1969 ел.*

Равил туган!

Мәскәүдә булдым. Секретариат үтте. Татарстан Язучылар союзында яңадан биш язучы артты. Ренатны котларга мөмкин. Арада иң яше. Яшьләр аз. Мәскәүдә дә шул хәл икән.

Сезнең кульязманы «Советский писатель» нәшриятына тапшырдым. Моннан соң Регистан Гарольд Габриэльевич белән эш итәсез. Поэзия бүлегенең башында ул. Хәзергә хат язуның кирәге юк. Алар башта берничә рецензия аша үткәрә, аннан гына фикерләрен әйтәләр.

РСФСР съезды октябрь-ноябрь тирәләрендә булырга тиеш. Шунда баргач, Регистан белән таныштырырмын. Әйбәт егет ул. Милли әдәбиятларга яхшы карый. Иң әһәмиятлесе: шигырьне әйбәт аңлый. Ярый, укый торсыннар...

Секретариат булды. Мине Горький премиясенә безнең Союз тәкъдим итеп йөргән иде бит. Җиренә җиткермәгәннәр. Башка республикалар (Хузангай, Рытхэу, Әбүбәкер) үз кешеләрен яклауны үтенеп, РСФСР секретариатына мөрәҗәгать тә иткәннәр. Бездән бернәрсә дә юк. Менә шулай бездә. Бар да күз буяу өчен, бар да формально. Тар ул татар. Зур дөньяга чыгу турында акыл саталар, конкрет эшкә килгәч, бар да туктала. Минем Мәскәүдә алып кайткан хәбәрләр шулар. Нәтиҗәсе шул: барысына да төкер дә шыпырт кына яз. Исәнбәт шикелле баш күтәрми яз...

Кульязмага адрес язмагансыз. Татарстан Язучлар союзын күрсәттем. Кирәк булса, табарлар.

*Өчегезгә дә күп сәлам белән, Сибгат Хәким.*

*11 ноябрь, 1972 ел.*

Равил!

Барыгызга да бездән күп сәлам.

Мин әле сугыштан калган аякларда һаман йөрим. Тагын берәрсенә күрсәтәләр. Керермен, бер керермен. Кергәнче әзрәк язасы да килә. КамАЗ да тарта, нидер бар, сизәм, тоям, ачкычын табалмыйм. Кечкенә чакта минем агач зәңгәр тартмам бар иде. КамАЗ шул тартма кебек, эчендә шигырь юллары көмеш ачкычлар күк чылтырый, ачкычы юк. Сез философларча әйтсәк, нокта, фәлсәфәгә бер нокта кирәк. Көчләп булмый. Вак-төяген яза торам. Чаллыда җәен булдым. Көз һәм кыш айларында барып карарга исәп. Минем үз хыялым, настроением шуный сорый. Шагыйрь әллә нинди тиле җан ул.

Безнең Нурия Әлмәттә кияүгә чыккан, 24 ноябрьдә туе. Аяклар авыртмаса, көннәр кояшлы, аяз булса, самолётлар очса, барсаң да ярар иде. Бәлки шуннан Чаллыга китәрмен. Алабугада Тәлгат Галиуллин кичә оештыра. Уйлыйк, бәлки бергә барырбыз? Планнар шундый.

«Кандалый» бик нык үзгәреп бара диләр иптәшләр, зарланалар. Хәтта Гомәр абый да аптырап калган. Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәтне Союзга керүне ул сузып йөртә икән. Кандалый: «Алар үзләре теләмиләр», – ди. Мөдәррис, Зөлфәт: «Безгә әйткән кеше юк», – дип җавап бирәләр. Сәер. Хәзердән үк андый юлга басса, кеше киләчәктә начальник юлыннан китәр. Талантың бар икән – ярыш, әйбәт әсәрләр язып ярыш. Мондый юл белән түгел. Сезнең буын да шушылай үзара талаша башласа, ваклана башласа, ерак бара алмас, кыйналып бетәр. Кайбер кешеләргә ул бик файдалы. Шулай итеп, күңел сүрелә, күңел кайта, җан бизә бара. Киләләр, постка менеп утыру белән икенче кешегә әйләнәләр. Җитмәсә икесен дә үзем тәкъдим иттем. Иптәшләр хәзер миңа үпкәлиләр.

Күпне күргән безнең әдәбият, З.Нуридан әллә рәхәтме? Уйламастан үзем тәкъдим итеп, мин китердем Сиңа афәтне...

Керәм-керәм дип йөрдегез, кермәдегез. Әле Әлмәттә буласызмы?

*Сәлам белән, Сибгат Хәким.*

*7 декабрь, 1972 ел.*

Равил!

«Советский писатель» нәшриятына кердем. Фәйзуллин шигырьләре әйбәт дип, шундагы кызлар елмаеп каршы алдылар. Миңа да әйбәт булып китте. Ике рецензия – икесе дә яхшы. Редакциядә укылган. Редподготовкага тәкъдим ителгән, планда. Сиңа хәтле ләкин рәис үзе, К.Латыйп, М.Садри чыгачак. Алар инде кайсы производствода, кайсы редакцияләнеп ята. Рәис белән М.Садри «Россия»да бар. Дәүлинең башына сукканнар. Ялагайлана белмәсәң, шулай була ул. Үзенә хат салдым.

Мин нәшриятларда йөрим, вакыт бар, 12дә генә китәм. Бабаҗаннан бөтен Мәскәү көлә, премияне шулай алырга Ходай язмасын. Рәшидов басым ясаган, ди. Аннан Трибичев, Сурков, Тихонов...

Бездә яшьләр яхшырак: Дудин, А.Югов, Я.Ухсай. Әле әйтергә ярамый, иртә. Өчесе буенча да чыгыш ясадым, фикеремне әйттем.

*Иптәшеңә, үзеңә күп сәлам белән, Сибгат Хәким.*

*29 октябрь, 1975 ел.*

Равил!

Мин китәм. Шигырьләреңне укыдым, синеңчә язылган шигырьләр, бары синеңчә. Әйбәтләр. Басыла торсыннар.

Кабул итү комиссиясендә Азат Ганиевне алдык. Шамил Маннапов, Әхмәт Рәшитов, Мәгъсүм Хуҗин үтмәде. Калганнарын – съезд узгач.

Рөстәм (Сибгат Хәкимнең улы. – *ред.*) минем Мәскәүдәге җыентыкка яңа шигырьләрнең подстрочникларын ясаган иде. Заявление калдырдым сезгә. Ул малайга мин югында теләсә кайда йөрмәсен өчен тагын берәр авыррак эш табылмасмы? Хәзер ул элеккедән рәтлерәк, эшләсә, кулыннан килә. Минем подстрочникларны бик яхшы эшләгән. Үз тәрҗемәләре дә әйбәт. Кыскасы, җигәсе иде. Бераз сабак укысаң да, ярый. Ул Синнән курка, хөрмәт итә.

*Сәлам белән, Сибгат Хәким.*

*1980 ел*

Равил!

Вагонда музыка тавышы... Сәер үзе. Әгәр, дим, мине шушы Бөек Ватан сугышыннан соң тынып калган Европа кырларына күзләремне бәйләп кертеп җибәрсәләр, үз җиремне табармынмы? Табармын. Идел буйларына мин барыбер Сәйдәш моңнары буенча барып чыгар идем.

Равил! Менә шушы юллар. Башкача кыса алмадым. Син кыскартып кара, бәлки башкачарак әйтерсең?

*Сәлам белән, Сибгат Хәким.*

## Мөхәммәт Мәһдиев хатлары

*29 март, 1971 ел.*

Менә без дә кайтып җиттек, Равил!

Казан һаман үз урынында тора икән, урамнары пычрак, трамвайлар нәкъ элеккечә тыгыз... Тик күңелләр генә бераз үзгәргән. (Кстати, теге укытучылар аудиториясе синең бу шигыреңне аңларлык уровеньда түгел иде, мин карап тордым, тетрәнүче булмады.)

Без маҗарасыз гына кайтып җиттек, нигездә, ычкындырылган урынсыз сүзләр һ.б. берничә действиене исәпкә алмаганда, минем өчен бик уңышлы булды һәм сагынып сөйләрлек бер сәяхәт булып хәтергә кереп калыр дип уйлыйм. Үзеңә, гаиләңә сәлам һәм, әлбәттә, рәхмәт.

Кайтып төшкәндә, Фәрвазның да настроениесе шәп иде. Мин сиңа биреп калдырган «язмалар» (З.Нури шулай дип атап, ике-өч ел тотканнан соң кире кайтарды) – болай гына бирдем, күңел йомшаганнан гына, бер килгәндә ала килерсең шунда, ун-унбиш тапкыр бастырып алынган иде, монысы бик аламасы булып чыккан. Алар арасыннан бер алты-җидесе сиңа ошамас та, шуңа күрә «болар ошамады дип әйтсәм, кәефе китәрме» дигән шик сине борчымасын, мин аны просто эчке дөньямны Равил белеп торсын дип кенә сиңа биреп калдырдым. Әлбәттә, әгәр Казанга килгәндә, портфелеңдә урын булса, мин сиңа үземнең «кирпеч»не дә салып җибәрер идем – укып чыгарга.

«Язылмаган законнар»ны минем беренче күрүем иде, кеше буларак, ул миндә бик яхшы тәэсир калдырды сиңа карата гел хәерхаһ сөйләшүе дә располагать итте инде – чынбарлыкка туры килүен генә теләп калам.

Алмазга персональ сәлам, ул бер-ике очрашуда миңа Искәндәрне сагынуымны бераз җиңеләйтергә ярдәм итте.

*Сиңа эшеңдә һәртөрле уңышлыклар теләп, Мөхәммәт Мәһдиев.*

*25-26 июнь, 1972 ел.*

Равил энекәш!

Бүген Аккош күленнән балалар яныннан кайттым да, күңел сафланып (балалар белән су кереп, вак-төяк сөйләшеп урманда йөргәнлектән), сиңа хат язарга булдым.

Син, чава-то, Казанны бик авыр йөрәк белән (с тяжёлым сердцем) калдырып киттең. Син бик оптимист идең, мин шуңа күрә сине якын итә идем. Мин пессимизмга бирелгән вакытларда да син минем эчке дөньяма бәреп кереп, кислород сибеп, шаккатарлык итеп яшәү дәрте сирпеп китә идең. Син төнлә, көтмәгәндә бәреп кереп, минем күңелне күтәрә, күңелне Кояш чыгышка таба борып җибәрә идең. Шуңа күрә мин синең әнә шулай җилләнеп, яңгырланып, давыл булып, минем шактый сыngалаган, күгәргәләгән тормышка килеп керүеңне ярата идем.

Бу килүеңдә мин синдә пессимизм сиздем. Сәбәбен аңламадым. «Син ник алай?» дип, җәйге булса да, подмёткасы калын ботинкалар белән синең күңелеңә бәреп керергә кыюлык җитмәде. Үзең беләсеңдер.

«Кандалый»ны син шактый бетереп киттең, ул көнне кич без аның белән тар бүлмәдә булдык, очрашудан соң. Ул удардан әле дә айнып җитмәгән иде – поделом. «Эйзенхауэр» аны алга таба үстереп доконать итте, егет мескенгә калды.

Мин 1 июльгә хәтлем Казанда булырга уйлыйм, 5есендә поезд белән Кырым ягына китәсе. Адресым (8/VII дән 30 на кадәр): Кырым, Дом тв-ва «Коктебель», фамилиям әлегә искечә.

Койрыкларны чистартып утырам, рецензияләр, сүз башлары һ.б.

К.Сибгатуллинның җыентыгына эчке рецензия яздым, сине бик кабатлый (мәхәббәт темасында). Ләкин – синең белән без дөрес фикердә икәнбез – оригинальный талант. Гаҗәп шигырьләре бар. Син мине беләсең – мине «тоту» өчен күп кирәк: салларга салып, менә без дә үсеп җиттек, әни, бөркетләр түмәктә, китәсезмени, аккошлар һ. б. – менә минем вкус. Ниже – миңа кагылмый.

Бу егеттә нәрсәләрдер бар.

Роберт Әхмәтҗановның теге көнне кулын кыстым. «Яңа җыентыгыңны иптәш Фәйз-ның өендә күрдем, һәм ул бик мактагач укыдым, һаман үзең булып калгансың, молодец», – дидем. Ул аны ук көтмәгән икән, «Нужэли Фәйз-ның өендә бар?» – дип...

Син киткәч, икенче көнне (Аккош күлендә) М.Кәрим, Н.Нәҗми, Муса Галиләрне кунакка алып бардым, мәҗлестәш булдым, алар олы сүз сөйләделәр, миңа утыруы авыр булды, бөкеләр ачкалап, пепельницалар китереп, күңелне юаттым, өлкәннәр арасында читен.

Менә эч бушап китте, хатымны укып чыккансыңдыр кебек тоелды.

Бүген әле күңелнең нечкә чагы. Яшисе дә килми, эшләр дә күп. Очып менеп китәм дә, әнә шул эшләр татар җөббәсенең итәгеннән тартып җиргә төшерәләр. Аннары тагын яши башлыйсың. Күрәсең, без яшәүдән «зарар юк».

*Хуш әлегә. Сәлам белән, Мөхәммәт Мәһдиев.*

*8 июль, 1975 ел.*

Равил!

Мин ялга китеп бардым. Берәр атнадан өйдә булсаң, телефон белән тотармын әле. Әй, бер килеп чыксаң! Союзның машинасы синең кулда түгелме соң? Арчадан 20 км, Гөберчәк дигән авылда мин.

Сиңа ике үтенеч:

1. «Детская литература»да безнең мәкаләләр чыга калса, аның бер санын минем өчен юнәтеп куйсаң иде. Мин карап йөрим – бер дә киоскларда андый журнал юк.

2. Шушы язуны Гарәфнең үз кулына тапшырсаң иде. Официаль юл белән түгел.

*Сәламнәр белән сиңа яхшы җәйләр, илһам байлыгы теләп,*
*Мөхәммәт абый.*

## Рәдиф Гаташ хатлары

*20 июль, 1975 ел,*
*Гагра.*

Дорогой... әй лә, Кадерле дус Равил эль Габдрахман Фәйзулла!

Бу мин әле – шул Гаградагы Рәдиф. Ни хәлләрдә яшисең? Казандамы?

Сиңа зур үтенечем бар: монда мин шәп белорус шагыйре Рыгор Бородулин белән таныштым. Шагыйрь һәм Есенин, Райнис, Лоркаларны тәрҗемә иткән егет. Күп телләр белә, эрудит. Оригинальный кеше. Татар поэзиясе белән таныштырдым. «Суровая нежность»ны җибәр әле монда, ә? Танышсын иде. Тәрҗемә итәр иде. Гомумән, «яшь татар шагыйрьләре»н җибәрерсең дигән иде, автограф та яз, яме!

«Лит. Россия»дә Коркин мәкаләсен һәм синең кичә турында информацияне укыдым. Әйбәт.

Монда эссе. Юеш була бүлмәләрдә. Кәгазь гел юеш тора. Су коенам диңгездә. Казакътан Айтен исемле шагыйрь бар. Ул сине белә, китабың (русча) бар анда. Ул – шагыйрь һәм тәнкыйтьче.

Монда язучылар аз. Гел гаилә членнары яки чит һөнәр кешеләре. Каян алалар путёвканы, һич аңламассың. Безнең язучыларга юк. Төп яхшы корпуста Мәскәүдән килгән кыз-хатыннар яши – язучылар булса, бер хәер иде. Кызык дөнья!

Сочины карадым. Сухумига барырга исәп. Көннәр тиз уза. Казан да сагындыра башлады. Әллә ниләр булгандыр кебек... Ә бер хат та килми.

Мин 5 августка кадәр булам, тиз салсаң, бандеролең килеп җитәр.

Гаиләң ничек?

Күп сәлам!

*Рәдиф.*

*7 август, 1975 ел.*

Равил!

Кайтуга (5 июль) хатыңны алдым, рәхмәт.

Көтелмәгәнчәрәк иде бу хәл – тәкъдим.

6ысында Союзда Гариф абзый очрап, алып кереп сөйләште. Аңлатты хәлне: Гәрәй, Фаил (бусы, әлбәттә, более чем оригинально, ә?!) үтмәгән икән. Зәкигә җибәрде, ә ул приказ да язып куйды – 11еннән (дүшәмбе) эшкә...[1]

Алдан белмәгәч, уйландым, икеләндем, вакыт та сорадым (киңәш-табышка), алар: «Обком белән хәл ителгән, чигенергә юл юк», – диделәр. Шулай итеп...

Зур эш, җаваплы эш инде. Малайлыкны, хәтта либеральлекне онытырга туры килер.

Сезнең (синең) ярдәмгә өметләнәм инде, дустым!

Тизрәк сине күрәсем килә. Кайтканнан бирле барып йөрим, син гел генә Займищедамыни?

Менә бу хатны ящигыгызга салам, шунда звонок биреп карыйм...

Мин шимбә, якшәмбедә Аккошта булам инде. Син китабың белән мәшгульдер инде, күрәсең.

*Күрешкәнчегә кадәр,*
*Рәдиф.*

[1] Әлеге хатта сүз Р.Гаташның 1975 елда журналга эшкә урнашуы турында искә алына.

# МӘГЪРИФӘТЧЕНЕҢ КӨНКҮРЕШ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

## Насыйриның Казанда яшәгән урыннары

Мәгърифәтченең күпкырлы эшчәнлеге ике конфессия – ислам һәм православие, ике халык – рус һәм татарлар үзара тату яшәгән губерна шәһәре Казан белән бәйле. Татарлар мәхәлләләр булып Иске Татар, Яңа Татар, Җиләк, Бишбалта, Дары бистәләрендә яшәгәннәр. Гасырлар дәвамында Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә шәһәр инфраструктурасына хас барлык объектлар пәйда булган (Печән базары, Юнысов мәйданы, сәнәгать предприятиеләре, гыйбадәтханәләр, уку йортлары, кунакханәләр, тулай тораклар, трактирлар, чәйханәләр, кибетләр һ.б.). Татарның сәүдә-сәнәгать элитасы үз йортларын шәһәр төзелеше нормаларына нигезләнеп корган.

Җанисәп кәгазьләрендә гасыр ахырына Казанда яшәүче татарлар саны 28 меңләп кеше дип теркәлгән.

…Рус-татар училищесыннан киткәч, К.Насыйрига акча эшләү юлларын эзләргә туры килә. Ул Татар бистәләрендә яшәүчеләргә документларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итеп, шулай ук гариза текстлары язып һәм арендага алып торган фатирында түләүле дәресләр үткәреп акча эшләгән булса кирәк.

Башлангыч рус-татар училищесы укытучысы булып эшләгәндә, Насыйри Казан уку-укыту округы идарәсеннән бу хакта рәсми документ алган. Аңа укырга йөргән шәкертләр К.Насыйриның бүлмәсендә рус телендә ике таныклык эленеп торуына игътибар иткәннәр. Шуларның берсе Казан уку-укыту округы идарәсе тарафыннан Насыйрига башлангыч мәктәптә русча укытырга хокук бирүче таныклык булган дип уйларга нигез бар.

Алда әйтелгәнчә, Насыйри берничә тапкыр яшәү урынын үзгәртә. 1865-1866 елларда ул гаиләсе белән арендага алган фатирда, аннан соң берничә ел – вафат булган хатынының әтисе йортында яши. 1869-1870 елларда янә фатир арендалап тора. 1871–1877 елларда рус-татар мәктәбендә эшләгәндә, мәктәп кайда урнашса, шунда яши. Рус-татар училищесыннан киткәч һәм сәламәтлеге шактый ныгыгач, К.Насыйри Тихвин урамында (хәзерге Тукай урамы) мәчеттән берничә йорт аша арендага фатир алып тора башлый. Шул көннән башлап Насыйри үз вакытына үзе хуҗа була, беркемгә дә хисап тотмый һәм үзен тулаем мәгърифәтчелек эшенә багышлый.

Аның 1885 елда 2 нче гильдия сәүдәгәре Гайсә Мусинның (1816–1887) Ак мәчет тыкрыгында (Попечерно-Сенная) гыйбадәтханәдән берничә хуҗалык аша урнашкан йортында яшәве билгеле. Бу йортта төнлә янгын чыгып, мәгърифәтченең 10 ел дәвамында туплаган кульязмалары, шул исәптән башлаган һәм кайбер тәмамлаган хезмәтләре янып бетә. Ул үзе янгында 2 мең бит караламадагы хезмәтем янды дип әйтә *(Гали М. Каюм Насыйриның кульязма мирасы. Б. 120)*.

Бәлагә тарган Насыйри, депрессиядән, төшенкелектән чыгу юлын эзләп, туган авылына кайтып китә. Авыл һавасы һәм яхшы ризык, якыннары янәшәсендә булу, аларның кайгыртуы, энесе Габделкави мулланың хуҗалыгында хезмәт һәм авылдашлары белән аралашу аның сәламәтлегенә уңай тәэсир итә. Өч айдан соң ул Казанга кайта һәм ярты ел чамасы туганы – әтисе Габденнасыйрның энесе Мөхәммәдгалимнең улы Мөхәммәтбәдыйгъ (Бәдыйгъ) мөәзин йортында яши. Ә 1887 елда сәүдәгәр Гайсә Мусинның янгыннан соң кабат төзелгән йортына күченә. Шуннан соң Насыйри кыска вакыт эчендә берничә фатир алыштыра: 1890–1891 елларда 12 ай чамасы Евангельский һәм Технический урамнары эчендә, Печән

үлчәве каршында Чуваш иле авылыннан булган Хәсән исемле кеше йортында тора; 1891-1892 елгы кыш айларында Захарьев урамы башында Сөләңгәр Камали йортында яши. 1892 елның көзендә Насыйри кардәше Бәдыйгъ мөәзин йортына күчә. Габденнасыйрның энесе Мөхәммәтгалим Хөсәенов бу яңа йортына 1859 елда күчкән була *(Каюм Насыйри язган хатлар // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Б. 356)*.

Ялгызлыкта көн күрүче абыйсын картаймыш көнендә үз өенә яшәргә чакыруын мөәзиннең уйлап кылган гамәле булган дияргә кирәк: биредә, туганлык бурычларыннан кала, Бәдыйгъ мөәзиннең К.Насыйриның мәгърифәтчелек эшчәнлеген югары бәяләве дә әһәмиятле роль уйный. Әлбәттә, Насыри биләгән бүлмәләре өчен акча түләп тора, ул яктан мөстәкыйль була.

Насыйриның соңгы яшәү урыныннан яңасына күчүе очраклы килеп чыга. Сәүдәгәр Сөләйман Аитов балачагында мәгърифәтчедән рус теле дәресләре алган була, шуңа күрә остазыннан үз улын гимназиягә керергә әзерләвен үтенә.

Сәүдәгәр тәкъдим иткән матди шартлар Насыйриның күңеленә хуш килә (Истәлегендә С.Аитов укытучыга күпме түләве турында әйтми). Балалар укытучы яшәгән йортка төркемнәре белән йөрмәсеннәр һәм мөгаллим үзе дә көн саен сәүдәгәр йортына килеп мәшәкатьләнмәсен өчен, кайгыртучан ата Насыйрига үз утарының ишегалдындагы агач йортка күчәргә тәкъдим итә *(Сөләйман Аитов. [Истәлек] // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б. 451-452)*.

Ике бүлмәле бу зур булмаган йортка Насыйри 1893 елның көзендә күчеп килә. Ул анда бушлай (йортны җылытуны һәм ашау ягын үзе кайгырта) яши. Күрәсең, бу йортны хуҗасы хезмәтчеләр өчен төзеткән булган. Әмма сәүдәгәр икенче репетитор яллагач, Насыйри янә Бәдыйгъ мөәзин йортына әйләнеп кайта *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 49, 50, 52)* һәм 1899 елдан 1902 елга кадәр ике катлы агач йортның беренче катындагы ике бүлмәсендә яши *(Исламов Р. Каюм Насыйри һәм аны өйрәнү // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б. 13)*.

Насыйриның бик пөхтә һәм җыйнак кеше булуын искәртәләр. Гарәп хәрефләре белән текстларны ул – каз каурые, русча текстларны каләм белән яза. Текстларының каралама вариантына соңрак төзәтергә яки өстәмәләр кертергә җайлы булсын өчен кырыйдан чиста буй калдыра. Акка күчергәндә, юлларны кәгазь битенең читенә үк терәп яза, шулай ук кәгазьнең арткы ягын да куллана, соңыннан үзе үк кульязмасын төпләп куя. Кульязмаларын шәкертләренә күчереп язарга бирә, соңрак аларны дәреслек урынына кулланалар *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 80)*.

Насыйри даими рәвештә «Биржевые ведомости», «Казанские ведомости», «Голос» (Санкт-Петербург, 1863–1883) газеталарын укып бара, кайбер материалларны күчереп ала, татар теленә тәрҗемә итә һәм үзенең Календарьларында файдалана. Шулай ук «Нива» журналын яздыртуы, И.Гаспринскийның «Тәрҗеман»ын укуы да билгеле *(Шунда ук. Б. 63-64)*.

Иделгә су юлы төшкәч, Насыйри ел саен пароходта туган авылына кайтып йөри. Шулай ук җәй көннәрендә берничә тапкыр кайтып килә. Ул бигрәк тә җигүле атта йөрергә яраткан. Габделкави энесе, кагыйдә буларак, аны алып кайтырга пар ат җиктереп җибәргән яисә Кече Шырданга кайту өчен ул үзе җигелгән ат яллаган. Авылда Насыйри кырлар һәм урманнарда йөрергә чыгып китә торган булган, дару үләннәре җыеп, Казанга алып киткән. Аның турында хатирәләр язып калдырган замандашлары бүлмәсендә кочагы белән дару үләннәре эленеп торуын искә алалар *(Шунда ук. Б. 60-61)*.

## Насыйриның көнкүреше замандашларының тасвирламасында

Каюм Насыйри турындагы хатирәләрнең күпчелеге мәгърифәтченең соңгы дистә елына карый, чөнки ул елларда аның шәхесе белән укучы татар яшьләре кызыксына башлый.

Насыйри турында 1870–1880 нче еллар башына караган берничә хатирә-язма сакланып калган: 1879 елда әтисе белән мәгърифәтче катына килгән Гарифулла Чокрыйныкы; ул вакытта Мәрҗани мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәтҗан Мозаффаровныкы (улы Мөхәммәтхәнәфи язып алган) һәм 1870 еллар урталарында, Күлбуе мәдрәсәсендә укыганда, берничә шәкерт белән Насыйридан түләүле рус теле дәресләре алган Габдулла Кәчимиринеке. (Бу чорда Насыйри көндез рус-татар мәктәбендә укыткан, кичләрен килгән мәдрәсә шәкертләренә түләүле дәресләр биргән).

Бу текстлардан күренгәнчә, Насыйри уртача буйлы, ябык гәүдәле, олы башлы, күпмедер шадра йөзле, зур колаклы һәм зур борынлы кеше була. Көрән төсле сирәк сакалын татарча, пөхтә итеп кистереп йөргән *(Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри. Б. 493)*. Җәй көне урамга аягына саурый читек-кәвеш, өстенә ак көмеш төймәле постау казаки, борынгы әйләнмә якасыз зәңгәр постау чикмән киеп чыккан. Зәңгәр постау чалбары кәвеш йөзенә төшеп торган. Башында түбәсенә хәтфә, кырыена бер карыш киңлегендә кондыз тиресе куеп тегелгән камчат бүрек, кулында зонтик булган. Кыш көннәрендә зонтикны кыска таяк алыштырган, урамда җәнлекләрнең тамак асты тиресеннән тегелгән затлы толып һәм яхшы туннар киеп йөргән. Шәһәр буйлап һәрвакыт җәяү, вәкарь белән генә атлап, гәүдәсен төз тотып йөргән *(М.Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында. Б. 483-484)*.

Насыйри күп сүз сөйләмәгән, сүзләрен ашыкмыйча әкрен генә әйткән. Замандашлары аны тыйнак, сирәк елмая һәм сирәк көлә, әйләнә-тирәсендәге кешеләрне тигез күреп сөйләшә торган кеше итеп истә калдырган.

Мәгърифәтче мәчеткә йөрмәгән, биш вакыт намазын өендә укыган. Янына килгән кешеләр бүлмәсендәге намазлыкка һәм чалмага игътибар иткәннәр.

Насыйри спиртлы эчемлекләр эчмәгән, әмма папирос тарткан, кайвакыт сигарет та суыра торган була. Кайчакта хәл белергә килгән кешеләр Насыйриның тәмәке тартып торган вакытына туры килгәннәр. Җәмәгать урыннарында, шулай ук шәкертләре янында беркайчан да бу начар гадәтен күрсәтмәгән *(Шунда ук. Б. 484)*.

Базарга кирәк-ярак сатып алырга барганда яисә урамда йөргәндә, Насыйри танышлары белән сөйләшмәскә тырышкан: әгәр кем дә булса берәрсе сүз катса, ул аны фатирына чакырган *(Шунда ук. Б.484)*. Аның бер авылдашы истәлекләрендә үзе белән булган бер очракны искә ала. Казанга кыш көне «барабыз» булып аты белән акча эшләргә килгән Кече Шырдан кешесе, ат чанасында барганда, юл кырыендагы җәяүлене күрмичә, тәртә башы белән Насыйрины бәрдереп егып киткән. Каюм егылган җиреннән торган һәм, «һай ахмаклар» дип, киеменнән карларны каккалаган да юлын дәвам иткән, полиция-мазар чакыртып тормаган *(Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945. Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материалары. Казан, 1948. Б. 137)*.

1870 елларда казанлыларның үзенә тискәре караулары Насыйрины борчыган. «Җыен» исемле бәет чыгарып, анда муллаларның, байларның, урам себерүчеләрнең, хуҗалыкта эшләүчеләрнең, ипи пешерүче һ.б.ларның караңгы эшләрен ачып салып тәнкыйтьләгән *(Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри. Б.494)*. Өендә дә, үзенә ошамаган шәхесләр турында сүз чыга калса (андый кешеләр, кагыйдә буларак, муллалар булып), алардан төртмә сүзләр әйтеп көлә торган булган *(Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында. Б.484)*.

Шуңа һәм артык аралашырга яратмый торган кеше буларак, ул мәҗлесләрне сөймәгән, әгәр дә барырга туры килсә, табын янындагы сөйләшүләрдә катнашмаган, эндәшмичә утыруны хуп күргән *(Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри. Б.493)*. Кәефе яхшы булганда, мәҗлесләрдә шигырьләр укыган.

Замандашлары аның хатын-кызлардан читтәрәк торырга тырышуын билгели. Күрәсең, балдызының үзенә кияүгә чыгудан баш тартуы Насыйрида хатын-кызга карата ышанычны тәмам какшаткан. Ул: «Хатыннар мәкереннән Аллаһ сакласын», «Адәм гомерен һәртөрле фетнә вә мәшәкать илә уздырыйм дисә, хатын алсын», –

дип кабатларга яраткан *(Мөхәммәтхәнәфи Мозаффар. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында. Б.484)*.

Мәгърифәтче үсемлекләрнең дәвалау үзенчәлекләрен бик яхшы белгән, дару үләннәре җыю белән мавыккан һәм алар турында сөйләргә дә яраткан *(Габдулла бине Таҗетдин әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри. Б. 493)*.

Насыйри кул эше белән шөгыльләнергә бик һәвәс булган. Аның фатирында агач кыру станогы, верстак һәм башка агач эшкәртү кораллары булган, ул йорт җиһазларын һәм хуҗалык кирәк-яракларын үзе ясаган. Китап төпләү, чабата үрү, слесарьлык, лак, крахмал, кара ясау, шәм кою, күзге ясау, электр тогы кулланып, әйбер көмешләү (гальванопластика), һәртөрле ризыклар, ашлар хәзерләү кебек һөнәрләрне яхшы белгән, кояш сәгате, циркуль кебек әйберләрне үзе ясаган *(Гарифулла ибне Гали Чокрый. Габделкаюм ән-Насыйри // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-библиографик җыентык. Б. 480.; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.58-59)*.

Насыйри музыка тыңларга яраткан, музыка тыңлау мөселманнар өчен тыелган гамәл дип санамаган. Замандашлары аның бүлмә диварында скрипка белән балалайка эленеп торуына игътибар иткәннәр, ләкин шәхсән үзләре бу музыка коралларында уйнаганын күрмәгәннәр, ишетмәгәннәр. Ул курайда уйнарга яраткан, кубызда искиткеч моңлы көйләр чыгарган. Ташаяк базарыннан алган агачтан курай ясарга һәвәс булган, кубызларны да үзе ясаган, һәвәскәр останың кубызлары озын булган – 10-14 см га җиткән *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.59)*.

Шушы өч хатирәдән күренгәнчә, 1880нче еллар башында Насыйри тышкы кыяфәтенә зур игътибар биргән: Европача һәм традицион стильләр катнашкан кыйммәтле киемнәр кияргә яраткан, җәй көне Казан урамнарыннан Европача манера белән кулына зонтик тотып йөргән. Ул шулай ук вакыт кадерен белгән, көнкүреш проблемаларына артык дикъкать итмичә, ыгы-зыгыдан читтә торырга тырышкан; кабинетта ябылып эшләүче галим буларак, актив аралашуга омтылмаган, хәтта шәһәрнең Татар бистәләрендә яшәүче мөселманнар уздырган җәмәгать чараларын урап узган. Биредә аның 1859 елда Мәскәүдә булуын, берничә тапкыр Мәкәрҗә ярминкәсенә баруын, 20 елга якын Россия мәгариф системасында эшләвен дә искә алырга кирәк. Мәдрәсә чорыннан ук ул мөстәкыйльлеккә күнеккән, буйдак тормышы аны үзе турында кайгыртырга өйрәткән.

Замандашларының хатирәләреннән аңлашылганча, 1890 нчы елларда Насыйриның тышкы кыяфәтендә шактый үзгәрешләр сизелә. 60 яшьләренә җиткәндә, күрәсең, тышкы дөнья белән элемтәләре чикләнү сәбәпле, Насыйри кием-салымына тиешле игътибар бирми башлый. 1890нчы еллар урталарында ул базарга иске модалы җилән киеп йөри, башында элеккечә – «камчат бүрек», аякларында – «читек-кәвеш», аның каравы, «урыс чалбары» белән зонт юкка чыга *(Исхаков М.Г. Габделкаюм Насыйри // Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 т. 12 т.: публицистика [томны төз., текст. иск. һәм аңлат. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин]. Казан, 2012. Б .161)*. 1860–1870 елларда Татар бистәләрендә Европача киенүне пропагандалаучы булса, өлкәнәйгәч, консерватив карашлы кешегә әйләнә. 1898 елда Казан мөселманнарын Европа модасы белән мавыгуда гаепли *(Нуреддин Ишаев. Габделкаюм Насыйри хакында // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б. 459)*.

Мәгърифәтченең көнкүрештә талымсызлыгы, тышкы дөнья белән элемтәләре чикләнү, үз эшенә бирелгәнлеге күпмедер дәрәҗәдә суфиларның үз-үзен тотышын хәтерләтә. Бигрәк тә Насыйриның гомере ахырында 3 мең сум акчасы булуы, аның зур өлешен авылдашларының җәмәгать эшләренә васыять итүе аның карашлары үзгәргәнлекне сөйли.

Бу җәһәттән, мәгърифәтченең иҗатында яңа юнәлешләрне дә атап китү урынлы булыр. 1883–1886 елларда Насыйри Коръәннең сүзлек-конкордансын төзү белән шөгыльләнә. 1887 елда кече энесе Габделкави белән берлектә әтисенең сакланып калган кәгазьләре буенча муллалар өчен гарәп телендә вәгазьләр җыентыгы төзеп

нәшер итә. Насыйри шулай ук фатирында малайларга гарәп теленнән дәресләр дә бирә. Үзенең педагогик практикасы нигезендә 1896 елда Коръән телен шактый үзләштергән шәкертләр өчен гарәп теленең сарыф һәм нәһүе буенча дәреслек бастырып чыгара.

Алда әйтелгәнчә, 1870нче еллар уртасында мөгаллимлек иткәндә, Насыйри күпсанлы һөҗүмнәрне, нахакка рәнҗетелүләрне кичерергә ярдәм иткән тормыш фәлсәфәсен һәм рухи көч чыганагын Көнбатышның фәнни терминологиясе белән аңлаткан, Көнбатыш Европа тарихыннан беренче булып юл табучыларның батырлыкларын мисал итеп китергән (Колумб, Гутенберг).

1880 һәм аннан соңгы елларда Насыйриның мәгърифәтчелек идеологиясендә, шул исәптән үзенең тормыш мәгънәсе белән дә бәйле яңа фикерләр барлыкка килә. Моңа Күлбуе мәдрәсәсе шәкерте Насретдин Хуҗаши хатирәләреннән дә инанып була. Ул 1902 елның 9 гыйнварында Насыйриның фатирында булган. Шәкертне мәгърифәтченең зур тырышлык һәм ихтыяр көче куеп хезмәтләр язуы шаккатырган. Камчат бүрекле карт кешенең, өстәл янындагы иске диванга утырып, сул яңагын тәмам өстәлгә тигезләп, каләменең яза торган очына күзен якын китергән хәлдә тырышып язганын күргән ул. Шәкерт түзмәгән: «Үзеңез карт, күзләрегез зәгыйфь булса да, язуыңызда дәвам итәсез икән!» – дигәч, Насыйриның яшь буын вәкиленә җавабы мәгърифәтченең соңгы дистә еллардагы тормыш фәлсәфәсен аңлата: «Аллаһ мине китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру Аның хөкеменә каршылык булыр дәюп куркам» *(Насретдин әл-Хуҗаши. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә (Хатирә дәфтәреннән). Б. 470, 471)*. Насыйри үзенең бу дөньядагы миссиясен шулай билгеләгән.

Насыйриның шушы фани дөньяда югары миссиясен аңлавы һәрнәрсәдә күренә: җәмәгатьчелек алдында үз-үзен тотышыннан алып өйдә ничек киенеп йөрүенә кадәр. Мәсәлән, 1890нчы еллар урталарында Күлбуе мәдрәсәсе шәкертләрен йорт хуҗасы кыска казаки һәм ялан аякларына кигән башмаклардан каршы алган *(Исхаков М.Г. Габделкаюм Насыйри. Б. 163)*. «Икъдам» госманлы газетасының баш мөхәррире (1894–1928 елларда) Әхмәт Җәүдәт Оран 1896 елда Казанга килгәч, Гөлнар ханым (Ольга Сергеевна Лебедева) белән мәгърифәтченең фатирында була. Хуҗа кеше шулай ук аларны яланаяк каршы ала *(Шунда ук. Б. 164-165)*. 1901 елда М.Укмасый эш белән мавыккан 75 яшьлек Насыйриның өй киемен түбәндәгечә тасвирлый: аякларында – читек, арык гәүдәсенә озын ак күлмәк кигән, аны кыска балаклы чалбарына кыстырып тормаган, күлмәк өстеннән камзул элгән, аны төймәләмәгән, башында – бәрхет кәләпүш *(Миргазиз Укмаси. Каюм абый Насыров // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль җыентык. Б. 512)*.

Шулай да замандашлары Насыйриның 1890 нчы еллар уртасыннан алып ямьсез итеп тасвирлаган тормышына күпмедер ачыклыклар кертеп төгәлләштерүләр таләп ителә.

Алда әйтелгәнчә, 1893–1898/1899 елларда С.Аитовның улын һәм аның яшьтәшләрен укытканда, Насыйри Казан сәүдәгәренең хуҗалык эшчеләре өчен төзелгән ике бүлмәле кысан йортында яшәгән. Шушы елларда аңа кунакка килгән кешеләрдә мәгърифәтче авыр тормыш шартларында яши дигән фикер калган.

Зур булмаган бер бүлмәнең бер як стенасында идәннән түшәмгә кадәр китап киштәләре булган, ул киштәләр китаплар белән шыплап тулган *(Исхаков М.Г. Габделкаюм Насыйри. Б .161)*.

Бәдыйгъ мөәзин йортының беренче катында Насыйри ике зур бүлмәне биләп торган. Бик күп китаплар һәм кульязмалардан торган шәхси китапханәсе, агач эшкәртү кораллары булса да, ялгызак өчен Казан шәһәре шартларында мәйдан җитәрлек булган. Кергән яктагы бүлмә кухня ролен үтәгән, анда керосинкада ризык әзерләнгән. Насыйри эшләгән бүлмә диварларында карталар эленеп торган. Җиһазлардан ике зур булмаган өстәл, берничә урындык һәм шкаф булган. Шкафның өске өлешенә кульязмалар һәм китаплар тутырылган, аскы өлешендә төрле кораллар (чүкеч,

keləшчə), тимерчыбыклар, катыргы кәгазьләр, химик тәҗрибәләр үткәрү өчен савытлар урын алган. Шкаф янында өстәлләрнең берсе урнашкан, аңа тәртипсез рәвештә татар, фарсы, гарәп, рус телендәге китаплар, газета-журналлар, картиналар, зурайткыч лупа, көч үлчәү приборы, глобус һ.б. өелгән. Тәрәзә төбе дә киштә вазифасын үтәгән: анда спирт лампасы, өчаяк, төрле ташлар тутырылган агач тартма, купорос һ.б. төрле химик тәҗрибәләр өчен кирәк-ярак куелган *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Б. 504)*. Икенче язу өстәле янына ук иске диван урнашкан *(Насретдин әл-Хуҗаши. Күрс. хезмәт. Б. 470.)*.

Көнкүрештә талымсыз Насыйрига иркен бүлмәләр кирәк тә булмаган. Иҗат кешесе буларак, биредә яраткан эше белән шөгыльләнү мөмкинлеге бар: аны берәү дә фатирга түләп торучы дип контрольдә тотмаган, шелтә белдермәгән. Моннан тыш, ялгыз кешегә картаймыш көнендә туганы белән аралашып яшәү бик кадерле булган, туганы да мәгърифәтчене бик хөрмәт иткән һәм беркайчан да аның үтенечләрен кире какмаган. 1865-1866 елларда кыска гына вакыт аралыгында гаилә бәхете күреп калган Насыйри икенче тапкыр туганнары янында уңайлы гаилә җылысына тиенә.

Шундый аралашуның бер формасы – бергәләп төшке яки кичке ашны ашау була. Насыйри – оста пешерүче, ул сәламәт ризыкка мөкиббән. Пылау яки «шәкерт салмасы», яисә «куллама» (камыр басып, сыер ите белән пешерелә) пешерсә, ул кисәү агачы белән түшәмгә шакый, бу исә Бәдыйгъ мөәзин гаиләсенең ир-атларын ашарга чакыру дигәнне аңлата *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр. Б.505)*.

Һәм, киресенчә, Бәдыйгъ мөәзиннең җәмәгате камыр ризыклары яисә башка тәмле мич тәгамнәре пешерсә, әтисе кушуы белән бәләкәй Әхмәт Насыйрига да алып керә. Кыскасы, Насыйрины өй ризыклары белән еш сыйлый торган булалар, бу исә өлкән мәгърифәтчегә, һичшиксез, өй җылысы биреп торган дип ышанырга була.

Бәдыйгъ мөәзиннең улы белән аралашканда, Насыйри үзенең аталык хисләренә дә урын таба, моның да психологик яктан әһәмияте зур. Насыйриның үзенә карата ачык мөнәсәбәтен тоеп, малай агасы янына сәбәпсез дә кереп йөри, тегесе исә олы кунакны конфетлар белән сыйлый, зур булмаган глобус бүләк итә, рус телендә чыккан рәсемле журналлар карарга бирә («Нива» һ.б.), зурайткыч пыяла аша («панорама») төрле картиналар күрсәтә һәм малайны рус телендә укырга өйрәтә. Гомеренең соңгы елларында Насыйри төсле шәмнәр ясау белән мавыга, буяуларны да үзе әзерли *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр. Б. 504)*, малай абыйсының әлеге шөгыльләрен игътибар белән күзәтә. Шул рәвешле, Бәдыйгъ мөәзин йортында карт Насыйри озак еллар хыялында йөрткән җылы өй мохите таба.

К.Насыйри агач йортның аскы катындагы ике бүлмәне биләгән дидек. Беренче катның икенче өлешендә – мөәзиннең кызы гаиләсе белән, икенче катында хуҗа үз гаиләсе белән яшәгән. Бәдыйгъ мөәзин утары биек койма белән уратып алынган, ике катлы йорттан тыш, биредә бүрәнәдән салынган җәйге йорт, келәт, башка хуҗалык корылмалары (ат абзарыннан башка) һәм шактый зур мәйданда җиләк-җимеш бакчасы (Казанның хәзерге 80нче мәктәбе урынында) булган. Бакчада челтәрле бизәкләр белән эшләнгән чатыр да корылган *(Хөснетдинова Р. Андыйлар сирәк очрый // Казан утлары. 1998. №4. Б. 143)*.

Бәдыйгъ мөәзиннең берничә ел дәвамында Насыйри белән якыннан аралашып калган улы Әхмәт Хөсәенов, үзе дә аңламастан, хатирәләрендә дөньяны ничек бар, шулай яраткан бәхетле ялгыз картны сурәтли. Аның язганыннан күренгәнчә, Насыйри табигатькә мөкиббән, ул биргән бүләкләрне дөрес итеп куллана белгән; кыш һәм яз айларында йортның ишегалдына чыгып, көн саен диярлек кошлар ашаткан *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр. Б. 507)*. Җәй көннәрендә мәгърифәтченең иң яраткан шөгыле яшел чирәмгә утырып, табигатькә хозурланып һәм кошлар сайраганны тыңлап чәй эчү булган. 1890нчы еллар ахырында яз һәм җәй

айларында Насыйриның Бәдыйгъ мөәзин белән самовар алып, ат җигеп, Арча кырына чыгу гадәте булган. Анда ул дару үләннәре җыйган, табигать белән хозурланган. Яисә инде, кәефләре булганда, агалы-энеле, шәһәр кешеләре уянганчы, иртә таңнан Черек күл ярына чыгып, чәй эчкәннәр. Җәй көне елгада коенганнар *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр. Б. 506, 508; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 59-60)*.

Сәламәтлеге өчен катлаулы вазгыятьләрдә Насыйри картаймыш көнендә табибларга һәм дару сатучыларга мөрәҗәгать итмәгән, химик юл белән ясалган дарулардан баш тарткан. Гимнастика белән шөгыльләнгән, авырганда да, профилактика өчен дә дару үләннәреннән төнәтмәләр ясап эчкән *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 60-61)*.

Насыйри янына бөек шәхес дип килгән яшьләрдә аның тормыш-көнкүреш шартлары начар дигән тәэссоратлар калу берничә факторга бәйле. Аның вакыты бик төгәл бүленгән була: биш вакыт намаздан һәм ашарга әзерләүдән, гыйльми тикшеренү эшләреннән һәм текстлар язудан тыш, ул көн саен мотлак рәвештә физик хезмәткә вакыт калдырган. Физик хезмәт дигәндә, агач эше һәм башка үзен кызыксындырган эшләр белән шөгыльләнгән.

Шунысы да мөһим: бүлмәләрне чиста итеп тоту, идән юу кебек эшләрне башкарган йомышчы малай хезмәтенә бармак аша караган. Агач эше өчен аерым бүлмә булмау да фатирда чисталык һәм тәртип саклауны катлауландырган. Өстәвенә, Насыйри агач эше белән шөгыльләнгәндә, йомышчы малай кайтып киткән, икенче көнне иртән килгәч кенә бүлмәне җыештырган, йомычкалар белән мич тергезгән. Ул арада мәгърифәтче янына килгән яшьләр бу тәртипсезлекне күреп китәргә өлгергәннәр. Алар идәндә яткан балта, өтерге, ышкы һәм башка эш коралларын, агач кисәкләрен күреп, Насыйрины тәртипсез һәм авыр хәлдә яши дигән нәтиҗәгә килгән. Бүлмәсендәге бу тәртипсезлекне хуҗа үзе йомышчы малай җыештырганнан соң эш коралларын табу кыенлаша дип аңлаткан *(Насретдин әл-Хуҗаши. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә (Хатирә дәфтәреннән). Б. 470)*. Бер үк вакытта текстлар язу, өстәл тутырып җәеп салып, берничә китап яки кулъязма уку белән дә мавыккан Насыйриның эшләү шартлары да начар дигән тәэсир калдырган. Чынлыкта берьюлы берничә эш белән шөгыльләнүче буйдак мәгърифәтче өчен гадәти эш обстановкасы булган.


Гомеренең соңгы елларында Насыйриның аягы җиңелчә генә параличлана. Авыруына карамастан, ул докторга күренүдән баш тарткан, үгетләүчеләргә үзенең табиблык сәләте бар дип җавап биргән. Авыруын үз методикасы белән җиңеләйткән, электр белән дәвалану ысулы кулланган, стенага горизонталь рәвештә беркетелгән таякка тотынып, өй буйлап хәрәкәтләнгән һәм... кабат йөреп киткән.

Гомеренең соңгы елында аның күзе күрми, колагы ишетми башлый, шулай ук вакыт-вакыт хәтерен дә югалткалап алган. Үләренә берничә ай кала бөтенләй сукырайган *(Әхмәт Хөсәенов. Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр. Б. 508)*. Соңгы айларда урыныннан тормаган. Бу вакытта аны, Бәдыйгъ мөәзиннән тыш, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре дә акчага тәрбияләп торган.

Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрь) вафат була. 21 августта җеназага берничә якын туганы һәм шәкертләр генә килә. Шәһәр мөселманнары бөек татар мәгърифәтчесе белән хушлашу мәрасименә битараф кала. Күбесе аның рус мәдәнияте белән мавыгуын, мәчеткә йөрмәвен, биш вакыт намазын укымавын (соңгы сәбәп уйлап чыгарылган) кичерә алмый *(Шунда ук. Б. 508)*.

Насыйри Татар зиратына, икенче бер күренекле татар мәгърифәтчесе Ш.Мәрҗани кабереннән 15 сажин ераклыкта җирләнә *(Рәхим Г. Насыйриның тәрҗемәи хәленә гыйлавә. Б. 52-53)*.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*



*Нәкый Исәнбәт эш бүлмәсендә. 1968-1969 еллар.*

*Нәкый Исәнбәт хатыны Гөлсем белән. Уфа,1924 ел.*



*Әдип гаиләсе белән. Алгы рәттә (сулдан уңга): оныклары Илдар, Ринат, Гөлнар, Айдар; икенче рәттә: Зөлфә (килене), Гөлсем (хатыны), Нәкый Исәнбәт үзе, Әлфия (килене), Булат; өченче рәттә: Празат, Йолдыз, Мәрзия (килене), Наилә (Булатның кызы), Арлат. Казан, 1960нчы еллар уртасы.*





*Бакый Урманче күргәзмәсендә. Сулдан уңга: Әмирхан Еники, Ренат Еникеев, Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт. Казан, 1982 ел.*




*Казан телевидениесе студиясендә композитор Салих Сәйдәшевка багышланган телевизион фильм төшерү вакытында. Сулдан уңга: Нәкый Исәнбәт, Хәким Сәлимҗанов, Сара Садыйкова. 1970 еллар. Рөстәм Нәбиуллин фотосы.*

*Нәкый Исәнбәт белән Хәсән Туфан профессор Хәйрулла Мәхмүдовта кунакта. Алма-Ата, 1962 ел.*





*Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы. 1957 ел.*

*Сәхифәне* **Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА** *әзерләде.*

# ТОРМЫШНЫҢ МАТУРЛЫГЫННАН КӨЧ АЛАМ!




«Әгәр дә милләтне көчле итеп бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан» дигән күренекле татар драматургы, язучы, публицист Туфан Миңнуллин. Свердловск өлкәсе Березовский шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез татар булулары белән горурланып яши дә беләләр, башкарган эшләре белән дә башкаларда соклану хисләре дә уята алалар, башка төбәктә яшәүче татарларны да ялкынлы эшләргә дәртләндереп торалар. Халкыбызның ана телен саклау өчен куйган көчләре, башкарган эшләре белән танышканнан соң, аларның бердәм булуларына, иңне-иңгә куеп эшләүләренә сокланмыйча мөмкин түгел. Мондагы милләттәшләребезне берләштереп торуда Березовский шәһәре татар һәм башкорт җәмгыятенең өлеше һичшиксез зур. Җәмгыятьнең рәисе Фрида Насретдинова белән аралашканнан соң да, моңа кат-кат инанасың. Милли хәрәкәт белән бәйле нинди генә чарага, эшкә алынсалар да, алар бер-берсенә булышып, ярдәмләшеп эшли беләләр. Бәлки шуңа күрәдер дә нәтиҗәсе көткәннән дә уңышлырак килеп чыга. «Татарстаннан читтә яшәсәк тә, милләтебезне саклый алуыбыз – безнең бердәм булуыбызда», – ди Фрида ханым.

Милләтебез дип янып яшәүче Фрида Насретдинова тумышы белән Башкортстанның Тәтешле районыннан.

«Бай тарихлы Аксәет авылыннан мин. Әниемнең әнисе – әбием тәрбиясендә үстем. Гашия әбием безнең якта бик танылган кеше иде. Аны халык «хирург» дип йөртте. Ул буыннарны утырта иде. Безнең йорттан халык өзелмәде. Кайвакыт больницадан: «Сезнең үз хирургыгыз бар», – дип, авыруларны кире кайтарып җибәрә торган булганнар. Терлекләрнең дә буыннарын утырта алу сәләте бар иде анда. Тирә-күршеләрнең аксаган чебиләрен кыстырып кергәннәрен әле дә хәтерлим. Тик үзем моңа өйрәнә алмадым», – дип, әби белән үскән балачак елларын искә ала Фрида апа.

Аксәет авылы мәктәбен тәмамлагач, яшь кыз Татарстанга юл ала. Хыялы – Казан дәүләт финанс-икътисад институтына укырга керү. Шул елларда ук үҗәт, тырыш, үз дигәненә ирешә торган булган шул Фрида ханым. Бу сыйфатлар булачак һөнәрен сайлауда да мөһим роль уйнагандыр, мөгаен. Һәр эштә төгәллек, җаваплылык аның холкында гына түгел, канына да сеңгән.

«Студент еллары бер сулышта узды да китте. Яшь белгеч буларак, мине Арча сөт заводына юлладылар. Анда күпмедер эшләгәч, кияүгә чыгып, Башкортстанга – Нефтекама шәһәренә күчендек. Анда да сөт заводына баш хисапчы урынбасары булып урнаштым. Гомер буе шушы өлкәдә эшләдем. Улым туганнан соң, Нефтекама автозаводында производство участогы хисапчысы булып эшләдем. 1979 елда язмыш җилләре мине Свердловск өлкәсе Березовский шәһәренә китерде. Монда яңа тормыш башланды. Ул чакта СССРдагы бердәнбер Эретмәләр заводына эшкә урнаштым», – дип искә ала Фрида апа, тормыш китабының битләрен барлап.

Ә бу китапта шатланып искә алырлык куанычлары да, искә төшерүгә күзгә яшь

килерлек әче сагышлары да булмый түгел. Нык холыклы, язмыш җилләрендә сыналган, әмма җил-давылларга бирешмәгән Фрида ханым ул хатирәләрне үтә дә сабырлык белән искә ала. Шулай, адәм баласының язмышы икенчесенекенә охшамый шул. Һәр кешенең үз тәкъдире, үз юлы. Шома, туры юл да сикәлтәләр белән бергә үрелгән. Кеше, шул сикәлтәле юлларны узганда сыналса да, алга таба яшәргә көч табып, алга атлый, авырлыклар вакытлыча булса да онытыла, ә сынаулар исә адәм баласын чыныктыра гына. Фрида апа да бирешмәскә, тормышның матурлыгын төрле яктан күрергә өйрәнә. Һәр туган көнгә шатланып яшәргә Аллаһы Тәгалә аңа көч бирә.

Хисапчы ханым милли эшләр дөньясына ничек килеп керде икән? Югыйсә саннар, хисап эше иҗаттан ерак тора кебек. «Березовскийда яшәгәндә, улым укыган мәктәптә бер елны «Милли ишегалды» бәйрәме үткәрделәр. Шәһәрнең мәдәният идарәсе миннән, татар-башкорт ишегалдын бизәүне оештыруны сорады. Татар җанлы активистлар белән бу эшне бик теләп башкарып чыктык: милли ризыклар, киемнәр – барысын да күргәзмәгә тәкъдим иттек. Шул вакытта Екатеринбургтагы активистлар татар оешмасы булдырырга кирәк дигән идея белән мәдәният идарәсенә мөрәҗәгать итә. Идарә ярдәме белән шул рәвешле Татар-башкорт милли мәдәни үзәккә нигез салынды. Менә шуннан бирле без милли эшләр белән мәшгуль булып яшибез. Төрле чаралар, кичәләр, очрашулар үткәрәбез. Бигрәк тә милли бәйрәмебез Сабан туен күтәреп алабыз. Дини бәйрәмнәрне дә читләп үтмибез. Үзебездә, Аллаһка шөкер, тулы куәттә мәчетебез эшләп килә. Анда татар теле һәм дин дәресләре укытыла. Мәчет каршындагы Попечительләр советы татар-башкорт эшмәкәрләрен туплап тора. Аның рәисе Фәрит Нәбиуллин һәрвакыт безгә ярдәм итәргә әзер. Менә шулай бердәм булып, милли рухыбыз ялкынын сүндермичә яшибез», – дип, үзәкнең эшчәнлеге белән таныштырды Фрида ханым.

Татарлар – җыр-моңга гашыйк халык. Татар булган җирдә җыр тынмый. Березовский шәһәрендә 15 еллап эшләп килә торган «Курай» ансамбле мәдәнияткә гашыйк халыкны туплап торган җылы учак кебек. Өлкәдә узган бер милли бәйрәм дә алардан башка узмый икән. «Гармунчыдан башка ансамбль чын ансамбль булмас иде. Кайвакыт гармунчыларга кытлык булды. Хәзер Татарстанның Балтач районыннан Илнур Хәмидуллин эшне җайга салды, ул эшли башлаганнан бирле ансамбль икенче сулыш алгандай булды. Икенче елда балалар өчен «Тамчы» коллективы оешты. Балалар – безнең киләчәгебез. Аларның да сабый күңелләрендә татар теленә мәхәббәт орлыклары чәчеп үстерәсебез килә. Хореограф булу да зур мөмкинлекләр бирә. Балаларыбыз татар халык биюләрен өйрәнә», – дип, куанычын яшерми милләттәшебез.

Халкыбыз элек-электән, кайда гына яшәсә дә, белем алуга омтылган. Шәһәрдә эшләп килгән китапханәнең татар телен саклауда алып барган эшләрен санап бетерерлек түгел. «Китапханәбездә дә Балтач кызы Гөлсия Равил кызы эшли. 2000ләп татар китабы саклана. Төрледән-төрле татар журналлары яздыртабыз. «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел» һ.б. татар басмаларын күтәреп алабыз, яратып укыйбыз. Ай саен халык җыеп, яңа килгән журналларга, китапларга күзәтү ясыйбыз. Кызыксынган һәр кеше өенә алып кайтып укый ала. Татарча китап укыйм дигән кешегә барлык мөмкинлекләр дә булдырылган. Китапханәбездәге чаралар да бәйрәм рухында уза. Язучы-әдипләрнең юбилейлары дисеңме, танылган шәхесләр белән очрашулармы – без мондый эшләрне бик яратып башкарабыз», – ди Фрида апа.

Милләтебез сагында менә шундый шәхесләр торганда, татар халкының киләчәге өметле. Фрида ханым үзе бар көчен куеп эшли, башкаларны да шундый эшләргә илһамландыра белә. «Татарстаннан читтә яшибез. Ничек булдырабыз, шулай саклыйбыз» дип түгел, ә «Без булдырабыз» дип, яңа идеяләр белән янып яшәүче милләттәшләребезнең хезмәте алдында баш иярлек. Алар тырышып эшли, ял да итә. Фрида ханым кебек ару-талуны белмәс, гел хәрәкәттә булучы, милләте өчен янып торучылар булганда, телебез, динебез, гореф-гадәтәребезнең киләчәге өчен күңел сөенә.

**Руфия МӨХЕТДИНОВА.**

*Фәйзулла Туишевның туууына – 140 ел*

# БЕРЕНЧЕ ГАРМУНЧЫ



Фәйзулла Туишев – виртуоз музыкант, татар халкының беренче профессиональ гармунчысы, Татарстанның халык артисты.

Энциклопедик чыганакларда бәян ителгәнчә, булачак музыкант 1884 елның 6 (19) декабрендә Самара губернасы Ставрополь өязе Ялхов волосте Иске Төгәлбуга авылында күп балалы батрак гаиләсендә туган. Туган авылында 3 ел мәдрәсәдә укый. 1895 елда Туишевлар гаиләсе Мәләкәскә күченә. Нәни Фәйзулла концертларда биеп туплаган акчага гармун сатып ала, үзлегеннән уйнарга өйрәнә. Гастрольләргә килгән артистларга ияреп, Казанга китә. Печән базарында кыйналганнан соң, Мәләкәскә әйләнеп кайта. Тиздән Идел буе шәһәрләренә гастрольгә чыгып китә. Танылып килүче музыкантны күчмә циркка эшкә чакыралар. 1907–1910 елларда Сембер шәһәре циркында җырчы, жонглёр, ат өстендә чабучы була.

1910 елда Мәкәрҗә ярминкәсендә «Сәйяр» труппасы артистлары белән очраша. Алар белән, соңрак Габдулла Тукай белән якыннан аралашу күңелендәге милли музыкага мәхәббәт хисләрен көчәйтеп җибәрә. Шул елдан башлап ул, профессиональ гармунчы буларак, Саратов, Мәскәү, Петроград, Түбән Новгород, Харьков, Чита, Самара, Баку шәһәрләрендә, Кытай, Япония, Монголия, Корея, Көньяк Америка илләрендә гастрольләрдә йөри. Баштарак рус халык көйләрен зур осталык белән башкара. Аның исеме танылган рус гармунчылары Петр Невский һәм Павел Малазов исемнәре белән янәшә куела.

Гастрольләр вакытында милли рухтагы музыкаль әсәрләр иҗат итә башлый. Репертуарына «Иске кара урман», «Агач башы», «Туганай», «Ташлар аттым Болакка» кебек татар халык көйләре килеп керә. 1915 елда концертта Фёдор Шаляпин белән бергә чыгыш ясый. Аны тыңлаганнан соң Максим Горький татар гармунчысының иҗатына югары бәя бирә.

Ф.Туишев 1918–1926 елларда Ерак Көнчыгышта һәм Себердә яши. 1926 елда Казанга кайта. 1934 елдан Татар дәүләт филармониясендә эшли башлый.

Концерт эшчәнлеге белән беррәттән музыкант халык арасында милли гармуннарны популярлаштыру юнәлешендә дә эш алып бара. 1933 елдан Казан гармун фабрикасының сәнгать шурасы әгъзасы була. Концерт гармуннарының саны иллегә якынлаша. Тик гомер азагында аларның бер өлешен сатарга мәҗбүр була. 1958 елда вафаты алдыннан гармуннарын республика карамагына тапшыра. Хәзерге вакытта әлеге уникаль коллекция Татарстан Милли музеенда саклана.

Журнал укучылар игътибарына гаҗәеп кызыклы бер язма тәкъдим ителә. Бу – фронтовик шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең дусты Фәйзулла Туишевка бәйле истәлекләре. Шулай ук тапшыруда виртуоз гармунчы язмасында берничә халык көен ишетерсез.

*Нәкый Исәнбәтнең тууына – 125 ел*

# ВАРИСЛАРГА ВАСЫЯТЬ



Быелгы декабрь ае күренекле шәхесләребезнең юбилейларына гаҗәеп бай. Әйтик, Татарстан радиосында тел галиме һәм шагыйрь Нигъмәт Хәкимнең тууына – 135, СССРның халык артисты Габдулла Шамуковның һәм дирижёр Хәсби Фазлуллинның тууларына – 115, СССРның халык рәссамы Харис Якуповның тууына 105 ел тулу уңаеннан тапшырулар эфирга чыга.

Менә шушы олпатлар арасында Татарстанның халык язучысы, Татарстанның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәтнең (1899–1992) исеме аерым бер урын алып тора. Аның тууына – 125 ел. Журнал укучылар игътибарына юбилее уңаеннан әзерләнгән тапшырудан бер өзек тәкъдим итәбез. Бу – әдипнең үз тавышы. Аның нәкъ менә шушы язмасына игътибар итүебез очраклы түгел, чөнки 1970нче елларда магнитофон тасмасына язылган әлеге чыгышы варисларына – бүгенге көн әдәбият-сәнгать дөньясында кайнашучыларга васыять булып яңгырый.

Биредә ул үзенең халык авыз иҗатын барлаучы фольклорчы булып китүе турында да беркадәр мәгълүмат бирә. Бу хакта ул болай ди:

«Мин үзем балачагымнан ук Тукайга ияреп шигырьләр яза башлаган кебек, аның йогынтысы белән үзем дә шул чактан ук табышмак, җыр, мәкальләр җыя башлаган идем. Бу эш башта шулай халык әдәбиятын ярату, аның белән мавыгу төсендә башланган булса да, бара торгач һәм үсә-үсә, миндә бу эшкә җитди караш һәм әһәмият бирү уянды. Чынлап та, әгәр мин үземне шагыйрь һәм татар язучысы димен һәм аңа хезмәт итәм икән, үзем дә бу халыкны яхшы белергә тиеш түгелме? Кем соң ул татар, нинди халык, ни белән яши, күңеле ни белән тибрәнә? Мин аны яхшы беләмме? Белмәсәм, мин ничек аның язучысы була алам да ничек аның күңел кылларын тибрәндерә алам? Димәк, мин язучы булу өчен иң элек халкымның тормышын, ни белән яшәвен, аның телен, күңелен, зәвыгын, нәрсә яратып, нәрсә яратмавын, аның тарихын белергә тиешмен. Моның өчен бердәнбер чара – аның үз иҗатын өйрәнү. Бу иҗат исә – үзе бер киң дөнья! Ул – аның җыр, көй, бәетләре, әкиятләре, мәкаль-табышмаклары, такмак-такмазалары, мифлары, хорафатлары, легендалары, мәзәкләре. Ул – аның фразеологиясе, ышанычлары һәм башкалары. Кыскасы, халык әдәбияты ул – аның тел казнасы, моң казнасы, күңел казнасы...»

Менә шуннан соң инде Нәкый Исәнбәт бүгенге көнебездә васыять дип бәяләнерлек фикерләрен әйтә. Аларны ишеткәч, бәлки кемдер канәгатьлек белән иркен сулар, ә кемдер, бәлки, сискәнеп куяр. Әйдәгез, QR-код ярдәмендә журналыбызның сайтына кереп, әдипнең газиз тавышын ишетик.

# ӘДӘБИ СКАНВОРД



Нота

Компо-зитор ... Хисамов

... Алунанс (латыш шагыйре)

Васко ... Гама

... Батулла

Төрле төстәге

Гарәп артикле

Актёр ... Шакиров

Шагыйрь ... Мәҗитов

Р. Фәхрет-диннең 4 томлык белешмә-леге

... Арагон

Шагыйрь ... Миңнуллин

Татар эстрадасы төркеме

Берләшкән Милләтләр Оешмасы

Аяк киеме-нең аскы өлеше

Танылган рус шагыйре

Иван Тургенев повесте

Рәссам ... Хаҗиәх-мәтов

Шәрык по-эзиясендә дүрт юллык шигырь

К.Тинчурин драмасы

Кыргый үгез

Ялтыравык тасма

Совет йөк автомобиле

Шагыйрь Харрас ...

Чын күңел-дән

... кузгалагы

Эмиль Золя романы

Җәен чананы алыштыра

... Ахматова

Жырчы ... Польна

Мәскәү өлкәсендә-ге елга

... Булычёв (рус фан-тасты)

Хәмзә Хәкимзадә Ниязиның милләте

... Памук (төрек язучысы)

Олег Газманов репертуа-рындагы җыр

Антуан де ...-Экзюпе-ри

Язучы Рөстәм Галиуллин туган авыл

Жюль Верн романна-рындагы капитан

... - клуб (язучы-ларның халыкара оешмасы)



Әмирхан Еники хикәясе

... Бажов (рус язучысы)

Япон драма театры төре

Борынгы грек фәл-сәфәчесе

**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Октябрь санында дөнья күргән әдәби сканвордның җаваплары:***

**Сулдан уңга:** садак, кына, Давид, Әмир, Риан, Шота, Гек, «Саз», ирән, күк, Кятиб, салями, әсәр, Акатуй, «Ра», «Рапид», Бәшәр, ишәк, Мар, Хаҗи, Әнәс, ре, ти, ятма.

**Өстән аска:** Ги, «Сааб», Кыям, Ермак, Иркә, Лаеш, Садри, ният, Әхмәт, ас, муар, Ани, «Дивана», кий, Әрә, Зыя, Кудаш, тәравих, кисап, шарт, «Тәүбә», Әҗем, Рудаки.

# 2024 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЛАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

«Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында. №6

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Абдуллин Ф. Чәчкә идек илләрдә... Повесть. №6

Әбүдәрова Л. Олабый. Хикәя. №9

Әхмәтгалиева А. Без андый малай түгел. Повесть. №12

Батталова Г. Чыра. Хикәя. №1

Бәдретдинов Р. Юлаучылар. Хикәя. №8

Галиуллин Р. Хикәяләр. №6

Гаязов Ә. Кайсы яктан чыга соң бу кояш? Роман. №7-9

Гәрәева-Акчура А. Куеныңда ни бар? Хикәя. №2

Гыйбадуллина Л. Әлиф ләм мим. Повесть. №6

Гыйльметдинова Н. Мөнбәрле мөгаллим. Повесть. №7

Гыймалтдинов Ф. Шом. Повесть. №3

Гыйматдинова Н. Гөлханым турында хикәят. Повесть. №3

Гыймаев З. Каторжан. Роман. №9

Диндаров И. Ак төннәрнең кара көннәре. Повесть. №4-5

Зәйдулла Р. Хикәяләр. №7

Кәбиров М. Гомер. Повесть. №8

Кәримова Н. Озын-озак язмышлар. Повесть-истәлек. №10-12

Корбан Р. Танкистлар. Документаль повесть. №10

Лерон Л. Кыршау. Бәян. №5

Миңнуллин Т. Робагыйлар. №8

Низамова Ф. Илһамлану. Повесть-сагыну. №11

Харисова Н. Мин кайтырга тиеш. Хикәя. №4

Хәким З. Серле тәңкә. Роман. №4-5

Хәлим А. Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?.. Балачак хатирәләреннән. №1-2

Хөснияр З. Әллүки. Роман. №10-12

Шәйдуллина-Мурат Р. Тау башында бүре бар. Роман. №1

Шәмси С. Миләш. Хикәя. №6

**ШИГЪРИЯТ**

Әхмәтҗанова С. Ак әләмем итеп шигырь типчим… Шигырьләр. №9

Әхтәмова Г. Өметләр һәрвакыт була ак... Шигырьләр. №10

Басыйрова Г. «Алтын Көз» минем исем!.. Шигырьләр. №9

Батталова Г. Тукай сандыгы. Поэма. №4

Бәшәр Р. Җәйнең соңгы алкышы... Шигырьләр. №9

Вафин М. Миңа таулар – ястык урынына... Шигырьләр. №6

Вәлиев Р. Яңарасы иде, агарасы... Шигырь. №1

Гаделша Ш. Яфрак бүген коела да коела... Шигырь. №9

Гайнетдинова Г. Мәхәббәтнең ике колы без... Шигырьләр. №6

Гарифуллин Д. Гомер фасылларын озатамын... Шигырьләр. №5

Гаташ Р. Сиксән яшьтән соң: «Сөюнамә». Газәлләр. №11

Гаташ Р. Язлар җиткәч. Шигырь. №3

Гыйләҗев Ф. Күңелләрдә утлар дөрли, тынмый... Шигырьләр. №6

Дәрдемәнд. Без. Шигырь. №11

Җамалетдинова Ф. Бүреләр улавын ишетәм якыннан. Шигырьләр. №5

Зарипова А. Кышкы салкыннарны яз назына төреп. Шигырьләр. №12

Зариф Ч. Синең күк янам мин, әй кояш! Шигырьләр. №7

Зыялы Ф. Ян син, ян, ярсу йөрәгем... Шигырьләр. №4

Иксанова И. Йөзем куйдым җилләргә... Шигырьләр. №10

Ильюп О. Җан ялганыр төнгә. Шигырьләр. №1

Исмәгыйлева Р. Сабырлык дулкыны көйләнә... Шигырьләр. №11

Кәбиров М. Автомат һәм... шигырь дәфтәре. Язылмаган поэма. №2

Кәрим М. Өченче көн тоташ кар ява. Шигырь. №10

Майорова Р. Бер тамчы моң җитми. Шигырьләр. №2

Мансуров З. Борынгылар сүзен барлаштырам... Шигырьләр. №7

Мөслимова Ф. Бәйрәм. Шигырь. №7

Мөхәммәтшин Р. Таш. Поэма. №10

Мөэминова Э. Хәтерлим мин әле бүгенгедәй. Шигырь. №5

Мингалим Р. Язгы Тукай янында. Шигырь. №4

Мирза М. Адәм баласы. Бишьюллыклар. №1

Рахмани Р. Кабынырга җитә сыңар чаткы... Шигырьләр. №5

Рахман Р. Гашыйк булган көннәр... Шигырьләр. №8

Сабирҗанова Н. Җылы сүзең җанны кочакласын... Шигырьләр. №3

Садә Г. Кайту. Шигырь. №2

Сафина Н. Гомер буе көткән ул якты таң... Шигырьләр. №3

Сафин Ф. Гөл җаны. Мәхәббәтнамә. Сонетлар бәйләме. №1

Сәгыйдуллина Л. Без – адашкан автобуста... Шигырьләр. №8

Суфиянов А. Карашыңда янсын чыраг! Шигырьләр. №2

«Такташ FEST» бәйгесенә нәтиҗәләр: Ибраһим Б., Рамазанова З., Батталова Г., Әхмәдиева Г., Фатыйхов И. Шигырьләр. №11

Фәттахова Л. Шагыйрь – бары юлчы... Шигырьләр. №3

Харис Р. Тагы бер союзник. Поэма. №12

Харис Р. Үлмәдек, торып бастык... Шигырьләр. №4

Хәбибуллина А. Казан теле сине күрергә... Шигырьләр. №8

Хәйруллин Д. Оча сүзләр... Шигырьләр. №8

Хөсәенова Э. Бер сөйләшик әле... Шигырьләр. №7

Шакиров Р. Яшәешең – каләм чарлау... Шигырьләр. №2

Шәмсуаров Т. Җир арынган чакта кыштан... Шигырьләр. №4

Ширмән. Х. Җылы көтә күңелем... Шигырьләр. №6

Янсуар Л. Яратуның чәрдәкләре оча җиргә. Шигырьләр. №12

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Имамов В. Мәңгелек мөһаҗир. Тарихи драма. №3

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Әхмәдиева Г. Мин очышка әзерләнәм… Шигырьләр. №9

Баһавиева А. Кояш элдем мин күгемә бүген... Шигырьләр. №7

Бикмәтова Ф. Таулар түбәсендә кылдай хыял… Шигырьләр. №10

Җиһаншина Р. Сабый чакта кышлар бүтән иде... Шигырьләр. №12

Кәлимуллина А. Кулга алам каурый каләмне... Шигырьләр. №8

Миңнуллина Э. Тормыш ул – аяусыз бомба... Шигырьләр. №5

Мортазина Г. Ышан миңа, ышан тылсымга! Шигырьләр. №6

Нуриев А. Тавык эше. Хикәя. №7

Сабитова А. 1:1. Хикәя. №1

Хәсәнова М. Хикәяләр. №3

Шакирова Р. Ап-ак көннәр белән яшим... Шигырьләр. №11

Шәйхи Г. Һава кебек шундый кирәк чагың... Шигырьләр. №3

Шәрипова Г. Могҗизалар барга ышанам... Шигырьләр. №1

**«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

Батулла Р. Миң. Хикәя. №5

Галиәхмәтова Э. Мәрхәмәтле бул, балам. Хикәя. №9

Галиева Ә. Бизмәннәр ни диләр? Хикәя. №6

Гыйлемханова Г. Парлы бию. Хикәя. №7

Гыйльманов Г. Бүләккә – эти. Хикәя. №12

Исхакова Г. Аламачы бабай дәресләре. Хикәя. №8

Фәттахова Л. Гаярьнекеләр. Хикәя. №4

Шәйдуллина-Мурат Р. Чәчкә таҗларында күз яше. Хикәя. №11

Якупова Ф. Гыйбрәтле хата. Хикәя. №10

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

А д ж и е в  Б. Шагыйрьдән соң илдә җыры җырлана. Шигырьләр. №9

Д ә ү л ә т б и р д и н а  Т. Эчәр сулар тагын тарта. Шигырьләр. №11

К а р а б а ш е в а  ( У з д е н о в а )  Ф. Начар бала диярләр. Шигырьләр. №7

М а к е е в  Д. Боз сөңгесе. Хикәя. (Фирүзә Җамалетдинова тәрҗемәсе). №2

М о и с е е в  Д. Кеше бакчасыннан өзгән кура җиләге. Хикәя. (Ландыш Әбүдәрова тәрҗемәсе). №4

М о х и т  к ы з ы  С. Ана телем – алга әйдәр байрагым! Шигырьләр. №10

Т ө р к у г л ы  И. Олыс нигезендә, телендә яши... Шигырьләр. (Фәнил Гыйләҗев тәрҗемәсе) №5

Рауф С. Яшәү җыры. Шигырьләр. (Фирүзә Җамалетдинова тәрҗемәсе) №5

У з д е н о в  Р. Дүртьюллыклар. Шигырьләр. №7

У з д е н о в  Ш. Ватансызлык. Шигырьләр (Рафис Корбан тәрҗемәләре). №7

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Х о н и н о в  М. Җәй җитте исә... Шигырьләр. (Әлфия Ситдыйкова тәрҗемәсе). №3

**КАЙТАВАЗ**

Ә х м ә т г а л и е в а  Г. Күтеп алган журналыбыз. №3

Г а т а ш  Р. Ләбиб Леронның чәчмәдә яңача ачылуы. №9

Г ә р ә е в а - А к ч у р а  А. Бердәй горурланып һәм сөенеп... №3

И с м ә г ы й л о в  Х. Авылыма кайтып килдем әле. №3

Фәттахова Л. Бәхетнең дә, бәхетсезлекнең дә сәбәпчесе... №9

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

И с м ә г ы й л е в  Р., З ә й н и  Ә., С и б а г а т у л л и н  Н., С о л т а н о в  А., З а р и п о в а  З., С и р а е в а  З., Җ и һ а н ш и н а  С., Г а л л ә м о в а  Г., Ә х м ә д и е в  Р., С а в г а н о в а  Г., Ш ә р и п о в а  Г., С а ф и н  Р., Р ә х и м җ а н о в  Р., К ә р и м о в  Р. шигырьләре. №1

«Чылбырдагы безнең урын...» (Роза Хәмидуллинаның кереш сүзе белән шигырьләр). №6

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Г а й н у л л и н а  Г. «Бу бит безнең сукмак!..» №4

Г а л и у л л и н  Т. «Дөрес чорда» тугансың, шагыйрь! (Зиннур Мансуров иҗатына бер караш). №7

Г а л и у л л и н  Т. Ике даһига – бер риваять. (Дәрдемәнднең тууына – 165 ел). №11

З а к и р җ а н о в  Ә. Инешләребез мул сулы булсын. №11

З а һ и д у л л и н а  Д. Кая барасың, татар әдәбияты? (Әдәби әсәрләр бәйгесеннән соң уйланулар – 2). №3

С в е р и г и н  Р. Хемингуэйлар бездән еракмы? №10

М а к а р о в а  В. Самара йолдызлары. №8

Р а х м а н и  Р. Себер – үзебезнеке?! №9

С о л т а н  Ф. Мин сызланам, син дә сызлан әле, укучым! (Шагыйрь Ркаил Зәйдулланың соңгы еллар лирикасына бер караш). №9

Х ө с н е т д и н о в а  Л. Бикләр ачылырга тиеш. №6

**2024 ЕЛ – РОССИЯДӘ ГАИЛӘ ЕЛЫ**

Я һ у д и н  Җ. Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем… №6

**2024 ЕЛ – ШӘХЕСЛӘР ЕЛЫ**

Милләтне авыл саклап калачак. (Фәнир Галимов белән Алинә Хәбибуллина әңгәмәсе). №3

**ФӘН**

З а һ и д у л л и н а  Д. «Мин үз урынымда...» №1

**СӘНГАТЬ**

**ХӨСӘЕН УРАЗИКОВНЫҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ**

А р с л а н о в  Г. Күпкырлы бай иҗат иясе. №1

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Б ә х т е г ә р ә е в а  У. «Телнең башка яшәеше»: туган тел яки чит (башка) тел. №6

Р ә ү п о в а  Д. Бер карлыгач яз ясамый. №2

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

Н и з а м и  Р. Ышанасы килә... Шигырьләр. (Рафис Корбанның кереш сүзе белән). №4

**КҮҢЕЛ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ**

Т а һ и р о в  И. Халкыбызның раушан көзгесе. №4

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

М ө х е т д и н о в а  Р. Шәхес тәрбияләү – төп бурычыбыз! №10

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА – 140 ЕЛ

Б а р г а н  Һ. Идел-Урал язучысы Шәриф Камалга Халит Зия Ушаклыгилнең йогынтысы. Төрекчәдән Р.Сәфәров тәрҗемәсе. №2

Г а и т о в  М. Казан энциклопедистика фәнни мәктәбе. (Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына – 30 ел). №5

Г а л и у л л и н  Т. Чор рухын, заман сулышын тоеп. (Тел галиме Фәрит Юсуповка 85 яшь тулу уңаеннан). №5

З а к и р җ а н о в  Ә. Киләчәккә йөз тотып. №10

Н у р и е в а  Г. Безнең остаз ул! (Факил Сафинга – 70 яшь). №1

**ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР**

(Сәхифәне Нәсим Акмал алып бара)

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

Сөй халыкның дөньясын... №8

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА – 115 ЕЛ

Затлы каләмнән затлы эз кала. №3

ФӘРИТ ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Күпме җырлар җырланмыйча калган. №1

САМАТ ШАКИРНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Батырлык һәм матурлык җырчысы. №4

ЭНҖЕ МӨЭМИНЕВАНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Шигырь ул – тере җан иясе. №5

ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА – 105 ЕЛ

Кыска гомер, озын юллар үткән әдип. №3

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА – 105 ЕЛ

Гомере көрәшләрдә үткән. №11

КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВНЫҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

Татарчасы барыбер кызыклырак... №6

РОЗА ХАФИЗОВАНЫҢ ТУУЫНА – 95 ЕЛ

Йөрәкләргә «Ялкын» салган язучы. №2

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВНЫҢ тууына – 90 ел

Иманым – халыкка хезмәт. №5

РАХМАЙ ХИСМӘТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Дөньяны тынгысызлар хәрәкәткә китерә. №9

ШӘҮКӘТ ГАДЕЛШАНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Язмышымның дәрьясы: Казан – Төмән арасы. №9

БИКӘ РӘХИМОВАНЫҢ ТУУЫНА – 85 ЕЛ

Оныкларым белән бергә язам. №4

ФИРДӘВЕС ӘХТӘМОВАНЫҢ ТУУЫНА – 85 ЕЛ

Бибидән Бибинурга кадәр иҗат юлы. №7

НАДИР ДӘҮЛӘТНЕҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Еракка китеп кара... №7

ӘХӘТ ГАФФАРНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Ул үз чорын төптән аңлап язды. №1

ӘХМӘТ ДУСАЙЛЫНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Әдипләрне интернетта танытты. №8

ТИМЕРГАЛИ ЗИННУРОВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Ул язмышын театрга багышлады. №11

ХӘЙДӘР БИГИЧЕВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Җырчы янарга тиеш... №6

НИЯЗ АКМАЛНЫҢ ТУУЫНА – 70 ЕЛ

Мин үземне әдип итеп тоям. №2

**ХӘТЕР**

Б и к т и м е р о в а  Т. Онытмадык сине, Зөһрә апа. №7

М о с т а ф и н а  Д. Күк асты иленнән – Казанга. №6

М у с и н  Ч. Сукаланган җир башы... Шигырьләр. №7

Я н с у а р  Л. Шундый төрле һәм шундый бөтен... язмыш (Фәйрүзә Мөслимова турында кайбер истәлекләр). №7

**ӘБУГАЛИСИНА МӘГАРӘСЕ**

З а һ и д у л л и н  И. Нәсел шәҗәрәсе кайларга китә... (Каюм Насыйриның 200 еллыгын каршылап). №7-8; Каюм Насыйри – православие уку йорты укытучысы. №9; Насыйриның Казан рухани семинариясендә укыту-методик һәм гыйльми эшчәнлеге. №10; Насыйри – рус-татар мәктәбе укытучысы. №11; Мәгърифәтченең көнкүреш шартлары турында замандашлары. №12

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

А к и ф  Ө з т ү р к  М . Аяз Гыйләҗев һәм аның «Берәү» повесте хакында: «Кемгә кагылма, төзәлмәгән йөрәк ярасы». №11

Б ә д р е т д и н о в  Р. Хатыйп Миңнегулов – инсаниятнең бөек үрнәге. №5

Й о с ы п о в а  Н . Мәңгелек сагышлар ярында... №6

К у т л у  Ф . Ходай бирде! №11

К ы я м о в  И . Саллы хезмәт. №6

К ы я м о в  И . Хакимлек – Ходайның бүләге дә, аның ләгънәте дә. (Фирдүс Гыймалтдиновның «Урда ханы Үзбәк» (2023) китабына күзәтү). №3

С ә й ф у л л и н а  Ф . Шәхси архив серләрен милләтебезгә ачып... («Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат», төзүче Зөфәр Мөхәммәтшин). №4

Х ә б и р о в а  Р. Тәлгат Галиуллинның 10 томлык «Сайланма әсәрләр» басмасына күзәтү. №5

Х ә б и р о в а  Р. Француз телендә нәшер ителгән «Хәзерге татар прозасы антологиясе»нә (Париж, 2021) күзәтү. №2

Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНА – 85 ЕЛ

Яшь галимнәребезгә юл һәрвакыт ачык. (Институт директоры Илгиз Халиков белән Алинә Хәбибуллина әңгәмәсе). №10

**МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ**

Хәйриячелекне якыннарыңнан башларга кирәк. (Ильяс Гыймадов белән Алинә Хәбибуллина әңгәмәсе). №4

**ЗАМАНДАШЫБЫЗ**

Гаделлек сагында (Динар Шакиров белән Алинә Хәбибуллина әңгәмәсе). №6

М ө х е т д и н о в а  Р. Янып-балкып яшәүче Фәрид Миңнеәхмәтов. №10

М ө х е т д и н о в а  Р. Тормышның матурлыгыннан көч алам! №12

**ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП**

Әдхәт Синугыл, Рәис Зарипов, Җәмит Рәхимов, Фәния Чанышева, Газиз Кашапов-Үзиленең Марсель Галиевка язган хатлары. №2

Әнгам Атнабай, Разил Вәлиев, Сибгат Хәким, Нажар Нәҗми һәм Вәзих Исхаковның Р.Гаташка язган хатлары. №7

Әнгам Атнабайның Рәдиф Гаташка язган хатлары. №5

Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Мәһдиев, Рәдиф Гаташның Равил Фәйзуллинга язган хатлары. №12

Иштван Даби, Разил Вәлиев, Клара Булатова, Флёра Сафиуллинаның Марсель Галиевка язган хатлары. №1

Мәхмүт Хәсәнов, укытучы Рафика апа, Нурихан Фәттах, Әсрар Галиев, Илшат Шакирҗанов, Нур Сафиуллин, Минтимер Шәймиевнең Марсель Галиевка язган хатлары. №3

Нажар Нәҗминең Халисә Мөдәррисовага язган хатлары. №4

Нурия Измайлованың Рәдиф Гаташка язган хатлары. №6

Фәсәхәт апа, Гамил Афзал, Сәйфи Кудаш, Сөембикә Кудашеваның Рәдиф Гаташка язган хатлары. №8

Хатыйп Миңнегулов, Әнгам Атнабаев, Мостай Кәримнең Рәдиф Гаташка язган хатлары. №9

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Сканворд. Р ә и с  Г а б д у л л а төзеде. №1-10, 12

Уены-чыны бергә. №1, 6

Фотоархив: Әдәби мизгелләр. №8, 9, 11

Фотоархив. Дания Заһидуллинаның тормыш мизгелләре. №10

Фотоархив: «Казан утлары» архивыннан. №1, 4, 7

Фотоархив: Хуш, Лилия! №6

Фотоархив: Шәриф Камалның тууына – 140 ел. Сәхифәне А й д а р  Ш ә й х и н әзерләде. №2

Фотоархив: Татарстан Язучылар берлеге оешуга – 90 ел. №5

Фотоархив: «Ялкын» журналына – 100 ел. №3

Фотоархив: Нәкый Исәнбәтнең тууына – 123 ел. №12

Фоторепортаж: «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» әдәби конкурсы җиңүчеләрне бүләкләү тантанасыннан фоторепортаж. №1

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. Сәхифәне В а к ы й ф  Н у р и е в алып бара. №1-12.

Яңа китаплар. Сәхифәне Р и ф а т  С ә л а х әзерләде. №8-11.

# 100 000 СУМ

## һәм башка бүләкләр

**Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз.**

Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

ТАТ
МЕДИА



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЯЗУЧЫЛАР – МӨСЛИМ, МИНЗӘЛӘ РАЙОННАРЫНДА

Мөслим муниципаль районында татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендә каләм ияләренең зур делегациясе кайтты. Кунакларны хакимият бинасында район башлыгы урынбасары Азат Әхмәтҗанов сәламләде. Язучылар «Мөслимлеләр әдәбиятта һәм сәнгатьтә» музеен, Сугышчан һәм хезмәт даны мемориаль комплексын карады, З.Басыйрова исемендәге мәдәният йортында шушы җирдә яшәп иҗат итүче язучы, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе Роза Хәбибуллинаның 90 яшьлек юбилеена багышланган кичәне тамаша кылды, Мөслимдәге гимназиядә, лицейда, Г.Тукай исемендәге урта мәктәптә, Иске Карамалы, Тат.Бүләр, Тойгелде, Әмәкәй, О.Чакмак авылларында укучылар белән очрашты. Аннары язучылар Минзәләгә килде, район үзәк китапханәсендә шагыйрь Рәшит Гәрәй музеенда булды, Салисә Гәрәеваның «Бер кайтырмын» дип исемләнгән яңа шигырьләр җыентыгын тәкъдим итүдә катнашты, М.Җәлил исемендәге педагогика көллиятендә – студентлар, Минзәлә гимназиясендә, Югары Тәкермән авылындагы Г.Сабитов исемендәге мәктәптә укучылар белән очрашты, «Туган як» музее, Г.Зәйнашева исемендәге мәдәният йорты белән танышты. Мөслим һәм Минзәлә районнарында үткәрелгән чараларда Татарстанның халык язучылары Фоат Садриев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, язучылар Рифат Җамал, Факил Сафин, Равил Сабыр, Мөхәммәт Мирза, Рафис Корбан, Шәмсия Җиһангирова, Рифә Рахман, Рахман Шәфигуллин, Миңзифа Әхмәтшина, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Садриева, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Гәүһәрия Мәһдиева-Хәсәнова, журналист Рәшит Минһаҗ һ.б. катнашты.

### ФЕСТИВАЛЬ

Кабарда-Балкар Республикасында балкар шагыйре Тәнзилә Зумакулованың 90 яшьлек юбилеена багышланган әдәби-музыкаль фестиваль булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән язучы, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан катнашты.

### БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН УТЫРЫШ

Татарстан Язучылар берлегендә әдәби тәнкыйть, проза, балалар әдәбияты остаханәләренең берләштерелгән утырышы – «Хәзерге татар прозасы: эзләнүләр, табышлар, югалтулар» дигән темага сөйләшү булды. Аны әдәбият галиме, әдәби тәнкыйть остаханәсе җитәкчесе Әлфәт Закирҗанов алып барды. Утырышта сүз Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге үткәргән әдәби конкурста җиңеп чыккан әсәрләр турында барды. Чарада филология фәннәре докторы, конкурсның жюри әгъзасы Дания Заһидуллина чыгыш ясады. Фикер алышуларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Илсөяр Иксанова, проза, балалар әдәбияты остаханәләре җитәкчеләре Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, язучылар Солтан Шәмси, Ринат Нуруллин, Гүзәл Әдһәм, Рифат Сәлах, Рәҗәп Бәдретдинов, Нурия Сәйяр, конкурсның жюри әгъзалары Айсылу Галиева, Рузилә Мөхәммәтова һ.б. катнашты.

### ЮБИЛЕЙ

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Татарстанның халык шагыйре, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зиннур Мансуровка 75 яшь тулу уңаеннан «Кош очар биеклектә» дип исемләнгән иҗат кичәсе (сценарий авторы Рүзәл Мөхәммәтшин, режиссёры Лилия Әхмәтова) булып узды. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Рәисенең мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды директоры Нурия Һашимова (ул ТР Рәисе Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров котлавын ирештерде), Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рәзил Зиннәтуллин, якташлары – Мамадыш районының мәдәният идарәсе җитәкчесе Степан Спиридонов (ул район башлыгы Вадим Никитин исеменнән дә котлады), шушы туфракта яшәп иҗат итүче Татарстан Язучылар берлеге

әгъзасы Вәрис Гали һ.б. тәбрикләде, бүләкләр тапшырды. Мамадышлылар «Притяжение» бию төркеменең чыгышын да бүләк итте. Кичәдә Г.Камал, К.Тинчурин театрлары артистлары Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ришат Әхмәдуллин, Резедә Сәлахова, Әдилә Хәсәнова (алар алып баручылар ролендә дә иде) Зиннур Мансуровның шигырьләрен сөйләделәр, яшь җырчылар Динар Шәрәфетдинов, Элина Сафина, Сөмбел Кыямова, Елизавета Убанкина, Айгиз Хәйдәршин бәйрәмдарның җырларын җырладылар. Экрандагы видеоязма аша Татарстанның халык язучысы Тәлгат Галиуллин, Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиеваның, инде мәрхүм шагыйребез Зөлфәт, мәрхүм галимебез Әнвәр Хәйринең Зиннур Мансуров турындагы фикерләре, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров укуында шигырь яңгырады. Кичә ахырында сәхнәне балалар – «Репетиция» театр студиясенә йөрүче Нурҗиһан Әхмәтова, Динә Закирова, Сафия Еремеева һәм кечкенә Зиннур ролендә чыгыш ясаган Самат Вәлиуллин тотты.

### ИСКӘ АЛУ

Татар җәмәгатьчелеге моннан 42 ел элек 43 яшендә фаҗигале төстә вафат булган прозаик, шагыйрь, юмор-сатира остасы Фаил Шәфигуллинны искә алды. К.Тинчурин театры сәхнәсендә әдипнең тууына 85 ел тулу уңаеннан «Яшьлегем тугае» дип аталган әдәби кичә (сценарий авторы Рәдиф Сәгъди, режиссёры Зөфәр Харисов) узды.

Аның беренче өлешендә язучының «Өй салуның ние бар...» автобиографик повестеннан театральләштерелгән күренешләр (рольләрне К.Тинчурин театры артистлары башкарды) күрсәтелде. Кичәнең икенче өлеше әдипнең гаиләсе – хатыны Эльмира Шәрифуллина, кызлары Раушания, Резеда Шәфигуллиналар, оныгы Сәйдәш Камалиев тәкъдим иткән шигырьләрдән, нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров, Г.Камал, К.Тинчурин, Г.Кариев театрлары артистлары Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Олег Фазылҗанов, Фернат Насыйбуллин һ.б. укыган әсәрләрдән, шагыйрь сүзләренә язылган җырлардан (Миңгол Галиев, Гөлнара Байназарова, Энҗе Шәймурзина, скрипкада Динә Закирова, баянда Ринат Вәлиев һ.б.) торды. Чарада ТР Дәүләт Советы депутаты Камил Ногаев тамашачыларга ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовның сәламнәрен ирештерде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Фаил Шәфигуллин турындагы истәлекләре белән уртаклашты. Ул әдипнең 4 томлык сайланма әсәрләре чыга башлавын әйтте. Тамашачыларны шулай ук Ф.Шәфигуллинның якташлары – Яшел Үзән муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Илнар Хантимеров белән районның музейлар комплексы директоры Резеда Данилова сәламләде.

### БӨТЕНРОССИЯ БӘЙГЕСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕ

«Милли китап» нәшриятында ТР Милли китапханәсенең «Татар әдипләре» сериясендә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин турында биобиблиографик күрсәткеч (төзүчесе Л.Заһитова, мөхәррире И.Һадиев) басылып чыкты. Анда әдипнең 2023 елның маена кадәр төрле телләрдә басылган әсәрләре, иҗатын, тормыш юлын яктырткан язмалар кертелгән. Әлеге уникаль биобиблиографик басма Бөтенроссия бәйгесендә (анда 87 китапханәдән 132 эш тәкъдим ителде) катнашып, II дәрәҗәле Дипломга лаек булды.

### КИЧӘ

Саба районы Шәмәрдән мәдәният йортында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рөстәм Зариповның «Бүре» китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Анда Татарстанның халык шагыйрьләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, шагыйрә Илмира Гыймаева катнашты һәм чыгыш ясады.

### ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә яңа җитәкче – җаваплы сәркатип билгеләнде. Ул – прозаик, драматург Равил Сабиров (Равил Сабыр).

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары белән әдәбиятны һәм массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе, нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Рөстәм Галиуллинга «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Хезмәттәшебезне котлыйбыз!

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть А.АХМЕТГАЛЕЕВОЙ «Мы ещё те мальчики», повесть Н.КАРИМОВОЙ «Долгие-долгие судьбы», роман З.ХУСНИЯРА «Аллюки»; стихи Л.ЯНСУАР, А.ЗАРИПОВОЙ, поэма Р.ХАРИСА «Ещё один союзник».*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Г.ГИЛЬМАНОВА «Папа в подарок».*
*«Литература родственных народов»: стихи Н.КАЛЫБЕКОВА.*
*«Памятные письма»: письма из архива Р.ФАЙЗУЛЛИНА.*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвящённая 200-летию К.Насыри.*
*«Современник»: статья Р.МУХУТДИНОВОЙ.*
*«Бесценные голоса»: статья к 140-летию Ф.Туишева и к 125-летию Н.Исанбата. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*Список произведений, опубликованных в журнале «Казан утлары» за 2024 год.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Новое здание театра Г.Камала. Фото И.АБРАМОВОЙ; генеральный директор «Полиграфическо-издательского комплекса «Идель-Пресс» АНАС АСКАРОВ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: story by A.AKHMETGALEEVA «We are still those boys», story by N.KARIMOVA «Long, long destinies», novel by Z.KHUSNIYAR «Alluki»; poems by L.YANSUAR, A.ZARIPOVA, poem by R.KHARIS «Another Ally».*
*Literary contest «Morals of the Father's House...«, story by G.GILMANOV «Dad as a gift».*
*«Literature of related peoples»: poems by N.KALYBEKOV.*
*«Memorable letters»: letters from the archive of R.FAYZULLIN.*
*«The Grotto of Abugalisina»: article by I.ZAGIDULLIN dedicated to the 200th anniversary of K.Nasyri.*
*«Sovremennik»: article by R.MUKHUTDINOVA.*
*«Priceless voices»: article dedicated to the 140th anniversary of F.Tuishev and the 125th anniversary of N.Isanbat.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLA.*
*Diary of social and cultural life.*
*The list of works published in the magazine «Kazan Utlary» for 2024.*
*On our covers: The new Kamal Theater building. Photo by I.ABRAMOVA; ANAS ASKAROV, General Director of the Printing and Publishing Complex Idel-Press.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Г.Камал театрының яңа бинасы. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры Әнәс Әскәров.